# казан утлары

10
ОКТЯБРЬ-1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

10

ОКТЯБРЬ
1970

## Бу санда:

### РОМАН, ХИКӘЯ, ПОЭМА, ПЬЕСА, ШИГЫРЬЛӘР

М. ЗАРИПОВ. Вакытсыз туй. Хикәя . . . . . 3
Ә. БАЯНОВ. Сәяхәтнамә . . . . . . . . . . 13
Н. ФӘТТАХ. Әтил суы ака торур. Тарихи роман . 23
Н. НӘҖМИ. Шагыйрьләр . . . . . . . . . 73
Ф. ЧАНЫШЕВА. Акыл-киңәш сорап... Кар өстендә... Яшьтәшемә. Шигырьләр . . . . . . 78
С. ШӘКҮРОВ. Мәхәббәт газабы. Пьеса . . . . 80
Р. ГӘРӘЙ. Туган якта. Ык өстендә йөзгән көймәләр. Безнең язмыш... Урман йоклый. Казлар каурый койган көннәрдә. Сагынуларым чиктән ашканда. Кабынып яшә. Күңелем минем... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 115
Г. ГӘРӘЕВА. Күк күз. Шигырь . . . . . . . . 118
Ф. ЯРУЛЛИН. Кичтән юллар кара елан булып... Бер начарлык эшләде дә бераү... Күккә менеп... Кайчакта кеше... Шигырьләр . . . . . . . . 118
Д. СИРАЙ. Буразна... Җир катысы... Болыннар... Тиргәмәсәләр... Яра. Шигырьләр . . . . . . 120

### БЕЗДӘ КУНАКТА

А. ТАЛВИР. Пиньпи. Хикәя . . . . . . . . . 122
П. ХУЗАНГАЙ. Йөрәк җыры. Шигырь . . . . 136
Г. ОРЛОВ. «Бергә атлап...» «Шыта да...» Көзгедәй төз юл... Шигырьләр . . . . . . . . . 137
М. УЙП. Безне кем таныштырды... Тып-тын иде... Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 138
М. СЕНИЭЛЬ. Ана җыры. Яр буенда. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 139
В. ДАВЫДОВ-АНАТРИ. Рәхмәт сүзе. Бала чак. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 140
М. ЮХМА. Коялы чигү. Хикәя . . . . . . . . 141

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЗАМ

А. СӘЛӘХЕТДИНОВ. Рәшә диңгезендә ак кораб. Баш конструктор. Очерклар . . . . . 150

ЗАҺИД ХӘБИБУЛЛИНГА 60 ЯШЬ

М. ЖИҺАНШИНА. Нурлы җырлар остасы . . 159

СӘНГАТЬ КИЧӘЛӘРЕ

Д. ГЫЙМРАНОВА. Тынгысыз кичә . . . . 162

КИТАП КҮЗӘТҮ

М. ГОСМАНОВ. Сүзлекләр тарихыннан . . . 170
З. РӘМИЕВ. Тормышның үзеннән . . . . . . 173

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

С. ШӘЙДУЛЛИН. Тутыкмас корал . . . . . 175

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

К. БОГДАНОВ. Габдулла абыйның соңгы күрүем. 183

Дусларча шаярулар . . . . . . . . . . . . 184

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

З. НУРИ. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 185

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 188

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 13/VII-1970 ел. Басарга кул куелды 27/VIII-1970 ел. ПФ 04102. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 80646 экз. Заказ С-407. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19. 1970 ел.

Марсель Зарипов

# ВАКЫТСЫЗ ТУЙ

хикәя



Салихов елганы ерып чыкты. Башта тракторчыларны көтеп торып, елга төбен шушы төштә бераз күтәрергәме, әллә вышканы күчерү өчен сайрак урын эзләргәме, дип киңәшергә теләгән иде дә, иртәнге ызгыш исенә төшкәч, алар белән сөйләшәсе килмәде. Ярсып гөрелдәгән тракторларга борылып карады да тиз генә өстен чишенде.

Салкын су аның табан астын, балтырларын куырып алды, ә яздан бирле тынгылык бирми килгән радикулит су белән бергә аның биленә үрмәләде. Салихов, аягы белән елга төбен капшый-капшый, алга атлый, киемнәрен төенләп тоткан кулын югары күтәргән, икенчесе белән тракторчыларга ишарәләр ясый, ә үзе эченнән генә һаман иртәнге бәхәсне дәвам итә иде:

— Тыгылган булалар бит! Ә мин нишләргә тиеш ди? Бер генә көнгә дә кичектерерлек эш түгел...

Ул әле үзен бу эшкә бик тиз күндерә алган директорны ачулана башлый, әле вакытсыз туйлап йөрүче — түзәрлекләре калмаган, имеш! — Востриковны тетеп сала, әле Айгөл-Гульканы һәм аның егетен сүгәргә тотына, әмма барыннан да бигрәк үзенең бернәрсәгә яраксыз холкын тирги: «Вышкачылар бригадиры булып түгел, шәфкать туташы булып кына эшләргә кирәк сиңа!»

...Салихов моннан бер атна элек үк ял сорап гариза язган иде. Путевка-мазар сорап тормады. Акча әрәм итеп, врачларның теңкәсенә тиеп йөрмим әле, тотам да бажаларга Идел буена китәм,— дип күңеленә беркетеп куйды. Бажасының үз көймәсе, бүтән кирәк-ярагы бар, ул балык тотар, ә Салихов ухасын пешереп ашар да, аякларын кызган ком эченә тыгып, рәхәтләнеп кырын ятар. Хатынын алып барып маташмас иде. Ялны балык шулпасы чүмереп үткәрергә туры килер.

Ләкин болар барысы да коры хыял булып калды. Башта ук кулына телеграммасын тотып килеп, Востриков эшне бозды: янәсе, кызы кияүгә чыга. Монда минсез нишләрсез икән, дип ник бер сүз әйтсен, ялын алды да туйга чапты...

Востриков китеп тә өлгермәде, бригадага контора директоры килеп төште.

— Кил әле, Салихов. Сүзем бар,— диде ул, «газигы»ның ишегеннән чыгар-чыкмас.

Директор кесәсендә йөреп ямьшәеп беткән «Беломор»ын сузды да, мә тартып җибәр дигәндәй, пачкасын селкеп куйды. Салихов сүзенең

ял турында бармаячагын шунда ук аңлап алды: юкса папирос белән сыйлап маташмас иде!

Ул, тартыргамы-юкмы, дип бер мәл икеләнеп торды. Ашыкмый гына башын кашып алды, әмма түзмәде, бер папирос суырып чыгарды.

— Бар өмет синдә, Салихов,— дип сүз башлады директор, йөнтәс кашларын кыймылдатып. Хикмәтле аның кашлары — кемнән дә булса берәр нәрсә ялварып сораганда алар кыймылдап кына калалар, ә инде берәрсен тирги башласа,— пружина куйган сыман сикерешергә тотыналар.

— Яңа промыселга унике вышка күчерергә кирәк. Ара — алтмыш чакрым, срок — бер ай...

— Шул гынамы? — дип сорады Салихов.

— Шул гына,— диде директор.— Беләм, беләм, синең ул гаризаң менә монда утыра,— дип, ул плащ якасы астыннан катлам-катлам булып бөлтәеп чыгып торган симез муенына сугып куйды.

— Теләсәң, хәзер, үз күз алдыңда ук кул куям. Карап та тормыйм... Тик башта эшеңне эшлә. Ул арада без путевка хәстәренә керә торырбыз. Кая телисең? Сочигамы, Цхалтубогамы? Хәтта Төньяк котыпка да җибәрә алабыз. Иртәрәк кирәк иде, әлбәттә... Мин вәгъдә бирергә өлгердем шул: таш яуса явар, иллә мәгәр минем вышкачылар сынатмаслар,— дидем!

Күзен дә алмыйча директорга карап торган Салиховның күңелендә «яңа промысел», «унике вышка», «алтмыш чакрым», «бер ай срок» сүзләре буталырга тотынды. Әллә акылыннан язганмы ул директор? Ул моны аның күзенә бәреп әйтмәкче дә булган иде, өлгерә алмады, директор зажигалкасын кабызып аңа сузды да, вышкаларны бер ай эчендә күчереп бетерергә кирәклеген сабый балага төшендергәндәй, бик тәпченеп аңлатырга тотынды. Ә Салихов нинди нормадан чыгып исәпләсәң дә мондый эшкә ким дигәндә дүрт ай вакыт кирәк булуын, директорның сүзен аяк астына салмыйк дигән сурәттә дә иртә таңнан караңгы төшкәнче кара тир түгәргә, атнага ике ял дигән нәрсәне онытып торырга туры киләчәген уйлады.

«Андый тинтәкләрне икенче бригададан эзләгез»,— дип әйтергә авызын ачты, ләкин үзе дә сизмәстән: «Ярар»,— диде дә тәмәке төпчегенә төкерде.

Ә иртәгесен, студент егетен ияртеп, Гулька килде. Егетнең авыр карашлы соры күзләре үҗәтләнеп карыйлар, күкрәк мускуллары көрәшчеләрнеке төсле кабарып тора иде.

— Владька бу,— диде кыз, үзен бик иркен тотып.— Студент ул, политехническийны тәмамлый. Аны Востриков тракторына утыртырга була. Аның хәзер каникул вакыты, без җәйне бергәләп үткәрергә булган идек. Ә бу вышкалар арасында мин өйгә дә кайта алмаячакмын,— дип зарлану катыш ялвару белән аңлата башлады ул һәм, кинәт исенә төшкәндәй, өстәп куйды:— Правалары бар аның...

Ул арада тракторчылар да килеп җитеп, егет белән кызны урап алдылар һәм, һич тартынмыйча, Гульканың егетенә төбәлделәр.

— Тапкан егет! — дип мыскыллап әйтеп куйды Ландышев һәм күзлек кигән күзләрен йомгалап алды.

— Таптым шул! — дип иңбашларын сикертеп, чәчрәтеп әйтте кыз.— Кемне табарга тиеш идем соң мин? Сине дисәм, пенсиягә чыгар вакытың җиткән...

— Әллә ул алланың кашка тәкәсеме? — дип сүз кыстырды Степан Мокрушенко.— Нигә Востриков машинасына ул утырырга тиеш?

Гулька югалып калды, ләкин студент, коймак төсле түгәрәк беретын бармагы белән күтәрә төшеп, һич исе китмичә:

— Кашка тәкәсе! Нәкъ өстенә бастың! — диде дә «коймакны» кире башына чәпәде.

Барысы да сүзсез калдылар. Студент егет, зәңгәр кеды кигән аякларын киң аерып баскан килеш, берни булмагандай, ялкын сыман җирән, куе чәчен береты астына сыйдырырга азаплана иде.

Кешене эшкә алу-алмау — бригадир кулында. Бүтәннәрнең киңәш бирергә, тәкъдим итәргә хакы бар, ләкин соңгы сүзне тик ул, Салихов кына әйтә ала. План үтәлеше өчен дә, хәттә кешеләрнең тырналган-киселгән җирләре өчен дә җавапны ул бирә. Шуңа күрә һәркем яхшы белә: өстенә вышка ауганда да йөзен чытмаячагына тәмам ышанмый торып, Салихов беркемне дә эшкә алмаячак.

Бригадир студент егеткә: «Кем белә бит әле сине, нәрсәгә ярыйсыңдыр»,— дип әйтмәкче булды, ләкин кинәт аның күңелендә Гулькага яхшылык эшләү теләге уянды. Чыннан да, ни рәхәт күрә инде ул кыз алар арасында эшләп: вышкалар, тракторлар, тимер-томыр...

Гулька — электросварщик. Чын исеме Айгөл аның, ә эштә барысы да Гулька дип йөртәләр. Конторда Салиховтан көләләр: сварщик итеп тикмәгә генә хатын-кыз тотмый ул, янәсе. Ә ул, үзенә калса, Айгөлне теләсә нинди ир сварщикка да алыштырмас иде. Вышка янсә лафетларда берәр нәрсәне ябыштырырга, «ямау салырга» кирәк булса, Салиховның күңеле тыныч: Айгөл ял димәс, бәйрәм димәс, барысын да ялт иттереп эшләп куяр.

Хатын-кыз мәсьәләсендә авыз чайкауларга килгәндә, Салихов аларга төкереп тә бирми. Дөрес, ялга туктаган араларда егетләр, җылыныр өчен дигән булып, Айгөлне уртага алып кыскалыйлар, ләкин хәзергә, әйтмәгәне булсын, Салихов кызның шуннан артыгына юл куйганын күргәне-сизгәне юк.

Хәер, бер заман, Айгөл Садыйк белән йөри икән, дигән хәбәр йөрде йөрүен. Алай гына да түгел, бригадада туй турында ук сөйләшә башладылар. Салихов үзе дә бер көнне эштән кайтышлый бригада исеменнән яшьләргә бүләк алу өчен шифоньер янсә диван-карават караштыргалый торыйм дип кибеткә кереп чыкты.

Туй чыннан да булыр төсле иде. Кызы белән егете бар, биреләчәк бүләк карап куелган, ә инде туйда кәеф-сафа кылып алырга теләүчеләргә килгәндә, алар күп: савыт-сабасын да, өстәл-урындыгын да төткәзерлек түгел. Ләкин көтелмәгән бер хәл бөтен эшне бозып ташлады. Бер көнне Айгөл эштән кайтып керсә, ни күзе белән күрсен: аның бүлмәсендә Садыйкның әнисе, туганнары утыра. Килен буласы кешене күзләргә килгәннәр. Айгөл, әлбәттә, булачак туганнарын пырылдатып куып чыгара. Шулай итеп, буласы туй булмый кала.

Садыйкны бүтән бер кызга өйләндерделәр. Күп тә үтми, ул үзенә икенче бер кәләш эзли башлады, аннары өченчесен... Гомумән, ул күбрәк вакытын буйдак булып йөри иде.

Бригададагы эшләр шулай үз көенә генә барганда, авыртмаган башка тимер таяк дигәндәй, һич тә көтмәгәндә алар тормышына менә нииндидер бер Владька килеп катнашты.

...Айгөл иңбашларын сикертеп:

— Нәрсә күзләрегезне чекерәйттегез? Я, алып килдем ди, миндә ни эшегез бар соң сезнең? Ә тракторны йөртә белә ул, менә күрерсез...— диде.

Салихов, аны бүлдереп: «Ташла әле шул Таһир-Зөһрә уенын!» — димәкче иде дә, Садыйкның ачулы карашын күреп, шатланып куйды. «Әһә, тырналамы йөрәгең!» — һәм ул һич көтмәгәндә студентка борылып:

— Ярый! Бар, утыр Востриков машинасына,— диде.

Шау-шу купты, барысы берьюлы сөйләнергә тотындылар, ә Садыйк бригадирның йөзенә бәреп кычкырып ук җибәрде:

— Нәрсә мәтәштерәсең, бригадир? Иң элек бездән рөхсәт сорарга кирәк!

Салихов бригада кешеләренең ни уйлавын шунда ук сизеп алды: кайберәүләр җидешәр ел эшләп тә беренче тракторга эләгә алмыйлар, ә килмешәк бер студент килмәс борын ук менеп утырсын, имеш! Ләкин чигенү юлы ябык иде инде: вышкаларны күчерә башларга вакыт. Салихов якындагы тракторның тәгәрмәче өстенә сикереп менде дә җен ачуы чыгып:

— Шаулама! Кайсыгызның бригадир буласы килә! — дип кычкырды.

Барысы да тынып калдылар. Салихов аларның авызын ничек капларга икәнен яхшы белә. Бригадирлык өчен аңа түләнә торган ун процент артык акча бер кемне дә кызыктырмый. Тракторчыларның эш башыннан алган акчалары бригадир тарифыннан ике тапкыр артык чыга. Менә шуңа ул хәзер, аларга аннарына килергә ирек бирмәстән, кырыс кына:

— Машиналарга! Тизрәк! — дип кычкырды.

Салихов шикләнми: бригадирның боерыгы үтәләчәк. Ул трактор тәгәрмәче өстеннән сикереп төште, тракторчылар моторларын кабызып, кабиналарына утырышкан арада, үз урынына барып басты.

Хәзер Салихов өчен дөньяда вышкадан башка берни дә юк. Ул акрын гына кузгалучы тракторларның, чылбырлары белән җир тырныйтырный, бер җепкә тагылгандай тип-тигез булып тезелүләрен күтә, ә үзе түземсезләнеп калтырана иде.

— Әй мескенкәй,— диде ул үзен-үзе үчекләп.— Ничә ел эшлисең, пенсиягә чыгар вакытың җиткән, ә үзең бала-чага төсле калтыранасың...

Чыннан да үз гомерендә ничәмә-ничә вышка тарттырганы бар аның, тик менә хикмәт: һәр очракта кузгалып китәргә дигән боерык бирер алдыннан сулышы кысыла башлый, бугазына төер менеп утыра. Күнегеп була торган нәрсә түгел, ахрысы, инде бу. Ул, үзен биләп алган дулкынлануның тракторчыларга да күчүен күткәндәй, бер мәл көтеп торды һәм, уналты тракторга утырган уналты кешенең машиналарын бер үк вакытта кабызырга әзер икәнлекләренә ышангач, кинәт кулын селтәп җибәрде:

— Кузгал!

Башта ул, әллә боерыкны аңламадылармы, дип, борчылып куйды, чөнки вышка да, тракторлар да урыннарыннан кузгалмадылар. Аннары тынычлана төште. Менә тракторлар ярсу айгырлар төсле арт тәгәрмәчләренә бастылар, бер мең ике йөз кырык ат көчле уналты машинаның уналтысы да берьюлы тартылып куйдылар һәм алыптай зур мәһабәт вышка, ялкау гына кузгалып, кырлар өстеннән йөзеп китте.

— Кузгалды! Китте! — дип кычкырып җибәрде Салихов. Ул артына әйләнеп карый-карый, абына-сөртенә, тракторлар янынан йөгерде, нидер кычкырды, кулларын бутап нәрсәдер аңлатырга теләде, аннары, металл чыңлавы, моторлар гөрләве астында беркемнең берни ишетмәячәген аңлап, тынып калды.

Юл тигезләнде, тракторлар бер үк ритм белән бара башладылар, тынычлана төшкән Салихов та гади адымнарга күчте: атлыйсы чакрымнар шактый әле! Аның уйлары һаман шул иртәнге ызгыш тирәсендә чуалды. Ни әйтсәң дә, юккарак җәберләде бугай ул кешеләрне. Беркем белән киңәшеп-нитеп тормады, ят бер кешене Востриков тракторына утыртты бит. Егетне сынамады, тикшермәде — Гулька сүзләренә ышанды.

Эш тикшерүдә генә дә түгел. Студентны ул барыбер бер сыначак. Тик менә бригада гафу итәрме икән үз бригадирын?

Салихов егеткә нинди сынау үткәрәчәген хәзергә тәгаен генә үзе дә белми, әмма шунысы ачык: ул үзенең бригадирлык абруена тап төшермәс, сынау бирәү дә тел-теш тидерә алмаслык булыр. Трассада моның өчен форсат чыгып кына тора.

Ул, әлбәттә, бер яктан маршрутның тыныч булуын тели: ул-бу булып, каһәр төшкән радикулиты кузгалып, өзлегеп-нитеп китсә, вышка-

ларны вакытында кучереп бетерә алмавы бар. Ләкин икенче бер эчке тавыш моның нәкъ киресен әйтә: юл таулар-чокырлар аша үтсен иде, менә шул чак студент егеткә репетиция булыр иде, репетициянең дә иңдие генә эле — генеральные,— ди.

Шуңа күрә, калкулык артыннан житез генә агып чыгучы елганы күргәч, Салихов шатланып уйлап алды: «Әйттем ич!.. Хәзер башлана!»

...Елга уртасына житкәч, Салихов артына борылып карады. Тракторлар яр буена килеп туктаганнар, бригада кешеләре бер урынга жыелып нидер сөйләшәләр. Тик базык гәүдәле Садыйк кына, ни эшләргә белмәгәндәй, бер читтәрәк арлы-бирле йөренә.

Салихов әнә шул Садыйкның аны көлкегә калдыруын исенә төшерде. Әлеге дә баягы шул Айгөл аркасында булды бу хәл. Теге барып чыкмаган туй вакыйгасыннан соң, бер көнне Садыйк шаярып кына Айгөлне кочакламакчы булган, ә кыз уйлап-нитеп тормаган, тоткан да тегеңә чүмеч белән тондырган. Садыйкның күз төпләре шешеп чыккан.

Ул көнне Салихов өенә кайтып, өстен-башын алыштырырга да өлгермәде, кабаланып Садыйкның әнисе килеп житте һәм, исәнме юк, саумы юк, тегенең тетмәсен тетә башлады:

— Бригадир икәнсең, бригадир була бел, яме, күрәләтә кешене имгәттермә. Гарип булса шунда, мин аны ничек өйләндерим, син шул турыда уйлап карадыңмы? — дип кычкырынды карчык, юан гәүдәсе белән Салиховны бүлмә почмагына кысрыклап. Ул карчыкка улының ни рәвешчә «гарип булганлыгын» сөйләп бирмәкче иде дә, күңеленнән генә үз урынына Айгөлне куеп карады да бу фикерен үзгәртте, гөнаһны үз өстенә алырга булды.

Ә теге кире беткән корткa конторга да барып житә, анда да гауга куптара, шуннан соң бригадага куркынычсызлык техникасы инженерын жибәрергә мәжбүр булалар.

Садыйкка өч көнгә бюллетень бирделәр, ә Салихов өстеннән акт төзеп, стена газетасына язып чыгардылар. Бөтен бригада эче катып көлде. Ә Садыйк килеп гафу да үтенмәде...

...Елга төбе сөзәк кенә күтәрелә башлады. Салихов каршы як ярга чыкты, тракторларга әйләнеп карады да бер бармагын күтәрде: «Елга аша беренче тизлек белән чыгыгыз!» Алдагы трактор, радиаторы белән суны иснәргә теләгәндәй, сагаеп кына елгага килеп керде. Салихов, трусиктан гына яр буенда басып торган килеш, бер-берсен узарга теләгәндәй тракторлар алдыннан йөгерешкән вак дулкыннарга карап торды...

Елга сай иде, «репетиция» барып чыкмады. Салихов тракторларның тәгәрмәчләреннән чупыр-чупыр су агызып, ярга чыгып бетүләрен көтеп торды да янә алар алдыннан атлап китте.

Кояш иртәнге томанны киптереп бетерде, көн эсселәнде. Салихов трассаны күз алдына китереп, алтмыш чакрым араны күңеленнән өч кисәккә бүлде. бүген шуларның берсен үтәләр дә куннарга туктыйлар, иртәгә тагын бер кисәген үтеп, тагын төн куналар, ә берсекөнгә барып та житәләр. Аннары буш килеш кире кайтып, тагын вышка тагалар... Уникe тапкыр шулай барып кайтсалар, вышкаларны кучереп бетерәләр, ә ул ялга китә...

Кинәт һава үзгәреп китте. Әллә каян килеп чыккан кечкенә генә болыт яңгыр булып сибелде, ләкин болыты чамалы булдымы, әллә кояшның кыздыруы көчле идеме, жир өстенә берән-сәрән тамчылар гына төште.

Юл тузанлы, көн эссе иде. Салихов, кепкасын салып, чалбар каешына кыстырган иде, чәчсез башы пешә башлагач, кире киде. Ул, моторлар гүләвен, лафетлар дөберләвен, вышкаларның аркылы тимерләрендә жил уйнавын тыңлап, тракторлар алдыннан атлады. Аның күңелен горурлык, канәгатьлек хисе биләгән иде. Горурланырлык шул: шундый

зур кәрванны шып туктату, хәрәкәтсез, өнсез итү өчен аның бер кул селтәве җитә.

Ул буыннарында арыганлык сизә башлады, күңелендә кайсы да булса бер машинаның кабинасына менеп, ун-унбиш минут кына булса да утырып бару теләге уянды, ләкин ул бу татлы хыялын шунда ук куып җибәрергә ашыкты. Чөнки шуңа бирелеп, тәмәке тартып алыйк, диденме, сулыш алырга гына дип туктадыңмы — калган юлның биш-ләтә, унлата кыенрак тоелачагын көт тә тор. Туктамавың, төшкә кадәр түзүең хәерле.

Ләкин аңа төшке ашны ашарга туры килмәде. Бер лафетның күчәре сынды. Шул форсаттан файдаланып, тракторчылар ашарга утырдылар, ә ул Айгөл белән сваркага кереште.

Лафет белән шактый озак маташырга туры килде. Эш беткәч тә ул, туктагыз, егетләр, мин дә капкалап алыйм инде, дип әйтергә базмады, дөресрәге, студент турындагы сүзнең тагын кузгалуыннан курыкты. Һәм, кипшергән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып, кычкырып җибәрде:

— Кузгал!

Тракторлар алдыннан атлаган Салиховның башында гел бер уй чуала: ничек кенә ашап алырга соң? Ашыйсы да артык килми аның үзе, аның турында гел кайгыртып тора торган хатыны алдында аклану өчен генә кирәк ул. .

Ул өенә кайтып керүгә, хатыны кулларын тезенә сугып:

— Менә сиңа мә! Мин ул ач йөрмәсен дип, таң тишегеннән торып басам, ә ул букчасын ачып та карамаган килеш кире күтәреп кайткан! — диячәк бит.

«Нигә аны үпкәләтергә? Әллә аяк өсте капкалап булса да букчаны бушатыргамы?» Менә шунда аның күңеле булачак.

— Һәрвакыт шулай итәләр аны,— дип үзен мактап та җибәрәчәк.— Юкса, тьфу, әстәгыфирулла, карар җирең дә калмаган ләбаса — тире дә сөяк.— Һәм икенче көнне букча тагын футбол тубы төсле күпергән булачак.

Салихов бер кулына колбаса, икенчесенә сөтле шешә тоткан хәлдә тракторчыларга ишарәләр биреп барса, нинди көлке кыяфәттә булачагын күз алдына китерде. Тракторчылар аттай кешнәргә тотыначаклар. Шуны уйлап, бригадирлык абруена ихтирам йөзеннән ул бу эштән тыелып калды.

Шул уйлары белән ул юлның, сөзәклэп кенә, ялангач калган калкулык өстенә менә башлавын сизми дә калды. Тракторлар радиаторлары белән өскә таба караганнар, шактый җиңел гөрелдиләр иде. Мондый очракларда вышкачылар калкулыкның сыртын бульдозерлар белән бераз кистерәләр яисә аны бөтенләй әйләнеп үтәләр, яисә, ахыр чиктә, вышка артка авып китмәсен өчен алга тагын берничә өстәмә трактор куялар. Салихов та шуларның берсен эшли ала иде. Ләкин бу очракта аңарда үҗәтлек өстенлек алды: «Менә хәзер студентка репетиция ясыйбыз!» һәм ул тыныч кына атлый бирде, ә тракторчылар бригадир ишарәсеннән башка туктамадылар.

Тау торган саен текәләнде. Моңа тикле шактый буш килгән алгы трос кылдай тартылды. Хәзер инде Салихов алдында бүтән юл юк: теләсәң-теләмәсәң, калкулык өстенә менәргә кирәк...

Тракторлар хәзергә шактый җиңел тартылалар әле. Ләкин бөтен эшне әлеге текәлек боза: вышка әкренләп артка таба авыша бара, аны бер генә нәрсә — алгы трактор тросы гына «аяк өстендә» тота иде.

Алгы трактор кабинасының арткы тәрәзәсендә студентның агарынган йөзе күренде. Салихов ачулы кыяфәт белән аңа йодрык күрсәтте, ә үзе егеттән күзен алмыйча эченнән генә:

— Я-я, акыллым, харап итә генә күрмә! — дип ялвара иде.

Һәм чылбыры белән бер урында җир тырный башлаган алгы трактор үҗәтләнеп яңадан югарыга үрмәләде.

— Әйдә, әйдә! Тагын бераз! Печтик кенә! — дип, тотлыга-тотлыга студентны үгетләде Салихов, ә үзе, вышканың гөрселдәп авып төшүенә әзерләнеп, артына борылып карарга куркып барды.

Үч иткәндәй, нәкъ шул чак яңгыр ява башлады. Теге иртә белән күнелләрдә җылы тәэсир калдырып сибәләп киткән төслесе түгел, ярсып, кыеклап, чыбыркыдай каты бәреп ява торганы.

Салихов җиңел пиджагын бөркәнде. Алдагы трактор тагын сөртенгәндәй итте, өметсез ярсу белән бер урында таптанып торды һәм юеш җирдән артка таба шуыша башлады. Трактор нәкъ Салихов басып торган урынга таба чигенде, анда һәм сулда торган тракторларның кабиналарында Садыйкның, Ландышевның, Мокрушенконың, бүтән тракторчыларның каушаган, куркынган йөзләре күренде. «Менә хәзер вышка ава да үзе артыннан алгы тракторларны өстери, ә ул бүтән машиналарны ега!» — дип уйлап алды Салихов. Эх, студентны алып эшне бозды бит...

Салихов пиджагын салып ташлады һәм, аны аягы белән таптавын да сизмичә, студентка яный-яный, җенләнеп кычкырды:

— Вышканы харап ит, яме... Харап ит!.. Мин сиңа, эттән туган нәрсәгә, күрсәтермен...

Алдагы трактор аның өметсез ачигылану тулы бу кычкыруыннан көч алгандай булды, башта бер урында туктап калды, аннары кинәт, «башмаклары» астыннан кызыл балчык кисәкләре ыргыта-ыргыта, алга шуыша башлады. Ул, бөтен көченә шаулап-гөрелдәп, әкрен генә калкулык өстенә таба үрмәләде һәм, магнит кебек, үзе артыннан бүтән машиналарны, вышканы, Салиховны тарттырды.

Калкулыкны кичкырын гына үттеләр. Салиховның бүтән барырлык хәле калмаган иде, шуңа күрә ул ике кулын берьюлы селтәп әмер бирде: «Тукта! Сүндер моторларны!»

Бу әмергә беренче булып яңгыр буйсынды. Ул, кинәт башланган-дагы кебек, кинәт кенә туктады да. Тик кайдадыр еракта, иртән алар вышка тарттыра башлаган тирәләрдә, күк күкрәгәне ишетелә иде әле. Тракторчылар шатланышып кабиналарыннан сикереп төштеләр, оеган аякларын язу өчен йөгерешергә тотындылар, колакларына тыгылган мамыкларын чыгардылар.

Салихов студентның килүен көтеп торды. Егет машинасыннан сикереп төште һәм тракторчылар яныннан бик җитди кыяфәт белән сүзсез генә үтеп китте дә Айгөлнең сварка агрегаты белән бер үк чанада йөри торган фляга янына су эчәргә ашыкты. Бөтенесе тынып кына аңа юл биреп калдылар. Студент кружка белән чумырып, йотлыгып су эчте, башкалар аның иягеннән ике яклап тамган су тамчыларына карагын хәлдә, аның эчеп туйганын көтеп тордылар.

Аннары Салихов студентка үзенең трубкасын сузды:

— Мә, суыр. Судан шифалырак бу...— диде һәм тракторчыларга җиңүле караш ташлады:— Күрдегезме инде? Гауга куптарган булган идегез...

Моннан соңгы көннәрдә хәтергә эләгеп калырдай берни дә булмады. Эссе көннәр, көнозын эшләп кызган мотор суынырга да өлгермәслек дәрәҗәдә кыска, сүз белән аңлатып булмый торган ниндидер көнчелек хисе тулы төннәр бер-бер артлы үтә бирде.

Барысы да студенттан көнләшәләр иде. Эшенә тел-теш тидерерлек түгел егетнең, машинаны яхшы белә, каһәр, шулай да вышкачылар Айгөл өчен, кызны үзенә карата алганы өчен аны һич гафу итә алмыйлар иде. Тракторчыларга тәмам җен кагылгандай булды, йокылары качты. Запас частьлар белән тулы будкадагы топчанында төн үткәрүче Салиховның да күзенә йокы керми иде. Төннәр тымызык иде. Йолдыз-

ларга кадәр сузылган озын карачкы сыман вышка калкып тора, трактор кабиналарының әле берсендә, әле икенчесендә тәмәке утлары җемелди иде. Тик ике кабинада — Айгөлнекендә һәм студентныкында һәрвакыт караңгы: аларның кабиналарында ут юк. Салихов үз-үзенә дә танырга теләми, ләкин аларның бу мәхәббәте бригадир күңелендә дә көнчелек уяткан, күптән таныш булып та инде онытылган татлы бер тойгы аның бөтен күңелен биләп алган, чигәләрендә ут булып яна иде...

Ул аякларын асылындырып топчанында торып утыра, трубкасын тартып бетерә дә тагын каты урынына ава, шомартылмаган такталар өстенә җәелгән сырмасы өстендә туктаусыз боргаланып:

— Иртүк торасың бар, ә син, карт җүләр, бүтәннәр гыйшкы өчен хафаланып ятасың! — дип, үз-үзен тиргәргә тотына.

Аннары тәмам миңгерәп, тынгысыз сизгер йокыга тала һәм яңа көн туып, кызгылт кояш будкага күз төшергәнче әллә нәрсәләр белән саташып бетә. Ә уянгач тиз генә сикереп тора да, күзләрен учы белән уа-уа бер трактордан икенчесенә атлап, авыр ачкыч белән кабиналарга сугып йөри.

— Торыгы-ы-ы-з! Җитәр сезгә!

Тракторчылар, йокыларыннан айнып-айнымас, машиналарыннан сикереп төшәләр дә эшләренә тотыналар, ә Салихов, барып бәйләнергә сәбәп эзләгәндәй, алар тирәсендә кайнаша. Әнә студент инде машинасын шприцларга тотынган, ә керфек очларына тикле шатлык сирпеп торган Айгөл агрегатын кабызып маташа. Бәйләнер сәбәп күренми...

Төннәрнең берендә Салихов сәер бер төш күрде. Имеш, тракторларның һәркайсына дилбегә тагылган, ә Салихов шуларның очларын учына җыеп тоткан да, кучер төсле, вышканың иң очына менеп утырган. Ә машиналар ул кай якка тартса, шунда күндәм генә борылалар. Ул гына да түгел, Салихов утырган җиреннән үз-үзен битәрли, имеш: «Әй, җүләр дә инде син, шушы көнгә тикле җәяү йөрдең бит, менә шулай рәхәтләнеп утырып йөрсәң ни була!..» Нәкъ шул вакытта ул куркынычсызлык техникасы инженерын күреп ала. Инженер, неп-нечкә бармагы белән ишарәләп, җиргә төшәргә куша.

— Я, төш әле, дустым. Тизрәк бул, тизрәк!

Салихов тирләп-пешеп уянып китте дә урыныннан торып утырды. Аның каршында Садыйк басып тора иде.

— Син нәрсә? — дип кычкырып җибәрде Салихов. — Бригадир йоклап ята, ә син кыз урларга җыенган егет төсле аның тирәсендә мәташәсең!

— Йоклап ятасың шул менә! — диде Садыйк, аны үчекләп. — Ә алар йокламый, гыйшык-мыйшык уйныйлар...

Салихов «алар»ның кем булуын шундук шәйләп алды һәм кырыс кына әйтте.

— Уйнасалар соң? Анда синең ни эшең бар?

— Минем эшем юк анысы. Ә менә сиңа әләгәчәк, — дип мыгырданды Садыйк. — Егете китер дә барыр, ә җавабын сиңа бирергә туры килер...

— Менә каһәр! — диде Салихов, Садыйк әйткән белән килешеп. — Чыннан да чәпәүләре бар шул: янәсе, Салихов үз бригадасында әхлаксызлыкка юл куя...

Ул күңелендә уянган шул әшәке уйга хәтта шатланып ук киткәндәй булды һәм, суга батучы кеше саламга ябышкандай, шул уена ябышып, топчан астындагы ямьшәйгән туфляларын тартып чыгарды.

— Я, барыйк әле, кайда алар?

Төн тымызык, бөркү иде. Тракторлар шыксыз карачкылар булып күренәләр, әйләнә-тирәдә ак стена булып яшь каеннар төсмерләнә. Беренче булып Садыйк атлады, арттарак, аңардан калышмаска тырышып, Салихов барды. Аларны төнге урманда була торган шомлы тын-

лык чолгап алды. Салихов бер яктан Садыйк әйткәннәрнең дөрескә чыкмавына, аның көлкегә калуын тели, Айгөл белән студент аларның килүен ерактан ук ишетеп, качсыннар өчен юри тавыш чыгарып атламакчы була, ләкин аның ихтыярын үзенә буйсындырган икенче бәрәү аны аяк астында бер генә чыбык та чытырдамаслык, баш өстендә бер генә яфрак та кыштырдамаслык итеп сагаеп кына барырга мәҗбүр итә иде.

Ак каеннар гүя көтүләре белән яр буена йөгерешеп төшкәннәр дә, ахыргы минутта судан куркып, текә яр өстендә тәртипсез рәвештә басып калганнар. Салихов яшеренеп тыңлап торырга да, астыртын гына күзәтергә дә теләми, шулай да аның күзләре, үзләре дә сизмәстән, нәкъ Айгөл белән студент торган урынны эзләп табалар.

— Менә монда,— диде Садыйк һәм агач кәүсәсе артына барып посты. Салихов аның калын җилкәсе артына яшеренде дә башын гына чыгарып карап тора башлады.

Айгөл бер зур каенның тамырына сөялеп утырган. Студент исә, куллары белән биленә таянып, аның каршында басып тора, гарьләнгәнрәк бер тавыш белән кызны нәрсәгәдер күндерергә тырыша, ә тегесе тыныч, ләкин каршы әйтергә урын калдырмый торган тон белән аның тәкъдименнән баш тарта иде.

— Китик моннан, синең унъеллык белемең бар бит! — диде егет, кулларын селтәп.— Имтихан тапшырырсың да укый башларсың...

— Синең беләнме? — диде кыз, урыныннан ук торып.— Киләчәкләр бит үзеңнән, тапкансың иртәләп кайтыр кеше, диячәкләр...

— Синнән дә көлделәр ич. Син монда берүзең, ә алар...

— Мин бит ул. Мин — үткән кеше. Ә син андый түгел. Менә соңгы вышканы илтеп куярбыз да син китәрсең — шуның белән безнең мәхәббәткә дә чик куелыр...

— Алайса мин дә китмим! — диде студент.— Эшкә кереп сездә калам...

— Син тилермә, соңыннан үкенерсең,— дип, олы кешеләрчә үгетләү тоны белән әйтте кыз һәм ярга таба йөгереп китте.

— Су керәбезме? Соңгы тапкыр?

Студент каенга сөялеп басып калды, ә Айгөл спортчыларныкы төсле җиңел чалбарын, күлмәген салып ташлады да колач сала-сала яр буеннан ук йөзеп китте: айлы юлдан, ишетелер-ишетелмәс чупырдап, вак дулкыннар йөгереште.

Салихов шымчы төсле посып күзәтеп торуы өчен үзеннән-үзе оялып куйды.

— Син нигә дип бүтәннәр гыйшкына үреләсең? — дип, ул Садыйкны битәрләргә тотынды.— Киттек. Монда безнең кирәгебез юк.— Һәм, ишетүләре бар дип тормады, кырт борылып китеп барды...

Соңгы көнне эшләр, алдан сорап алгандай, уңышлы барды. Трасса тигез булды, бернәрсә дә ватылмады, сынмады, лафетларга тикле ничектер башка көннәргә караганда күңеллерәк, җиңел марш ритмы беләнрәк чыңгылдыйлар иде, ә вышка, шундый әйдәп баручысы булуга шатлангандай, горур һәм вәкарь бер кыяфәт белән Салихов артыннан йөзеп кенә бара иде. Һәрхәлдә, Салиховның үзенә шулай тоелды.

Көн уртасында, тракторчылар төшке ашны ашарга утыргач, Салихов Айгөлне якындагы авылга җибәрде:

— Бар әле, кызым, җәһәт кенә күрше авылга барып кил әле. Коеларыннан су алып кил.

Айгөл тракторын сварка агрегаты урнаштырылган чанадан ычкындырды һәм өч чиләк керешле сөт флягасын бер селтәнүдә кабина эченә ыргытты да китеп тә барды.

Айгөлнең тракторы калкулык артына күмелгәч, Салихов түгәрәккә

тезелешеп ашап утыручы тракторчылар янына килде һәм студентның чигәсенә күзен терәп:

— Тыңла әле, егеткәй...— дип сүз башлады һәм ничек дәвам итәргә белмичә, бер мәлгә тотлыгыбрак калды. Студент чәйнәвеннән туктады һәм, бер кулына сыр белән колбаса, икенчесенә икмәк телеме тоткан хәлдә, аягүрә басты.

Салихов туп-туры аның күзләренә карады:

— Сыпырт әле син моннан, егеткәй... Йөрмә кызның башын әйләндереп...

— Мин әйләндермим... Мин чын-чынлап...— диде егет һәм тыныч кына өстәп куйды:— Мин яратам Айгөлне.

Салихов бу сүзләрнең мәгънәви гадилеге алдында каушап калды булса кирәк, үзе дә сизмәстән кычкырып җибәрде:

— Буталма монда үзеңнең гыйшкың белән, аңладыңмы! Ычкын яхшы чакта...

Студент күзен дә йоммады, Салиховка таба кыю атлап:

— Синең ни эшең бар соң анда? — диде.— Кем соң син?

«Колак тамырына тондырса, мәтәлеп китәрсең»,— дип уйлап алды Салихов, студентның зур йодрыкларына карап. Бүтән тракторчылар да урыннарыннан сикерешеп торгач кына ул кыюлана төште.

— Нәрсә әтәчләнгән буласың? — дип кычкырды ул.— Синең ише ыспай егетләр күп булыр. Ә кызыйга тормыш итәргә, семья корырга кирәк.

— Кем әйтте моны, Айгөл үземе? — дип сорады студент.

Салихов җавап биреп тормады, үзенекен дәвам итте:

— Ә син шаярып туярсың да, хуш — сау бул!

Егет Салихов янына атылып килде һәм аны иңбашыннан тотып селки башлаган иде дә, нәкъ шул мәлне Садыйк, Ландышев, Мокрушенколар сүзсез генә бригадир янына килеп бастылар.

Ләкин егет аларга бәйләнеп тормады, кырт кына борылып, тракторын ычкындырды, кабинага менеп утырды да машинасын бар көченә кузгатып китеп тә барды.

Салихов Айгөлгә бирәчәк җавабын әзерләп тә өлгермәде, кыз үзе кайтып җитте. Алдагы тракторның юклыгын шунда ук күреп алды да Салихов янына йөгереп килде:

— Владька кайда? Кайда ул?.. Нәрсә дип әйттегез сез аңа?...

— Берни дә әйтмәдек,— дип, малайларча алдашты Салихов.— Ул үзе. Сезнең эшмени ул, ди...

Салиховның алдашуын күз карашыннан ук сизеп алган Айгөл аның белән артык сүз озайтып тормады, тракторына сикереп менде һәм, моторын бар көченә гөрләтеп, машинаны студент киткән якка борды. Аннары трактор кыска бер мәлгә туктап калды, кабинадан әлеге өч чиләк сыйдырышлы фляга мәтәлеп килеп төште, ә машина алга ыргылды...

Бер сәгатьтән Салихов тагын тракторлар алдыннан атлый иде. Алгы тракторга Садыйк утырган. Элеккечә ләфетләр чыңгылдый. Каршы җил Салихов өстенә тузан болытын һәм моторлар җылысын бөрки. Ләкин Салиховка бу чыңгылдауда, бу гөрелтедә күнегелгән ритм юк кебек, һәр трактор үзенчә гүли кебек иде. Аның күңелендәге үз-үзеннән канәгать булу хисе, бу куәтле машиналарны үзенә буйсындыра алу белән горурлану хисе каядыр качкан, югалган иде. Кинәт аңа вышка буйсынудан туктар һәм, гөрселдәп, аның өстенә авар төсле тоелды.

— Картайдым, ахрысы! — диде ул үз-үзенә.— Ташларга кирәк, ахры, бу эшне. Миңа хәзер бригадир булырга түгел, елга буенда балык чирттереп утырырга гына калган... Алай да Гулька үзенең студентын куып җитә алды микән? Тегесенең тракторы ватылса иде, ичмасам!..

## Әхсән Баянов

# Сәяхәтнамә

*Кама этюдлары*

«Без жирне үтерәбез».—
*Жан Дорст, француз галиме.*

«Жирдә биосфераны саклап калу мөмкин булыр».—
*Д. Арманд, совет галиме.*

Дөньяның мин килдем үзәгеннән,
Идел буйлап чыктым Камага.
Төнбоеклар үскәч күл буена,
Кузгалаклар үскән яланга
Чакыр, әйдә, Кама, яшер мине.
Уйларымнан яшер, арала.
Кыштырдаулар дигән, тынлык дигән
Бөек республика бар анда —
Чакыр мине, Кама, шул иленә,
Ял, урын бир арган аңыма.
Ыгы-зыгы, юрау, янаулардан
Мескен башым чатный, ярыла.

Ракета һәм яшәү тизлегеннән,
Самолет һәм поезд шавыннан,
Трамвайлар чинау, калтыраудан,
Машиналар исе, газыннан,
Үкерүеннән... этү-төртүләрдән,
Бәхәсләрдән — яшер барыннан.
Чакыр мине, Кама, ашыгу, каушау,
Тизлекләрне мәңге сагынмам.
О, Табигать анам, кайтты балаң
Борыла-борыла аккан көннәрдән.
Рәхәт шавың — бишек җырын тыңлап,
Бәлләүемдә кабат тирбәләм.

* * *

Ник уяттың мине, төнге Кама?
Су төбеннән сәер тавышлар
Ишетелде. Кемнәр дәшә шулай?
Тавышлары, ахры, танышлар.

«Мин — авылың синең, син яралган туфрак,
Аунап үскән яшел чирәмең.
Күккә карап аунап яткан жирең,
Бишек жырың, яшьлек көйләрең.
Беренче һәм үлмәс мәхәббәтең.
Узган гомерең, күмелеп ятамын.
Узган гомере әнкәң, атаңның.—
Син жаныңны ташлап киттең, бала...»

Жавап бирәм белмим кем өчен:
«Син улыңны артык сагынып бугай,
Бүтәннәрне белми, күрмисең.
Улың үзе генә синдә бәхетле иде.
Хәзер сине күмгән сулардан
Көн-төн ургый нурлар: миллион күзләр
Бәхет, сөенеч ала шуңардан.
Бәлки шуңар улың үзе теләп
Бөек хисен корбан иткәндер.
Күз яшьләрен яшерә-яшерә синнән,
Язмыш сүзен тыңлап киткәндер».

«Язмышны мин белмим, беләм тик сөюне,
Бары шуны сорыйм баламнан.
Бер югалтсаң, булмый табып мине,
Булмый яңадан.
Мин булмагач ирнең йөрәгендә,
Ул соң тиеш кемне якларга?
Кемне яклап китсен яуларга ул,
Каршы ятларга?
Ышансыннар дисә, тиештер ул
Су төбенә төшеп,
Күкрәгемә төшеп ятарга».

Хаклы да син, ана, тик хаксыз да...
Һәм еракта балаң, еракта.
Мин дә менә синнән ары китәм
Үзәннәр һәм ярлар буйлата.

* * *

Мин урманнар, таулар буйлап йөрим,
Үзәннәргә эндәшәмен.
Өйләр белән сөйләшәмен,
Бәхәсләшәм, киңәшәмен.

Ава койма, ава читән.
Ир төзәтми: «Тиздән китәм».
Авыл күчә, сүзләр оча:
— Без бу жирдә вакытлыча.
Без бу жирдә кунак төсле,
Төзү-кору — үкенечле.—
Сүзләр оча һәр көн туса:
— Вакытлыча, вакытлыча...
Яшәү монда барыбер бетәр,
Китәселәр барыбер китәр.
Әйттереп кал! Иртәгесен?
Иртәгесен — шайтан белсен.

...Искерде дип, кечерәйде дип,
Әгәр җирне ташлап китсәк,
Анда бары кунак булсак,
Калмас димсең тетелеп, бушап?

Йорт-кураны өметсезлек
Җимереп йөри: гамьнәр оча.
Гамьнәр очса, ямьнәр оча.
— Вакытлыча, вакытлыча...

* * *

Яр буенда яшел тыкрык.
Шаярган сымак кына,
Яшь киленнәр килә суга
Тар сукмак буйлап кына.

Көяшлар төшеп чиләккә
Уйныйлар чума-чума.
Уза китә яшь киленнәр.
Бер әби кала шунда.

Юл күрсәткән аңа кемдер
Бу чишмәгә кайчандыр.
Ул эзләп йөри хәзер
Тапмак булып шул чакларын.

Өй сүтелгән, күрше авылда
Өр-яңа өй көтә.
Гомер үтелгән — хыял
Күзгә күренми тилмертә.
Сөенми әби өй белән хәтта
Чишмә күчә дисән:
«Яуда калган ирем кайтып,
Шушыннан эзләп йөрсә?»

Бер төшә дә бер менә ул,
Нидер укый, ялвара.
Аңламыйсың? Бар, шул яшьтә
Син тормыш башлап кара,

Яңадан башлап кара!

* * *

Соңгы кабат сайрый сандугачлар,
Соңгы кабат сөя күлне яз.
Килер язны болын каршыламас,
Диңгез булыр — болын, күл булмас.
Диңгез булыр, ләкин ул шауламас,
Сай суларга җилләр файдасыз.
Сандугачлар, талларыгыз калмас,
Кая куныл, ничек сайрарсыз?
Чит яклар мактап җырларсызмы
Мәңге оя корган җирләрсез?
Сөйгән тирәкләрне эзләрсез дә
Табалмагач кемне тиргәрсез?

...Яңа юллар ярып бара шау-шу,
Яңа җирләр яулап ала су.
Сез хаклы да, дуслар, тик хаксыз да.
Кирәк безгә, кирәк аңлашу.

* * *

Күренми шул монда җәнлек эзе,
Кәкүк тавышлары ишетелми.
Болын буйлап, ерак урманнарга
Кача тынлык, җәнлек шикелле.
Кайчан аны куып җитәрмен мин?
Куян бәбие төсле сөярмен
Кулларыма алып кайчан аны?
Юкка бугай эзләп килгәнмен.
Тынлык кача моннан кырык чакрым,
Таптый юкса кразлар һәм мазлар.
Кайтыр юлы бикле: балчык, таулар —
Чыгалмаслык чокыр һәм базлар.

Яңа юллар ярып бара шау-шу,
Яңа җирләр яулап ала су.
Сез хаклы да, кошлар, тик хаксыз да —
Кирәк моны белү, аңлашу.

* * *

Биеклектә тора Түбән Кама,
Канатларын җилпеп бөркеттәй.
«Әй, авыллар, кушылыгыз миңа,
Алып китим зәңгәр киңлеккә!»
Дигән сыман изи краннарын.

Чыга Чаллы аңа ярышка.
Театрга торган чират кебек,
Тезелә чират «Отдел кадров»ка.
Кичә күрсәң, бүген таныш түгел
Гомер буе белгән урамың.

Тынлык эзләп килгәнемне онытып,
Хәйран калып карап торамын.

Бишәр катлы яшь урамнар буйлап,
Чал калага керә иркенлек.
Теле-антенналар,
Кибет-ашханәләр:
«Нәрсә җитми?!» — диләр шикелле.

Илнең барлык, барлык якларыннан
Нигә дисең кешеләр агыла?
Беләм, күрәм,
Яшәү өләшәләр,
Бәхет өләшәләр
Кама ярында...

* * *

Жырларыгыз, кошлар, таныш миңа,
Шундый матур сезнең телегез.
Шул тел белән сөйли безнең сөйгән
Нәселебез, туган җиребез.
Сөйләшик без, әйдә, шушы телдә,
Шикләнмәгез, зинһар, килегез.
Кирәк түгел миңа каурыегыз,
Кирәк түгел йонygыз, тирегез,
Килегез.

Энеләрем минем, сеңелләрем,
Яныгызга, юк, мин килмәдем
Яман уйлар белән. Ник куркасыз?
Берегезгә дә юк бит тигәнем!
Тишек чалбар, ялан аякларым
Исегездәдер. Һич тә йөрмәдем
Туздырып, я тентеп оягызны
Шул чакта да. Тик бер үрдәгем
Рәнҗегәндер миңа. Су буенда
Теге еллар, хәтәр елларда
Кошлар белән бергә, мескен җаным
Очам, очам диеп торганда,
Ах, сузылды яфрак хәтле кулым
Чын ярдагы яшерен ояга...
Бала чакның шул гөнаһы өчен
Сакал баскан йөзем кызара.

Кичерегез, кошлар, кичерегез,
Я чукыгыз җыелып бәгъремне.
Тик белегез, барыгыз да миңа
Коштай җаным кебек кадерле.
Иңнәремә кунып сайрагыз сез,
Әй күп җырлар бергә сайрыйсы!

Ах, пырылдап тагын югалдыгыз:
Сүзне бүлде мылтык тавышы...
Энеләрем, сеңелләрем, шулай
Өйрәткәннәр сезне куркырга.
Бар кешелек гүя җинаятьче...
Мин дә кеше — сезнең каршыда
Кызарамын, башым июле.
Кичерерсезме, кошлар, сез мине?

Арабызда мең гасырлык чокыр
Аерым иткән безнең телләрне.
Калган сезнең чиста хәтерегездә,
Калган керле бармак эзләре.
Бурыч безнең — юу шуны, бетерү
Һәм ант бозмау һичбер вакытта.
Бар кешелек гаебен алып өскә,
Үзебезнең күңел сафлыкка
Ышандыру сезне... Без ия шундый көчкә:
Бераз җирләр сорап килсәк тә,
Юк, кормабыз бәхетебезне ләкин
Сезнең исәпкә.

* * *

Туган өйдән аерылулар яман...
Кайгырыштык шуңар, елаштык.
Тик елашып озак яшәп булмас,
Тынычланыйк бераз, уйлашыйк,
Уйлашыйк...

Энеләрем минем, сеңелләрем,
Үпкәләшмик, без бит — туганнар.
Вәгъдә бирсә бозмый торганнар
Күбрәк бездә... Корып куйганнар
Ниләр әнә!
Чакрымнарга киткән торбалар
Сузылып ята болын буйлата.
Снарядлар!
Тик атылмый туплар.
Снарядлар
Су астыннан алып ком ата.
Су кумәр як белән сезне аерып,
Дамба дигән ташлы юл ята.
Снарядлар сезнең өскә түгел,
Яклап ата, килгән дә сакка.
Җиребезнең бер өлеше бары
Кала диңгез дигән кунакка.
Кунакка!
Әйдә, килсен,
Яхшы ният белән булгач,
Килсен ул диңгез.
Мәңге шулай йола-гадәтебез:
Ачык чырай бездән, якты йөз.

Энеләрем минем, сеңелләрем,
Әйе, монда дамба үтәсе.
Һәм ил бирде закон: яз-җәйләрдә
Күтәрелмәс мылтык көпшәсе...
Юк, кимемәс сезнең нәселегез,
Юк, югалмас җырыгыз, телегез.
Кунак булгач, килсен ул диңгез...

Кунак килсә, түргә чакыру фарыз,
Бүтән чакта дәшәр ул безне.
Ерактагы дуслар күңеле, хакы
Итеп каршы алыйк диңгезне.

Йөрәкләрнең түр почмагы безнең —
Дуслар урыны... Ачык һәр чакта.
Җиребездә дә шундый изге пәрә
Дус килүгә тора запаста.

Илебез киң булгач, өй тараймас,
Киң дә булсын Кама, тирән дә.
Суыбыздан ургып чыккан утлар
Яктылыгы төшсен илләргә,
Ерак өйләргә.

Сәлам булып житсен
Шушы жирдән китеп
Мәңгелеккә калган ирләргә...

* * *

Яр буенда — бакча.
Ахры, үзганнарны
Сөйли наратлар.
Наратларның сүзен ил-көн ятлар,
Ятлап ирләр мәңге кабатлар.

Яшь чирәмдә йөри яшь бибиләр,
Үләннәрдән жыеп яшел төс.
Малайлар һәм кызлар
Орлык-куркә
Жыеп йөрде монда иртә-кич.
Һәм чәчтеләр биек киңлекләргә,
Сулар мәңге житмәс жирләргә.
Яшь наратлар инде башлар игән,
Саубуллашкан төсле тирбәлә...

Төнлә яуды яңгыр.
Яшен суы
Юды ылысларны.
Тузан, чүп-чардан,
Яшел төсләр шуңа чистарган.
Яр Чаллының яр буенда бакча
Бәйрәм көткән төсле бизәнгән.
Наратлар тын, салмак чайкалалар
Язгы жилдән, кичке көйләрдән.

Кичке көйләр ылысларны гүя
Чәнчәләр дә качып йөгерәләр.
Твист дигән тиле бер ритмнан
Йомшак билләр менгә бөгеләләр.
Пычкы белән агач кискән төсле
Чыж-чыж итә көйләр.
Тилеләр
Биләр.

Әллә гамьсез бәйрәм, әллә хәмер,
Әллә юксә нарат исеннән —
Йомшак башлар йөри тәгәрәшеп —
Йомшак башлар бүген исергән.
— Ah-ha-ha-ha! —
Ботакларга бәреләләр,
Көлү тавышы — кузсез, кургаш кош.
Авыр туа бөек эшләр бары,
Азгын хисләр туа тулгаксыз...

Соңгы бию монда, соңгы бәйрәм —
Шашкын була соңгы биюләр.
Йөз елларга житәр шатлыкларны
Татып бетерергә телиләр.

Әй,
Биегез сез әйдә.
Ә иртәгә...
Твист түгел,
Наратларны төбеннән ук
Кисәр, кыркырлар
Пычкылар —
Гильотина түгел,
Вакыт, язмыш дигән пычкылар.
Наратлар бит яшен суы белән
Юындылар кичә соңгы кат.
Шуңа барысы, бәйрәм киткән төсле,
Тора бүген горур мок сулап.
Ә иртәгә йөгерер монда дулкын...
«Бөек шатлык калсын аларга —
Безнең бәйрәм булып ду килергә,
Безнең яшәү булып шауларга».

Шул сүзләрне кабатлыйлар яшьсез,
Тын чайкалып, яшел солдатлар.
Ә иртәгә...
Геройлар күк,
Төз көенчә,
Тез чүкмичә егылыр наратлар.

* * *

Кама белән инде килештек без.
Тик бит әле бөек дөнья бар:
Күпме анда болын һәм урманнар,
Күпме анда күлләр, елгалар!

Кай төштәдер кибә күл һәм елга,
Диңгезләр дә сусый, кибеләләр.
Җәнлек-кошлар, өйдән, судан язып,
Югалуга таба йөгерәләр,
Иегәләр...

Дөнья буйлап гади шартлау йөри —
Җилпенмичә төшә күктән кош.
Кошлар һәм җәнлекләр —
Кешелекнең башы.
Башыбызны үзебез кисәбез.
Шартлау, кисү... Шулай киләчәкне
Кырып, таптап йөри кыргый хис.
Браконьерлык юаш аю түгел,
Ә нацист ул, расист һәм хәсис.
Гамьсезлектән азган шул кыргый хис
Кешелекнең ырлый үзенә.

Газетада хәбәр:
— Илнең үз хуҗасын,
Соңгы индеецны ябып кемдер
Дөнья йөзенә
Алып чыккан тимер читлек белән...
Зоопаркка куйган карарга.

Цивилизованныйлар
Кызыл тәннән,
Без яраткан төстән көлеп,
Авыз ерып баккан аңарга.

Бүген аңа, ә иртәгә читлек —
Бүтән халык, бүтән милләткә.
Тик исемнәр йөрер җир йөзендә,
Урманыннан качкан җәнлектәй.

Кайсыгызга тансык
Үзегез койган корыч читлек,
Богау, челтәрләр?
Җимерелмәсә,
Исән калса бу челтәрләр,
Зоопаркта кемне көтәрләр?..

Дөнья буйлап һаман чапса җәнлек,
Ерак китәр, озак дисезме?
Һәм дәрьялар кибеп, сусыз төптә
Балыклармы сикерер, кешеме?

Атом кебек шартлап, үкереп түгел,
Тавыш-тынсыз атлый һәлакәт.
Һаман итәр яшерен хәрәкәт ул,
Бакчабызның кадерен белмәсәк без,
Саклый белмәсәк.

* * *

Кызылмы төс, акмы, я карамы,
Кешелек тоташ, бер җан, бер үк тән.
Таза, тыгыз тәндә җәрәхәт һәм
Кутыр күренә элек-электән.

Аңлатты фән: әгәр авыру тәнгә
Сәламәт тән алып күчерсәң,
Авыру бетә...

Камил бер заманнан
Яфрак хәтле генә тән алып,
Күчерә алсак шуны безнең чорга,
Китәр иде савыгып, яңарып.

Әй, докторлар, табыгыз сез әмәл,
Кайда, кемдә шундый көч, кодрәт?!
Заман безнең көчле, таза, һиммәт,
Ярдәм аңа ләкин бик кирәк.

Ул үзенең тыгыз җилкәсендә
Күкне һаман тора күтәреп.
Калтырый тик тезләр, каушый уйлар:
«Очмас микән кинәт күк янып?
Очмас микән кинәт
Сөлкенмичә мәңге торган
Аяк баскан җир?

О, Табигать-тәнре, киңәш бир!»
Титан сүзен ишетеп ага Кама.
Кошлар шуңа моңсу җырлаша.
Башта минем уйлар, уйлар таша,
Бар дөньяны гүя су баса...

Китәр идем бүтән дөньяга мин,
Көченүләрнең беләм,
Күрдем газабын...
Саклый алырмынмы? —
Керпе улын түгел,
Җир язмышын,
Уч төбемдә күтәреп барамын...

* * *

Дөнья!
Моңлы дөнья!
Сиңа
Мең күз карый миллион төс күреп.
Бәяләрдә — шундый төрлелек.

Мең тел бергә әйтә алмый сине
Гүзәл дип һич тә.
Туры килде гомерем синең шундый
Чуар чагыңа,
Әллә бәхет, әллә үкенечкә.
Нишлим, нишлим,
Кабул итәм сине
Һәм яратам
Булган көеңчә.
Әйтәм:
Зәвыкыбызча бизәү кирәк сине,
Саклау кирәк,
Саклау кирәк ләкин үзеңчә.

Чаң кагам мин:
— Бар халыклар!
Барлык теләк-гадәтләрне
Буйсындырып бары акылга,
Кул бирегез бер-берегезгә
Җир хакына,
Яшәү хакына!

1969

**Нурихан Фәттах**

# ӘТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

ТАРИХИ РОМАН

## XVI



Кулга төшерелгән байлыкларын — көтүләрне, олауларны, кешеләрне калдырып, кыйналып, казаяклар якындагы урманга качтылар. Инде урманга життем дигәндә генә, Ямгырчы би чак кына болгарлар кулына эләкми калды. Аны бары ырудашларының батырлыгы да, Тотышның яралануы гына коткарып калды. Тотыш исә бөтенләй көтмәгәндә яраланды.

Казаяклар яшел байраклы тирмәне калдырып киткәч тә, ул шактый жир аларны үзе генә диярлек куып барды. Әллә ул бик нык алга чыккан иде, әллә инде якынтирәдә бер генә болгар да калмаган иде — Тотыш берни белмәде. Аннары ул үзе янында болгарлар булмавына бик үк пошынмады да. Ул үзен болгарлар өчен сугышам дип уйламады. Ул бары Ямгырчы бигә каршы гына сугышты. Ул, үзенен сөеклесен саклап, бары аннан үч алырга гына тырышты.

Алдын-артын карамыйча, жилдәй очып барганда, каяндыр аның янына Торымтай килеп чыкты.

— Тотыш! — дип кычкырды ул, адашкан кеше сыман.

Тотыш кебек, ул да ниндидер иясез атка атланган иде. Кулындагы кылычыннан башка аның берниндн коралы да, тимерле киеме дә юк иде.

— Чүлмәк тавышын ишеттеңме? Котларын алдым! — диде ул, Тотыш алдына чыгарга тырышып. Куанычыннан аның колагы авызына киткән иде.

Шулай барганда, сул яктан, Ямгырчы бинең юлын кисеп, бер төркем болгарлар килеп чыкты. Ямгырчы би кырт кына уңга борылды, анда-санда үләкләр белән, төргәкләр белән чуарланган яшел болын буйлап жилдерә башлады. Тотыш та уңга каерды, бинең юлына төшмәкче булып, шулай ук бар көченә атын алга жибәрде. Ике ара кыскарганнан-кыскарды.

---

[1] Дәвамы. Башы 8—9 саннарда.

Казаяклар, урман алдындагы ниндидер ерганакка юлыгып, тоткарланып калгандай иттеләр. Ерганак атлар сикереп чыгарлык түгел иде бугай. Менә шунда әләгә язды да инде Ямгырчы би бүре базына! Бер яктан болгарлар килеп житте, икенче яктан Тотыш белән Торымтай килеп басты. Ике арада каты сугыш башланды. Кешеләр, ярсуның шашынуның соңгы чигенә житеп, соңгы сулышлары, соңгы тамчы каннары калганчы сугыштылар. Тимергә тимер тиеп очкыннар чәчрәде, иткә тимерләр тиеп, каннар чәчрәде. Үзләренең җиңелә язып калулары өчен ачулары кабарган, инде канатланып киткән, ярсыган болгарлар казаякларны утын турагандай турадылар, ит чапкандай чаптылар. Соңгы чиккә килеп терәлгән казаякларның шулай ук җиңел генә биреләселәре килмәде — болгарларга каршы алар арысланнар кебек сугыштылар. Казаяклар каны белән бергә җиргә болгарлар каны да акты. Башы ярылган, кулы, аягы киселгән болгарлар казаяклар янына барып төштеләр, бер-берсенә аркылы килеп я булмаса башаяк килеп, кочаклашып, мәңге бергә тынып калдылар. Чокыр төбе үлеләр белән, яралылар белән тулды.

Болгарларның төп көчләре белән казаякларның төп көчләре бер-берсенә якынлашканда, Тотыш, үзенә булышка килгән унлап болгар белән бергәләп, Ямгырчы би кешеләрен читкә җибәрмичә, бүлеп торды. Аның ничек тә тезмәне өзеп, Ямгырчы би янына үтеп кереасе, ничек тә аның үзе белән генә орышасы килде. Ул анда берничек тә үтә алмады. Киресенчә, казаяклар туктаусыз аның үзенә басым ясадылар, аның үзен таптап үтеп, чокыр буйлап качып китмәкче булдылар.

Менә шул чагында кемдер Тотышның башына күсәк белән тондырды. Үзенә суккан ирнең Тотыш бары усал күзләрен генә күрде дә, таныш шикелле тоелган ач янагын гына күрде. Күз алдында утлы бөжралар биеште, бөтен нәрсә зырылдап әйләнде дә, башаяк килеп, каядыр түбән тәгәрәде.

Аның янына шундук Торымтай килеп житте, атыннан авып төшкәндә аны тотып калды. Казаяклар, берничә бөртек болгарны як-якка сибәләп, камалуны өзеп чыктылар да, ур буенча бераз җир чабып бардылар, аннары сөзәк ярга туры килеп, барысы да ур эченә коелдылар, тиз арада икенче як ярга барып чыктылар, комга сибелгән су кебек, урман арасында юк та булдылар. Казаякларның калган бер өлеше, ур төбенә тулган үлекләр өстеннән чыгып, шулай ук урман арасында таралып бетте. Калган өлеше, атын-ниен ташлап, җәяүләп качты.

Уң кулны өзеп чыккан казаяклар арасында Ямгырчы би дә бар иде.

## XVII

Тотыш күзләрен ачып җибәргәндә, ничектер төн дә шикелле иде, кич тә, иртән дә шикелле иде. Әйләнә-тирә ниндидер болганчык караңгылыкка төренгән иде. «Кайда соң мин?» — дип уйлады Тотыш, күзләрен бер ачып, бер йомып.

Күпме тырышса да, ул үзенең кайда ятканлыгын төшенә алмады. Аның бик каты башы авыртты. «Тукта-ле, минем башка сукканнар иде ич!» — дип уйлады ул бераздан, әлерәк кенә булып үткән сугыш күренешләрен күз алдына китереп. Димәк, ул тагын исән калган! Тик менә Ямгырчы бинең артына гына житеп булмады. Нишләде икән ул? Ничек тәкәнде икән сугыш?

Ул, күзләрен нык ачып, яткан килеш тагын караңгылыкны бер айкап чыкты, тыңлаштырып торды. Юк, ул берни дә күрә дә, ишетә дә алмады. Шуннан соң ул тирә-ягын капшап карады. Ул ниндидер коры, йомшак җирдә ята иде. Ярый әле, чокырда түгел! Дулкын булып аның башына җылы кан йөгерде. Якында гына ниндидер тавышлар ишетелеп

киткәндәй булды. Карале, аның колагы томаланган булган ич! Әллә күзе дә шуңа күрмиме? Күрә ич, күрә! Ул, башын калкыткандай итте дә:

— Торымтай! — дип кычкырып җибәрде.

Аның тавышы, төштәге кебек, үзенә дә көчкә ишетелде. «Әллә телдән дә язганмынмы?» — дип уйлады ул, коты алынып.

Бераз тынып яткач, тагын кычкырып карады. Монысында ул үзенең ишетүен, ишетмәвен аера алмады — кинәт аның күз аллары яктырып китте: кемдер аның каршындагы чыбылдыкны сыдырып куйды. Сиек кына көн яктысында Тотыш үзенең бай итеп җыештырылган тирмә эчендә ятканлыгын күрде.

Ул торып утырды, як-ягына каранды. Чыбылдыкның тартылып, җыерылып торган кырые янында ниндидер хатын-кыз карачкысы күренде. Өстенә ул җинелчә бөркәнчек ябынган иде, бер кулына озын муенлы комган, икенче кулына көмеш күбәтә тоткан иде. Менә ул урыныннан кузгалды...

Туктале, тукта... Бу соң тагын теге... ни... аның күзен буган, аның тынычлыгын алган, аны юлдан яздырган... Әйе, шул үзе! Тик бу тагын теге чактагы кебек төш күрү генә түгел микән? Бер күренеп, бер югалып тора торган нинди серле кыз булды соң бу? Димәк, аңа да берни булмаган. Ул да исән!

Аның баш авыртуы шундук онытылды. Ул урыныннан сикереп торды. Елмаеп, сокланып, үзенең танышына, үзенең сөеклесенә карап тора башлады. Шул ук мәлдә аның күңеленә: «Тагын Алмыш хан кызы җибәрде микәнни?» — дигән бер уй килде. Чиксез куаныч тойгысына тузан бөртегедәй генә күңелсезлек өстәлгәндәй булды.

— Мин кайда? — диде ул кызга.

Кыз бөркәнчеген ачып җибәрде, чын күңелдән сөенеп, балкып-елмаеп, яралы егет янына килде.

— Исәнме, Тотыш! — диде ул, язгы тургай тавышыдай бер тавыш чыңлатып.— Башың авыртмыймы?

Тотыш берни әйтә алмады — ул яңадан телсез калды, яңадан күрми башлады. Ул, кызның яңгыравык, көйле тавышына, иртәнге кояштай балкыган гүзәллегенә исе китеп, таң калып, алыштырып куелган кешедәй карап тик торды. Кыз да оялып, шулай ук сокланып, елмаеп аңа карап торуында булды.

Беренче соклану кими төшкәч, Тотыш, пышылдап:

— Мин кайда — ник әйтмисең? — диде.— Тагын Аппак тырнагындамы?

— Син тырнакта түгел, ышанычлы кулда, Тотыш,— диде кыз, тыелгысыз елмаюын йомып, юаш кына.— Син мине үлемнән коткардың. Мин сине... мәңге онытмам.

— Мин кайда — ник әйтмисең? — диде Тотыш, соравын кабатлап.

— Син яралы, Тотыш. Терелгәнче син шушында ятачаксың.

— Син имчеменни? — диде Тотыш, елмаеп.

Кыз, матур иреннәрен тешләп, тынып калды, күзләрен түбән иде.

— Мин яралы булсам, минем янга имче килсен,— диде Тотыш.

— Ярар, сау бул,— диде кыз, күңеле кырылып.— Синең янга Байтал имче килер.

Ул, күрәсең, теге чактагы кебек, Тотышның тагын үзен куалып чыгаруыннан курыкты: шуңа күрә ул, ныклап торып бозылышканчы, тизрәк чыгып китү ягын карады. Ул инде ишек бавына да тотынган иде. Тотышның йөрәге жу итеп китте. Үзе яраткан, үзе тагын бер дә юктан күңелен кырган кыз аңа бик-бик кызганыч тоелды. Ул да, кыз кебек үк, теге чактагы күңелсезлек кабатланудан курыкты.

— Тукта, китмә! — диде ул.

Кыз туктады, яңы белән борылды да, кызарынып, аның тагын берәр сүз әйтүен көтә башлады.

— Кил эле,— диде Тотыш.

Кыз күндәм генә урынынннан купты, сөрмәле күзләрен күтәреп карарга кыймыйча, яралы егеткә таба атлады.

Тотышның ана: «Мин сине генә яратам. Сине генә яратам!» дип әйтәсе килде. Тик ул тагын андый сүзне бернichek тә әйтә алмаганлыгын, андый сүзне әйтү өчен кешe көченнән килми торган ниндидер бик зур батырлыкка, кыюлыкка ия булырга кирәклеген аңлап алды. Тел очына аның бөтенләй икенче сүзләр, җинел сүзләр килде.

— Аппакка әйт... хан кызына... Мин аны яратмыйм! Яратмыйм! — диде ул, ашыгып, үртәлеп.

Ягымлы, юаш, күндәм кызны, әйтерсең, күз алдында икенче кешегә әйләндерделәр. Кинәт ул башын калкытты, күкрәген киерде. Күз ачып йомганчы ул билендәге кәзлеген [1] тартып чыгарды. Көн яктысында очлы тимер ялтырап китте.

— Менә мин ул Аппак! Мин! — диде ул, авызыннан утлар чәчеп.

— Син?! — диде Тотыш, шаккатып.

— Мин! — диде кыз, борынын югары чөеп.— Телим икән, «ә» дигәнче башың менә монда аяк астында аунап ятыр!

— Кис! — диде Тотыш, башын иеп.

Ул моны чынлап әйттеме, шаяртып әйттеме — кыз берни аңлый алмады. Шулай да егетнең бу сүзе, бу кыланышы, агулы ук булып, туптуры аның йөрәгенә кадалды, аның болай да кимсетелгән мин-минлеген яралады. Ул моны Тотышның әлеге дә баягы кирелеге итеп, Алмыш хан кызын яратмавы итеп аңлады. Коры ку сыман кинәт гөлт итеп кабынган ярсуы кинәт юкка чыкты. Баш бирмәс алып егет алдында ул үзен иң беренче очрашудагы кебек көчсез итеп, кызганыч итеп тойды. Шулай да аның җиңеләсе дә килмәде.

— Ник яратмыйсың, ник?! — диде ул, янау катыш ялвару белән.— Мин шулай яратмаслыкмы? Котсызмы?

Тотыш карулашып өлгергәнче ул бөркәнчеген өстеннән салып ташлады. Чын ташлар белән бизәлгән каптырмаларын ычкындырып, кыска тунын салды, күлмәген, каюлы читекләрен салып ташлады. Беләзекләрдән, муенсадан башка аның өстендә берни калмады. Күкрәгендәге тулы, тыгыз алмаларын учлап тоткан килеш, уң кулындагы үткер кәзлеген ычкындырмыйча ул, бер-ике адым артка чигенде дә, озын кара толымнарын җилфердәтеп, алтын-көмешләрен чыңлатып, үз тауарын мактаган сатучы кебек, егеткә әле яны белән, әле арты, алды белән борылды.

Аның килмәгән бер генә җире дә юк иде. Нечкә биле камыш кебек сыгылмалы; иңбашлары, беләкләре, аяклары тулы, тыгыз. Сөттәй ак, сылу буеннан яшьлек, кайнарлык бөркелеп тора иде.

— Әйт: кай җирем ямьсез? — диде ул, чын күңелдән пошынып, чакчак кына масаю белән.

Тотыш инде чынлап та телдән калды. Иреннәре кипте. Күз алдын ялкын каплап алды.

— Син мине... алдадың...— диде ул, күпмедер тынып торганнан соң.

— Мин сине яратам! — диде кыз.

— Мин дә...— диде Тотыш, иреннәрен көчкә кыймылдатып.

## XVIII

Исән калган ир-атларын, олауларын, терлекләрен җыйнап, Тәкин углан кичекмәстән арьякка чыгара башлады. Үлгән ырудашларын болгарлар үзләре белән алдылар, казаяклар җирдә ятып калды.

[1] Кәзлек — хатын-кыз хәнҗәре.

Яшел болыннарга оялчан кулләргә көндәгечә елмаеп кояш карады. Күктә мендәр кебек кабарынкы ак болытлар йөзеп йөрде. Пыяла күзләрен тондырып, яраларын шәрә ачып, җирдә үләләр ятып калды. Якты көннен ямен җибәреп, ярым үле яралылар ыңгырашты. Яралылардан да уздырып, таза кешеләр елашты. Бөтен Чулман буе елау-сыктаудан дер калтырап торды. Терлекләргә, кешеләргә кушылып, әйтерсең, бөтен туган җир ачы күз яшьләрен түкте.

Шулай итеп, җиңүчеләр, җиңелеп, таланып, көчкә үз якларына чыгып өлгәштеләр. Сал-күпер алынды. Чулман өсте бушап, иркенәеп калды. Болгар илен кара төн чыбылдыгы каплап алды.

Икенче көнне, бераз тын алгач, ял иткәч, кешеләр артларына борылып карадылар, югалган, юкка чыккан нәрсәләрен барладылар. Бары шуннан соң гына икенче бер кайгы — үзләренекеннән дә зуррак кайгы турында исләренә төшерделәр. Болгар-тора нишләде икән? Алмыш ханның эшләре ничегрәк икән? Җиңә алганмы ул суарларны, әллә ул да шулай суга төшкән тавык кебек таланып-йолкынып калды микән?

Алмыш ханның исә эшләре мактанырлык түгел иде. Тулысынча агач өйләрдән, киез тирмәләрдән, чыбык-чабык куышлардан торган, агач коймалар белән әйләндереп алынган, агач күперләре, агач капкалары булган Болгар-тораны хан килеп житкәндә инде ут-ялкын чорнаган иде. Суарлар берничә урында койма әчеңә бәреп кергәннәр. Ялкын ялмый алмаган урамнарда, ишек алларында, койма буйларында каты сугышлар бара. Коралсыз кешеләрнең күбесе, йорт-җирләрен, терлекләрен ташлап, болын, урман ягына качышып беткәннәр. Ханбалык янындагы юл буйларында, кырларда-басуларда үлгән, яраланган кешеләр аунап ята, кая барып бәрелергә белмичә, иясез терлекләр каңгырап йөри. Кара болыт булып күккә күтәрелгән кара төтен баганалары ягыннан, кызгылт ялкыннар, кара күмергә әйләнгән каралты-куралар ягыннан каты чыртлап-шартлап янган агач тавышлары, шашынып кычкырулар, йөрәк өзгеч сыкранулар ишетелеп тора иде.

Шуларның барысын да күргәч, ишеткәч, Алмыш ханның күз аллары караңгыланып китте. Тиле кеше кебек ул кинәт:

— Яна-а! — дип кычкырып җибәрде.

Болгар ирләре тетрәнеп киттеләр. Боерык булганны да көтмәстән, буасын ерып киткән язгы су кебек, төп юлдан читкә бәреп чыктылар да, киң болынга тарала барып, сөрән салып, ут-ялкынга таба ыргылдылар.

Алмыш ханның кайтып төшүен суарлар да, ханбалык сакчылары да күреп алды. Суарлар, кара болыттай ябырылып килүче болгарлар белән очрашырга теләмичә, ашык-пошык чигенә башладылар. Иң беренче булып Килдеш би үзе табан ялтыратты. Кинәт купкан ыгы-зыгы, буталыш арасында аның качып китүен болгарлар түгел, суарлар үзләре дә күрми калдылар. Ерак юлдан кайтучы болгарларның иң өлгер ирләре Ар-капкага якынлашып килгәндә, Килдеш бине уртага яшереп качып барган суарлар төркеме инде Өчкүл ягындагы урман авызына барып житкән иде. Беренче төркемнең үкчәсенә басып, суарларның икенче, өченче төркемнәре кузгалды. Алар да Өчкүл ягы урманына юл тоттылар.

Болгарларның болын тутырып килгән ир-атлары икегә бүленде. Берсе качучыларны эзәрлекли китте, икенчесе янган торага ашыкты. Шул ук авыкта капкалардан, янган, ауган коймалардан калдык-постык болгар сакчылары бәреп чыкты. Капка алларында, киң болынның әле бер төшендә, әле икенче төшендә чигенүче суарлар белән болгарлар арасында сугышлар бәйләнеп китте. Өчкүл ягындагы урман буенда да икe арада яман сугыш башланды.

Сугыш бик каты булды. Яндырылган, таланган ханбалык өчен болгарлардан берниндн изгелек, берниндн кызгану көтмәгән суарлар

ярсып, котырынып сугыштылар. Болгарларның ачуына, ярсуына чик чама булмады. Тиз арада болып өсте үле атлар, үле кешеләр белән тулды. Чабылган, туралган аяк-куллардан, киселгән башлардан таулар өелде. Тапталган яшел ут-үлән арасыннан чишмә булып кызыл кан акты. Кыргый тавышлардан, ыңгыраштан якындагы урман кан-калтырап торды.

Төшкә сугыш бетте. Суарларның меңләгән ирләре мәңгегә күзләрен йомды. Болгарларның чыныккан, күпне күргән таза ирләре үз өйләренең капка төбендә аякларын суздылар.

Качып киткән Килдеш бине дә, башка суарларны да Алмыш хан эзәрлекләп тормады. Бу көтелмәгән яу, бу көтелмәгән җиңү-җиңелү аны шундый нык какшатып ташлады — кайгысыннан ул күзен дә күтәреп карый алмады. Атын әкрен генә атлатып, ул үзенең туздырылган оясына юнәлде.

Башта ул үз урдасына кайтып керде. Урдадан җилләр искән иде. Шулай да әле анда, әле монда кайбер нәрсәләр күренгәли иде. Текә яр буендагы ат абзарлары, каравыл өйләре, җимерелә башлаган койма — барысы да исән иде. Хәрәземнәр салып биргән таш мәчеткә дә берни булмаган. Бары тик аның ишекләре генә каерылып ташланган иде дә, ак ташларына сыек ләпек, сыер тизәге укәлгән иде... Җөфүтләр коткысына бирелгән суарлар эше...

Урда уртасындагы ак өй — Алмыш ханның агач сарае да, шул тирәдәге башка өйләр дә — барысы да кара күмергә әйләнгән иде. Берничә кеше шунда кайнар көл, күмер арасыннан нидер эзләп маташа, икенче берәүләр, елашып, янып бетмәгән кием-салымнарын коткарырга тырышалар иде.

Алмыш хан урдага читтән генә күз ташлап алды да, янып җир белән тигезләнгән Төп-капу ягына юнәлде. Ул монда да озак тора алмады, тынгысызланган атын әйдәп, янадан кузгалып китте. Кайгылы башын салындырып ул ханбалыкны аркылы-торкылы йөреп чыкты: янган, җимерелгән коймалар буенда булды, капкаларга, каравыл өйләренә сугылды, күл буена, иске йорт янына барып әйләнде. Кая гына бармасын, теләсә кайда аңа пыскып-көйрәп яткан кара күмер, агач өемнәре, үлгән, янган кешеләр, көлгә-корымга буялган, шашыпып, әрлебирле чабышкан ирләр, хатыннар, балалар очрады. Кая гына бармасын, аның колак төбендә елау-сыктау, үксү тавышлары яңгырап торды.

Шунда аның күз алдына икенче төрле янгыннар килде, җимерелгән, таланган авыллар, катаулар килде... Әйе, әле кайчан гына ул үзе талап, яндырып йөрде. Инде менә аның үзен талап-яндырып киттеләр. Барысы да юкка чыкты, барысы да көлгә очты! Күпме көч куеп, ничә еллар буе җыйган байлыгы суга акты. Йа тәңрем, йа алла, аның әле беркайчан да бу тикле талау, бу тикле кыран күргәне юк иде бугай! Беркайчан да әле болгарларның мондый зур оятка калганнары юк иде. Шундый күп көч түгеп, тырышып торгызган өйләр, коймалар, капкалар — барысы да әнә аяк астында аунап ята. Менә сиңа бөек Болгар, менә сиңа җинелмәс болгарлар!

Алмыш ханның күңеленә шундыйрак уйлар килде. Мондый чакта аны бары: «Чулман иле... Чулман байлыгы минем кулда»,— дигән бер уй гына бераз тынычландыра алды.

Менә яндырылган, таланган ханбалыкка таланган, өтәләнгән Тәкин углан да кайтып төште. Алмыш хан, углын шулай ярым-йорты килеш күреп, аяктан егылды. Ике көн, ике төн буе ул баш калкытмый урынында ятты. Ашамады, эчмәде, беркем белән сөйләшмәде. Өченче көнне хан аягына басты, туган-тумачаларын яшерен киңәшкә җыйды.

Үзенең биек түрендә калкып утырган килеш, берничә көн эчендә тартылып калган Алмыш хан сүзгә башлады.

— Моннан күп еллар элек бу якларга килеп, безнең борынгы эта-бабаларыбыз бу җирләрне яулап алганнар,— диде.— Күктә — кояш таныҗ. җирдә — Әтил таныҗ: бабам, атам туган чакта Әтилнең үрге агымы Ука суынача, түбән агымы — Кызлар тавынача, Чулманның Ала Бука катауга тикле барлык җир-сулары болгарныкы булган. Кояш таныҗ — анам мине тапкан чакта шушы төбәктәге йорт-ил тулысынча болгарныкы булган. Көн дә иртән кояш монда безнең өчен чыга, көнтөн Әтил, Чулман җир читеннән безгә таба агып тора. Күктә кояш сүнми торып, болгар бетмәс, Әтил, Чулман корымыйча торып, Болгар йорт бозылмас!

— Шулай булсын! Сүзең изге! — диештеләр агай-эне, күңелле гөрелдәп.

— Күреп торасыз, белеп торасыз,— диде Алмыш хан, бераз тын алганнан соң,— безнең йортта тыныч түгел. Кайчакта мин үз йортымда үземне чит сизәм. Өч ел буена Чулман бездән аерылып торды. Инде аны яңадан яулап алгач, яңадан үземә тиешле калаәны сугышып алып кайткач... Барысы да күз алдыгызда. Искә төшерәсем дә килми. Әйтегез, кайчангача суар, бүләр, башка барлык ягы ырулар, улуслар, хазарларга аркаланып, минем йортымны шулай талап-яндырып китәрләр?! Кайчан мин үз йортымда үзем баш булып, тынычлап яшәрмен?! Кайчан без, җөфүтләргә кол булудан туктап, үз башка, үз иркебезгә яши алырбыз?! Кайчан без бер-берсе белән талашып, ызгышып яшәгән таркау улусларны, ыруларны берләштереп, бөек Болгар йорт кора алырбыз?!

— ...Менә шулар турында уйладым мин соңгы көннәрдә. Менә шулар турында баш ваттым, агай-эне, туганнар... Барыгызның да күз алдында — Болгар йорт чак-чак кына аумый калды. Суарларга, казаякларга Бүләр дә кушылган булса, без инде күптән су төбендә булырыек. Безнең язмыш кыл өстендә калды — аңлыйсызмы шуны, агай-эне?! Киләчәктә дә без шулай яшәсәк, ягылар, үзара берләшеп, безне баш аркылы чөеп ташлаячаклар. Баш аркылы чөймәгәндә дә, белегез: безгә тынгы булмаячак. Без аларны барып таларбыз, алар безне килеп таларлар. Башкача болай яшәп булмый. Аңлыйсызмы — булмый!

Шулай дигәндә аның таштай авыр, салмак тавышы калтыранып китте, мыек чылгыйлары сикерешеп алды. Авыр йодрыкларын йомарлап ул аягүрә басты да, тавышын көчәйтеп:

— Искечә яшәсәк, без юкка чыгачакбыз! — диде.— Менә шул турыда уйладым мин, агай-эне... Тыңлагыз сүземне. Элеккечә ил тотып булмый. Талау, яндыру белән ерак китеп булмый. Көтү көр булсын өчен, терлекләр тынычлап утларга тиеш. Беләктә — көч, калтада — алтын тулып торсын өчен ил тыныч булырга, бердәм булырга тиеш. Безгә бердәмлек кирәк, иминлек кирәк, көч-байлык кирәк. Шуларны ничек булдырырга?

Ул, сүзеннән туктап, агай-энегә күз йөртеп чыкты. Аннары тагын салмак кына ялгап алып китте:

— Безгә барысын да өр-яңадан башларга кирәк булачак,— диде.— Беренчедән, без яңган ханбалыкны торгызырга тиешбез, икенчедән, тораны беркемнең дә теше үтмәслек таш койма белән уратып алырга кирәк.

Кемдер түзмәде, исе китеп:

— Таш койма белән? — дип куйды.

— Әйе, таш койма белән! — диде Алмыш хан.— Таш койма эченә кереп бикләнмичә торып, безнең хатыннарга, балаларга, безнең кара-

ларга тынгы булмаячак. Шунсыз без усал, көнчел күршеләрдән котыла алмаячакбыз. Болгар җирендә таш җитәрлек.

— Таш җитәрлек тә, аш белән баш җитәрлек түгел шул! — диде шунда чәрелдек тавышлы бер картлач, урыныннан кузгалгандай итеп.— Таш койманы коры кул белән салып булмый. Ташчылар кая, түләргә акча кая?

— Әйе, әйе!

— Әйтүе генә җиңел — таш койма!

— Балта белән таш чабып булмый, ташчылар кирәк,— диештеләр башкалар да, телгә килеп.

— Ашыкмагыз, сүзем бетмәде,— диде хан.— Мин барысын да уйладым. Таш койма ул мине саклар өчен, сезне саклар өчен, безнең күчләрне, караларны, колларны саклар өчен. Барлык Болгар йортны — җир-суларны, урман-болыннарны таш коймага бикләп булмас, шулай ук ягы улусларга да богау салып булмас. Менә аларны ничек богаулап, авызлыклап тотарга — иң авыры шул. Бүләр, суарны, Чулманны, угыз, кыпчакларны ничек кулда тотарга?..

— Син юкка кайгырасың, хан,— диде Корыч-Тимернең атасы Алып-Тархан.— Бүредән курыккан — урманга бармаган. Син югында бүре килеп сарыкларыңны алып киткән икән, сарыкларны абзарга ябып асрамакчы буласыңмы?

— Ата-баба күршеләрдән куркып, таш коймага бикләнеп яшәмәгән.

— Кулында кылыч барында, күршеләрдән куркып яшәү — оят! — диештеләр кайберәүләр, шаулаша башлап.

Кашларын җыерып, йодрыкларын йомарлап Алмыш хан яңадан урыныннан торды.

— Ата-баба дисезме?! — дип кычкырды ул, күкләрне күтәрерлек итеп.— Тора янганга сөенәсезме?! Койма да кирәкми, тора да кирәкми, дисезме?! Ничек телегез бара шундый сүзләр сөйләргә? Сезнең күзегез берни күрмимени, колакларыгыз берни ишетмимени? Көлгә очкан байлыгыгызны күреп йөрәгегез янмыймыни? Юк, мин уйлаган уемнан кайтмаячакмын! Әтил суын кире борып булмаган кебек, үткәнгә кире кайту юк. Ата-бабаларны без олылыйбыз... Урыннары оҗмахта булсын! Шулай да мин аларның шыр сөякләренә табынып кына яши алмыйм. Кулдагы кылычка гына да таянып яшәп булмый. Миңа кылычтан да, ук-җәядән дә, сөңгедән дә көчлерәк корал кирәк. Бармы шундый корал?

— Юк! — диде Алып-Тархан, үчекләшеп.

— Андый корал бар! — диде аңа каршы Алмыш хан.— Ул да булса — чумаклар йоласы... гарәп алласы! Менә ул нинди корал!

Агай-эне, мондый сүз ишетеп, аптырап, тынып калды. Барысы да, ханның аңлатыбрак сөйләвен теләгәндәй, аның авызына карап утыра бирделәр.

— Күрдегезме таш мәчетне? — диде Алмыш хан.— Тирә-якта барлык каралты-кура күмергә әйләнгәндә, таш мәчет бер үзе утырып калган... Утка да, кылычка да бирешмәгән. Гарәп йоласы да менә шундый. Аны румнар да, җөфүтләр дә, потлар[1] да җиңә алмый. Барлык алдынгы, көчле улуслар аллага табына. Болгар, тауга үрләргә теләсә, аллага табынырга тиеш.

— Без болай да чумаклар түгелме соң? — диде Алып-Тархан.

— Әйе, без — чумаклар, без аллага табынабыз,— диде хан, аның мыскыллы соравына исе китмичә.— Ничек табынабыз соң без? Без чынлап аллага да табынмыйбыз, тәңрене дә олыламыйбыз. Без ата-баба йоласын да аяк астына салып таптадык, чын чумак та була алмадык. Без беркемгә, бернигә инанмыйбыз. Без — урталыкта. Аннары, без күпме — ни барысы биш йөз өй. Суар аллага табынмый, бүләр табынмый,

---

[1] Потлар — монда: будда динен тотучылар мәгънәсендә.

Ямгырчы бине санамаганда Чулман шулай ук табынмый. Безнең дә аллага табынучылар — аксөякләр генә. Каралар гарәп йоласын ни дип тә белмиләр. Ырулар үзара талашкан кебек, аларның оганнары да үзара талаша. Чирмешнең — үз йоласы, арның, мукшы, буртасның — үз йоласы. Юк, болай булмый! Болгар йортның ханы бер генә булган кебек, аның күгендәге оганы да бер генә — Алла гына булырга тиеш! Безгә тәҗикләрдән, гарәпләрдән, румнардан үрнәк алырга туры килә. Бөтен ил — аксөякләр, каралар, коллар, барлык улуслар, ырулар, токымнар бер генә йолага — чумак йоласына табынырга тиеш! Менә шул турыда уйладым мин, агай-эне... туганнар...

Агай-эне, яшенле янгыр алдыннан куркышып теләсә кая качып беткән кош-корт сыман, барысы да кинәт шып булдылар. Күңелләргә мең төрле сорау килде. Бөтен Болгар йортны аллага табындырырга? Булырмы бу? Бөтен йортны! Барлык улусларны, ыруларны... ханбалыкны яндырудан да тартынмаган, күзенне йомдың исә, чокырга төртеп төшерергә генә торган ыруларны!.. Ничек итеп? Шул ук кылыч белән куркытыпмы? Үз ирекләре белән табынырга теләмәсәләр, чыннан да аларны янадан яулап алырга, янадан кан коярга, таларга, яндырырга туры килмәячәкмени? Бер үк балык башы булып чыга түгелмени?

Тирмә эче бердәм гөрләргә, шауларга тотынды.

— Әйтеп кара — ничек ирешерсең икән моңа?

— Аңлатыбрак сөйлә! — диештеләр агай-эне.

— Мин болай итәргә уйлыйм,— диде хан, тавыш басыла төшкәч.— Әйткәнемчә, мин ханбалыкны ныгытам. Моның өчен таш койма салдырам. Шул ук авыкта мин үземә буйсынган барлык ыруларга, улусларга аллага табынырга боерам. Буйсынмаган, баш бирмәгән ыруларны, улусларны соңыннан әкренләп кылыч белән дә, алла белән дә яулап алам. Боерыгым буш сүз генә булмасын өчен, бөтен Болгар йорт чыннан да үзенең абакларын, сыннарын, сарыганнарын аяк астына салып таптасын, бары аллага гына табына башласын өчен мин бер сугуда берәгәйле сукмакчы булам. «Мин йола билгәләре[1] — муллалар, мәзиннәр сорап, табындыручылар сорап туры Багдадка, хәлифәнең үзенә илче җибәрәм!

Тирмә эчендә тантаналы, киеренке бер тынлык урнашты.

— Сез тагын сорарсыз: Багдадкача илче ничек барыр, каян барыр, диярсез,— диде хан.— Мин аңысын да уйладым. Хазар каганы безне Багдадка уздырмаячак. Шулай ук Хәрәзем дә безнең юлга аркылы төшәчәк. Шулай булгач, без ачыктан-ачык мең кешелек илче җибәрә алмыйбыз. Безгә алдарга, ялганларга туры киләчәк. Безгә ничек тә Багдадка үтеп керергә, хәлифәнең үз кулына үтенечебезне тапшырырга кирәк. Моның өчен безнең илче илче булып түгел, сатучы булып, кирәк икән, теләнче булып, юлбасар булып барачак! Безнең өчен башка юл юк. Багдадка илче җибәреп мин берьюлы ике куян гына түгел, өч куян атачакмын. Миңа хәлифәнең үз илчесе килсә, башка йортлар, илләр арасында Болгарның аты бермә-бер күтәреләчәк. Болгар йорт башкалар арасына керә башлаячак, Болгар белән саплаша башлаячаклар. Икенчедән, үз кул астымдагы ыруларны, улусларны турыдан-туры хәлифә җибәргән илчеләр, табындыручылар булышлыгында аллага инандыру миңа җиңелрәк булачак. Өченчедән, Хәрәземнән яңа йола алганда, без алардан берни сорамадык. Таш мәчетләреннән башка алар безгә берни бирмәделәр. Бөтен йортымны яңа йолага күчергәндә мин үз йоламнан бушка гына аерылырга теләмим. Үз иркем белән мин хәлифәнең колы булам икән, үземнең коллыгым өчен мин түләү сораячакмын. Ул миңа ташчылар, йола белгечләре җибәрәчәк. Ул миңа, ким

[1] Билгә — галим, белгеч. Йола билгәсе — дин белгече.

дигәндә, биш мең динар акча бирергә тиеш булачак. Менә шул акчага мин таш койма корачакмын!

Хан тынып калды. Тирмә эче дә, каршы сүз әйтергә кыймыйча, тыптын утырды. Агай-энесенең эндәшмәвен килешү дип аңлап, Алмыш хан бераздан, боеручан тавыш белән:

— Багдадка илчем итеп Тәкин угланны җибәрәм. Аның белән Барыс углан да барыр,— диде.— Үзенә йөкләнгән бурычны Тәкин углан үтәп чыгарга тиеш. Шуның белән ул үзенең атасы-анасы алдындагы, барлык болгарлар алдындагы языгын җуя алыр.

## Дүртенче бүлек

### I

Элегрәк, тыныч елларда, Болгар ханы, язгы ташу кайтып, җир өсте кипшергәч тә, киң болыннар яшеллеккә күмелгәч тә, җәйләүгә чыга иде. Барлык күче, көтүләре белән, коллары, чирүе белән, үзенә буйсынган биләре, ырулары белән ул Әтил болыннары буйлап көн ягына — кояшка — җылыга таба юнәлә иде. Җәй урталарында ул Болгар йортның көньяктагы чигенәчә барып җитә иде дә көнчыгышка таба борыла иде. Аннары, Җаек суы буйлап, Урал-тау итәкләренә сугылып, ургә таба — төн ягына урли башлый иде. Җәйнең-җәй буена терлекләр яшел болыннарда утлыйлар — түл җыялар, май җыялар иде. Көзге кырпак төшүгә бөтен Болгар иле яңадан үзенең кышкы торак урынына — Чулман белән Чирмешән арасындагы болыннарга кайтып керә иде.

Элегрәк шулай иде. Соңгы елларда болай күченеп йөрүләр кыенлаша башлады. Иген игә торган, елга буйларында авыл корып, утрак тормыш белән яши торган ыруларны урыннарыннан кузгату елдан-ел авырлаша башлады. Алай гына да түгел, монарчы гел күченеп йөргән ырулар да әкренләп-әкренләп үз җирләрендә төпләнә тордылар: агачтан өйләр салып, иген игеп яши башладылар. Шулай ук базарларда сатучылар да күбәйде. Үзара яулар да, ызгыш-талашлар да күченеп йөрүләрне тоткарлый торды, я булмаса бөтенләй бозып ташлады.

Менә быел да шулай булып чыкты. Җәйләүгә чыгу турындагы уй быел ханның башына да килеп карамады. Үзенең күчмә урдасын ул янган, күмергә әйләнгән ханбалыкка якын җиргә — Өсән суының аръягына, Әтил буе болынына — иңкү, тигез җиргә корды. Бу тирәдәге яхшы болыннар барысы да ханның үз көтүлекләре, үз җирләре санала иде. Хан үзе беркая китмәгәч, аның биләре дә үз җирләрендә торып калдылар.

Алмыш хан Тәкин углан башлыгындагы яшерен илчелекне ерак юлга озатты да җиң сызганып эшкә тотынды. Каяндыр күктән төшкәнне көтеп, кул кушырып ятмыйча, кыш җиткәнче ул үз кайгысын үзе кайгыртырга булды. Ханбалыкка ул тагын тирә-яктагы балтачыларны чакыртып алды. Аларга үзенең яндырылган урдасын, коймаларны, күперләрне, капкаларны торгызырга боерык бирде. Кулына балта тота алмаган барлык ирләр урманга агач кисәргә я булмаса Ага-базарга сал сүтеп, өстән төшерелгән салкүперне сүтеп, агач чыгарырга җибәрелде. Кирәк тота алганнар ханбалыкта җир казырга, койма, ур буйларын, урамнарны янган-җимерелгән агач, таштан әрчергә калдырылды. Ханның бу боерыгы бары каралты-куралары янган, җимерелгән кешеләргә генә кагылмады — үз каралты-кураларын алар үз көчләре белән торгызырга тиешләр иде. Алар инде болай да кырмыскалар кебек күптән эшкә тотынганнар иде: кайберәүләр, кыш торыр өчен генә дип, яр буена базлар казый, кайберләре чыбык-чабыктан читән өйләр урә иде. Әзмекүпме байлыклары исән калган чүлмәкчеләр, тимерчеләр, тиречеләр,

кисмәкчеләр — шунын ише кылчылар кечкенә итеп булса да бурап агач өйләр житкерергә тырышалар иде.

Үзенең урдасыннан да, коймалардан, капка-күперләрдән дә элеграк Алмыш хан таш мәчетне төзәтергә кушты. Мәчетнең каерылган ишекләре яңартылды. Тышкы яктан ул агартылды, чылгыена көмештән эшләнгән ярым ай куелды. Җиргә, сырган төбенә йөз кеше сыярлык итеп киң түбә ясатылды. Башына ак чалма ураган, озын кара чапан кигән Бохар мәзине, ханның боерыгы буенча, төннең, көннең кайсы гына күлемендә булмасын, сырган башына менеп, бар көченә азан кычкырды.

Яудан соң Алмыш ханның чумаклар йоласына кагылышлы бар нәрсәне артыграк күрүен, мулла-мәзиннәргә элеккегә караганда да ачыграк йөз күрсәтүен болгарлар сизми калмадылар. Багдадка илче җибәрү турында ханның иң якын кешеләреннән башка беркем дә белмәсә дә, йорт башының ниндидер зур үзгәрешләр ясарга теләве турындагы имеш-мимешләр каралар арасына да үтеп керде. Кайгыдан, ачлык-ялангачлыктан башларын кая куярга белмәгән, бәгырьләре таштай каткан өйсез, җирсез кешеләр карт мәзиннең карлыккан тавышын котлары алынып тыңладылар. Янган, җимерелгән каралты-кура өстендә яңгыраган бу ят, ямьсез, аңлаешсыз тавыш аларга күктән иңгән ниндидер усал кисәтү булып, янау-куркыту булып тоелды.

Алмыш ханның караларны да аллага табындырырга, авылларда, тораларда мәчетләр, мәктәпләр салдырырга, читтән китерелгән муллалар куярга уйлавы турындагы яман сүзләр, имеш-мимешләр күптән инде йөри иде. Сырган чылгыена көмеш ай куелып, мәчет үзе төзәтелеп, мәзиннең кычкырулары ешая башлагач, бу имеш-мимешләр тагын да көчәя төште. Таш багана башына менеп, тар ярыктан муенын сузып, килмешәк карт ишәк кебек бакыра башладымы, шул тирәдә көл-күмер арасында казынып яткан каралар шундук аңа — көмеш айлы сырганга аркалары белән борылдылар, кулларын күккә сузып, төрек тәңресенең гарәп алласын Болгар җиренә якын җибәрмәвен үтенеп ялварырга тотындылар. Уттан-яудан исән калган таш багана Алмыш хан өчен изге тоелса, ата-баба йоласын бар нәрсәдән артыграк күрүчеләр өчен ул, киресенчә, явыз өрәк булып, албасты булып тоелды. Йортка килгән зур талауны алар яудан түгел, менә шул исән калган таш мәчеттән күрделәр.

Болгарда җөфүт йоласын, рум йоласын тотучылар да бар иде. Алар башлыча читтән килеп, монда утраклашып калган кешеләр. Ханның чумак йоласын артыграк күрүенә эчләре пошканга, алар, үзара ызгышудан туктап, төрек йоласы яклы караларны якынрак күрә башладылар. Күп тә үтмәде, көннәрдән бер көнне Болгар-торада бөтен кешене шаккатырган бер сүз таралды. Ниндидер кешеләр, каравылчыларны бәйләп ташлап, караңгы төндә таш мәчет төбен казыганнар, сырганны аударырга, җимерергә маташканнар. Таң алдында мәзин килеп житеп, тавыш куптармаса, чын-чынлап аударасылар икән!

Шул турыда ишеткәч тә, Алмыш хан, барлык эшен бер читкә куеп, таш мәчет янына китте. Чыннан да, таш манара төбе тирән итеп казылган, кызыл балчык өемнәре, таудай булып, ерактан ук күренеп тора. Шул тирәгә инде шактый кеше җыелып өлгергән. Таш сырганның төбе казылган килеш тә аумый торуына күпчелекнең исе киткән иде. Кешеләр, чылгый очындагы ярым айга, озынча төннекләргә бармаклары белән төртеп күрсәтә-күрсәтә, үзара гөр киләләр иде.

Ханның мәчеткә якынлашуы булды, кешеләр тынып калдылар, башларындагы бүрекләрен салып, култык асларына кыстырдылар.

— Исәнме, ил-көн,— диде Алмыш хан коры гына.

— Бик исән.

— Аманбыз,— диештеләр кешеләр дә, тыелып кына.

Алмыш хан атыннан төште, мәчет тирәсен әйләнеп чыкты, нигезнең кызыл балчык аралаш күренеп торган ак ташларына карады. Аннары җыелган кешеләргә борылды да:

— Менә, күрдегезме алланың көчен! — диде. Бу — изге багана. Җир йөзендә аны аудара алырдай берниндн көч юк. Күрәсезме, Болгар җирендә ул нинди нык утыра! Бу җирдән аны кешеләр дә, тәңре дә, албастылар да — беркем дә кузгата алмаячак. Бүген төнлә качып-посып шушы изге җирне казучылар бөек аллага каршы кул күтәргәннәр. Белексезләр, күтәргән кылычларының үзләре башына төшәчәге турында алар уйлый алмаганнар. Угрылар барыбер тотылачак. Аларга кызгут[1] ясалачак!

Кешеләр, «кызгут» сүзеннән котлары алынып, аһылдап җибәрделәр. Ирексездән күзләр күккә текәлде, куллар югары күтәрелде. Аларның күбесе, ханны да онытып, көмеш айга аркалары белән борылдылар. Алмыш ханның йөзе бозылып китте.

— Тезләнегез! — диде ул, бар көченә кычкырып.

Кешеләр, кан калтырап, манара ягына борылдылар, чапкан үләндәй җиргә егылдылар, барысы да бер авыздан, җирәнеп, котлары алынып:

— Алла! — дип кычкырып җибәрделәр.

— Моннан ары сез алла ялчылары,— диде хан.— Күккә, тәңрегә, абакларга табынган кешеләрне яшен сугачак!

Тып-тын калган төркем арасында мышык-мышык елаган, үксегән тавышлар ишетелде. Тигез итеп киселгән, шомартылган ак ташлардан өеп мендерелгән очлы багана, үз аяк астындагы җир кортларының кайгысына, елау-сыктавына әз генә дә исе китмичә, канлы ярадан төртеп чыккан сөңге башагыдай, казылган җир янында котны алып басып тик торды.

## II

Алмыш хан мәчет яныннан Ага-базарга китте. Янган торадан ераклашкач та аның уйлары йола, тәңре, алла кайгыларыннан арынып, базар кайгыларына, акча кайгыларына күчте. Бу арада базар, акча кайгылары аны йола кайгыларыннан бер дә ким борчымады. Үз көче, үз кешеләре белән генә урданы, койманы яңадан торгыза алырмы ул? Барысын да яңа баштан корыргамы, элеккедән дә нык итеп, яхшы итеп корыргамы, әллә соң әлегә күп көч түкмәскәме? Тәкин угланның юлы унып, уйланган уйлар тормышка ашырылса, соралган акча белән соралган кешеләр килеп җитсә, күпме байлык, күпме көч янга калачак!

Әйе. Тик шулай да хәлифә акчасы — күктәге торна шул! Ярый әле Чулман буеннан алып кайткан тиренең күбесе исән калган. Аны быел ук сатып җибәрергә туры киләчәк. Агач менә кыйбатланды. Икеләтә кыйбатланды. Яу килеп, яндырып киттеме, салчылар шундук комсызлана башлыйлар. Сычканга — үлем, мачыга — көлке. Болгар янса, арга, чирмешкә җылы, ар, чирмеш янса,— болгарга җылы.

«Ашлык та исән калган»,— дип уйлады Алмыш хан, яңадан базар кайгыларын исенә төшереп. Чокырлардагы богдай, тары, арпа шул көе. Озакламый яңа ашлык житә. Шуңа чаклы сатып калганда яхшы булырые да, каян табасың аңа акчалы ач тамаклар? Үз ачларыңа таратудан ассу юк.

«Тагын нәрсәне сатарга була соң?» — дип уйлады ул бераздан. Чулмәк савыт-саба ватылып беткән. Бал аз. Байлык эзләп, суарларның үзләренә яу чабаргамыни? Әллә төн кешеләре ягына юл тотаргамы? Мондый чакта анда ничек үтеп кермәк кирәк?! Ах, каян табарга күп,

---

[1] Кызгут — күргәзмә хөкем; халык алдында ясала торган суд процессы.

би-ик күп акча! Ходаем, ник юлыма чыгарып куймыйсың тирмә зурлыгындагы чүлмәк белән алтын-көмеш?!

Йөрергә чыкканда ханны беркем дә озатмый да, сакламый да иде. Үзенә кирәк җиргә ул үзе йөри иде. Кирәк икән — көтүчеләр янына бара, кирәк икән — балыкчылар, игенчеләр янына бара, базарларга сугылып чыга иде. Көне буена диярлек тирмәдә кешеләр белән булып арыгач, ул, атына атланып, тузанлы юлдан, я булмаса яшел болыннардан үз алдына уйланып барырга ярата иде.

Менә ул, ачык, кояшлы җирне үтеп, тын, күләгәле нарат урманына килеп керде. «Әллә шушы наратларны гына кисеп аударыргамы соң?» — дип уйлады ул, биек, төз агач башларына караштырып. «Юк,— диде ул аннары, үз-үзенә каршы килеп.— Ханбалык янындагы урман — тере койма ул. Ярамый. Үзең утырган ботагыңны үзең чабу кебек булачак».

Шул чакны алда, куе агачлар артында, майланмаган арба шыгырдавы ишетелде. Комлы урман юлыннан үргә таба, тырышып тарта-тарта, мышный-мышный, атлар менеп килә иде. Иөгертмәле арбаларга озын наратлар сузып салынган. Агачлар, күрәсең, әле яңарак кына судан чыгарылган — аларның кабыклары карайган, ләмгә, комга буялган, ә арба артларыннан пычрак су тамып бара.

Атларга юл бирү өчен Алмыш хан читкә чыкты, көтеп тора башлады. Йөкчеләр, аның турысына җиткәч, бүрекләрен салдылар, исәнлек-саулык сораштылар, туктамыйча, атларын куа-куа, югары менеп киттеләр. Алмыш хан, унлап йөкнең барысын да уздырып җибәрде дә, иң арттан ашыгып атлаган урта яшьләрдәге бер аксак ирне туктатып:

— Каеклар белән кемнәр килгән анда? — диде.

— Урыслар килгән, хан,— диде аксак ир, башындагы бүрегенә тотынып.

— Урыслар дисеңме? Ниткән урыслар? Урыс-улакмы, сатучылармы? — диде хан, чиктән тыш бер кызыксыну белән.

— Сатучылар, хан. Тыныч күренәләр.

— Иртәгә ташып бетерерсезме? — диде хан, сүзне икенчегә борып.

— Бетмәс,— диде йөкче.— Арбалар җитми.

— Бар, юлыңда бул,— диде хан, кулын селтәп.— Анда арба җитми, монда кеше җитми. Нишләргә дә белмәссең.

— Хан, туктале,— диде йөкче, ханның кузгалып китүен күреп.— Мин — Сатылмыш балтачы булам.

— Беләм, ни йомыш? — диде хан, борылып.

— Без анда үзара сүз көрәштердек. Син шушы сулы агачлардан койма коярга, багана кагарга боергансың, имеш? — диде Сатылмыш балтачы.

— Боерса? Шуннан?

— Бу килеш багана утыртырга ярамас, хан. Баганаың җиргә күмеләсе башын нәни генә җандырганда җакшы булырые. Алай ул черемн. Сурыккач агач җакшы яна. Күрәсең ич — чи, сулы.

— Син әллә агач сурыкканчы көтәргә киңәш итәсеңме? — диде Алмыш хан.

— Юк,— диде Сатылмыш балтачы.— Син башта баганалар кагарга, койма коярга боергансың түгелме соң?

— Мин алай боермадым,— диде хан.— Мин койманы да, өйләрне дә кыш җиткәнче өлгертергә боердым. Башта койма коярга, баганалар утыртырга Чүти балтачы әйтте.

— Ә-ә! Шул шул! — диде Сатылмыш балтачы, куанып.— Чүти балтачы гел шулай үзенчә мәтәштерергә ярата.

— Син соң ни киңәш итәсең, Сатылмыш? — диде хан, кызыксына төшеп.

— Мин шуны киңәш итәм, хан,— диде Сатылмыш балтачы, үрһ менеп җиткән атына карап алып.— Иң элек бурага тотынырга кирәк Баганаларны да юна башларга була. Башын яндырмый утыртмаска — шул минем киңәш.

— Ярар, шулай эшләгез,— диде хан, килешеп.

«Димәк, урыслар килгән,— дип уйлады ул, Сатылмыштан аерылгач.— Биш-алты ел инде күренгәннәре юк иде. Карап карыйк, ни белән, нинди уйлар белән килделәр икән».

### III

Этил яры буена урнашкан Ага-базар яудан исән калган иде. Суарлар, ханбалыкны талау, яндыру белән булашып, куе урман артындагы базарга килеп җитә алмаганнар иде. Юкса, талар, яндырыр өчен монда байлык та, каралты да җитәрлек иде. Ага-базар бөтен Этил, Чулпан буенда, Хазар йортның ханбалыгы Итил-торадагы базарлардан кала, иң зур базар санала иде. Бөек Этил, язгы боздан әрчелеп, яңадан боз белән капланганга тикле монда җир йөзенең барлык якларыннан, каекларга утырып, төрле ил сатучылары килә иде. Базар монда язын-җәен, көзен генә түгел, кыш көннәрендә дә тукталып тормый. Болгар йортның бу атаклы базарында күңелең ни тели, шуны алырга, күңелең ни тели, шуны сатарга була.

Күләгәле, талгын урманнан Алмыш хан кояш яктысы белән тулы яланга килеп чыкты. Калкулык итәгеннән үк, калын урман яныннан ук яшел болын башланды. Болын аша, ярты чакрым чамасы ераклыкта, Ага-базарның каралты-куралары калкып күренде. Агач өйләрнең, кибет, кураларның күбесе, бер-берсенә сыенып я булмаса бер-берсеннән бик нык читләшеп, оя-оя булып, төркем-төркем булып, Этил буена ук утырганнар. Болайрак исә, иркен болын ягында, киез тирмәләр, киндер чатырлар тезелеп киткән. Шунда ук, тирмә-чатырлар белән аралашып, терлек өчен киртәләп алынган утарлар, биек коймалар тырпаеп утыра.

Эреле-ваклы өйләр, куралар, чатырлар ягыннан, киртә-коймалар ягыннан күңелне җилкендергеч бер гөрелте — бары базарларда гына, кеше күп урыннарда гына була торган тынгысыз гөрелдек ишетелеп тора иде. Арырак, сул якта, урман буендагы утарларда җирне-күкне тетрәндереп бога үкерә; аннан да арырак, ярга якынрак төштә сал чыгаручыларның күмәкләшеп, үзләренә көч биреп, өзек-өзек итеп кычкырулары ишетелә иде.

Алмыш хан, тузанлы тар тыкрыкларны узды да, базар уртасына кереп тормыйча, атын туры яр буена борды. Яр буенда, тамга өендә аны базар башы Бигеш каршылады. Симез, шадра битле, зур корсаклы Бигеш Алмыш ханның туганнан туганының туганы иде. Төрле кеше белән эш итеп өйрәнгән, шомарган, каешланып беткән базар башы көчлеләр алдында төлкегә әйләнә, көчсезләр алдында бүрегә әйләнә белә торган астыртын, сак, комсыз бер кеше иде. Алмыш ханны күрү белән ул тиз генә бүреген салды, җиргә егылды.

— Урыслар килдемени? — диде Алмыш хан, яр астындагы ят каеклар ягына ымлап.

— Килде, ханым,— диде Бигеш, мышнап, аягына басмакчы булып.

— Тор,— диде хан, аның ингегүен күреп.— Ник килгәннәр? Кая юл тоталар?

— Туры безгә килгәннәр, ханым,— диде Бигеш, хан атының тезгенен тотып алып.

Алмыш хан атыннан төште, өстен-башын каккалап алды. Бигеш төзгенне үзенең бер кешесенә тоттырды да, иелә-бөгелә, ашыгып, басмага атлады. Хан белән икәүләп алар яр астына төштеләр.

Ханның боерыгыннан башка ярга чыга алмаган, шуңа күрә аның килеп житүен түземсезлек белән көтеп торган урыслар хан белән Бигешне күрделәр дә каек кырыйларына жыела башладылар.

Яр буена барлыгы егермеләп каек туктаган иде. Аларның барысы да күпер читенә үк килеп житкәннәр, тик берсеннән дә ярга басма ташланмаган иде.

Алмыш хан белән Бигеш күпернең уртасына житмичә туктап калдылар. Беренче каекның борын өлешендә басып торган урысларның берсе, бүреген салып, билен бөгеп, хан белән исәнләште дә аңа котлау сүзләре әйтте.

— Суздал [1] кенәзе Родославның илчесе... бертуган инесе Святослав сатучы бөек Булгар юртның башы Алмыш ханга исәнлек-саулык, байлык тели, күп яшь тели! — диде урыс.— Иленә-юртына тәңри көч, байлык, тынычлык бирсен, хан!

— Синең туганыңа да, синең үзеңә дә шуны ук телим,— диде хан, урыс кенәзенең илчесен караштырып.

Ул яшь нарат кебек төз, таза буйлы, киң күкрәкле иде. Аның жил кискән кырыс битен жирән сакал-мыек баскан. Ул үзе генә түгел, аның артындарак басып торган юлдашлары да яшьләр, тазалар, озын буйлылар. Өсләренә тунга да, күлмәккә дә охшамаган ниндидер кыска кием кигәннәр. Жиңсез ул киемнәрнең озынрак булган сул як итәге ирләрнең сул як ботларын каплап тора. Киемнең уң як итәге исә кыскарак иде. Уң кулларына алар озын туры кылыч — бычкы тотканнар, бил каешларына — балта белән пычак такка괄ннар. Таза беләкләренә, шәрә күкрәкләренә, ботларына аларның төрле чәчәк, үт-үлән, киек бизәкләре төшерелгән иде.

— Ни алып килдең? — диде хан.

— Илле баш кол, ун меңнән артык тире,— диде илче-сатучы Святослав.

— Төшер басманны,— диде Алмыш хан.

Каектан күпергә басма суздылар, аркан ташладылар. Хан белән Бигеш каекка менгәндә, басманың бер башыннан урыслар, икенче башыннан болгарлар тотып торды.

Суздал кенәзе Родославның бер туган энесе Алмыш ханга үзенең ярлыгын күрсәтте, битек бирде. Хан, сургычны ватып, битеккә күз төшереп алды да, яшь урыска борылып:

— Күрсәт таварыңны,— диде.

## IV

Беренче каектагы коллар кызлар иде. Озын буйлы, житендәй аксыл чәчле яшь кызлар барысы да таза, чибәр иде. Тик ерак юл килгәнгәме, әллә инде бик үк яхшы ашамаганга, алар шактый сулыкканнар иде. Аларның төпкә баткан күзләрендә, кипшергән яшь, сылу ирен читләрендә йончылганлык билгесе күренә иде. Өсләренә иске-москы гына киенгән, ярым шәрә дип әйтерлек бу кызлар каекның аскы катындагы утыргычларда тезелешеп утырганлар иде. Шунда ук идәндә, аларның аяк астында, богадай таза, яшь бер ир кеше, мышный-мышный, соңгы кат үзенең сөяркәсен әвәли иде. Аның бу эшен утыргычтагы кызлар да, көрүчеләр дә, әйтерсең, бөтенләй күрмәделәр дә. Алмыш ханга астагы кызның битен-йөзен күрсәтергә кирәк булгач, урыс сатучысы әлеге ирнең арт санына берне тибеп алды. Ир кеше ярсып шундук билендәге пычагына тотынды, башын калкыткандай итте, як-ягында кораллы ирләрне күреп, үз телендә нидер мыгырданып алды.

---

[1] Суздал — X гасырда Болгар күршесендә нинди дә булса рус шәһәре яисә рус кенәзлеге булуы билгеле түгел. Идел белән Ока елгалары арасындагы Ростов-Суздаль кенәзлеге бары XI гасырда гына барлыкка килә. Монда анахронизм.

— Моңысы яхшырак, миңа булыр,— диде хан.

— Булыр, хан,— диде сатучы, килешеп.

Әлеге чибәр кызга ул нидер әйтте. Кыз теләр-теләмәс кенә урыныннан торды, өстендәге сәләмәләрен селкетеп, баскычка таба атлады. Алмыш хан аның артыннан карап торды да, кулын селтәп:

— Юк! — диде.— Әллә чирле, әллә бетәшкән... Ач тоттыңмыни?

— Алар барысы да шундый, хан,— диде сатучы, уңайсыз елмаеп.— Үкенмәссең, мунысы яхшы.

— Ач тоттыңмыни? — диде Алмыш хан, соравын кабатлап.

— Мин ач тотмадым,— диде сатучы, көрсенеп.— Урыста ачлык. Былтыр иген уңмады. Аннан суң юлбасарлар күбәйде. Ачлык илдә, ачлык, хан. Агам кенәз Родослав сиңа кюп бюлякляр җибәрде. Алары бер каек. Кая илтергә буерасың, хан?

— Урдага илтерсең,— диде Алмыш хан.

— Бюляк белән бергә агам кенәз сиңа зур үтенеч юллады,— диде урыс илчесе.— Муңарчы без синең белән тату яшядек, мундан соң да тату яшяргя язсын, диде.

— Мин сезнең белән тату яшим — сезнең юлбасарлар гына миңа тынгы бирми,— диде Алмыш хан, шелтә белән.

— Муннан биш ел илек булган яуда Суздал кенәзенең языгы юк, буюк хан,— диде кенәз энесе Святослав.— Алар юлбасар улакчылар. Алар безгә дә тынгы бирмиләр. Суздал кенәзе юлбасарлар белән туган түгел.

— Беләм, беләм! — диде Алмыш хан, кулын селтәп.— Ул юлбасарлар арасында өч меңе Суздал кенәзе ирләре булганлыгын да беләм.

— Анысын мин белмим,— диде илче тыйнак кына.

Алмыш хан усал гына көлеп куйды.

— Кирәк чакта сез берни белмисез,— диде ул.— Ник алайса бишалты ел буена Урыстан Болгарга бер каек та килмәде?

— Синең ачуыңнан куркып, хан,— диде илче-сатучы.— Иелгән башны кылыч чапмый. Безгә ашлык киряк. Ачтан кише кырыла.

— Ашлык кирәк? — диде Алмыш хан.— Әйдәле, башка товарларыңны карыйк.

Алар басмадан ярга төштеләр, икенче каекка менделәр. Бу каекта ир коллар иде. Алар да каекның аскы өлешендә тезелешеп утырганнар. Боларның аякларына тимер богау салынган. Ирләр дә, күрер күзгә яшь, таза күренсәләр дә, ачлар, йончылганнар иде. Хан, бармак белән төртеп, колларны санап чыкты да тазарак ике колны үзенә алды. Мондагылар белән эшне бетергәч, алар бүтән каекларга менделәр, колларны, тиреләрне берәм-берәм санап чыктылар. Ханның теркәүчеләре тамгалыкка алынган товарларны санап, язып, теркәп бардылар, теркәлгән берен алып китә тордылар. Санау, язу, теркәү эшләре беткәч, урыс сатучысына Болгар җирендә сату итәргә ал тамгалы ярлык бирелде.

— Иртәгә урдага килерсең,— диде хан кенәз энесенә.— Шунда ашлык турында да сөйләшербез.

Алмыш хан, атына атланып, шау-шулы базардан салчылар янына китте. «Бирермен дигән колына чыгарып куяр юлына», дип уйлады ул эчке бер куаныч белән. Чокырларда тулып-артылып яткан ике-өч еллык ашлыкларны кая куярга белмичә, әлерәк кенә пошынган иде түгелме соң? Менә алучы да табылды. Күктән төшкән кебек булды бу!

Салчылар янына барып җиткәнче ханның күңеле күтәренке булды. Юлда йөкчеләр аңа күңелсез күү әйттеләр: балтачы Кабанны сал басты, диделәр.

— Ничек... кайда басты — судамы, җирдәме? — диде Алмыш хан.

— Сал сүткәндә, суда,— диделәр йөкчеләр.— Ярга чыгардык. Аяк сузды.

— Өйләнгәнме, балалары бармы? — диде хан.

— Яшь җегет ирде, хан,— диделәр йөкчеләр, кайгырышып.

— Урыны оҗмахта булыр,— диде хан, күккә карап.

Салчылардан соң ул яңадан торага әйләнеп кайтты, ташылган агачларны карады, ур төбен, янган койма, капка урыннарын тазартучы кешеләр янында булды. Шуннан соң ул тагын таш мәчет ягына борылды.

Мәчет янында ханны симерә башлаган яшь Бохар мулласы каршылады.

— Чокырны күмдерергә ирде, ханым... тиз кирәкте...— диде ул, ак, симез кул аркаларын сыйпаштырып.

— Күмдерергә? — диде хан, исе китеп.— Син үзең кирәк тота белмисеңмени? Ир кешеме син, сабыймы?

— Мин... кирәк тотып? — диде мулла, коты алынып.

— Мәзин белән икегез...— диде хан.— Бер кирәкне ничек тә күтәрә алырсыз. Алай изгелеге күп булыр.

— Б-баш өсте, х-ханым,— диде мулла, ашыгып, баш иеп.

## V

Болгар-тораның яндырылуы, талануы күп санлы ярлылар өчен мәңге төкәнмәс кайгы булса да, Алмыш хан өчен көтмәгәндә, әйтерсең, куанычка әйләнде. Урысларга ул ике йөз батман богдай сатты. Шуның өстенә Урыс җирендә биш ел буе тамгалыксыз ашлык сату өчен кенәзнең энесеннән ярлык алды. Соңгы елларда Болгар белән Урыс арасында сату-алу эшләре тукталып тора иде. Моннан соң инде болгар сатучылары берниндн тоткарлыксыз, берниндн тамгалык түләмичә, Этилнең иң югары тармакларынача үтеп керә алачаклар. Сатучылар, Урыс җирендә кенәзгә тамгалык түләмәсәләр дә, ярлык өчен монда Алмыш ханга кулбау [1] түләячәкләр! Димәк, ханның чокырына [2] өстәмә байлык агылачак! Берәр елдан, юлы уңып, Тәкин углан кайтып төшсә... көмеш дирһәмнәр, алтын динарлар тутырылган капчыкларын чылтыратып, Багдад илчеләрен ияртеп... У-у, бүресе улаячак ул чагында Алмыш ханның!

Йорт башының Урыс илчесе белән килешүен Болгар сатучылары икенче көнне үк белеп алдылар. Белделәр дә, ашыгып, бер-берсен уздырырга тырышып, Алмыш хан тирмәсенә агыла башладылар. Ярлык өчен хан уннан бер өлеш кулбау сорады. Сатучылар аптырый калдылар, ык-мык иттеләр, кайберәүләр каршы да килеп карады — ник дигәндә, чит илләрдә сату-алуга ирек бирә торган хан ярлыгына беркайчан да алай күп түләнелми иде. Еш кына алар уннан ярты өлеш, күп булса, йөздән алты өлеш түлиләр иде.

— Мин сездән дә алмасам, янган ханбалыкны ничек торгызырмын? — диде хан аларга.— Йөкнең авырын болай да мин тартып барам. Сез дә тартышыгыз — җиңелгә туры килер.

Сатучылар хан белән артык сатулашып тормадылар. Күршеләрдә ачлык! Мондый җай гел булмый!

Шулай итеп, сатучылар бер-бер артлы куна тордылар, хан кулыннан ал тамгалы ярлыкны ала тордылар. Шулай итеп, ханның чокырына байлык агыла башлады. Шулай итеп, кайгы көтмәгәндә куанычка әйләнде.

Шушындый көннәрнең берсендә Алмыш ханның күңеленә юш килгән тагын бер яңалык булып алды. Таш мәчет төбен казучыларны

---

[1] Кулбау — процент.

[2] Болгарлар ашлыкны чокырларда саклаганнар. Чокыр монда байлык җыю урыны мәгънәсендә кила. Халык телендә бүгенге көнгә кадәр: аның чокыры тулмас (тула белмәс), дигән сүз сакланып калган. Ягъни: комсыз кеше байлык җыюдан беркайчан да туктамый дигән мәгънәдә.

эзләп табарга дип үзенең шымчыларына каты боерык биргән булса да, шымчылар, бик тырышып эзләүләренә дә карамастан, турыдан-туры языклы беркемне дә тота алмаганнар иде. Аның урынына, көтмәгәндә икенче бер угрый табылды. Аны аллага, мәчеткә, Алмыш ханга тел тидерә, диделәр. Аның мәчет төбен казуда турыдан-туры катнашы бармы-юкмы икәнлеген беркем дә анык кына әйтә алмады, шулай да аның тотылуы башка угрыларга булган ачуны басу өчен, яңа йолага каршы килүчеләрне куркыту өчен бик тә ярап куйды. Бу угры турында ханга Турай чәчән килеп әйтте.

— Аның коткы сүзләр сөйләгәнен мин үз колакларым белән ишеттем, ханым,— диде Турай чәчән.— Кирәк булса, мин таных була алам. Шулай да мине таныклыктан коткарсаң яхшы булыры. Мин башка таныклар табармын.

— Кем ул угры? — диде хан.

— Ул — Бәкәч чәчән,— диде Турай.— Җиңү туенда синең ягыңны мактап кошуг әйткән...

Алмыш ханның йөзе үзгәреп китте. Тотыш угланның батырлыгына чын күңелдән сокланган булса да, аның Койтым бикә углы икәнлеген белгән булса да, җиңелүчене мактап кошуг әйткән белексез чәчәнне ул берничек тә оныта алмады. Аның күңеленә ул чәчән агулы ук булып, яман шырпы булып кадалып калды. Ул аны бөтен күңеле белән яратмады. Ул аны Тотышны мактаганы өчен түгел, бөтенләй икенче нәрсә өчен — аны — ханны олыламавы өчен, үзен шундый бәйсез, иркен тотуы өчен яратмады бугай.

Кызгут өчен ханга шундый кеше кирәк тә иде. Турай чәчәнгә ул бер уч бакыр ярмак бирде.

Шул ук көнне Бәкәч чәчәнне кулга алдылар, тоткынга[1] ябып куйдылар.

Өченче көнне төштән соң, хан урдасыннан бераз читтәрәк, киң языда кызгут булды. Языны бар яктан да кораллы ирләр уратып алды. Кешеләрне уртага капка сыман итеп калдырылган ачыклыктан керттеләр. Кызгут буласы алдан билгеле булганга, кеше бик күп килде. Атларга атланып ерак болыннардан көтүчеләр килде, авыллардан игенчеләр, Ага-базардан сатучылар, базарчылар, чит ил кешеләре килде. Алмыш хан языга караларны бернинди тоткарлыксыз кертергә боерды. Кызгут, аксөякләрдән бигрәк, ярлы-ябагай өчен, каралар өчен эшләнелә иде.

Менә язы читенә хан җаважы да корылды. Шунда ук, җаваж каршысына тәгәрәтеп имән бүкән китерделәр. Биленә күн алъяпкыч бәйләгән, кара куллы, кара сакаллы тимерче учагына ут дөрләтеп җибәрде, шалтыр-шолтыр килеп, бик эшлекле кыланып, кыскычларын, чүкечләрен, өткеч безләрен бер урыннан икенче урынга күчергәләде.

Кешеләр җитәрлек җыелгач, җаважына Алмыш хан кереп утырды, аның хатыны, балалары, туганнары килде. Хан белән, ханның туганнары белән бер үк авыкта диярлек языга угрыны да алып керделәр.

Аның куллары, артка каратып, аркан белән бәйләнгән иде. Арканның бер очын арттан атлап килгән кораллы ир тоткан иде. Башында бүреге булмаганга, аның озын кара чәчләре маңгаена, иңбашына таралып төшкән. Куркуыннан, төнне йокысыз уздырудан аның болай да ак йөзе тагын да ныграк агарып, төссезләнеп калган иде. Үз-үзен нык тотарга тырышса да, ул, исерек кеше сыман, алпан-тилпән атлый иде.

Кемгә кызгут буласын кешеләрнең күбесе белми иде әле. Алар бары мәчет сырганын аудармакчы булган, яңа йолага, аллага тел тидергән ниндидер угрыны тотканнар, дип кенә ишеткәннәр иде. Куллары аркан белән бәйләнгән яшь кенә, бала сыман гына егетне — Бәкәч чәчәнне

[1] Тоткын — монда төрмә мәгънәсендә.

күреп, барысы да таң калдылар. Шулмы угры? Шулмы таш мәчетне аударманчы булган? Соң аның думбырадан башка нәрсә тотып карагы да юктыр!

Кешеләргә күрсәтеп аны дүрт тапкыр түгәрәк әйләндерделәр. Шуннан соң аны хан каршысына — ачык җиргә алып килделәр, кулын чиштеләр. Язгы зур булганга, кызгутны яргучы[1] түгел, хан үзе алып барды.

— Әй, син, ярлы чәчән! — диде хан яшь егеткә.— Атың кем, атанапаң, ыруың кем? Әйт кычкырып, ишетерлек булсын.

Бәкәч эндәшмәде, куркынган, котсызланып калган күзләрен әрлебирле йөртеп, як-якка чайкалгалап тик торды. Ул, ахрысы, үзен монда ни өчен алып килүләрен дә аңлап житкерми иде. Хан соравын тагын кычкырып кабатлады. Яшь егет, кемнең дә булса үзенә булышуын, ханның сүзләрен аңлатып бирүен үтенгән сыман, артына, як-ягына борылып карады. Артта да, алда да, як-якта да мөңләгән күзләр, очлы кораллар күреп, ул тагын да ныграк бөрешеп калды.

— Д-д-д...— диде ул, нидер аңлатмакчы булып.

Аның янына яргучы килде, аның ни әйтергә теләвен белмәкче булды. Бәкәч чәчән, бармакларын думбыра чирткәндәге кебек чиртеп, үзенең уен коралын сорады. Яргучы аңлап алды. Тиз арада яшь егеткә аның думбырасын китереп бирделәр. Бәкәч чәчән күз алдында үзгәреп китте. Салынган башын югары күтәрде, тар күкрәген киерде дә, күзенә төшкән чәчләрен артка сыпырып куйды, думбырасын жайлап тоткан килеш, орышка җыенган алып сыман, Алмыш хан ягына тынгысыз бер күз карашы ташлап алды.

## VI

— Атым минем Бәкәч булыр,
Атам — Ала Серкәч булыр,
Туган ыру — Куян-Колак,
Туган урыным — Тирән Болак.
Туган илем — Бөек Болгар,
Әйтче, ханым, ни кирәк? —

диде чәчән, думбырасын чиертеп.

Аның карлыккан тавышы башта бик көчсез булып чыкты, аннары ныгыганнан-ныгый барды, бит алмаларына кызыллык йөгерде, тынгысыз күзләре, тере очкыннар чәчеп, як-якка йөгергәләп торды. Аның сүзләрен язудагы кешеләр тын да алмый тыңлап тордылар.

— Аңлашылды,— диде Алмыш хан.— Ала Серкәч углы Бәкәч чәчән, синең язгың зур, син угрылыкта тотылдың. Сиңа менә кызгут ясала. Әйт кычкырып, якчыларың бармы, таныкларың бармы?

— Якчыларым — жыруларым,
Таныкларым — ыруларым,
Олуг Тәңре мина юлдаш,
Әйтче, ханым, ни кирәк?

— Сине угрылыкта тоттылар,— диде Алтмыш хан, яшь егетнең кыюлана баруына үзенең ургалүен сизеп.— Син, аллага тел тидерә торган жырулар жырлап, илне-көнне котыртып йөрүең генә житмәгән, Болгар йортының башы — хан табына торган таш мәчетне аударманчы булып, аның төбен казыгансың. Син аллага, ханга каршы кул күтәргәнсең! Шул синең язгың Ала Серкәч углы Бәкәч чәчән. Инде әйт — турә буенча яргулыйммы, йола буенчамы?

Бәкәч чәчән, ханның әйтеп бетерүен көтәр-көтмәс, кызып, жилкенеп такмакларга тотынды:

---

[1] Яргучы — хөкем итүче.

— Ташлаган язгын — авыр,
Итәсең башымны син хур,
Тик шуны бел, олуг ханым,
Булмадым, булмамын угыр!
Куанычым — җыруларым,
Юанычым — җыруларым,
Кайгырганым — ил кайгысы,
Табынганым — бөек Тәңре!
Уйлап кара үзең, ханым:
Җир казучы мин түгелмен,
Җир сөрүче мин түгелмен —
Таза куллы, көчле куллы
Чура эшли ул эшләрне.
Минем коралым — думбыра,
Минем корал — бармакларым.
Ничек итеп таш мәчетне
Думбырамән аударалыйм?!
Алла, дисең, мәчет, дисең,
Баганага табынасың,
Читне уйлап юанасың,
Боздың тәңрегә антыңны,
Пычраттың изге атыңны,
Кем син үзең, олуг ханым?!

— Булды! — диде хан, кулын күтәреп.
Яшь егет аның ачулы сүзләрен әллә ишетте, әллә ишетмәде, әллә инде, күңелендә ташыган ярсуын тыя алмыйча, күзен дә йоммыйча, кайнарланып кошуг әйтүендә булды:

— Тәңрегә син кул күтәрдең,
Йолага син лач төкердең,
Мин түгел языклы, ханым,
Син ул, син иң явыз угры!

— Җитте! — дип кычкырды хан, аягүрә басып.
Аның тавышыннан кешеләрнең йөрәкләре кинәт туктап калгандай булды, тамырлардагы каннар, әйтерсең, бозга әйләнде. Барысының да башлары ирексездән түбән иелде. Бары тик яшь чәчәннең генә башы бөгелмәде. Усал елтыраган куркусыз күзләрендә аның кыю очкыннар чәчрәде. Ул бары бераз тотлыккандай гына итеп торды, аннары, тиз арада исен җыеп, кем дә булса авызымны килеп томалаганчы дигәндәй ашыгып, әле төркемгә, әле ханга карый-карый, ялкынлы җыруларын такмаклауда булды:

— Куркасың минем җырудан,
Куркасың минем торудан.
Беләм, мине астырырсың,
Я булмаса кистерерсең.
Тик шуны бел, явыз угры,
Асалмассың җыруымны —
Андый көч юк бу ажунда!
Төкерәмен баганаңа!
Төкерәмен сакалыңа!
Үкенмимен, кайгырмыймын
Астырсаң да, кистерсәң дә,
Тик яшәсен илем-көнем,
Тик яшәсен туган җирем.
Очармын тәңре катына.
Сиңа тамуг — явыз угры!

Түземлеге төкәнгән Алмыш хан, «авызын томалагыз!» дигәнне аңлатып, сакчыларга кул изәде. Сакчыларның берсе шундук зур көчле кулы белән җыручының авызын каплады. Бәкәч чәчән, нидер әйтмәкче булып өзек-өзек өннәр чыгарды да, кулыннан думбырасын төшереп, кинәт тынып калды.
— Менә, тыгылдымы тамагың, пычрак каргасы! — диде Алмыш хан, усал кеткелдәп.

— Юк, сандувач! — дип кычкырды шунда кемдер төркем арасыннан.
Тораташтай катып калган кешеләр тетрәнеп киттеләр, барысы берьюлы диярлек әлеге тавыш килгән якка борылып карадылар. Тик беркем дә ул кыю кешене күрә алмады.
— Күктән килде! — дип кычкырды кемдер, көчәя барган гөрелдекне күмеп.
Барысы да — сакчылар да, каралар да, аксөякләр дә, борын-борыннан килгән, өйрәнелгән бер омтылыш белән, күз карашларын күккә юнәлттеләр. Алай гына да түгел, Алмыш хан үзе дә, башкалар кебек, билгесез бер көчкә буйсынып, ак болытлар йөзгән төпсез зәңгәр күккә карады. Төрек йоласы буенча, күккә карау ул тәңрегә ялваруны аңлата иде.
— Тынлагыз! — дип кычкырды Алмыш хан, бөтен языны яңгыратып.
Менләгән күзләр янадан түбән иелде, әле генә канатланып алган йөрәкләр янадан уч төбенә йомылды. Күз алдында үткер сөңге башаклары, кылычлар ялтырап күренде.
— Инде әйтегез: Ала Серкәч углы Бәкәч чәчән аллага, ханга тел тидердеме? — диде Алмыш хан, төркемгә карап.
Беренче булып Турай чәчән кычкырды:
— Тидерде, ханым! — диде.
— Ул гына ишеткән, без ишетмәдек,— диде шунда төркем арасыннан бер усал теллесе.
— Мин дә ишеттем!
— Без дә...— диештеләр Турай чәчән янындагы ниндидер шома, сәләмә кешеләр.
— Тидерде, тидерде! — диделәр икенче яктан тук йөзле, яхшы киемлеләр.
— Син... Ала Серкәч углы Бәкәч чәчән, алла каршында, хан каршында языклысың,— дип кычкырды Алмыш хан, бераз тынып торганнан соң.— Синең телең озынайган. Түрә буенча синең телең төбеннән үк кисеп ташланырга тиеш. Әй, болгарлар, белегез: кем дә кем тагын да йорт башы, аның күче табынган бөек аллага, чумак йоласына тел тидерә... кул күтәрә... кем дә кем ханга, түрәгә, биләргә каршы тел озайта, кул күтәрә, аңа да менә шулай кызгут ясалыр. Минем боерыгым җиренә житкерелергә тиеш!
Язы өстендә шылт иткән тавыш та ишетелмәде. Бары тик зур, кара куллы тимерченең тырышып-тырышып күрик басканы да, утлы күмергә озын саплы кыскыч күмгәне генә бу тынлыкны бозды. Кешеләрнең борыннарын ярып, тимерче учагы ягыннан көйгән ит исе килгәндәй булды.

## VII

Яңа урында Тотыш өчен хан урдасының читендә аерым тирмә кордылар. Шунда ук, аның янына, кечерәк тирмәгә Торымтай урнашты. Торымтай аңа ашарга пешерде, аның вак-төяк йомышларын башкарды. Тотыш беркая чыкмады, беркем белән аралашмады. Ул әлегә үзен монда ничек тотарга да, нәрсә эшләргә, нәрсә эшләмәскә тиешлеген дә аңламады. Ул бары үзенең болгарларда ике ел тоткында яшәргә тиешлегән генә белде. Ике ел әле яңа гына башланган иде. Шуңа күрә, көн үтсә дә, үтмәсә дә аның өчен барыбер иде. Ул берничек тә үзенең мондый тоткынлыгына күнегеп житә алмады. Шулай ук аны иректә тормыш та — Торымтайдан, ялгыз тирмәдән башка ниндиләр бүтән тормыш та кызыксындырмады. Ул мәңгегә монда калу турында да уйламады, тизрәк атасы-анасы янына кайтып китәргә дә омтылмады. Атасына-анасына, туган ыруына, андагы йолаларга, карашларга үзен бәйләп тора торган ниндидер җеп аңа искәрмәстән өзелде шикелле тоелды. Ул мон-

да, үзе ягы дип белгән болгарлар илендә ят җирләр, ят кешеләр күрде, аларның куанычларын, кайгыларын үз җилкәсендә татыды. Элекке жепләр урынына аны бу якка — Болгарга тартып тора торган икенче җепләр, арканнар барлыкка килгәндәй булды. Менә шул икенче җепләр аны торган саен ныграк тарта, өстери шикелле тоелды.

Мондый нәрсә кайчакларда аның котын алды. Үзенең икейөзлелегенә, үзенең бу тдыксызлыгына, җебегәнлегенә ачуыннан аның бүре булып улардай чаклары булды. Ул Аппакны... Алмыш ханның кызын ярата! Ул үзенең туган җирен, туган ыруын килеп баскан кешенең кызын ярата!

Ул Аппакны, Аппак аны ярата... Була торган эшме бу? Кемнең тоткыны соң ул — ханныкымы, әллә аның кызыныкымы?

Тик шулай да нинди татлы, нинди куанычлы бу тоткынлык!

Үзара аңлашкан теге кичтән соң әле алар бөтенләй очрашмадылар. Тотыш аны эзләп йөри алмады. Аппак исә, күрәсең, көпә-көндез аның тирмәсенә килергә шулай ук батырчылык итмәде. Аннары, бер-берсенә үзләренең күңелләрен ачып салгач, алар әле ныклап торып исләренә дә килә алмаганнар иде бугай. Аларның күңелендә әлегә, яратудан-сөюдән бигрәк, курку-өркү, бер-берсеннән оялу-тартыну өстенлек итә иде бугай.

Шулай да очрашмый тору озаккарак сузылды. Тотыш бүген аны көтә башлады. Күңеле сизенде: бүген алар очрашырга тиешләр иде.

Үз алдына уйланып утырганда, аның янына Алмыш ханнан кеше килде.

— Сине хан үз янына чакыра, Тотыш,— диде йомышчы.

Тотыш каушап калды. Хан янына? Ник? Кызы белән очрашканны сизде микәнни?

Чакырган җиргә ул теләмичә генә барды, бик нык эче пошып, борчылып барды. Кин тирмәгә барып кергәч, бу борчылу тыелгысыз бер куркуга әйләнде.

Менә ул хан каршысына — күңеленнән ин явыз, иң кансыз дип уйлаган кеше каршына, үзе өчен аҗундагы барлык нәрсәдән, барлык үледән-тередән артыграк, сөеклерәк булган кызның атасы каршысына килеп басты.

— Синең боерыгың буенча...— диде ул, авыз эчендә ботка кайнатып.

— Тезләнү,— диде Алмыш хан.

Тотыш, йоланы исенә төшереп, бүреген салды, тезләнде.

Яшь егет тирләп-пешеп идәндә тезләнеп торганда, Алмыш хан каш астыннан гына аны күзәтте. Аның күңелен, мачы булып, бер сорау тырнады: «Минекеме, түгелме?» дип уйлады ул, батыр егетнең киң, таза иңбашларында, киң маңгаенда, борын-күзләрендә үз чалымын табарга тырышып. Төсе-бите белән ул анасына охшаган иде. Тик шулай да аның күз карашындамы, кара кашларының куелыгындамы... Алмыш ханның да төсмерләре бар иде шикелле. Әллә Күрән бинекеме соң? Киң яңаклар, кысыграк күзләр... үткен, очлы күзләр... Юк, шулай да Алмыш ханның каны кайный, ахрысы, моның күкрәгендә!

— Мин сине, Тотыш... угыл, сөйләшер өчен чакырдым,— диде хан, сүзгә башлап.— Моннан соң син минем урдада яшәячәксен.

— Мин инде айдан артык синен урдада яшим, хан,— диде Тотыш.

— Син миндә ике ел яшәячәксең,— диде хан, аны тыңламыйча.— Атаң синен урынга башка углын җибәргәч тә, туган җиреңә кайтып китәрсең. Шул булыр тоткынлыгың... тоткынлыгың...

— Беләм,— диде Тотыш.— Ике ел буена мин шулай ялгыз тирмә саклап ятырмын микәнни, хан? Ат бир, корал бир син миңа, хан!

— Ат, корал? Ни өчен? Миңа каршы бер үзең яу чыкмакчы буласыңмы? Хе-хе...

— Мин яшь, таза. Беләктә көч ташып тора. Нишләп ятыйм мин анда? — диде Тотыш, ханның ягымлы сөйләнүеннән күңеле үсеп.

— Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый,— диде хан коры гына.— Синең сүзләреңдә миңа бүре өне ишетелде, Тотыш углан!
Ханның кырыслыгы Тотышның каушавын кинәт юкка чыгарды.
— Бүреләр янында бүречә уларга туры килә, хан! — диде ул, урыныннан кузгала язып.
Алмыш хан йөзен чытып куйды. Шулай да Тотыш углан үзенә нинди генә каты сүз әйтсә дә, ул аңа чын-чынлап ачулана алмас иде шикелле.
— Син — тыйнаксыз,— диде ул бераздан, җинелчә шелтә белән.— Сиңа өлкәннәр алдында үз-үзеңне тотарга өйрәнергә кирәк. Син өеңдә генә ятмаячаксың. Болгар түрәсен, йоласын тотсаң, теләгән җиреңә барырсың, теләгән кешең белән очрашырсың, теләгән кешең белән аралашырсың. Тик алдан ук кисәтеп куям: качу турында башыңа да кертеп карама! Качасың икән, янадан яу белән барып, күчеңне, ыруыңны канга батырачакмын! Минем беләк синекеннән дә тазарак, Тотыш углан.— Син анаң карынында ятканда минем инде кулда кылыч уйнады. Синең үз язмышың үз кулыңда. Атаңны-анаңны кайгыга салырга теләмәсәң...
— Син салган кайгыдан да зуррак кайгыга салып булмас, хан! — диде Тотыш, кызарынып.
— Бар, чыгып кит! — диде хан.
Тотыш аягына басты, ханга арты белән борылды да, иксез-чиксез төелгән озын, йомшак келәмне таптап, ишеккә юнәлде. «Аяк атлавында да нидер бар»,— дип уйлады хан, аның артыннан күзәтеп. Тотыш инде чыгып китте дигәндә генә ул аны кычкырып туктатты да кире үз янына чакырды.
— Сорарга онытканмын — синең анаң кем әле? — диде ул тыныч кына.
— Койтым бикә.
— Ярар, китә бир,— диде хан.
«Шулай да ул миңа охшаган! Кыю, усал, таза! — дип уйлады Алмыш хан үзалдына.— Ничек итеп аны кулга ияләштерергә! Ничек итеп... куркытмыйча?... Ничек итеп мәңге аны үзеңнеке итәргә?!. Анда — минем каны! Шулай да аның үзенә бернн сиздерергә ярамый. Аталарның, аналарның яшерен эшен балалар белмәскә тиеш».
Хан чатырыннан чыгып киткәндә Тотыш та уйланды. «Ярый әле, берни сизмәгән икән!» — диде ул үз-үзенә, сөенеп.

## VIII

Торымтай янына Тотыш күтәренке күңел белән кайтты.
— Миңа нишләсәм дә, кая барсам да була! — диде ул.
— Нишләсәң дә микән? — диде Торымтай, шикләнеп. — Сиңа качарга ярамый — әйтмәдеме?
— Әйтте,— диде Тотыш.— Качсам, мине нишләтәчәкләр?
— Тотачаклар,— диде Торымтай, көлеп.— Качкын дип, аягыңны чабып өзәчәкләр дә, агач башына элеп куячаклар.
— Алайса, баш исән калачак? — диде Тотыш.
— Кулларың да исән калачак,— диде Торымтай, әз генә дә шаяртырга уйламыйча.
— Тоттырмаеам? — диде Тотыш.
— Тотачаклар,— диде Торымтай тыныч кына.— Этилдә, Чулманда, базарларда, юлларда, авылларда, көтүләрдә Алмыш ханның шымчылары бар. Аларның күзе җиде төн уртасында да күрә, аларның колагы җиде кат җир астында елан кушаганне ишетә.
— Урманда да шымчылар бармы? — диде Тотыш бик үк ышанмыйча.
— Урманда — бүреләр. Син соң качарга җыенмыйсыңдыр ич? —

диде Торымтай, эчке бер сагаю белән.— Тотыш, мин сине генә җибәрмим. Качсаң, миңа да әйт.

— Сиңа да? Син соң үзең дә хан шымчысы түгел микән?

Торымтайның кара-кучкыл йөзенә сизелер-сизелмәс кенә кызыллык йөгерде.

— Мин — ханның колы,— диде ул, ык-мык итеп.— Әйе, миңа шымчылык та йөкләнгән. Шулай да син миңа ышан, Тотыш! Син кайда — мин шунда. Син мине үлемнән алып калдың. Шуннан бирле мин синең колың, Тотыш! Колың булмаса, кадашың[1], юлдашың, карындашың, Тотыш!

— Монысына мин килешәм! — диде Тотыш, Торымтайның кулын кысып.— Тыныч бул, мин беркая качмаячакмын. Ике елдан мин үз ыруыма кайтып китәчәкмен. Беләсеңме, Торымтай, шунда мин сине ханнан сатып алырмын. Шуннан соң мин сиңа ирек бирермен. Син дә үз ягына — Кучәргә кайтып китә алырсың.

— Тотыш! — диде Торымтай, күңеле тулып.— Аяк астында тузан булыйм! Теләкләрең изге улсын... юлдашың тәңре улсын!

— Чынлап та, ник качарга? Теләгән җиреңә барырга булгач...

— Синең кая барасың килә соң? — диде Торымтай.

«Синең кемне күрәсең килә соң? дип әйтмәде»,— дип уйлады Тотыш узалдына. Нишләп соң әле ул бер дә Аппакны телгә алмый? Әллә ул берни белмиме, берни күрмиме? Белсә дә, күрсә дә юри күрмәмешкә, белмәмешкә салынамы? Ник?

— Минем суны күрәсем килә, Әтилне...— диде Тотыш, көттеребрәк.

— Әтил ерак. Әйдә Өсән буена гына,— диде Торымтай.

Алар, өсләрендәге авыр киемнәрен, итекләрен салдылар да, җиңеләеп, киез, киндер өйләр арасындагы тар сукмактан Өсән ягына юл тоттылар. Хатын-кызларның суга йөри торган сукмагы башта калку җирдән барды, аннары түмгәкләр, тотам-тотам булып утырган куе яшел үләннәр белән капланган, кипкән тизәкләр белән чуарланган тар гына үзәнлек аша үтеп, шомырт, зелпе куаклары артындагы Өсән ярына барып чыкты.

Болгар-тора урнашкан текә калкулык астыннан, яшел болыннар, куе урманнар арасыннан боргаланып аккан Өсән суы киң генә, тирән генә иде. Аның түбәнге өлешендә, Әтилгә койган тамагында — Ага-базарга каршы якта, тамгалар, агач өйләр бар иде. Әтил ярыннан алып ханбалыкка җиткәнче, бер-ике чакрым чамасы арада, әле анда, әле монда төрле зурлыктагы көймәләр, каеклар, улаклар туктап торуын, я булмаса аларның әкрен генә кыймылдавын күрергә була иде.

Тотыш белән Торымтай барган турыда елга сай иде, яр буйлары комлы иде. Балыкчы көймәләреннән башка бу тирәгә каеклар да, улаклар да менә алмый. Монда елганың ике ягында да бала-чага су кerә. Арада яшүсмерләр дә, буй җиткән кызлар да, егетләр дә бар. Алар барысы да анадан тума шәрәләр: барысы да юешләр, барысы да никтер көләләр, кычкыралар, чыркылдыйлар иде. Су өстендә, яр буенда, зур яудагы кебек, колакларны тондыргыч бер тавыш, чыр-чу яңгырап тора иде.

Тотыш белән Торымтай су янына якынрак килделәр дә, тирә-яктагы үсмерләргә, бала-чагага карамыйча, өсләрен чишенә башладылар. Тотыш балаларның, үсмерләрнең кызыксынып үзенә карауларын сизеп торды. Ул, ялан аяклары белән йомшак комга басып, эчке бер сөенеч, күтәренкелек тойгысы белән су читенә килде, елгада чагылган кояштан күзләрен йомыштырып, беравык тын гына карап торды, аяк очларын тидереп, суның җылымы, түгелме икәнлеген белде.

Шул чакны аның колак төбендә генә:

[1] Кадаш — иптәш.

— Әй, син, килмешәк, кая тыкшынасың?! — дигән сүзләр ишетелеп китте.

Тотыш ялт кына артына борылып карады. Аннан берничә адым читтәрәк бер егет басып тора иде. Ул Тотыштан калкурак. Беләкләре юан, күкрәге киң. Кылтаеп үрелгән озын чәчләрен ул арттан маңгай турысына китереп бәйләгән. Аның ачу китергеч чибәр йөзендә мыскыллы көлемсерәү бөркелеп тора. Бу теге Тотышны җиңгән Корыч-Тимер алып иде.

— Исендәме, син минем аяк астында аунап яттың?! Сине анда хан коткарып калды. Монда беркем коткармас — яхшы чакта үкчәңне күтәр! — диде Корыч-Тимер, бала-чага куркыткан сыман, янап, көлеп.

Тотыш, аптырап, сыену эзләгәндәй, Торымтайга күз салды, якындагы үсмерләргә карап алды. «Бу ни була инде? Миңа кая барсам да ирек түгелмени?» — диде аның сораулы күз карашы. Торымтай шундук аңа булышка ашыкты.

— Корыч-Тимер, тынычлан! — диде ул яшь егеткә, үтенеп.— Тотыш — Алмыш ханның тотыгы, аңа Өсәндә су керү тыелмаган.

— Кит әле моннан! — диде Корыч-Тимер, колны җиңел генә читкә этәреп.— Килмешәккә монда урын юк. Күземә күренмәсен, юкса мин аны!

Янап, күзләрен чекрәйтеп, ул Тотышка якын ук килде. Ул аны, күрәсең, суга төртеп җибәрмәкче булды.

Суга сикерергә укталган җиреннән Тотыш туктап калды. Аның күңелендә, давыл булып, үч, ярсу, оят — барысы берьюлы калкып чыкты. Корыч-Тимернең ташланганын көтеп тормастан, ул беренче булып үзе ыргылды. Масайган Корыч-Тимер исенә килергә дә өлгермәде, куй эләктергән бүре кебек, болан бугазлаган барыс кебек, Тотыш аның биленнән ике куллап кысып алды да, «ә» дигәнче баш аркылы атып та бәрде. Бу шундый тиз булды, шундый искәрмәстән булды — тынып калган яр буе кинәт чыркылдап җибәрде.

— Ягез, кем тагын килмешәккә каршы килә? — диде Тотыш, усал елмаеп.

Аңа каршы чыгарга беркем дә батырчылык итмәде. Кемдер бары арттан гына таш ыргытты. Елга төбеннән алынган шома таш шап итеп аның калак сөягенә килеп тиде. Барлык тамырлары, сеңерләре киергәдәй тартылган, күкрәгендәге утлы ярсуы уятай атылырга гына торган Тотыш үзенә таш ыргытучыны эзләп тормады — күзенә эләккән беренче угланны тотып алды да аны да баш аркылы җиргә орды. Орды да, читлеген ватып чыккан киек сыман, шундук икенче якка ташланды — авызын ачып торган икенче бераүнең яңагына тондырды, өченчесенең корсагына төртеп алды.

Яр буе кинәт кузгалып куйды. Бала-чага куркып читкә йөгерде, өлкәнрәкләр бер тирәгә укмаштылар. Ул арада Корыч-Тимер дә аягына басты. Басты да, ярсып, уларен белмичә, яңадан Тотышка таба килә башлады. Чын орыштагы кебек үзенең сизгерлеген, үткенлеген югалтмаган Тотыш искәрмәстән аның эченә тибеп җибәрде — Алмыш ханның макталган алыбы гөрс итеп арты белән җиргә барып төште.

Бер тирәгә җыелган егетләр, Корыч-Тимернең тынсыз калуын күреп, куаклар арасына шыпан-шыпан гына шыла башладылар.

— Әй, болгар куркаклары, белегез, бу мин — Тотыш булырмын! — дип кычкырды Акбүре батыры, качып баручыларны мыскыллап...— Минем белән очрашканда бер чакрымнан бүрегегезне салыгыз, юкса, башыгызны култык астыгызга кыстырып җибәрермен!

— Юлбасар! Килмешәк!

— Ханга әйтеп, үзеңнең башыңны ч[illegible]тырырбыз!

— Сиңа монда барыбер көн булмас! — диделәр яшь әтәчләр, куак арасыннан йодрык янап.

Көмеш тараклары белән бер-берсенең чәчләрен тараган булып, бер читтәрәк сылу кызлар басып торды. Сокланып, исләре китеп алар каш астыннан гына атаклы Тотышны — орышта ханның ике алыбын чәнчелдергән яшь батырны күзәттеләр. Пышын-пышын гына нидер сөйләнеп алдылар, тыелып кына көлешеп куйдылар. Тотыш аларның үзенә теләктәшлек белдергән ягымлы күз карашларын тотып алды. Аның күкрәген чиксез куаныч тойгысы, җиңү тойгысы биләде. Очынып, җинеләеп ул суга ташланды, колач салып ары йөзеп китте.

## IX

Яр буендагы ызгыштан соң күп тә үтмәде, хан чатырына ачулы аталар килеп җитте. Аларның берсе Корыч-Тимернең атасы Алып-Тархан, икенчесе чүлмәкче Котылмыш, өченчесе бакырчы Юлай иде.

Корыч-Тимер атасының чын аты — Болан, шулай да телдә аны Алып-Тархан дип кенә йөртәләр иде. Яше буенча алтмыштан узган бер карт булса да, көче, тазалыгы белән әле ул кайбер яшьләргә дә бирешерлек түгел иде. Яшь чагында ул тиңдәшсез алып булган, күп яуларда катнашкан, күп ягының канын койган. Алып булуы өстенә, ул тарханлык[1] та били иде. Шуңа күрә дә аны шулай Алып-Тархан дип атыйлар. Алмыш ханның ул иң якын, иң ышанычлы кешеләреннән санала. Үзенең тотнаксызлыгы, былагайлыгы, сугыш чукмарлыгы белән ул бөтен Болгар йортка билгеле. Берсеннән-берсе усалрак, берсеннән-берсе йөгәнсезрәк угыллары да аның аталарыннан бер дә калышмыйлар иде. Моңарчы хан катына елап-сыктап Алып-Тархан өстеннән, аның угыллары өстеннән башкалар килә иде. Бүген әнә ул үзе килде.

Алмыш хан аның сүзләрен тыныч кына тыңлап утырды да, берни әйтмичә, «сөйлә» дигәнне аңлатып, Котылмышка баш кагып алды. Котылмыш сөйләп бетергәч, шулай ук, авыз ачып бер өн чыгармыйча, бакырчы Юлайга ымлады. Юлай туктап калгач та ул сүз әйтергә ашыкмады. Йомшак келәмдә тезләнеп торган кешеләргә күз кырые белән дә карамыйча ул артына иелде, биек түр — утыргыч артыннан алтын комган тартып чыгарды. Комган авызына каплап куйган көмеш аякны бер кулына, комганның үзен икенче кулына тотып, бик бирелеп ачы бал агыза башлады. Теләр-теләмәс кенә аккан балны ирләр күзләрен дә алмыйча, ымсынып карап тордылар, борыннарын тарттылар, төкрекләрен йоттылар. Ачы бал сузылып кына, нечкә генә булып акты да акты, аннары өзек-өзек тамчылады да туктап калды.

— Аякчы! — дип кычкырды хан ачу белән.

Чыбылдык артыннан ашыгып аякчы килеп чыкты, идәндә аунап яткан комганны алып, агач чапчактан аңа бал агызмакчы булды. Хан, түземсезләнеп, чапчакны култык астына кыстырды да, сычукны турыдан-туры шуннан гына агыза башлады. Тезләнгән ирләр, күзләрен уттай яндырып, сычук тулы аякка текәлделәр. Алмыш хан, үзе эчкәч, башта Алып-Тарханны, аннары Котылмыш белән Юлайны сыйлады. Бары шуннан соң гына ул Алып-Тарханга күтәрелеп карады.

— Анда тагын кемнәр булган... таныклар? — диде.

Алып-Тархан үзе белгән унлап угланны санап чыкты. Котылмыш белән Юлай да шул ук угланнарны әйттеләр.

— Алайса, беренче булып Тотыш ташланган? — диде Алмыш хан.

— Беренче булып Тотыш ташланган, ханым,— диде Алып-Тархан.— Углым әнә билсез булып ята.

— Синеке ничек ята? — диде хан Котылмышка.

— Минекенең колак төбе канаган,— диде Котылмыш.

---

[1] Тархан — үзенә буйсынган биләргә хан тарафыннан бирелә торган дәрәҗәле исем. Тархан төрле өстенлектән файдаланган һәм салымнар түләүдән азат ителгән.

— Синеке ничек ята? — диде хан Юлайга.

— Аның җуйган. Байтал имчене китердем,— диде Юлай.

— Үзегез ни киңәш итәсез? — диде хан, аталарның әле берсенә, әле икенчесенә карап.

— Кулын чабып өзәргә! — диде Юлай.

— Юк, башын чабарга! — диде Алып-Тархан, кызып, аягүрә басып. Хан, кулын селтәп, аңа тезләнергә боерды.

— Син? — диде ул Котылмышка.

— Хан үзе ничек теләсә, шулай яргуласын,— диде Котылмыш.

Алмыш хан, берни әйтмичә, янадан артына иелде, комганын тартып чыгарды да көмеш аякка шаулатып тагын бал агыза башлады. Ачулы аталарны икенче аяк белән сыйлап чыккач ул, күзләрен усал кысып, Алып-Тарханга борылды.

— Син, Алып-Тархан, минем урында булсаң, нишләриең икән? — диде.— Син әйтмәдең: ник Тотыш беренче булып синең углыңа ташланды икән? Күрәсең, углың үзе башлагандыр...

— Юк, юк, минем углым андый түгел! — диде Алып-Тархан тормакчы булып.

Алмыш хан, кулын селтәп, аны тагын урынына тезләндерде.

— Бүлдермә! — диде ул.— Син үзең дә, углың Корыч-Тимер дә төшеп калганнардан түгел. Юкка-барга кыерсыттырып тормассыз. Корыч-Тимер үзе бәйләнмәсә, Алмыш ханның атаклы алыбына... шундый таза иргә бәйләнергә кемнең йөрәге җитсен?!

— Үзе бәйләнгән, үзе! Корыч-Тимер башлаган, ханым! — диде Юлай, сүзгә катышып.

Алып-Тархан, ярсып, билендәге бөктәсенә тотынды.

— Белеп сөйләш, бакырчы! — диде ул, Юлайга ташланмакчы булып.

Алмыш хан урыныннан торды, кулына кылычын алды.

— Үзара кыйнашкан, ызгышкан угланнарның башын чабарга, дигән түрә юк! — диде ул.— Ханга ялган сөйләүченең башын кисәргә, дигән түрә бар. Син кайсын яклыйсың, Алып-Тархан?

Эшнең болайга китүен күреп, Алып-Тархан өнсез калды, бөктәсен кыныга тыкты да, маңгаен идәнгә орды, кинәт кенә күз яшьләрен түгеп, ялынырга тотынды:

— Кичер, ханым! Углымны мин ялгыш аңлаганмын,— диде.

Аннан күрмәкче, Юлай белән Котылмыш та башларын җиргә ордылар.

Җиң очлары белән авыз читен сөртеп, бил каешын төзәткәләп, Алмыш хан урынына утырды.

— Күпме көч түгеп, күпме төн йокыларын калдырып... күпме кан коеп мин Чулман буен тез чүктереп кайттым,— диде ул, сүзгә башлап.— Анда йөргәндә минем күпме эшемә монда талау килде! Чулманны алдым — торасыз калдым. Күпме алыпларым, бөркетләрем юкка чыкты! Оямны торгызырга миңа акча кирәк, акча! Син бирәсеңме үз акчаңны, үз байлыгыңны, Алып-Тархан? Сез бирәсезме, чүлмәкче Котылмыш, бакырчы Юлай? Мин әле сездән дә алырмын аның. Җиде кат тирегезне тунармын әле мин сезнең! Тик миңа җиде кат тире генә дә аз. Миңа ун кат, йөз кат тире кирәк! Тотыш угланның башы елына ун мең тора. Сезнең угланнарыгызның башы күпмешәр тора?

— Минем углым — җиңүче! — диде Алып-Тархан, күкрәген киереп.

— Әйе, үтерелгән ике алыптан соң! — диде Алмыш хан.— Тотыш аннан көчлерәк, белеклерәк. Синеке, алып булса да, җилкуар, эшлексез.

— Кичер, ханым, ялгыш миндә,— диде Юлай, тагын баш орып.

— Кичер, ханым,— диде Котылмыш та, ашыгып.

Алып-Тархан да икенче кат шул ук сүзләрне кабатлады.

— Мин сезне кичерәм,— диде хан, тынычланып.— Колагыгызга киртеп куегыз: моннан соң минем тотыкларыма тел тидерәсе, кул күтәрәсе булмагыз. Тотыклар алар шул ук болгарлар. Болгар түрәсе алар өчен дә, сезнең өчен дә бер.

Аталар, оятлы йөзләрен яшереп, кызарынып, өйләренә кайтып киттеләр. Бик кыен, үкенечле булса да, аларга ханның әйткәне белән килешергә туры килде. Тик Корыч-Тимернең генә берни белән килешәсе килмәде. Алмыш ханны ул чын-чынлап Тотышның башын чаптырыр, дип уйлаган иде. Атасы кайтып сөйләгәч, ул моңа ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Аның күңелендә коточкыч бер көч белән Тотыштан, булдыксыз атасыннан, Алмыш ханнан, барлык кешеләрдән үч алу теләге туды. Шул көннән соң ул бары шул теләге белән генә яши башлады.

## X

Тотышның өйгә кайтасы килмәде. Өйгә кайтты исә, анда аны кемдер сагалап, көтеп торадыр шикелле тоелды. Су кереп чыккач, алар Торымтай белән икәүләп Өсән буендагы куаклар арасында йөрделәр, кура җиләге ашадылар.

Төштән соң күк йөзен кара болытлар каплап алды. Көнне кисәк кенә карангылатып җибәрде. Түбә өстендә Куар оган, ачулы мыгырданып, биек таулардан ташлар тәгәрәтте, явыз айналарны куалап, утлы кылыч белән селтәнде. Шуннан соң коеп яңгыр яварга тотынды. Тотыш үзенең колы белән яңгыр туктаганчы агач төбендә көтеп утырды.

Аларның тирмәләре түгәрәкләнеп, балдак эчендә балдак булып утырган хан урдасының иң читенә — тышкы «балдакка», төн ягына урнашкан иде. Өйләренә алар болын ягыннан кайттылар, шуңа күрә аларга тирмәләр арасыннан үтәргә туры килмәде. Алар кайтып җиткәндә яңгыр инде туктаган иде, аның урынына, көн карангылана башлаган иде.

Үзләре тирмәсенә бер йөз адым чамасы калгач, Торымтай барган җирендә туктап калды.

— Карале! — диде ул, Тотышның тирмәсенә күрсәтеп.

Тотыш та туктады, аптырап, үз күзенә үзе ышанмыйча, сыек карангылык аша, үз өе ягына карап тора башлады. Анда, аныкы булырга тиешле тирмәдән, күккә шәбәеп төтен үрләп ята иде.

— Учак сүнмәде микәнни? — диде ул Торымтайга.

— Безнең өй түгел бу,— диде Торымтай, икеләнеп.— Әллә яшен ташы төшкәнме соң, тьфү, тьфү!

— Сөйләнмә! — диде Тотыш.— Учакта утын калгандыр.

Ул тизрәк өенә ашыкты. Аның бу серле төтен чыганагын тизрәк үз күзләре белән күрәсе килде. «Яшен ташы... яшен ташы...» дип уйлады ул, эсселе-суыклы булып. Булмас ла. Яшен булса, иң элек Алмыш хан тирмәсен сугарга тиеш. Тәңредән, Куардан йөз чөергән башка кешеләрнекен сугарга тиеш. Аларны сукмаган. Әнә тирмәсе, күкне каплап, кукыраеп, масаеп урда уртасында утыра.

«Яшен башта Алмыш хан тирмәсен сугарга тиеш», дигән уй Тотышны бераз тынычландыра төште. Югыйсә, яшен суккан булса, анда инде бөтен нәрсә юкка чыкты дигән сүз булачак! Хан урдасы, яшен суккан өйнең кешесе белән үзен генә калдырып, шундук күченеп китәчәк. Аңа беркем якын килмәячәк, аңа беркем ашарга-эчәргә бирмәячәк. Барлык кеше аннан баш тартачак, шулай итеп, ул үзеннән-үзе кеше булудан, тотык булудан, Күрән би углы Тотыш булудан туктаячак. О, ул чагында... аның янына төнлә бары ач бүреләр генә киләчәк!

Әйе, бу аның өе иде. Коты алынган Торымтайның үзен тотып калыр-

га тырышуына да карамастан. Тотыш йөгереп диярлек ишек янына килде, тартып ишекне ачты.

Учак янында кемнедер күреп, ул чак-чак кына артына авып китмәде. Аның артыннан ук өйгә килеп кергән Торымтай да учак янындагы кешене күреп алды. Икесе дә, ачык ишектән кереп түргә узарга кыймыйча, чакырылмаган кунакка карап торуларында булдылар.

— Аппак ич! — диде кинәт Торымтай, кычкырып.

Шулай диде дә, телен тешләп, тынып калды, куркып як-ягына каранды. Тирмәләр бер-берсеннән ерак урнашкан иде, аннары ярым караңгы булганга, якын тирәдә беркем күренми иде.

— Әйттем исә кайттым! — диде Торымтай, пышылдап, кабаланып.— Минем күзем күрмәде, җирдә яткан таш күрде. Минем күзем күрмәде, агып яткан су күрде. Минем күзем күрмәде, исеп киткән җил күрде!

Ул узалдына сөйләнә-сөйләнә, сак кына атлап, каядыр китеп барды. Аның бу сөйләнүләрен дә, кинәт тынып, юашланып калуын да Тотыш аңламады.

— Аппак шул! — диде ул, куанып, өенә кереп.

Ул учак янына килде, ишеккә арты беләнрәк торган кызны кочып алды, аның күзләренә карады. Кыз тыелып кына көлеп куйды, кайнар битен аның юеш, салкын битенә тидерде, аның озын чәчләреннән тамган янгыр тамчыларын учына җыйды. Кинәт ул йомшап, авыраеп калгандай булды. Үзенең беләкләрендә, күкрәгендә Тотыш аның шул йомшаклыгын, исерткеч кайнарлыгын тойды.

— Син — минеке! — диде ул.— Аппагым, ишетәсеңме, син минеке! Нинди куаныч! Бу көннәрдә шундый сагындым мин сине.

Кызның ярым йомык, сөрмәле күзләре ачылып китте. Ул аңа исе китеп, елмаеп карап торды да, шаяртып:

— Түгел,— диде.

Ул Тотышның кочагыннан балык кебек шома гына чыкты да, башын чайкап, битенә төшкән чәчләрен артка ташлады.

— Мин синеке түгел, син — минеке! — диде кыз, көлеп.

Аның болай сөйләнүе тотык егетнең кирәкмәгәндә мин-минлеген кытыклап куйды.

— Нишләп алай? — диде ул, сагаеп.

Кыз, берни әйтмичә, егеткә бер өздереп карап алды да серле генә көлеп куйды, идәнгә төшкән бүреген алып киде. Шуннан соң, куенындагы күнчегеннән кечкенә көзге алып ул учактагы ут яктысына якын килде. Көзгегә карый-карый төзәнгән арада Тотыш ягына да күз төшергәләп алды.

— Әйт әле, нишләп син минеке түгел дә, нишләп мин синеке? — диде беркатлы егет, кашын җыерып.

Кыз аңа телен күрсәтте.

— Син Алмыш хан кызы булган өченме? — диде Тотыш.

— Әйтмим! — диде Аппак, үчекләшеп.

— Ник?

— Юри! Килмә, ярамый!

— Нәрсә ярамый? — диде Тотыш.

Тычканга ташланган мәче кебек ул бер генә ыргылды да кызны янадан эләктереп алды, кочагына кысты.

— Тотыш, үтерәсең! — диде кыз, чыркылдап.

— Әйтәсеңме, юкмы? — диде Тотыш.

— Җибәрсәң, әйтәм,— диде кыз.

Тотыш аны иплəп кенә йомшак киезгә бастырды.

— Син — тиле,— диде кыз, яратып, үз итеп.— Син минеке булмасаң, өең дә минеке булмасые. Үзе югында чит кеше өенә керү ярамаганлыгын беләсеңдер? Сорамыйча керү — шул ук угрылык.

— Син болай да угры кебек,— диде Тотыш.

— «Кебек» белән «бугай» ат койрыгында гына була,— диде кыз, көлеп.

— Чын. Минем янга син бары караңгы төшкәч кенә, кеше күрмәгәндә генә киләсен,— диде Тотыш.— Беркайчан да без кеше алдында очраша алмабыз микәнни? Беркайчан да без бергә була алмабыз микәнни?

Кыз, йезендәге елмаюын сүндереп, тынып калды.

— Әйдә ул турыда сөйләшмик? — диде ул бераздан, уйчан гына.

## XI

Тотыш юеш киемнәрен салып идәнгә ташлады да шәрә килеш учак алдына килеп утырды.

— Киен,— диде кыз, үтенеп.— Торымтай килеп керер әллә.

— Керсә, ни булган? — диде Тотыш, исе китеп.

— Ярамый, киен,— диде кыз.

Тотыш, сүз тыңлап, өстенә коры киемнәрен киде. Ул әле генә Торымтайның «Аппак!» дип кычкырып җибәрүен, никтер куркып тизрәк чыгып китүен күз алдына китерде. Ана монда ниндидер сер бар шикелле тоелды.

— Син... Торымтайдан курыкмыйсыңдыр ич? — диде ул кызга.— Әллә Торымтай синнән куркамы соң?

— Мин сиңа әйттем: мин чумаклар йоласын тотам,— диде Аппак.

— Беләм,— диде егет.

— Менә шул, гарәпләр йоласы буенча, ир кеше алдында хатын-кыз битен каплап йөрергә тиеш, ди, үз ирс булмаган ирләр белән очрашмаска тиеш, ди.

— Битен каплагач, аны ничек таныйлар соң? — диде Тотыш, шаккатып.— Очрашмыйча кешеләр ничек торалар соң?

— Мин аны үзем дә аңламыйм,— диде Аппак.— Мулла шулай куша. Атам соңгы көннәрдә мулладан да арттыра башлады. Мулла әйтә, ирләр белән хатын-кызлар бергәләп су керергә, мунча керергә тиеш түгел, ди, шәрә килеш бер-берсенә күренергә тиеш түгел, ди. Анысы ярамый, монысы ярамый. Барысы да хатын-кызга ярамый! Көн дә мулла безне җыя да шундый нәрсәләр өйрәтә. Аннары гарәпчә укырга-язарга өйрәтә.

— Кызык. Авырмы?

— Авыр. Мин бернәрсә дә аңламыйм,— диде Аппак, көлеп.— Мулланың юан корсагын, майлы күзләрен күрдемме, берни башка керми — сине уйлап тик утырам.

— Мин муллага охшаганмынмыни?

— Юк! — диде кыз, көләргә тотынып.— Син шундый булсан, нинди ямьсез булырыең!

— Беләсенме, син өйрән! Язарга да, укырга да өйрән. Миңа да өйрәтерсең,— диде Тотыш, чын-чынлап кызыксыну белән.— Гарәпчә белекләр күп. Йолалары җайсыз булса да, алар үзләре бик башлы, ди. Минем ишеткәнем бар. Беләсеңме, аларча өйрәнсәң, Багдадка, Мисырга барырга була.

— Ник барасың анда? — диде кыз, күнелсезләнгәндәй итеп.

— Кызык итеп. Минем барлык җирләрне күрәсем килә: Румны, Бохараны, Хәрәземне...

— Әй лә, кызык түгел,— диде кыз, балаларча киреләнеп, иркәләнеп.— Телләрен дә, язуларын да өйрәнәсем килми. Башта син өйрән, аннары миңа өйрәтерсең.

— Кемнән?

— Ага-базарда сатучылар бетмәгән. Таныштырырмын,— диде Аппак.— Яратмыйм шул мулланы. Үзе хатын-кыз ирләргә карамаска тиеш, ди, үзе гел миңа карый, башка кызларга карый.

— Сина карый? Нигә аны элегрәк әйтмәден? — диде Тотыш, йодрыкларын йомарлап.

— Нәрсә дип әйтергә? — диде Аппак, исе китеп.

— Мин аны! — диде Тотыш, мыгырданып.— Алар барысы да оятсызлар... көньяктан килгән ирләр... Беркайчан хатын-кыз күрмәгән кебек кыланалар.

— Шуның өчен дә көнләшәсеңме? — диде кыз.

— Юк, мин көнләшмим,— диде егет.— Минем ачу килә. Юк мин куркам, шикләнәм бугай.

— Нәрсәдән, кемнән куркасың? Корыч-Тимердәнме, аның атасыннанмы?

— Көлмә,— диде Тотыш ачусыз гына.— Мин инде аны онытып та бетергәнмен.

— Син онытсаң да, мин онытмадым,— диде Аппак, эчке бер борчылу белән.— Шуңа да ашыгып килдем менә. Нишләдең... нишләдегез анда? Корыч-Тимернең кем икәнлеген, кем углы икәнлеген беләсеңме син?

— Беләм,— диде Тотыш, караңгы чырай белән.— Икенче бәйләнә калса, мин аны!.. мин аны... нишләтеремне үзем дә белмим. Ни генә булмасын, мин аннан үземне кыерсыттырып тормам. Мин аны чебен кебек, таракан кебек сытачакмын! Мин аны он итәчәкмен!

— Син нинди усал, Тотыш! — диде кыз, сокланып.— Шулай да саграк булырга кирәк. Син мондагы кешеләрне дә, йолаларны, түрәләрне дә белмисең.

— Йола... түрә! — диде Тотыш, ачудан йомарланган йодрыкларын селтәп.— Илгә яу килсә, яуга каршы сугышырга була. Өстенә бүре ташлана икән, аның белән дә сугышырга була. «Килмешәк» дип сине берәрсе мыскыллый икән, аны җиргә күтәреп орырга була. Йола, түрә юлына аркылы төшсә, ул чагында нишләргә? Берни эшләп булмый. Башыңны иеп, килешергә тиеш буласың. Мин инде күптән уйланам ул турыда. Мин күктәге тәңрегә ышанам, җир, су, урман, ут-учак ияләренә... җил-давыл, яңгыр, яшен... җәй, кыш, яз, көз ияләренә... ажунда була алган барлык ияләргә табынам!

— Мулла әйтә: җир, су, урман ияләре, айналар, өрәкләр, албастылар юк, ди, бары бер алла гына бар, ди.

— Күрдеңме, әнә алар йоласы бөтенләй башкача! — диде Тотыш, никтер кыза башлап.— Гарәпләр дә безнең кебек кеше. Таҗикләр дә, румнар, хытайлар... ар, чирмеш, урыс — барысы да ике аяклы, ике куллы кеше. Телләре башка да, йолалары башка. Менә шуны аңламыйм мин — барлык кеше өчен җир дә, күк тә, ай-йолдызлар да бер булгач, нигә аларның йолалары гына төрлечә соң? Ник берәүгә яраган икенче берәүгә ярамый? Гарәпләр... чумаклар өчен әнә бер-берең йөзне күрсәтү дә язык, безнең өчен — түгел. Ник болай бу? Кайсы моның чын? Бармы ажунда чын йола? Әллә болар барысы да бер саташу гынамы?

— Мин белмим,— диде Аппак.— Син әллә нинди сүзләр сөйлисең, Тотыш. Мин куркам. Мин тәңредән куркам, ияләрдән куркам.

— Син чумак ич — алладан курык,— диде Тотыш, көлемсерәп.

— Мин барысыннан да куркам, Тотыш,— диде кыз.— Курку минем каныма сеңгән. Мулла әйткәннәр исемә төшсә, кайчакларда котларым алына: ияләр ни әйтер, дим, ташлаган, оныткан өчен тәңре таш белән бәреп үтермәсме, дим. Күңелемнән минем беркайчан да ата-баба йоласыннан баш тартканым юк. Син алай тәңрегә, йолага тел тидермә, Тотыш.

— Мин тел тидермим,— диде егет.— Мин аңламыйм, мин аптырыйм. Минемчә, йолаларның яхшысы бар, яманы бар. Урлашырга, кеше үтерергә ярамый — яхшы йола. Ирләр, хатын-кызлар бер-берсенә битләрен күрсәтмәскә дигәне — яман йола.

— Әйе шул,— диде Аппак, килешеп.— Мин синнән йөз яшермим ич. Аны мин дә яхшы йола димим.

— Шулай да син миңа киенергә кушасың!

— Торымтай күрмәсен дим...

— Минеме? — диде Тотыш.

— Безне,— диде кыз.

Тотыш, әйтергә сүз таба алмыйча, аптырап, күңелсезләнеп утырды. Нәрсә соң бу? Нинди серле, яшерен нәрсә бар соң монда?!

— Атаңнан... ханнан курыксаң, мин әле аңларыем,— диде ул, әкрен генә сүзгә башлап.— Билгеле, хан кызы теләсә кем белән йөрергә тиеш түгелдер инде ул. Билгеле, ата кеше, хан булган кеше үз кызының ниндидер тотык белән очрашуын, яратышып йөрүен теләмәс. Анысы аңлашыла кебек. Ник Торымтайдан да яшеренергә? Ник?! Менә монысы аңлашылмый. Ник син, чумак йоласын яман дип уйлап та, үзең минем белән янәшә, минем белән бергә башка кешеләргә күренүдән куркасың? Нишләп син, кешеләрдән генә түгел, көннән, кояштан куркасың? Әллә дә баягы мин тотык булган өченме, «килмешәк» булган өченме?

— Юк, юк, Тотыш! — диде Аппак, куркып, аның муеныннан кочып.— Ни сөйлисең?! Ташка язмаганны!.:

— Алайса, син мине кызганып... алдап йөрисең?

— Юк, Тотыш!

— Нәрсә, тагын «йола»мыни? — диде Тотыш, мыскыл белән.

— Әйе, йола,— диде кыз.

— Йола?! Чынмы? Алда да йола, артта да йола, уңда да, сулда да! Төкерәм мин йолаларга! Төкерәм! — дип кычкырды Тотыш.— Мине яратудан тыя торган, мине ашаудан-эчүдән, күрүдән, ишетүдән тыя торган... минем кулларымны, аякларымны богаулап ташлый торган барлык йолаларга, инануларга төкерәм мин!

— Тотыш, тукта! — диде кыз, чыркылдап, коты алынып.

— Туктамыйм! — диде егет, ярсып.— Миңа тын җитми, миңа иркенлек җитми! Канатлар кирәк миңа — тәңре катына күккә менәм, болай яши дә, ярата да алмыйм!

— Язык, язык! — диде кыз, дер-дер калтыранып.

Колакларын ике кулы белән томалап, ул ишеккә ташланды.

## XII

Тотыш аның артыннан китеп тормады. Әзләргә чыкса да, ул инде аны таба алмас иде. Тапканда да, ни ассу?[1]? Үз кочагында чагында да ул аны үзенеке итеп тоя алмый. Аның өчен Аппак бар да, юк та. Ул аны — Тотышны — ярата да, яратмый да кебек. Ул буй җитмәслек агач башындагы матур алма шикелле. Аны алып булмый, кулга тотып булмый. Ике арада күзгә күренмәгән ниндидер киртә ята. Ул әйткәнчә, йола гынамы монда, әллә тагын бүтән нәрсә дә бармы?

Төптән уйлап караганда, монда әллә нинди аптырар нәрсә дә юк. Хан кызы була торып, нишләп әле ул аны... тотыкны... каяндыр урман арасыннан килгән бер томананы яратканлыгын башкаларга сиздерергә тиеш? Торымтай — шул ук озын колак. Сизсә, атасы аны шундук бирәр бигәме, чит илнең берәр ханынамы кияүгә тотып бирәчәк! Әйе, әйе! Чынлап та, сиздермәскә кирәк! Ничек тә кеше-карага сиздермәскә кирәк. Килсен генә, яратсын гына!

Үз-үзенә урын таба алмыйча, үкенеп, пошынып ул тирмәдән чыкты. Теге чактагы кебек ул аны эзләп каядыр китеп бармады. Бик үк теләмичә генә Торымтай тирмәсенә юнәлде.

— Аппакны күрмәдеңме? — диде ул аңа.

---

[1] Ассу — файда.

Торымтай, берни эндәшмичә, үзенең учагын дөрләтеп җибәрде, учак тирәсендәге чүлмәкләрен бер тирәгәрәк утыртып куйды.
— Аппакны күрмәденме? — диде Тотыш тагын, соравын кабатлап:
— Йокы да килми,— диде кол, чукрак кеше сыман үз алдына сөйләнеп.
— Нәрсә мыгырдыйсың син? — диде Тотыш, аның кисек колагына күзе төшеп.— Ник әйтмисең — Аппакның чыгып киткәнен күрмәдеңме дим?
— Нинди Аппак? — диде Торымтай.— Мин бернинди Аппакны күрмәдем.
— Баягынак та күрмәденме? — диде Тотыш юри генә, сынап карау өчен генә.
— Күрмәдем,— диде кол чын-чынлап.
— Син нәрсә, шаштыңмы әллә?! Әллә мине тилегә санныйсыңмы? — диде Тотыш, үз колагына үзе ышанмыйча.
— Юк, синең тирмәдә мин баягынак та, әле дә синнән башка беркемне күрмәдем,— диде Торымтай, кабатлап.
— Алайса, минем янга Аппак булып албасты килеп йөридер?
— Тфү, тфү! Минем колак ишетмәде, җирдә яткан таш ишетте...— диде Торымтай, такмакларга тотынып.
— Сез барыгыз да миннән нидер яшерәсез! — диде Тотыш, колның каршысына килеп.— Нәрсә? Әйтәсенме, юкмы?
— Син юкка кызасың, Тотыш,— диде кол ачусыз гына.— Синең тирмәдә минем синнән башка беркемне күргәнем юк.
— Син инде аны әйттең.
— Әйттем,— диде Торымтай, килешеп.— Син монда яңа кеше: йоланы, түрәне белмисең.
— Син дә шул ук сүзне сөйлисеңме?!
— Сөйләмичә! Балыксыз күл булмас, йоласыз ил булмас. Йолага, түрәгә, ханга буйсынмаган кешенең башын чабалар. Иртәгә кызгут була — онытмадыңмы?
— Онытмадым,— диде Тотыш кинәт сүрелеп, төшенке генә.
Торымтай янынннан ул тагын да ныграк пошыну, борчылу белән чыкты. Адым саен түрә, йола, хан... Билгеле, Акбүредә дә йола, түрә бар иде, тик анда ул үзен андый нәрсәләрдән ничектер көчлерәк сизә шикелле иде. Көчле үк сизмәгәндә дә, ул алардан курыкмый иде. Анда барысы да — урман, сулар да, иләр дә якынрак, аңлаешлырак иде. Монда да шул ук җир, шул ук күк, тик монда, кая гына барсаң да, ни генә эшләсәң дә, күзгә күренмәгән ниндидер коймага барып төртеләсең.
«Тотык өчен шулай булырга тиештер дә инде»,— дип уйлады ул бераздан, тагын үз уйларына үзе каршы килеп. Моннан соң ул чыннан да саграк булырга тиеш, алдын-артын карап йөрергә тиеш.
Тик икенче көнне үк ул үз-үзенә биргән сүзен онытып ташлады. Ул тагын саксызлык эшләде. Кызгутта, бөтен кеше алдында, хан алдында яшь чәчәнне яклап, сандувач!» дип ул кычкырды. Шулай ук «күктән килде!» дигән сүзләр дә аның авызыннан чыкты.
Якын-тирәдәге кешеләрнең барысы да диярлек ул икәнен күреп, ишетеп тордылар. Алай гына да түгел, Алмыш хан үзе дә, җаваҗ тирәсендәге башкалар да аның кычкыруын күреп-ишетеп калдылар. Тик беркемнең дә: «Тотыш кычкырды!» дип әйтергә теле бармады.
Кызгуттан соң аны хан янына чакырдылар. «Үлемем шушыдыр», дип уйлады башсыз егет, шүрли калып. Алмыш хан ака, көмеш аякка салып, агу урынына сычук бирде, аннары, тыныч булырга тырышып, сүзгә башлады.
— Тотыш углан,— диде,— күреп торам, син чыннан да бүрелар токымыннан икәнсең. Шуңа күрә ошыйсың да син миңа!
— Шуңа?! — диде Тотыш ышанмыйча.

— Шуна,— диде Алмыш хан.— Мина куйлар түгел, бүреләр кирәк. Кулга ияләшкән бүреләр...

— Анысы инде булмас, ханым! — диде яшь егет, әтәчләнеп.

— Мин сиңа ат бирергә, үзеңнең коралларыңны кайтарырга боердым, Тотыш углан,— диде Алмыш хан.— Корал сиңа кирәк булыр. Тик, кара аны, кеше арасында саграк бул!

— Ханым! Чынлапмы?! — диде Тотыш елмаеп, аягына басып.

— Минем көтүдән үзең теләгән атны сайлап алырсың,— диде хан.

— Изгелегеңне мәңге онытмам, ханым! Бай бул, тәңре сиңа күп яшь бирсен! — диде куанычыннан нишләргә белмәгән егет.

## XIII

Таң атар-атмас борын Тотыш тирмәсе янына ханның баш көтүчесе Утамыш килеп туктады. Җәен-көзен, төнен-көнен кырда-болында үткәргәнгә, аның җил кисеп бетергән җыерчыклы йөзе, корымланган чүлмәк төбе кебек, кара янып чыккан иде. Башына ул колакчынлы төлке бүрек, аякларына — озын кунычлы күн итекләр кигән иде. Үзе атланган атның ике ягына да иярләнгән ике ат таккан иде.

Иң элек ул Торымтайны уятты.

— Тотыш углан кирәкте. Уят аны,— диде, карлыккан тавыш белән, пышылдап.— Көтүгә барабыз. Үзенә ат сайлар. Ханның боерыгы... Иртәнге чык күтәрелгәнче тотарга кирәкте.

Торымтай ханның боерыгын белә иде. Ул тиз генә Тотышны кереп уятты. Тотыш аны-моны аңлап өлгергәнче, өйгә Утамыш көтүче килеп керде.

— Тор, киен. Тиз бул, углым,— диде ул, сүзне кыска тотып.— Ат сайларга барабыз. Чык күтәрелгәнче.

Йокысы ачылып җитмәгән Тотышның күз аллары яктырып китте. Ул берни сорашып, карулашып тормады, тиз арада киенеп тә алды, көтүче карт артыннан ияреп тышка да чыкты. Утамыш аңа үзе белән алып килгән атның яшьрәген, көрән төстәгесен бирде. Торымтай киң янбашлы ала бияга атланды. Алар, чыклы үләндә яшькелт эзләр калдырып, кояш чыгышына таба юл тоттылар.

Иртәнге күренеш искиткеч иде. Иксез-чиксез болын өстендә, Әтил аръягындагы сызылып кына күренгән күксел калку ярлар өстендә, ул яктагы урман буйларында йокымсырап иртәнге тынлык ята. Җирнең күе үлән белән, түмгәкләр белән капланган түбәнрәк урыннарында, ястык-ястык булып аксыл томаннар кабарып күренә. Шулай ук кайбер урман ачыклыкларында да, куаклар арасында да төргәк-төргәк томан кисәкләре эләгеп калган. Чикерткәләр әле уянмаган. Аның урынына әле анда, әле монда сыздырып-сыздырып сандугачлар сайрый, бытбылдыклар кычкыра. Шулай да бөтен җирдә, бөтен аҗунда олы, серле бер тынлык саклана.

Күктән ингән бу иртәнге тынлык та, сандугачлар сайравы, бытбылдыклар кычкыруы да Тотышка бик-бик таныш иде. Чык күтәрелгәнче, кояш чыкканчы дип, шушылай ат өстендә тирбәлә-тирбәлә каядыр барулар да, йокымсыраган аяк-кулларның авырлыгы да, салкынча тын алудан күкрәктә әкренләп-әкренләп күтәрелә барган җиңеллек тойгысы да — барысы да, барысы да таныш. Шулай да монда — җирдә, күктә, бөтен тирә-якта ниндидер яңа төрле киңлек-иркенлек бар, ниндидер яңа төрле куаныч-сөенеч бар шикелле. Бер карасаң, монда бөтен нәрсә җырлап-көйләп тора сыман, икенче бер карасаң — ниндидер әйтелмәгән моң-сагыш бар, гүзәллек, күркәмлек бар сыман. Чык тамчыларына күмелеп утырган үлән сабакларын, ак, сары, күк чәчәкләрне, сандугачларны кызганудан, яратудан, ниндидер, кайсыдыр бик якын кешеңне сагынудан, кайчандыр күңелеңне өтеп алган яшерен әрну, кимсену той-

гыларын искә төшерүдән үзгән өзгәләнеп елыйсы да килә, шул ук мәлдә каядыр күккә, биеккә ашасы да килә шикелле иде.

Шулай моңланып, уйланып барганда ул үзенең кичәгенәк «сандугач!» дип кычкырган үз тавышын ишеткәндәй булды. Гүзәллек, серлелек югалды. Тирә-як көтмәгәндә салкынаеп, шыксызланып калды. Билгесез куанычлар, моң-сагышлар белән тибрәнгән күңелне, ачы таш булып, әткеч без булып, чын кызгану тойгысы көйдереп алды. Бозылган, канаты каерылган сандугач белән чагыштырганда, күзгә күренмәгән сандугачларның сайравы моңсыз, күңелсез булып тоелды.

Алар сөйләшмичә шактый ара киттеләр. Хан урдасы утырган болын да, болын читендәге таллыклар да артта калды. Алар сирәк-мирәк куаклар белән, язгы ташу алып килгән ботак-сатаклы, тамырлы агачлар белән чупләнгән икенче бер болынга килеп чыктылар. Тирә-якта ниндидер вак күлләр, камышлыклар күренеп калды. Алда жиз кыңгырау тавышлары ишетелде. Көтүгә барып житәргә инде күп калмаган иде, ахрысы.

Менә Этил ягыннан беренче талган жил исеп куйды. Шомырт, кара зелпе куаклары, бер-берсе белән исәнләшкән сыман, жинелчә генә талпынышып алдылар. Каяндыр борынарга әчкелтем төтен исе килеп бәрелде. Атларның аяклары астыннан, куе үлән арасыннан, ыргытылган таш сыман булып, чәчрәп кошлар очып чыкты. Шул ук мәлдә тәбәнәк калкулыклар, урманнар артыннан кояшның сөңге башаклары күренгәндәй булды. Утамыш, киек куалаган аучы сыман, ашыгып тагын юртты-ра бирде.

Күп тә үтмәде, тәбәнәк куаклар да, жир өстенә сузылып яткан тамырлы агачлар да артта калды. Алда искиткеч киңлек, иркенлек ачылды. Монда болынның иге-чиге юк иде. Ут-үлән монда куерак, йомшаграк. Шушы иксез-чиксез киң болынны тутырып, елкы көтүе утлап йөри. Куаклыктан бер ярты чакрым чамасы арырак, тирә-ягын яшел камышлар әйләндереп алган түгәрәк күл буенда көтүчеләрнең киез тирмәләре күренә иде.

Куаклар арасыннан килеп чыккан жайдакларны иң элек этләр сизеп алды. Этләр өргән тавышка атлар да башларын калкытып карадылар, колакларын үрә торгызып, борын тишекләрен киереп, ят исләрне иснәделәр, кешнәп жибәрделәр. Тотышның Күрәне дә аларга каршы сузып кына кешнәп куйды.

— Исәнләшәләр,— диде Утамыш.— Этләр белән атлар кешедән белеклерәк. Алар әнә бер-берсен танып та алдылар, көтүчеләр әле күренми.

— Әнә берсе күренде,— диде Торымтай.

Чыннан да, тирмәләр ягыннан болай таба бер атлы кеше килә иде. Бу яшь бер көтүче булып чыкты.

— Барыгыз да аманмы? — диде Утамыш яшь көтүчегә, якынайгач.

— Аманбыз, Утамыш баба,— диде яшь көтүче.

Шулай дигәндә ул кызыксынып Тотышка карап алды, нечектер үз итеп, ягымлы итеп елмайды да, кырт кына борылып, кире чапты. Өрә-өрә аның артыннан этләр дә иярде.

— Менә сезгә Тотыш углан,— диде Утамыш, көтүчеләр янына килеп житкәч.— Кояш чыга, балалар. Чык күтәрелгәнче тотып бирергә кирәк берәр тулпарны. Корыкка элэктергәнче бәкәлдә чык суы кибеп өлгермәсә, атланган ат чыктай жинел, жилдәй житез, арысландай көчле була.

— Тотабыз, Утамыш баба!

— Була ул! — диештеләр көтүчеләр, ияр өстендә төз, нык утырган алып егеткә караштырып.

— Мин үзем тотармын. Корык бирегез дә...— диде Тотыш.

— Тотарсың, тотарсың, углан,— диде Утамыш.— Шулай да булышмый булмас.

— Минем булышчым бар,— диде Тотыш.— Каян икәнен күрсәтегез дә корык бирегез.

— Күрсәтәсе юк,— диде Утамыш, яшь егетнең үзсүзлеген ошатмыйча.— Көтү — янында. Алмыш ханның иң яхшы атлары шушында. Чапкын өчен, яу өчен симертелә. Ияр күрмәгәннәре дә, күргәннәре дә бар. Кайсын сайлыйсың?

— Мин үзем белермен, Утамыш баба,— диде Тотыш.— Корык бирәсезме миңа, юкмы?

Аның мондый кирелеген күреп, көтүче башының чын-чынлап йөзе җимерелде.

— Ай-яй! — диде ул, телен шартлатып.— Утамыш кебек көтүче бөтен Болгарда юк. Алмыш хан башта минем белән киңәшә. Син соң ханнан да белеклерәкмени, углан?

— Ат тоту өчен хан булуның кирәге юк, Утамыш баба,— диде Тотыш тыныч кына.— Үзең әйттең: сайлап алырсың, дидең. Ханның да боерыгы шундый. Ник аяк чаласың?

— Аяк чалган кеше юк, Тотыш углан,— диде Утамыш, йомшарып.— Әйтәм генә. Бар, кайсын телисең, шунысын сайла. Шулай да тиз кыймылда. Бирегез аңа корык!

Читтәрәк торган көтүчеләрнең берсе, Утамыш авызыннан «корык» сүзе чыгар-чыкмас, искәрмәстән Тотыш кулына җыелган аркан ыргытты. Тотыш көтүченең селтәнүен, күрүдән бигрәк, тоеп алды. Ялт кына борылды да кулын сузды, читкә очып барган аркан тәргәген эләктереп тә алды. Чит егетне сынарга чамалаган көтүченең, шулай ук аның янындагы башкаларның күз карашларында соклану билгесе чагылып китте. Торган саен ныграк үртәлә барган Утамыш та кинәт тынып калды.

— Ак юл сиңа, углан,— диде ул, мыгырданып.

Торымтай белән Тотыш күлдән ераклашкач исә, ул ачуыннан тузына башлады.

— Карап карарбыз, нинди тотарсың икән! — диде, төкеренеп.— Утамышны өйрәтүче табылган! Акбүре кергене! Урман арасыннан, аюлар яныннан килеп чыгалар да шулар, болгарлар алдында борын чөяргә тотыналар.

— Арканны нинди шәп тотты! — диде көтүчеләрнең берсе, телен шартлатып.

— Чәкән алпагытны шул чәнчелдергән ич инде! — диде икенчесе.

— Чәнчелдергән! — диде Утамыш, үртәлеп.— Алып-Тархан углы кебек бер селәгәйдер әле.

— Ә-ә! — диде шунда бер көтүче.— Корыч-Тимерне ул билсез калдырган.

— Орышта Корыч-Тимер үзен чак-чак кына чәнчеп үтермәгән! — диде Утамыш ачу белән.

— Үчен кайтарган инде,— диде икенче көтүче.

— Барыгыз, читтән генә күзәтеп йөрегез — көтүне куркытып, таратып бетермәсеннәр анда,— диде Утамыш.

— Таратсалар, үзебез җыярбыз,— диде яшь көтүче.— Тотыш алыпны бөтен Болгар мактап сөйли — ул гына танырга теләми, имеш!

— Ярар, телләшмә! — диде Утамыш, кырт кисеп.— Бар, эшегездә булыгыз.

Көтүчеләр якында гына утлап йөргән иярле атларын тотып алдылар да, атланып, кайсы кая китеп бардылар.

## XIV

Көтү бик зур иде. Меңләгән яшь, таза атлар, күз күреме җитмәслек киң болынны иңләп, таралып, иркенләп йөриләр иде. Аларның кайберләре, муеннарын сузып, каршы искән җилдә ниндидер үзләренә генә

таныш исләрне тоталар; кайберләре, койрыкларын селтәп, тынычсызланып, биеп, уйнаклап, башкалар арасында туктаусыз йөренеп торалар. Кайберләре, көтмәгәндә берәрсе белән очрашып, куркып-өркеп бер-берсен иснәштерәләр, икенче берәүләре, чиный-чиный, мышный-мышный, каты тояклары белән дөп-дөп бәреп, үзара чын-чынлап яу ясап яталар. Үзара тибешүчеләрдән арырак, икенче берәүләре, шаянраклары, матур башларын алга сузып, озын ялларын җилфердәтеп, койрыкларын күтәреп, бер-берсен узыша-узыша, «качышлы уйныйлар».

Монда күк атлар да, акбүзләр дә, кара-туры, коба-турылар да, җираннәр дә, колалар да, алалар да, кашкалар да — барысы да, барысы да бар иде. Кайбер атларның койрыклары юри озын көе калдырылган, кайберләренеке, киресенчә, кыска итеп киселгән иде. Күз тимәсен, урман иясе, саз иясе бозмасын өчен, кайсыбер атларның ялларына, койрыкларына төрле төстәге чүпрәкләр тагылган иде.

Күзләре уттай янып торган, яфрак селкенсә дә, колаклары үрә торган сизгер яшь байталлар, яшь айгырлар, чит кешеләр якынлашу белән, шундук читкә китеп бардылар я булмаса, күптәнге танышларын күргән сыман, бернинди тартынусыз яннарына килделәр, атларын иснәләштерделәр: әрсезрәкләре, арттан калмыйча, койрык булып тагылып йөрделәр.

Атлар күп иде, бик күп иде. Аларны җентекләп карау өчен бер көн түгел, биш көн кирәк булыр иде. Баш көтүче әнә биш көн түгел, бер күлем дә бирми — тизрәк, тизрәк, ди, чык күтәрелгәнче, ди. Кара, нинди белекле! Кем уйлап тапкандыр ул «чык күтәрелгәнче»не?!

Тотыш атын кызу атлатып барды. Аңа атларның берсе дә ныклап торып ошамады. Көр, чибәр атларның ул әле берсенең, әле икенчесенең кимчелеген тапты. Кайсының төсен, кайсының башын, аягын, кайсының билен яратмады. Күңеленнән ул үзенә коштай җиңел, корычтай чыдам, ялкындай җитез ат эзләде. Ни әйтсән дә, ул аның үз аты булачак! Ике ел буена ул аның иң якын юлдашы, кадашы булачак. Шулай булгач, ничек инде ул ашык-пошык сайласын аны!

Як-ягына карана-карана, күзәтә-күзәтә ул болынның әле бер җиренә, әле икенче җиренә барып чыкты. Юк, аңа ошаган ат очрамагач очрамады. Ул арада кояш күтәрелгәннән-күтәрелә барды, көн җылынды, чыклар кипте. Чәчәкләрдән татлы исләр бөркелә башлады. Әтил ягыннан искән талкын җил үзе белән бал исе, су исе алып килде. Меңләгән, ун меңләгән тояклар таптаган, шулай да таптап, тигезләп бетерә алмаган биек үләннәр арасында берөзлексез чикерткәләр чәкелдәде, кошлар сайрады. Ажун уянды, чын-чынлап уянды.

Яшь егетнең чырае бозылганнан-бозыла барды. Утамышның сүзләренә бик үк ышанмаса да, шулай да аның «чык күтәрелгәнче»се күңелен тырнап, эчен пошырып тик торды.

— Болай ашыгырга ярамый,— диде ул, атын туктатып,— Ашыйсы да килә. Әйдә кире борылабыз. Төштән соң яхшылап карарбыз.

Алар борылдылар да түгәрәк күл ягына карап киттеләр.

— Тапмадыгызмыни? — диде Утамыш, аларның буш кул белән килүен күреп.

— Тапмадык,— диде Тотыш.

— Иртәгә иртәрәк карап карарсың тагын,— диде Утамыш, ашыгып.— Әйдәгез, ашарга утырыгыз. Кояш югары — ашаган югале...

Тотыш атны кешәнләп утларга җибәрде. Торымтай белән алар күлдә битләрен, кулларын юдылар, учак янына, киез өстенә килеп утырдылар. Утамышның ише, озын киндер күлмәк итәген биленә кыстырып куйган шадра хатын, агач табакка салып, пешкән балык, ботка китерде, тулып, бүлтәеп торган турсык китерде.

— Без ашадык. Сез генә калдыгыз. Әйдәгез, җитешегез,— диде хатын Тотыш белән Торымтайга.

Кунаклар ашаган-эчкән арада Утамыш, аякларын чирәм өстенә сузып җибәргән килеш, үзенең нярен төзәткәләде.

— Якын-тирәдә кан коелдымы, бүре җыела,— дип сөйләнде ул үзалдына.— Төннәрен көтүгә киләләр. Бүген төне буе шулар белән сугышып чыктык. Бишесен үтердек. Бер байталны талаганнар.

Тотыш аның шулай әкрен генә сөйләнеп утыруына бөтенләй колак салмады. Шулай да бүреләр белән сугышу турындагы сүзләрне ул ишетеп калды. Шундук ул үзенең изге нарат янындагы төнге сугышын исенә төшерде. Нинди башсыз булган ул! Атасы булмаса, Утташ кам инде күптән аның башын ашаган булыр иде. Атай, анай!.. Кайда икән алар? Өйдә микән, исән микән алар? Уйлый микән алар үзләренең игелексез угылларын?

Шулай уйланып утырганда аның күзенә бер нәрсә чалынып калды. Кулмәк итәген биленә — эч тун бөрмәсенә кыстырып куйган шадра хатын, кулына тоткан чүлмәген ничектер качыргандай кыланып, якындагы куаклыкка кереп чыкты.

— Булдымы, туйдыгызмы? — диде Утамыш, эшеннән аерылып, кунаклар ягына карап.— Бал куйганыек та, булуы җитмәгән. Иртәгә авыз итәрсез инде.

«Тизрәк кайтарып җибәрмәкче була»,— дип уйлады Тотыш, яратмыйча.

Бераз тынып утыргач, алар яңадан атларына атландылар. «Тагын бер әйләнеп чыгарга кирәк»,— дип уйлады Тотыш, ныклы бер уйга килеп.

— Ярый, алайса, углан,— диде Утамыш, саубуллашырга ашыгып.— Иртәгә иртәрәк үзегез килерсез, мин барып алганны көтеп ятмассыз.

— Сау бул, Утамыш баба,— диде Тотыш, кузгалып.

Ул, урда ягына китәсе урынга, көтү ягына юнәлде. Баш көтүче, моны күреп, тынычсызлана башлады. Авызын ачып, нидер әйтергә дә итте, әйтә алмады. Куаклык буйлап китеп барган Тотыш кинәт сулга каерды, тар аралыктан андагы әрәмә эченә кереп китте. «Эх!» диде Утамыш көтүче, ырылдауга охшаш бер өн чыгарып. Кулына күсәк алды да ашыгып Тотыш артыннан йөгерде.

## XV

Куаклык эчендәге кечкенә аланда утлап йөргән атны Тотыш бөтенләй искәрмәстән күреп алды. Ат тышаулы иде. Нукта тезгене тышауга тарттырып бәйләнгән. Шуңа күрә ат, теләсә дә, теләмәсә дә, башын калкытмыйча, шушы аланда гына утларга тиеш.

Тотыш якынрак килде, караштыра башлады. Тышаулы ат, чит кеше килүен сизеп, ашавыннан туктады, колакларын шомартты, башын калкытырга тырышып карады. Ул озын, нечкә торыклы, киң күкрәкле иде. Аның йомры, нечкә биле, янбашлары сыгылып, уйнаклап тора иде. Ялы, койрыгы яхшылап киселгән, таралган. Бу Тимеркүк искиткеч сылу иде!

— Кашка! — диде Тотыш, аның маңгаендагы ак йолдызын күреп.

Сикереп ул атыннан төште, Тимеркүкнең нуктасыннан эләктереп алды, тезген очын чишеп җибәрде дә иплән кенә, иркәләп кенә атның күкрәгеннән, муеныннан сыйпалый башлады. Маңгаендагы кашкасы белән генә түгел, үзенең буй-сыны белән, үз-үзен тотышы, күз карашлары белән ул Тотышның йолыкка чалынган Йолдыз-кашкасына охшаган иде!

Тотыш бар нәрсәсен онытып Тимеркүкне сыйпалаганда, аланга, агарынып, Утамыш көтүче килеп җитте.

— Бүре талаган! Бүре талаган! — дип кычкырды ул ерактан ук, тыны бетеп.

— Мина бу ошый,— диде Тотыш, елмаеп.
— Бүре талаган диләр сина! — дип кычкырды Утамыш, күсәге белән кизәнеп.
Кабаланудан ул туры төзи алмады — күсәк Тотышка тимәде, бары Тимеркүкне генә өркетте. Утамыш, тиле сыман, атның муенына асылынды.
— Бүре талаган, бүре талаган! — дип сөйләнде ул, бер үк сүзләрне кабатлап.
— Кай җирен талаган? Берни күрмим — диде Тотыш.
— Талаган, талаган! — диде Утамыш, атның нуктасыннан кысып тотып.— Ярамый! Булмый! Бирмим!
— Таласын. Мин шушы атны алам,— диде Тотыш, үзсүзләнеп.— Ярасын үзем төзәтермен.
— Кит! Якын килмә! — дип кычкырды Утамыш, күсәген яңадан кулына алып.
Тотыш атның бер ягында, Утамыш икенче ягында иде. Тотыш, теләсә, билгеле, атка сикереп атланган да булыр иде. Ул атланмады. Ул каушабрак калды. Утамыш эре сөякле, каты куллы иде. Анда тыелгысыз көч котырына иде.
— Ярар, бирмәсәң бирмә,— диде ул, кире чигенгәндәй итеп.— Ханга җиткерәм. Торымтай, таные бул: хан боерыгын үтәмәде.
— Таные! Таные! Хан боерыгын үтәмәде! — дип кычкырды Торымтай.
Тотыш, Тимеркүкнең нуктасын ычкындырды да, читкә китеп барган иярле аты янына ашыкты. Иярле ат аланның икенче башында ашанып тора иде. Тотыш, атына атланганда, куаклар арасында шалаш сыман нәрсә күреп, тоткарланып калды. Аягын өзәнгедәй кире алып, кызыксынып, ул әлеге яшерен куыш янына килде.
Агач ботакларыннан корыштырган шалашта, яңа чабылган печәндә бер кеше ята иде. Ул, ахрысы, чирле иде. Өстенә аның юка түн ябып куйганнар, авызы турысына ак яулык каплаганнар иде. Ник шулай кеше күзеннән яшерделәр икән соң аны? Шалашы тәбәнәк кенә — ерактан түгел, якыннан да күрерлек түгел.
Тотышның якынлашуын күреп, шалаштагы кеше ыңгырашып куйды, калкынгандай итте. Шунда аның авызын каплаган яулыгы бер читкә шуышты. Тотыш, куркуданмы, таң калуданмы, чак-чак кына кычкырып җибәрмәде: яшерен шалашта Бәкәч чәчән ята иде! Аның иреннәре күпкән, авызы ярым ачык иде.
— Сан-ду-у-ва-ач! — диде Тотыш, исе китеп.— Менә кайда икән синең ояң!
Аның янына ашыгып тагын Утамыш килеп җитте.
— Кит моннан, кит, Тотыш углан! — диде ул, үтенеч сизелгән бер йомшаклык белән.— Ярамый. Савыксын, борчыма.
Бәкәч чәчән, күрәсең, янына кешеләр килүенә куанып, көчәнеп урыныннан торды, ниндидер кызганыч бер тавыш белән мөгердәп, ярым йомык күзләрен киереп ачты да Тотышка текәлде. Аның бу күз карашы — соклану да, нидер үтенү дә, әрнү дә белдергән моңлы күз карашы тотык егетне тетрәндереп җибәрде.
— Кузгалма, балам, тыныч кына ят,— диде Утамыш, яралы сандугачның авыз тирәсендәге чебеннәрне куып.
Аңа каршы чәчән ниндидер өн чыгарды, Тотышка төртеп күрсәтә-күрсәтә, чандыр кулы белән селтәнеп-селтәнеп алды — аның бу селтәнүен кылыч белән чабу, сөнге белән кадау дип аңларга була иде. Шуннан соң ул Тотышка үзенең балаларныкы шикелле кечкенә кулын сузды. Тотыш иплән кенә аның йомшак, көчсез кулын кысты.
— Тотыш углан була бу, балам,— диде Утамыш, никтер каушагандай итеп.

Бәкәч чәчән, белгәнлеген аңлатып, көтүчегә баш какты, күзләре белән елмаеп куйды.

— Шулаймыни? — диде Утамыш.— Син каян беләсең аны, Тотыш углан?

— Беләм инде,— диде Тотыш, чәчәннең үзен тануына аптырап.— Аны бөтен Болгар белә... нишләп белмәскә!

— Кичер мине, углан,— диде Утамыш көтүче, читкә борылып, күз яшьләрен сөртеп.— Тимеркүкне мин аңа... үзебезнең сандугачка атаганыем. Күз алдында булсын, юанып ятсын дип янына җибәргәнием. Синең кебек ул да атны таный, ярата. Теләсәң ал, миндә тагын икенчесе бар.

— Юк, Утамыш баба! — диде Тотыш, билен язып.— Болай булгач, мин Тимеркүктән баш тартам. Син миңа, булмаса, шул икенчесен бир.

## XVI

Шулай да ул урдага Тимеркүккә атланып кайтты. Йолдыз кашкалы байталны аңа Утамыш түгел, Бәкәч чәчән бирде. Тотыш атны алса да алды, алмаса да алды. Бары тик Бәкәч чәчәннең, баш тартканын күреп, йөзе үзгәргәч кенә ул үзенең икеләнүен җиңә алды. Төрле ымлыклар, кул болгаулар белән Бәкәч аңа Тимеркүкне бүләк иткәнлеген аңлатты. Бүләктән баш тартмыйлар, диде, яхшы ат миннән бигрәк сиңа кулайрак, диде.

Юл буена Тотыш уйланып кайтты. Моңарчы ул бары үзе турында гына, үзенең язмышы турында гына уйланса, бүген ул башкалар турында уйланды. Үзенең кордашы, яшь егет аңа бик-бик кызганыч булып тоелды. Ник шул тикле күңеленә якын алды соң әле ул илгизәр чәчәннең авыр язмышын? Җырулары шулай тиз арада күңел кылын чиртеп өлгердеме, әллә аның кызгуттагы кыюлыгы күңелен биләдеме? Ни генә булмасын, яшь чәчән язмышында ул үз язмышын күргәндәй булды.

Урдага кайтып җитү белән, аның каршысына каяндыр шар күзле юан гына бер кеше килеп чыкты. Ул үзен Алмыш ханның агычысы [1] дип белдерде.

— Сиңа, Тотыш алып, шаеңны [2] кайтарып бирергә, дигән боерык бар,— диде ул түбәнчелек белән.

Тотыш аның артыннан иярде. Алар хан тирмәсенә якын урнашкан бер зур гына тирмә янына килделәр. Агычы, билбавына тагылган ачкычларын бармаклары белән аралаштырып, арадан берсен тотты да калын ишектәге зур йозакны ачты, эчкә кереп китте. Ул Тотышның сөңгесен, күбәсен, калканын чыгарып җиргә куйды, аннары җәясен, уклыгын, ияren алып чыкты. Үз коралларын күреп, Тотышның йөзе балкып китте. Ул шундук үзенең сөңгесен, калканын кулына алмакчы булды.

— Башта кулыңны куй,— диде агычы.— Яза беләсенме? Менә бу тузга тамгаңны куй.

«Шаемны Алмыш ханнан алдым. Тотыш», дип язып куйды яшь егет, үзенә бирелгән туз кисәгенә.

Агычы аның шома, җиңел язуына исе китеп карап торды.

— Син әле шулай язу таягы белән дә селтәнә беләсен икән! — диде ул.

— Беләм шул,— диде Тотыш.

— Беләге бар — берне егар, белеме бар — меңне егар! Сиңа битекче булыргае,— диде агычы, Тотыш биргән барчакны калтасына салып куеп.

— Битекче? Нигә? — диде Тотыш болай гына, артык сүз куертасы килмичә генә.

---

[1] Агычы — хәзинәче.

[2] Шай — сугыш кирәк-яраклары.

— Битекченең эше изгерәк. Сез, алыплар, кеше үтерәсез. Кеше үтерү — язык. Алмыш хан әнә төрек ижекләре язылган абакларны, билгеташларны юкка чыгармакчы була, ди.

Соңгы сүзләрен ул Тотышка якын ук килеп, пышылдап диярлек әйтте. Әйтте дә сакчылар ягына хырын күз карашы ташлап алды, көрсенеп куйды.

— Син монда яңа кеше шул әле,— диде аннары, үз итеп.— Син әле күп нәрсәне аңламыйсың. Бозылды ажун, бозылды тормыш. Ханнын, биләрнең балаларын җыеп әнә гарәпчә укыталар, төрек ижегенең көне төкәнде. Ничек түзә моңа тәңре?! Уйласаң, башлар әйләнә. Кичә мәнә Бәкәчтән дә колак кактык. Бозылды улус, бозылды ханнар...

Тотыш анын кайгылы сүзләрен бик үк тынламады. Сөенеченнән нишләргә белмичә ул үзенең киемнәрен киде, билен буды. Аннары ул атына атланды, алпаклы башын югары тотып, биек тирмәләр арасыннан үз өенә юл тотты.

Көне буена ул үзендә бер куанычлы җиңеллек тойды. Әйтерсең, аңа инде бүтән берни дә кирәкми иде. Әйтерсең, аның инде барлык теләкләре тормышка ашкан иде. Көне буена ул үзенең Тимеркүге белән булды: Өсән буена барып ул аны су кертте, юды, кыргычлады, анын ялларын, койрыкларын тарады. Аты белән эшен бетергәч, ул үзенең коралларына тотынды — ышкыды, ялтыратты, кайрады...

Ул арада кояш та баеды. Җир өстенә кичке талгынлык саркый башлады. Ышкыйсы, тазартасы, төзәтәсе эшләре беткәч, Тотыш бушанып калгандай булды, өенә керде дә, тезләрен кочаклап, кызу учак каршысына утырды.

— Корал тотып кая барырмын икән соң мин? — диде ул, үзалдына сөйләнеп.— Миңа инде су керергә барганда да кылыч күтәреп йөрергә туры килер микәнни?

Кинәт аңа күңелсез булып китте. Тимеркүк тә, кораллары да, киемнәре дә — бөтен нәрсә аңа кирәксез булып, чит, ят булып тоелды. Чыннан да, ник сөенде соң әле ул көне буена? Кемгә каршы сугышачак, кем өчен сугышачак соң ул? «Сандувач»ның телен кистергән хан өченме, әллә аның кызы өченме?!.

Ах, шулай ук яратмый микәнни ул аны? Тимеркүккә атланып кайтканны күрде микән? Чын күңелдән яратса, билгеле, күрер иде, каршысына чыгар иде, котлар иде. Ни языгы бар моның? Юк, чыкмады, котламады. Аның өчен, аңа күренү өчен атланып йөрде түгелме соң ул өйләр арасында? Кайда булыр ул көндез? Баш калкытмый мулла алдында укып утырамы, әллә соң Әгил буенда кызлар уенындамы?

«Уйламаска кирәк моннан сон. Хан кызы белән тотык арасында беркайчан да чын яратышу булмаячак»,— дип уйлады ул. Учак яныннан торды да, Тимеркүкне күрәсе килеп, тышка чыкты, Торымтайның Җирәнкәе белән утлап йөргән тышаулы аты янына килде.

Бүген ул беркемне дә көтмәде. Җиргә җәелгән киез өстенә сузылып ятты да еракта янган йолдызларга текәлде. Тиздән аңа монда да күңелсез була башлады. Ул янадан өенә керде, йокларга ятты. Күзен йомып та өлгермәде, ишек тарткан тавыш ишетеп, сикереп урыныннан торды. Эчке бер сизенү белән ул аның Аппак булырга тиешлеген аңлап алды.

— Кер! — диде ул, эчтән ишек бавын чишеп.

Ишекне ачып җибәргән иде, тимер киемнәрен чылтыратып, чатыр эченә караңгыдан ниндидер кораллы ир атылып килеп керде. Тотыш артка чигенде. Шул ук мәлдә ул, үзенең кылычын, калканын исенә төшереп, ятагы янына омтылды.

— Кузгалма! — диде кораллы ир, боерып.

Аның бу куркыныч тавышында көлемсерәү ишетелеп киткәндәй булды. Тотыш кинәт телсез калды. Сүрелеп барган учак яктысында ул

кораллы ирнен буй-сынын күздән кичерде, карлыккан, иокылы бер тавыш белән:

— Син кем? — диде.

Коралллы ир, битлеген артка ташлап, көлеп җибәрде. Тотышка бикбик кыен булып китте.

— Сиңа ни кирәк? — диде ул, каушавын яшерергә тырышып, ясалма бер усаллык белән.

— Син кирәк! — диде Аппак, көлә-көлә.

— Төн уртасында... кеше өенә басып керергә...— дип мыгырданган булды Тотыш.

— Үз өемә керү... басып керү түгел,— диде Аппак.

— Атаң өенә дип белсәң генә...— диде Тотыш, чеметтереп.

Аппак, башына суккан сыман, тынып калды, коралларын идәнгә куйды да алпагына тотынды.

— Авыр, үлә яздым,— дип сөйләнде ул.

Шуннан соң ул көйрәп яткан учак янына килде, учакка утын өстәде дә чәчләрен төзәткәләргә тотынды.

— Кичер мине, Тотыш,— диде ул.— Үзең «кер» дидең ич. Ник тагын авызыңны күптердең? Киен, әйдә киттек.

— Кая?

— Кая булса да! Оялмыйча йоклап ятмакчы буласыңмы? Җәйге төн шундый матур? Синең инде атың, коралың бар... Теге көнне әллә нәрсәләр әйтеп минем күңелемне кырдың да, мин бик борчылдым. Әнә, карар йөзем дә калмаган. Карале, мин бик ямьсезләнмәгәнменме?

Ут яктысында ул Тотышка әле бер як битен, әле икенче як битен күрсәтте, ак тешләрен юри ыржайтып, ясалма бер елмаю белән елмаеп алды.

— Син — гүзәл! — диде Тотыш, күңелендәге бозны йотып.— Шулай да мин аңламыйм: ник киендең ул киемнәрне? Нишләп болай килдең? Кая бармакчы буласың?

— Баргач күрерсең,— диде Аппак, серле итеп. Ул алпагын яңадан башына киде.— Болай матурмы? Чын ир булдыммы?

— Булдың! — диде Тотыш.

— Коралларыңны ал, Тимеркүккә атлан,— диде кыз.

— Син күрдеңмени! Тимеркүккә атланып йөргәнне син күрдеңмени?! — диде Тотыш.

— Күрдем,— диде кыз.— Әйдә, киенәсеңме, юкмы?

— Киенәм! — диде Тотыш.

Бераздан алар, атларын әкрен генә атлатып, сөңгеләрен югары тотып, караңгылыкка кереп юк булдылар. Хан урдасын саклаучы төнге каравылчылар да шулай, сөңгеләрен югары күтәреп, икешәрләп йөриләр иде.

## XVII

— Мин сине бүген килерсен дип уйламадым,— диде Тотыш, кычкырып.

Аппак үрелеп каты гына аның беләгенә орынып алды.

— Шауламa! — диде ул, пышылдап.— Әкренрәк. Үзем әйтермен.

Ул үзенең нәрсә әйтергә теләвен әйтеп бетермәде, Тотыштан читкәрәк китте. Алар, каядыр ашыккан атларын тыя төшеп, урдадан ераклаша бардылар. Якында гына башын калкытмыйча, ниндидер ялгыз ат ашанып йөри иде, шунда ук ялгыз ат янында ялгыз кеше басып тора иде. «Торымтай ич!» дип уйлады Тотыш. Ул аңа берни эндәшмәде, бары атлар гына, җиңелчә кешнәп, бер-берсенә тавыш бирделәр.

Алар Өсән буена, таллыклар арасына барып чыктылар. Анда да, сулда да — куаклар арасында ниндидер карачкылар күренгәндәй булды, ат мышнаган, тимер чыңлаган тавышлар ишетелеп китте.

— Ник килдек монда? — диде Тотыш, пышылдап.
— Үзем беләм,— диде кыз.— Миннән калышма. Шаулама.
Комлы сөзәк ярдан Аппак беренче булып төште. Берни сорашмыйча, берни аңламыйча, Тотыш аның артыннан нярде. Таллыкта да, яр буенда да аларга беркем очрамады. Шулай да Аппак атын әле булса сак атлатырга тырышты. Тавыш-тынсыз гына алар, карачкылар кебек, суга керделәр. Бу төштә елганың төбе ташлы иде. Атлар аягы астында таш шакылдаганы, шаулап су акканы ишетелеп торды. Елга уртасында Аппак атын эчерергә туктады. Тимеркүк тә туктап эчәргә тотынды. Атларны эчергәч, алар яңадан кузгалып киттеләр, икенче як ярга чыктылар да, караңгы, текә ярдан өскә менделәр. Монда тирә-як урманлы иде. Урманда да Аппак шактый сөйләшми барды. Бары тик ниндидер ачыклыкка килеп чыккач кына ул шаулатып бер тын алды да тыелып кына көлеп куйды.
— Уф, шундый курыктым! — диде ул, йөрәген тотып.— Таллыкта... бездән уң якта... икәү торып калды. Күрдеңме?
— Күрмәдем,— диде Тотыш,— Торымтайдан башка мин беркемне күрмәдем.
— Тотып карале: нинди тибә! — диде Аппак, аның сүзен тыңламыйча.
Тотыш, үрелеп, кызның йөрәк турысына кулын куйды: аның йөрәге чыннан да кош кебек талпынып, ашкынып тибә иде.
— Сиңа күңелле түгелме монда? — диде кыз, биек агач башларына, агач араларындагы караңгылыкка карапып.
— Күңелле! — диде Тотыш.— Шулай да мин Этил буена барырыем. Мин төнге елганы яратам.
— Мин дә! — диде Аппак.— Кечкенә чакта без барадырыек кич су буена. Үскәч менә булмый. Әле бүредән, әле юлбасардан куркасың.
— Безгә бүре дә, юлбасар да чыкмас,— диде Тотыш.— Киттекме?
— Юк, ул якта каравыл көчле,— диде Аппак.— Монда — урман, Өсән. Монда тынычрак. Мин юлны беләм. Урда турысын узгач, каравыл юк. Тик безгә кире елга буена төшәргә туры килә.
Алар шулай иттеләр дә. Яңадан Өсән буена чыктылар да ниндидер аланнар аша киттеләр. Аппакның әйтүенә караганда, төнге каравыл бу якка чыкмый иде, шулай да алар бу якны да күзәтәләр иде. Алар ничек тә тавыш-тынсыз барырга тырыштылар. Бер-ике җирдә аларга елга аръягында ягулы учаклар, учак тирәсендәге кешеләр күренеп калды.
Менә учаклар да, учак тирәсендәге карачкылар да ерагайды. Ул арада җирне каплап яткан куе караңгылык сыеклана башлады. Юлчылар ниндидер сөзәк яр буенда туктап калдылар. Кайдадыр якында гына өздереп-өздереп сандугач сайрады, әллә яр астында, әллә теге яктагы сазлыкта бакалар кычкырды. Тезгеннәрнең бушаюын сизеп, атлар сусыл үлән умырдылар.
— Монда аулак,— диде Аппак.— Мин арыдым. Кием авыр.
— Әйдә, төшик,— диде Тотыш.
Алар атларыннан төштеләр дә киемнәрен, коралларын салып куйдылар, аякларын салындырып, яр буена утырдылар.
— Мин менә шундый яр буенда утырырга яратам,— диде Аппак, егетнең кулыннан тотып алып.— Беләсеңме, төнлә әллә ничек... бөтен нәрсә серле, моңлы... агачлар да, елга да. Этилне мин бик үк яратып житкермим,— диде ул, әлерәк кенә үзе әйткән үз сүзләренә үзе үк каршы килеп.— Миңа менә шушындый кечкенә елгалар ошый. Этил киң, тирән, якын бардың исә, таргып алыр сыман. Монда миңа бөтен нәрсә таныш, якын. Шушы төштән астарак, теге якта — кура җиләклеге. Көндез без анда җиләккә барабыз.
— Миңа зур сулар ошый,— диде Тотыш, уйчан гына.— Нәзә белсәң, бер су да куркыныч түгел. Минем төнлә Чулманны йөзеп чыкканым бар.

— Төнлә дисенме?! — диде Аппак, куркь ергә ярамый — су иясе тота.

— Бездә дә шулай куркыталар... бала-чаганы,— диде Тотыш, көлеп.— Сынап карамакчы булдым, Юри. Беренче көнне сай җирдә генә йөздем. Күнегә төшкәч, ераккарак йөзеп бардым. Бер көнне тоттым да икенче якка йөзеп киттем.

— Беркем дә тотмадымы?

— Юк,— диде Тотыш.— Балыкчылар төнлә балык тоталар ич! Салчылар төнлә сал белән агалар ич! Аларны тотмагач, ник мине генә тотсын!

— Сөйләмә, мин куркам,— диде кыз, дерелдәп.

— Кемнән? Миннән курыкмыйсындыр ич?

— Курыкмыйм,— диде кыз.— Юк, кайчагында куркам. Син мине яратмассың шикелле. Мин яраткан кебек. Чынлап. Мин сине теге орышта беренче күргәч тә... юк, син Чәкән алпагытны дөмектергәч тә ярата башладым шикелле. Алай да түгел. Мин синең турыда уйлый башладым. Беләсенме, Чәкән Алпагыттан куркадырыем мин. Ул мине үзенә хатынлыкка сораган. Син мине ике тапкыр үлемнән коткардың, Тотыш!

— Син мине шуның өчен генә яратасыңмы? — диде Тотыш.

— Әйе, шуның өчен дә,— диде кыз.— Аның өчен генә дә түгел. Белмим. Мин синнән башка тора алмыйм. Мин гел сине уйлыйм, Тотыш. Карале, син мине мәңге яратырсың микән?

— Мәңге! — диде Тотыш, нык итеп, кызны күкрәгенә кысып.

— Инде үлсәм дә үкенмим! — диде кыз, кайнар пышылдап.

## XVIII

Төн карасы чынлап тарала башлаганчы алар кузгалып киттеләр. Килгән юллары аларны урда ягына алып кайтты.

Алар икенче, өченче көнне дә, атларына атланып, шулай Өсән аръягына чыктылар, киң болыннарда, караңгы аланнарда йөрделәр, шаярып атларын узыштырдылар. Төнлә аларны беркем борчымады, беркем уңайсызламады. Тотыш кызның бары караңгы төшкәч кенә, кеше аягы басылгач кына үз янына килүенә инде аптырамады да, борчылмады да. Болай аңа күңеллерәк тә тоелды. Көндез ул Агабазарга барды, Этил буенда йөрде, балык тотты, су керде, кич караңгы төшү белән, түземсезләнеп, яшерен очрашуны көтә башлады. Очрашкач алар бер-берсенә көндез күргән нәрсәләре турында сөйләделәр, бер-берсен яратулары турында, беркайчан да, берничек тә бер-берсен ташлашмаулары турында антлар бирделәр.

— Карале, Тотыш,— диде бер көнне Аппак, ничектер уйчанланып.— Мин картайгач, ямьсезләнгәч, син яшь хатын алмассыңмы?

— Син миңа картаймассың кебек,— диде Тотыш, кызның кайнар, йомшак кул аркасын иркәләп.— Синең белән бергә булганда без беркайчан да картаймабыз да... үлмәбез дә шикелле, Аппагым!

— Тотыш, нигә шундый сүзләр сөйлисең? — диде кыз, пошынып.— Үлми торган кеше булмый. Тәңре генә, ияләр генә үлемсез.

— Алай дип әйтүнең ни языгы бар? — диде Тотыш.— Мин яшь, көчле. Буем җитсә, берәм-берәм йолдызлар чүпләрием мин... синең өчен!

— Тагын! — диде кыз, шелтә белән.

Күзләре белән генә елмаеп, егет аның сылу йөзенә карап торды. Иплән кенә аның биленнән кочып алды, аның кайнар иреннәренә үрелде, үпте. Сандугачлар кинәт тынып калды, йолдызлар күзләрен йомдылар. Бөтен тирә-як — каралҗым болыннар, күлләр, куаклыклар, артта калкып утырган калын урман, ике яшь йөрәкнең куанычлы тибешен тыңлап, оялчан гына тынып калдылар.

— Син мине языклы иттең,— диде кыз, ярым ачык иреннәрен көчкә кыймылдатып.

— Юк әле, итмәдем,— диде егет, шаянланып.

Шашкын бер көчкә буйсынып, ул аягына басты, кызны кул очына күтәрде, сабый бала тибрәткәндәй, бер-ике тапкыр селкетте дә, туп шикелле итеп күккә чөйде, тотып алды.

— Күрдеңме, чак-чак кына очырмадым! — диде ул, мактанып.

— Шулай да син әйтмәдең: миннән башка хатын алырсыңмы? — диде Аппак.

— Син дә әйтмәдең: кайчан без бергә булырбыз? — диде Тотыш.

— Мин әйттем: синең тотыклыгың бетми торып, атам мине сиңа бирмәячәк.

— Бирсә әле! — диде Тотыш, кинәт уйчанланып.

— Әйдә онытыйк ул турыда? — диде Аппак.— Тик торганда кирәкмәгән нәрсә сөйли башлыйсың.

— Минем эчем поша. Күнелдә әллә нинди төен бар,— диде Тотыш.— Ник тотыклык беткәнне көтәргә? Барыбер түгелмени? Әйт: атаң каршы килмәсә, син үзең... бүгеннән үк чыгарыенмы?

— Әйе,— диде кыз, башын иеп.

— Чынмы? — диде Тотыш, кызның алдына тезләнеп.

— Чын.

— Антмы?

— Ант! — диде кыз, бернинди икеләнүсез.— Инде ышанасыңмы?

— Ышанам! — диде Тотыш.

— Алайса, син дә әйт: бары мине генә, мине генә яратырсыңмы, башка беркемне дә алмассыңмы?

— Алмам! — диде Тотыш, нык итеп.— Синнән башка беркемне дә яратмам!

— Беркайчан дамы?

— Беркайчан да!

— Зур көчкә, байлыкка ия булсаң дамы?

— Кем генә булсам да!

— Болгар ханы булсаң дамы?

— О-о!.. Болгар ханы булсам да!

— Хазар каганы булсаң дамы?

— Хазар каганы булсам да! — диде Тотыш, елмаеп.

— Ант ит син дә! — диде Аппак.

Тотыш кылычын тартып алды, салкын тимерне үпте дә:

— Олуг тәңрем, ишетәсеңме! — диде.— Ак бүре ыруының изге иләре, ишетәсезме?! Җирем-суым, күгем... бөек Әтил, Чулман, ишетәсезме, күрәсезме?!. Алланы әйтәбезме? — диде ул кинәт, Аппакның чумак иҗкәнлеген исенә төшереп.

— Алла ишетмәс. Ул еракта,— диде кыз.

Тотыш, алланы әйтмичә генә, ант сүзләрен ялгап китте:

— ...Мин ант итәм,— диде.— Алмыш хан кызы Аппак алдында, сезнең алда мин ант итәм: синнән башка, Аппак, мин беркемне дә яратмам, өйләнгәч бары синең белән генә торырмын, сине генә ишем, кадашым, хатыным дип белермен! Шушы антымны бозсам, торган җиремдә җир йотсын, яшен суксын!

Антын әйтеп бетергәч, аңа кинәт бик тә эссе булып китте. Суларга аңа тын җитмәгәндәй булды. Үз-үзен ул әле генә бик зур эш, бик изге, яшерен бер эш эшләгән кебек тойды. Аны ниндидер олыгаю катыш курку, эчке бер тетрәнү тойгысы биләп алды. Алай-болай антын бозса? Аның Тәңкәсе дә бар ич әле! Тәңкә...

Әле генә үзен тулысынча өлешле дип уйлаган егетнең күңелен усал бер корт кимерә башлады. Тәңкә, Тәңкә! Аңа да ант бирмәде микән әле

ул? Юк бугай. Алар бернинди антлар бир [illegible] иш-мадылар да алар. Әллә нәрсә генә булды ул. Бөтенләй уйламаган җирдән... тилелек, сабыйлык...

— Инде күңелем чыннан да тынычланды,— диде Аппак, җиңел сулап.— Күпме көтәргә туры килсә дә, син — минеке, мин — синеке, иеме?

— Ие,— диде Тотыш.

Аппак та, тынычландым, дисә дә, аның да күңелендә бер төен калды. Ул әлегә бу турыда уйламаска тырышты.

## XIX

Бүген алар яктыра башлаганны сизмичәрәк калдылар, ахрысы. Кайту ягына борылганда, җир өстендәге карангылык инде таралган, болыннар, урманнар, күк йөзе таң алды йокысына чумып, тынып-изрәп ята иде.

Алар атларын кызулый төштеләр. Таныш куаклыкларны, ауган карамаларны узып киттеләр дә куе таллыкка килеп керделәр. Таллыкны чыккач болын башланырга тиеш иде. Таллык урынында кайчандыр үтеп булмаслык сазлык булган. Инде ул кипкән. Көтү йөреп, арасыннан юл ясап бетергән. Алар куе таллар арасындагы тар гына ачыклыктан, көтү сукмагыннан киттеләр. Сукмак тар булганга, ике ат сыймады — Тотыш алдан барды, Аппак, бераз җир калышып, арттан килде.

Таллык авызына якынлашып килгәндә, Тимеркүк кинәт тынычсызлана башлады — як-ягына каранды, пошкырып-пошкырып алды. «Бүре микәнни?» — дип уйлады Тотыш, сөңгесен җайлабрак тотып. Аппакны көтеп ул атын тыя төште.

— Нәрсә бар? — диде кыз.

Атта йөрүдән, иртәнге салкынлыктан аның бит очлары алсуланган иде, шаян күзләреннән, иртәнге кояш яруклары сыман, тыелгысыз сөю, сөенеч чаткылары бөркелә иде. Тотыш аның чык тамчылары белән юылган болын чәчкәседәй алсу, күркәм йөзенә елмаеп бер карады да, шауламаска, тыныч булырга кушып, кулын күтәргәндәй итте. Шуннан соң ул, тезгенне җыя төшеп, сак кына яңадан кузгалып китте. Алда шылт иткән тавыш та ишетелмәде.

— Нәрсәгә исең китте соң? — дигән булды Тотыш, туктаусыз пошкырынган, тынычсызланган атына эндәшеп.— Беркем юк, котың алынмасын!

Ул моны, аттан бигрәк, Аппакны тынычландыру өчен әйтте бугай. Үзе ул уяулыгын аз гына да киметмәде. Ат, билгеле, тикмәгә генә пошкырынмый иде, алда ни дә булса булырга тиеш иде.

Шулай булып чыкты да. Таллык бетеп, тәбәнәк калкулыктан менеп килгәндә, алда, як-якта ниндидер атлылар күренде. Алар алты-җиде кеше иде, барысы да кораллы, тимер киемле иде. Болар төнге каравылчылар булырга тиеш иде.

Тотыш каршысына беренче булып килеп җиткән кораллы ир, әтәчләнеп, битлеген күтәрмичә:

— Ым? — дип кычкырды.

Тотыш каушап калды: ул ымны оныткан иде. Ул арада башкалар да килеп җиттеләр, сөңгеләрен җайлап, юлга аркылы төштеләр дә көтә башладылар.

— Әһә, белмисез? — диде ым сораган ир, усал итеп, сөенеп.

Тотыш аны тавышыннан танып алды. Каушау, аптырау шундук кыргый бер ярсу белән алышынды. Ул кизәнеп сөңгесен Корыч-Тимергә тондырыйм дигәндә генә, арттан Аппак килеп, аның беләгеннән тотып алды.

— Тотыш, ярамый! — диде ул, куркып, ялварып.

Тотыш, аның үтенеченә буйсынып, сөнге башагын түбән иде.

— Кистән! — диде Аппак, ымны әйтеп.

Корыч-Тимер битлеген ачып җибәрде. Тотышка туры карап, җинүче төс белән шаркылдап көләргә тотынды.

— Тотышмы? Тотыш! Тотыш белән Аппак! Төнге каравылчылар! Җибәрегез, китсеннәр!

Аның сүзләреннән Тотыш берни аңламады. Ул бары үзенең көчкә тиелып торуын гына, Аппак ирек бирсә, бер карамый үзенең ягысына ташланачагын гына аңлады. Ник туктатты ул аны, ник тота ул аны? Кырын күзе белән генә ул Аппакка карап алды.

— Барыгыз, бар, ник туктадыгыз? — диде Корыч-Тимер, көлеп, атын читкә борып.

Җиңүче булып сөйләнсә дә, ул Тотыш кулындагы сөңгедән күзен алмады. Узып китәргә юл биргән булып, әкрен генә читкә каерды. Башкалар да аннан күрмәкче атларын читкә бордылар, ике ара шактый ераклашкач кына: нишләр икән болар, дигән сыман, читтән генә карап, көтеп тора башладылар.

— Тотыш... беттек! — диде Аппак, пышылдап, алга узып.

— Бетмәдек! — диде Тотыш.— Ник туктаттың?!

— Беттек, беттек! — диде Аппак, дер-дер калтыранып.

— Йә алар, йә без! — диде Тотыш.

Күз ачып йомган арада ул ияреннән калыкты, ике аягы белән дә өзәңгегә ныгытып басты да, сөңгесен Корыч-Тимергә ыргытты. Сөңге тимәде. Корыч-Тимер, җирне-күкне калтыратып:

— Уйнаш!— дип кычкырып җибәрде.— Тотыш — Аппак: уйнаш!

Атын борып ул урда ягына чапты. Башкалар да, «уйнаш!» дип кычкыра-кычкыра, атларын куалап, урда ягына ашыктылар. Йоклап яткан җир күкрәген дер селкетеп, дөп-дөп бәргән ат тояклары да, куркып таллыктан очып чыккан кошлар да — барысы да:

— Уйнаш! Уйнаш! — дип кычкырдылар.

Тотыш куа китте. Арттарак калган бер ирне ул ук белән яралады, икенчесенең атын аксатты. Корыч-Тимерне ук та, Тимеркүк тә куып җитә алмады.

## XX

Болгар кешеләрен Тотыш юньләп белмәсә дә, болгарлар аның үзен яхшы ук беләләр иде. Аның атагы Өсән буйларына, Ага-базар якларына үзеннән элегрәк килеп житте. Кеше арасына чыкмыйча, көннәрен, төннәрен ялгыз башы чатырда үткәргән Тотыш үзе турында сөйләнелгән сүзләрнең берсен дә ишетмәде. Ишеткән булса, ул билгеле, күп кенә яңалыклар белгән булыр иде.

Беркемгә күренмичә, яшеренеп йөрибез, дип уйласалар да, аларның икәүләшеп, төнге каравыл булып йөрүләре күпләргә билгеле иде. Алай гына да түгел, хан кызының яралы тотык янына барып йөрүен инде теге чакта ук, Чулман буеннан кайтып килгәндә үк сизеп алганнар иде. Аларның бер-берсен яратышулары Алмыш хан белән Айкын хатыннан башка беркем өчен дә сер түгел иде, ахрысы.

Тик шулай да бу турыда — Аппак белән Тотышның бергә очрашулары турында да, икәүләшеп болыннарда, урманнарда йөрүләре турында да ачыктан-ачык әйтергә я булмаса ханга җиткерергә беркемнең дә башына килмәде. Ник дигәндә, болгар йоласы буенча, кояш баегannнан алып кояш чыкканчыга тикле чит ир белән чит хатын-кыз бергә очрашса, уйнаш санала иде. Уйнаш өчен исә, ирне дә, хатынны да — кем булуларына да карамастан! — аяк-кулларын чабып, тураклап үтерәләр иде. Болгарда әле моңарчы хан кызы гүзәл Аппакның да, атаклы яшь алып Тотышның да үлемен теләүче кеше юк иде.

Андый кеше менә табылды. Корыч-Тимер аларны үзенең кешеләре белән ике төн күзәтеп йөрде. Инде менә каптылар үзләре дә! Баш тартып

карасыннар! Таныклар җитәрлек. Уяныгыз чыларны! Баш кисүче, кайра балтаңны! Уяныгыз кешеләр, җыелыгыз киң языга — уйнаш, уйнаш!

Урдага карап чапканда Корыч-Тимернең күңеленә шундыйрак уйлар килде. Тирмәләр арасына килеп кергәч тә ул чынлап та кешеләрне кычкырып йокыларыннан уятмакчы булды. Шулай да эчке бер тавыш аны бу тилелектән тыеп калды. Башкаларның чабылган кул-аяклары турында уйлаганда ул үз башын да онытып җибәрмәде. Кояш чыкмый торып тиктомалга урданы, димәк, ханны да йокысыннан уяткан өчен аңа бик каты эләгәчәк иде. Ханны, урданы исә теләсә кайчан бары яу килгәндә генә, йортка-илгә талау, кыран килгәндә генә уятырга ярый иде, анда да әле чит кеше түгел — өй-агасы я булмаса ханның үз кешеләре, сакчылары гына уята ала иде.

Аннары, нинди генә үчлекле, мин-минлекле булмасын, Корыч-Тимер дә Аппакның — хан кызы, Тотышның — хан тотыгы икәнлеген исеннән чыгара алмады. Ул, упкын аша сикерергә укталып та, сикерә алмыйча, упкын кырыенда тукталып калган кеше сыман, шып туктады. Кире борылды. «Көн тусын»,— дип уйлады ул, көтәргә булып.

Аппак белән Тотыш та шулайрак уйладылар. Аларга да тизрәк көн туу, кешеләрнең, бигрәк тә ханның уянуы кирәк иде.

Аппак Тотышка барысын да сөйләп, аңлатып бирде. Егетнең йөзен кайгы-сагыш биләп алды. Менә ни өчен Аппак бары төнлә генә килгән икән аның янына! Менә ни өчен Торымтай аларны бөтенләй күрмәмешкә салынган икән! Көндез хан кызына тотык белән очрашырга түрә кушмый, төнлә очрашырга йола кушмый! Хан кызы, хан балалары тотык белән бернинди бәйләнешкә кермәскә тиешләр. Ах, менә нинди кеше икән ул тотык!

— Ник башта ук әйтмәдең?! — диде ул, ачынып.

— Мин курыктым,— диде Аппак.— Белсәң, мине яратмассың, дип, ташларсың, дип курыктым.

— Инде менә бергәләп үләргә туры килә,— диде егет, үкенү сиздереп.— Безне йола үтерә. Иң зур ягым Корыч-Тимер дә түгел,— йола! Мин менә тагын шуны аңладым. Мин... без ниндидер күзгә күренмәгән арканнар белән уратып алынганбыз, бәйләп ташланганбыз. Үз иркебез белән без тел дә кыймылдата алмыйбыз. Тәңрем, син бирдеңме андый йолаларны кешеләргә, әллә алар үзләре уйлап тапканмы?! Миңа күрергә ярамый — алайса, ник миңа күз бирдең? Миңа сөйләшергә ярамый — алайса, ник миңа тел бирдең? Миңа йөрергә ярамый — алайса, ник миңа аяк-кул бирдең?! Миңа сөяргә ярамый — алайса, ник син минем канымны кайнар иттең?! Юк, минем әле үләсем килми! Минем әле яшисем килә, сөеклем белән бергә куанасым килә, тәңрем! Коткар безне, коткар языклы балаларыңны!

— Тизрәк, тизрәк! — диде Аппак, Тотышны ашыктырып.— Мин әле ышанам. Ничек тә атамны алданрак күрергә кирәк.

Алар ашыктылар. Үлемгә ашыгалар идеме алар, ирекккәме — беркем дә белмәде.

## XXI

Болгар җирендә таң атып кояш чыгу белән, төрле яктан урдага кешеләр килә башлады. Берәүләр якындагы авыллардан, көтүлекләрдән килделәр, икенче берәүләр ерак илләрдән сату итеп кайтып, хан янына йомышларын йомышларга ашыктылар. Өченчеләре, киресенчә, чит илләрдән, чит җирләрдән килеп монда нинди дә булса эш эшләргә уйладылар — шуның өчен йорт башына күренергә кирәк таптылар. Ханда йомышы-табышы булган кайберәүләр, аның янына эләгә алмыйча, урда читендә чатыр корып, ничә көн инде төн куналар иде.

Каравылчылар кешеләрне урдага берәм-берәм карап, тикшереп керттеләр. Теркәүче яза барды, терки барды. Соңыннан хан ашапэчеп, үзенең зур тирмәсендәге биек түренә чыгып утыргач, хан агасы[1] аңа кемнәр килүен, нинди йомышлар белән килүен җиткереп торды.

Аппакның Тотыш белән бергәләп керергә теләвен ишеткәч, Алмыш хан, аңлап җитмәгәндәй:

— Минем каршыгамы? — диде.

— Әйе, ханым,— диде хан-агасы.— Анда тагын Алып-Тархан углы Корыч-Тимер алып та килгән. Никтер кызган, бик ашыгыч, ди, мине алданрак керт, ди.

— Корыч-Тимер сүреләә төшсен. Әйт, керсен кызым,— диде хан.

Аппак үзе генә кермәде. Кулга-кул тотынышып, куркып-өркеп, кыюсыз гына алар икәүләп керделәр. Керделәр дә, ары барырга батырлыклары җитмичә, ишек төбендәге йомшак паласка тезләнделәр.

— Синең үзеңне генә керә дигәннәрие, кызым,— диде хан, мондый күренешне бик үк ошатмыйча.

— Мин икебезне дә әйттем, атам,— диде Аппак.

— Торыгыз. Килегез бире,— диде хан.

Алар тордылар, алгарак уздылар, тагын тезләнделәр. Хан, чатырдагы барлык кешегә чыгып китәргә кушып, кулын селтәде. Хан-агасы, битекчеләр, сакчылар тавыш-тынсыз гына юк булдылар.

— Атам! — диде Аппак, әчке бер омтылыш белән, ялвару белән.— Без синә зур йомыш белән кердек — тыңлыйсыңмы безне?

— Сөйлә, тыңлыйм, кызым,— диде хан.

— Атам,— диде Аппак, барлык батырлыгын җыеп.— Атам! Мин Тотышны яратам, Тотыш... мине... Без өйләнешергә булдык — ирек бир безгә!

Хан атасының кырыс йөзенә бер генә күтәрелеп карады да тынып калды. Тотышның беләгенә тотынган көе, тынын кысып, бар нәрсәсен онытып көтә башлады. Уттай янган дүрт күз, тораташка, абакка, потка текәлгәндәй, куркып, ялварып, түрдә утырган ханга текәлде.

Болгар кешеләре генә түгел, хан үзе дә күп нәрсәне белә иде. Яшерен шымчылар аңа барысын да җиткереп торалар иде. Аппакның Тотыш белән бергә булуына ул ничектер бармак аша карады, хан кызына нишләсә дә килешә, диебрәк карады. Аннары, андый нәрсәләр белән булашырга бу арада аның җае да булмады. Башка кайгылар да баштан ашкан иде! Нәрсә, көймәсе комга терәлде микәнни? Тотыш белән Аппак... Тотыш. Аҗундагы барлык алтын-көмешкә торырлык Аппак әнә кемне сайлаган! Алмыш ханның тотыгын, кем белә, әллә... углын сайлаган! Иа тәңре, йа алла, кирәгеннән артык яратмый микән ул үзенең Аппагын? Кирәгеннән артык ирек бирмәде микән ул аңа?

— Өйләнергә? — диде ул кабатлап, төшенеп җитмәгән сыман.

— Әйе, атам,— диде Аппак.

— Син, кызым, үзеңнең кем икәнлегеңне онытып җибәргәнсең, ахрысы,— диде хан, авыр, салмак сүзләрен теш арасыннан кысып чыгарып.

— Юк, атам,— диде Аппак, тынгысыз бер кабалану белән.— Син бу сүзләрне миңа түгел, Тотышка әйтсәсең. Тотыш мине үлемнән коткарды! Мине саклап ул унлап казаякны үтерде. Ул минем өчен, синең өчен сугышты. Ышанмасаң, күргән ирләр әйтер.

— Мин ышанам,— диде хан, коры гына.— Мин барысын да беләм.

— Беләсеңмени?! — диде Тотыш, куанып, сүзгә катышып.

Хан, эндәшмәскә кушып, аңа кул гына селтәде.

— Беләм,— диде хан, кабатлап.— Тик шулай да син үзеңне үлемнән коткарган теләсә кемгә кияүгә чыга алмыйсың, кызым.

---

[1] Хан-агасы — вәзир.

— Тотыш теләсә кем түгел, атам,— диде ш кына.— Тотыш — би углы.

— Тотыш — Алмыш ханның тотыгы,— диде хан.

— Мин аны яратам, атам! — диде кыз, учактагы ялкындай кызарынып.— Синең миңа әйткән сүзең бар: яраткан кешеңә генә бирермен, дидең. Исеңдәме?

— Исемдә,— диде хан, теләмичә генә.— Мин синең Тотышны яратуыңа каршы түгел. Өйләнешүгә килгәндә...

— Ханым! Атам! — диде Тотыш, түземичә.— Күктәге тәңре белән, җирдәге-судагы изге ияләр белән ант итеп әйтәм: аяк астында тузан булырмын, кая куйсаң, шунда торырмын, кая җибәрсәң, шунда барырмын! Ягыларыңны себереп түгәрмен, Хазар каганын юк итәрмен! Барлык абаклар белән, атам-анам белән, изге Чулман белән, изге Әтил белән ант итәм! Күк кылычым белән ант итәм. Бир миңа Аппакны!

— Миңа синең антларың да, тузан булуың да кирәкми, Тотыш углан,— диде хан салкын гына.— Син беләсең булыр: Аппак, минем кебек үк, абакларга да, ияләргә дә табынмый. Ул бары бер аллага табына. Мөселман түрәсе буенча ул бары мөселман яисә, каралар әйткәнчә, чумак йоласын тоткан кешегә генә чыга ала.

— Син каршы килмәсәң, мин яңадан ата-баба йоласына кайтырыем, атам,— диде Аппак.

— Менә монысы инде үлгәндә дә булмас! — диде хан, тавышын көчәйтеп.— Үткәнгә кире кайту юк. Әтил кирегә акмаган кебек, сиңа да, миңа да, бөтен Болгар йортка да кирегә кайту юк.

— Аппак кемгә табынса, мин дә шуңа табынырмын, ханым! — диде Тотыш, күп уйлап тормыйча.

— Шулаймы? — диде хан, үчекләшкән сыман, көлемсерәгәндәй итеп.— Атаң-анаң, ыруың ни әйтер икән соң?

— Кирәк икән, атамнан-анамнан, ыруымнан баш тартырмын, ханым! — диде күзе-башы акайган егет.

— Хы,— дип куйды Алмыш хан, авызын кыйшайтып.— Нинди кызу канлы син, Тотыш углан! Атасыз-анасыз, ырусыз кем булырсың икән соң син? Ничек яшәрсең аҗунда? Кол булып, йолкыш булып?

— Аппак белән бергә булсам, кол булсам да, йолкыш булсам да миңа барыбер!

— Миңа барыбер түгел,— диде хан.— Мин кызымны тотыкка да, колга да, йолкышка да бирә алмыйм. Сау булыгыз, угланнар.

Ул, соңгы сүзләрен әйтеп, урыныннан тормакчы булды. Аппак белән Тотыш, үз колакларына үзләре ышанмыйча, каттылар да калдылар.

— Атай! — диде кинәт Аппак, чыркылдап, ап-ак агарынып.

Аягүрә баскан ата кеше, күңеле йомшап, кире урынына утырды.

— Нәрсә тагын? — диде ул, икеләнгәндәй итеп.— Әйтәсе сүзең калдымы, кызым?

— Әйтәсе сүзем шул гына, атам,— диде Аппак, еламсырап.— Бар ышаныч синдә, атам! Безне бергә күрделәр. Корыч-Тимер... тозак... Кызган минс, атам!

Алмыш ханның кара сакал-мыек баскан киң йөзен кара болыт каплап алды. Усал очкыннар бөркегән усал күзләре калын кашлары астында күмелеп кала язды. Киң, авыр күкрәге, тимерче күрегедәй, гыж-гыж килеп, бер төште, бер күтәрелде. Баскан килеш, авыр йодрыкларын йомарлап, ул язык.лы яшьләргә карап торды. Кызына кычкырудан үзүзен көчкә тыеп, кире урынына утырды.

— Тыңлагыз, сүзем шул: — диде авыр гына сүзгә башлап,— Тотыш үзе, атасы-анасы, ыруы гарәп йоласына күчсә, тиешле калымын түләгәч, ике елдан соң өйләнешерсез. Ак юл сезгә, балалар.

*Дәвамы бар*

## Нажар Нәҗми

# ШАГЫЙРЬЛӘР

### Багышлау

Озын иде һәм тун иде ул төн...
Төн каплаган иде тун җирне.
Урманда өй.... Мин бер үзем идем...
Килеп тапты шагыйрь шагыйрьне.
Китап белән без икәүдән икәү...
Шигырьләрдә күңел саф иде.
Уйларыма хаким булды шул чак
Татарның зур, моңлы Хәкиме[1].

Шул тун төндә эреп китте йөрәк,
Язганнарым — шагыйрь биргән бүләк.

### Габдулла Тукай

Булганнар бит бөек шагыйрьләр!
Тугач урын — алтын бишектә.
Үскәч — киткән, кайткан чакларда
Кеше торган саклап ишектә.
Булган башка бөек шагыйрьләр,
Тар бүлмәдә сулып, сүнгәннәр.
Бала чакта исә базарда:
«Асрарга бала бирәм!» дип,
«Кем ала?!» дип, сатып йөргәннәр.
Әй язмышның шомлы агышы!
Бөеклекнең алтын ярлары...
Гомерендә — халкы язмышы,
Җырларында — халкы моннары.
Хәзер инде башка заманнар,
Заманнарда башка базарлар,
Базарларда — башка малайлар,
Малайлар да башка — Нажарлар.
Күңелемнең заман кошчыгы
Басып сайрый алтын кыртәгә.
Сатсалар да бүген әзермен,
Тукай чыкса миннән иртәгә.
«Я кем ала?!» Сезгә кирәксәм,
Мин тукталам табып мәрхәлә[2]...
Ах, алай да килми кешегә
Шагыйрь дигән бөек мәртәбә.

---

[1] Сибгат Хәким.
[2] Юлчылар туктап китә торган урын (гарәпчә).

## Рәсүл Гамзатов

Омытмыймын, бер чак шулай белгәч
Мин Мостайдан өлкән икәнне,
Синең миңа: «Нигә болай булгач,
Син билгеле түгел?» дигәнне.
Өйрәнелгән синең тапкырлыкка,
Синең сүздән озак көлештек.
Көлештек тә, шәрабыңны эчкәч,
Без үбештек бугай, үбештек!
Дусыңның мин дусы булган өчен
Дус күрәсең бугай бүген дә.
Ул хакта бит синең шигырь дә бар —
Сөйләдең син авар телендә.
Яшермимен, синең кебек данлы
Кеше белән, ничек булса да,
Дус булуы ул горурлык, димен,
Яшәү җиңелрәк дөньяда.
Тик авырдыр сезнең кебекләргә,
Бигрәк тә нәкъ синең кебеккә.
Чит тел аша күпме «...шагыйрьләрнең
Баш өстеннән» сикереп биеккә
Очар өчен кирәктер ул булу
Үз халкыңның Пушкин, Тукае.
Ә соң Тукай, Мәхмүт бөтен илгә
Синдәй билгелеме, дускаем?
Һәр юлында очкын чәчрәп тора,
Ул булмый бит, булмый һич юктан.
Анда чыңлау!.. Чыңлап торганны бит
Ясап булмый кызыл балчыктан.
(Балчыктан ул чүлмәк ясап була,
Чүлмәкнең дә була үз чыңы.
Кайсы чакта чүлмәк тавышында
Күмелеп кала чынның иң чыны).
Һәр талантның җирдә үз урыны бар,
Һәр телдә бар акыл, моң вә ямь.
«Син Тукайдан өстен!» дияр идем,
Татар телен әгәр белмәсәм.

## Кайсын Кулиев

Килә дидең, ләкин дөнья хәле
Һәр чак безгә килеп туктала.
Якташларың көлмәс иде әле,
Кайсын, диеп, китте Уфага [1].
Көлмәс иде... Чөнки күптән беләм
Сөйгәнеңне безнең якларны.
Укыган бар Сәйфи Кудаш картка
Бер чак синең язган хатларны.
Син язгансың: «Үз телемдә миңа
Язып булмас инде, күрәсең.
Ә бит безгә Тукай теле якын,
Гафури да якын,— дигәнсең.—

[1] Балкарларда көлке сүз бар: кеше исереп егылса — «Уфага китте», диләр.

Бәлки миңа мөмкин булыр язу
Татар яки башкорт телендә...»
Сорагансың Тукай китапларын
Кыен чакта, авыр көнендә.
Җир дә, тел дә кабул итәр иде,
Итәр иде сине үз улы,
Үз шагыйре итәр иде халык.
Ә бит шагыйрь — халык күз нуры.
«Яралы таш» исә ул барыбер
Калмас иде җирдә язылмый.
Тибәр идемени синең йөрәк
Чегеменне үлеп сагынмый.
Сагынудан, туган җирең ерак
Калулардан янып, җан атып,
«Таулар поэмасы»н ул барыбер
Бирер иде синең талантың.
Бүгенгедән бәлки яктырак та
Балкыр иде данын — ялкын-кош!
Тик бүгенге Кайсын булмас иде —
Тау бөркете, Шагыйрь, алтын дус!

## Сәйфи Кудаш

Килде дә ул, килмәде дә кебек
Җитмеш бишне төяп моңсу көз.
Җитмеш биш яшь яши алган кеше
Болай да зур шагыйрь, үлемсез.
Озын гомер, борылмалы гомер,
Заманнары нинди, заманы!
Ихлас йөрәк белән аңлап кара:
Кайда яхшы, кайда яманы.
Озын гомер, борылмалы гомер,
Хаталар да булмый һич булмас.
Сермени бу! Бүген дә бит болай,
Я тегеләй дибез С. Кудаш.
Тешләнмәгән җире, тешләнмәгән елы,
Тешләнмәгән юлы юк кебек.
Ә бит тәнне хәтта черки генә
Тешләсә дә яна ут кебек.
Башка тәндә ул сизелмәс иде...
Яшь шагыйрь һаман җан атып.
Иҗатында һаман сокланырлык
Яшьлек дәрте җәя канатын.
Үтте бугай әдәбият язы,
Язда — моңнар, язда — сут тула.
Хәзер җәе, чәчкә аткан вакыт,
Черкиләр шул җәен күп була.
«Шигърият тигез юлмыни ул?
Күпмени соң аннан үнганнар?
Тигез юлдан йөрегәнгәмени
Арада бар Бабич, Туфаннар?»
Килде дә ул, килмәде дә кебек
Җитмеш бишне төяп моңсу көз.
Җитмеш биш яшь яши алган кеше
Болай да зур шагыйрь, үлемсез.

## Хәсән Туфан

«Белеет парус одинокий».
*М. Лермонтов.*

Уфаларга килсә — урамнардан үтә,
Я булмаса, бизәп араны,
Утыра ул безнең белән бергә,
Ялгыз җилкән кебек агарып.
Ул ялгыз да һәм ялгыз да түгел,
Безнең белән утырып янәшә,
Ул яшьлеге, ул бүгене белән,
Киләчәге белән сөйләшә.
Без дә хәзер бик карадан түгел,
Без дә хәзер инде агарган.
Әй барыбер, янәшә утырсак та,
Без малайлар әле, малайлар.
Ак башында кара кайгылармы,
Әллә микән Себер карлары?
Бардыр инде, барысы да бардыр —
Сөзәк түгел гомере ярлары.
Бардыр инде, барысы да бардыр,
Шагыйрь гомере — бару ал ярып,
Бер агаргач, кабат караймыйча,
Ул яшәсен, шулай, агарып.
Юк, акланып түгел, агарып!
Бардыр инде, барысы да бардыр,
Җиңел түгел гомер юллары.
Бөтенесе бергә тәйнәлгән бит —
Язмыш моңы, шигырь моңнары.
Уфтану ят аңа, ишеттермәс
Яшәү хакында ул авыр сүз.
«Бер газапсыз шагыйрь буламыни,
Океан буламыни давылсыз».

## Шәйхзадә Бабич

Дуртөйледән без дуртәүбез [1] —
Синнән башлап миндә бетә.
Дуртнең дәвамын якташлар
Синең кебекләрдән көтә.
Күпме еллар инде киткәнеңә,
Безнең гомер еллар санында.
Алтын орлык арасында тавык
Тибенгәндәй, синең янында
Тибенәбез һаман, эзләнәбез...
Үлгәч тә бит түгел син тыныч.
Үләннәрдәндәме без куркабыз,
Гомереңме әллә куркыныч?..
Мондый язмыш кемгә тәтегән соң —
Балкып сүнүең дә үзеңчә.
Күпме кешеләрнең язмышына
Керден хәтта үле көенчә.

---

[1] Шәйхзадә Бабич, Бәдрүш Мокамай, Зыя Мансур һәм шушы юлларның авторы.

Нигә шулай? Әллә синең рухың
Артык усал, артык яманмы?
Әллә заман сине аңламыймы,
Синме аңламадың заманны?
Их, барысы да аңлашылып торса,
Син дә булмас идең үзеңчә.
Мин дә язмас идем бу шигырьне,
Синнән өлкән малай көемчә.
Дүртөйледән без дүртәүбез —
Синнән башлап миндә бетә.
Дүртнең дәвамын якташлар
Синең кебекләрдән көтә.

## Мостай Кәрим

Мостай белән без сөйләшә идек
Шигырь, язмыш, тормыш хакында:
«Шушы заман әгәр булмаганда
Без кем булыр идек асылда?»
Ә чыннан да, без кем булыр идек?
Мин кем булыр идем? Җырчеме?
Әйе, җырне сөрдем, сөйдем, сөям...
Моңлы идем... Берәр җырчымы
Булыр идем?.. Ятим булгангамы,
Керен безгә күрше хатыннар,
Уйнаталар, җырлаталар иде,
Ә үзләре, һе, елыйлар иде
Миңа карап мич артында.
Бер һөнәрче булыр идем, бәлки,
Абыйларыма бик охшасам.
(Кыек атып туры тидергәндәй
Мин мактаныйм әле, ичмасам).
Ә без шагыйрь булыр идекме соң?
Ә кем белә, чөнки заманнар
Нинди булганнар бит!.. Ә шулай да
Тукайлар бит туган, булганнар!
Шагыйрьлек ул килә тумыштандыр,
Канда буладыр ул, мөгаен.
Ташны тишеп чыккан чәчкә кебек,
Еллар, ни булса да, Тукаен
Биргән кебек, мотлак бирер иде
Рәсүлләрен, Кайсын, Мостаен.
Әйт, шигърият! Син нәрсә соң? Талант
Көчеме син? Сихри йоламы?
Заман җилеме син? Түгелме әллә?
Ә замансыз шагыйрь буламы?
Аллаларга әллә алласыңмы,
Аларгамы үзең бер иман?!
Бер җавап юк... Төнге тынлык... Ә мин
Йолдызларга карап утырам.
Вакыт саклый әдәп —
Суга сәгать...

## Фәния Чанышева

●

*Мостай Кәримгә*

Акыл-киңәш сорап сиңа килдек,
Җанга авыр булган чакларда,
Кичер безне, өлешебез булса
Чәчләреңә төшкән акларда.

Теләкләрнең изгеләре бездән,
Якты гәүһәрләре күңелнең,
Теләсәк тә инде гомереңнең
Калган ягы илле түгелдер...

Тик калганы булсын бәрәкәтле,
Иҗат чишмәләрең тынмасын,
Пар канатың биекләргә илтсен,
«Ташта үскән гөлләр» сулмасын!

●

Кар өстендә нурлар җемелдәшә,
Йомшак җилләр сыйпый битемне,
Илаһи моң чыңлый колагымда,—
Яңа җырым туа шикелле.

Көлә-көлә кызлар атлап килә,
(Кызлар холкы көлү бит инде!)
Күзләрендә күрәм яшьлегемне,—
Яңа җырым туа шикелле.

Бер җылыйсым, бер җырлыйсым килде,
Бер дә юкка күңел кителде...
Үзәгемне өзеп, сулкылдатып,
Яңа җырым туды шикелле.

# Яшьтәшемә

Таң нурларын күзләремә манчып,
Озатып калуларым — еракта;
«Көтә белсәң, җинеп кайтырмын», дип,
Әйтеп киткән сүзең — колакта.
Шул китүең — соңгы китү булды...
Сандугачлар кайтты җырларга,
Тыныч тормыш иртәләрен мактый
Басуларда сабан тургайлар.
Күкрәк куеп танкларга каршы
Утлы кырлар аша үткәнсең.
Замандашлар урта яшьне узды,
Син һаман да үсмер икәнсең.
Син һаман да киткәндәге кебек...
Әле дә елгыр икән Бузатың.
Үткән юлларыңны сөйләдең дә
Моңсуланып калдың озатып.
Күз алдымнан китми син атлаган,
Ут үртәлгән кырлар, болыннар.
Тынычлык юк җирдә, хәвефләнем:
Синең яшькә җиткән улым бар.
Экранда тик сының, ә чынында
Баш очында үсә яшь имән.
О, яшьтәшем, мин тормышны сөям,
Каһарманлыгыңа баш иям!

## Сәет Шәкуров

# МӘХӘББӘТ ГАЗАБЫ

*Драма 8 картинада*

КАТНАШАЛАР:

Фазыл
Сурия
Гадилә тути
Рәкыйп
Кәусәрия
Энже

## БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Гадилә тути йорты. Кечкенә генә ике бүлмәдән торган агач өй. Гадилә тути ялгыз. Эченнән нидер көйли-көйли керләр үтүкли.

Гадилә.

. . . . . . . . . . . . .
Сагынганда саргайтырга
Сайрый сандугачлары...

Ишек шакыйлар.

Керегез!

Кәусәрия керә.

Кәусәрия. Исәнме, Гадилә түтикәем!

Гадилә. Әнекәем лә, Кәусәрия, әйдә, әйдә, түрдән уз. Өемнең җыештырылмаган вакыты туры килде бит беренче килгән кешегә.

Кәусәрия. Әле синең ялт иткән. О... анда, эчтә дә бер бүлмәң бар икән... Үз йортыңмы?

Гадилә. Сугыш башланасы елны гына житкереп кергән идек. Шушы үзебезнең пристаньда шкипер булып эшли иде минем Хәйдәрем.

Кәусәрия. Сугыштан кайтмадымы?

Гадилә. Стенадагы карточкасы белән генә сөйләшеп йөрергә калды.

Кәусәрия *(рәсемгә карап)*. Бу шул үземе?

Гадилә. Үзе. Ә янындагысы — улым. Әтисеннән ике яшьлек кенә булып калган иде. Сигез класс бетерүгә елга техникумына укырга китте. Әлек әтисе генә юк иде, хәзер малае да.

Кәусәрия. Малаең кайтыр, ел саен каникулга кайтыр, тик менә әтисе генә...

Гадилә. Ансы да кайтыр шикелле, балакаем, әй. Менә сугыш беткәнгә егерме биш ел булды, ә мин көн саен көтәм үзен. Бу хатсыз-хәбәрсез югалу бигрәкләр дә авыр икән. Үлде дигән хәбәре килсә, яшең кипкәнче бер елар идең дә аннан өметең киселер иде. Ә болай... көндез истә, төнен төштә. Тол хатынның сәер икән ул.

Кәүсәрия. Картыңның үлгән хәбәре килгәндә, ничә яшеңдә идең соң?

Гадилә. Кырык та тулмаган иде.

Кәүсәрия. Берәр җан юаткыч таба алмадыңмыни?

Гадилә. Димләмәделәр түгел, димләделәр, бик әйбәт кешеләргә димләп карадылар.

Кәүсәрия. Соң, тәвәккәлләргә иде. Үлгән артыннан үлеп булмый, диләрме әле?

Гадилә. Юаныч өчен генә тәвәккәлләп булмый икән ул, Кәүсәрия сеңелем!.. Унөч яшьтән бирле сөешеп, күзебез күзләрдән китмәде, диләрме әле? Унөч яшьтән бирле саклап алып килгән татлы хыялыма тап төшерммм инде мин, кем, Кәүсәрия, шуның белән генә яшим. Җан юаткыч дип, аңа хыянәт итсәм, бөтенләй стенага ук борылып утырыр. Чәй куеп җибәрим, Кәүсәриякәем, шәһәребезгә әллә кайчан күчеп килсәгез дә, йортыма беренче мәртәбә керүең бит әле синең...

Кәүсәрия. Рәхмәт, Гадилә түтикәем, вакытым юк. Әле менә кер-ләремне алып чыгыйм дип кенә керүем иде. Үтүкләп бетермәгәнсең икән.

Гадилә. Кертеп биргән булыр идем. Алып чыккан әйберне кертеп тә бирә беләм бит инде мин. Әле менә бүген эштән соң кайттым. Җыештыручының эшен сәгатькә салып буламыни соң аның. Син бер бүлмәне җыештырып бетереп кенә чыгасың, алар икенчесен чүплэп өлгергән булалар.

Кәүсәрия. ФЗУшниклар шулай инде алар... Әле менә безнең завод лабораториясенә дә узган ел гына ФЗУ бетергән бер малайны өйрәнчек лаборант итеп алган булдылар. Син приборларны чистартып кына куясың, хәзер шунда ук быкырдатып бетерә. Рәкыйпчикнең исе киткән була бит шуңа. Әйдә, быкырдатсын, имеш, кызыксына, күпне белергә тырыша. Болай үзе өметле егет, кичке техникумда да укый.

Гадилә. Яшьләрнең дә төрлесе бар бит, Кәүсәриякәем. Бик акыллы, бик тыйнак, бик тырышлары бар. Шунда, синең Рәкыйбең янында, лабораториядән чыкмый ята торганнары бар. Бик яраталар үзен — синең Рәкыйбеңне.

Кәүсәрия. Үзем дә бик яратам картымны. Тик менә сәер гадәтләре бар. Әз генә борылдың исә, Идел буена төшеп кача да шунда сәгатьләр буе балыгы белән мавыга. Бала-чага шикелле.

Гадилә. Борылуың озаккарак булгандыр шул, Кәүсәриякәем.

Кәүсәрия. Кая инде. Әле бүген менә киногә гына кереп чыгам дигән идем. Ә ул балыкка... Өйдә бер тамчы су юк, керосин юк... Харап кына иттеләр бит башкайларымны, гөрләп торган шәһәрдән шушы Идел буена күчереп заводны. Әйттем, күчмик дидем, юк, үз заводымнан калмыйм, имеш. Шәһәрне, утлы-сулы квартираны ташлап, менә шушы караңгы почмакка китереп бастырды бит. Бер чәйлек суга тилмереп йөр инде син хәзер...

Гадилә. Алайса, син бар, кинодан соң чәйгә тилмереп йөрмә, әзләп алып мин тизрәк картыңны.

Фазыл керә.

Фазыл. Исәнмесез.

Кәүсәрия. Менә минем картымның сәкле лаборант егете шушы була инде. Нихәл, чибәр егет? Һай, кинепп алгач, сине бөтенләй танырлык булмый икән, чибәр егет!

Ф а з ы л. Менә сез кинодан чыкканчы, фонтаннан бер көянтә су алып кайтып куярга кушкан иде Рәкыйп абый. Суыгыз крыльцода. Шуны әйтергә кердем.

К ә ү с ә р и я. Рәкыйп абыең үзе кая соң?

Ф а з ы л. Балыкта. Тиз кайтырмын, диде.

К ә ү с ә р и я. Рәхмәт, егетем. Алайса кайтып самовар куя торырга кирәк. Әйдә, озатып та куй инде мине. Мондый кавалер белән урамнан бер узуы гына да ни тора.

Ф а з ы л. Юк, минем Гадилә түтигә йомышым бар иде.

К ә ү с ә р и я. Шулаймыни? Алайса, йомышыңны йомышлагач, чәй эчәргә кагылырсың...

Чыгып китә.

Г а д и л ә. Суын алып кайткач, чәен дә кайнатып куярлар аның. Начальнигың хатынына шулай бераз тәлинкә тотмасаң, тиз генә ирешә алмассың дәрәҗәгә.

Ф а з ы л. Рәкыйп абый начальник түгел ул. Өлкән лаборант кына. Әйбәт кеше ул үзе. Хатыны менә йөрәк авырулы икән. Авыру кешегә бер көянтә су алып кайтып бирмәгәч...

Г а д и л ә. Андый изге ният белән йөрүең бик әйбәт. Әллә мин начальствоңа тәлинкә тотып...

Ф а з ы л. Менә анысы миннән булмый инде, бигайбә, минем бабай әйтмешли.

Г а д и л ә. Горур димәкче буласыңмы? Кыяфәтең бер дә горурга охшамаган бит, нәрсәдер мескенләнеп торасың.

Ф а з ы л. Башыма хәсрәт төште әле, Гадилә апа.

Г а д и л ә. Ни булды?

Ф а з ы л. Квартира кирәк.

Г а д и л ә. Нәрсә, тулай торактан куалармыни?

Ф а з ы л. Кумыйлар да.

Г а д и л ә. Соң, шулай булгач?

Ф а з ы л. Укучы түгел бит инде мин хәзер, ФЗУ тулай торагында торырга. Заводта эшлим.

Г а д и л ә. Заводта булса соң, тулай торак ФЗУныкы, ФЗУ заводныкы, тор да тор.

Ф а з ы л. Булмый, аерым бер бүлмә кирәк. Әнә синең эчтәге бүлмәң шикелле кечкенә генә бер бүлмә.

Г а д и л ә. Укучылар белән бер бүлмәдә торырга хурланасыңмыни?

Ф а з ы л. Хурланмыйм да.

Г а д и л ә. Соң?

Ф а з ы л. Өйләндем.

Г а д и л ә. Нәрсә?

Ф а з ы л. Өйләндем.

Г а д и л ә. Синме?

Ф а з ы л. Мин булмыйча, күрше булмас ич инде.

Г а д и л ә. Син? Шушы Фазлуш?! Мыек та чыкмас борынмы?

Ф а з ы л. Мыегы чыгар аның, күңелгә ошаганы чыкмас.

Г а д и л ә. Минем улым булсаң... Кеше баласына кулым бармый. Ә укуың нишли, ташлыйсыңмы? Өйләнгәч, эшли дә, укый да алмассың бит, техникумда укыйсың түгелме?

Ф а з ы л. Укыйм. Әле институт бетергәнче укыйм, укуны инде мин анысы алты балам булса да, ташламыйм.

Г а д и л ә. Соң шушы яшьтән өйләнмәсәң, качар дип уйладыңмыни?

Ф а з ы л. Нәрсәсен уйлыйсың инде аның, эш узгач.

Г а д и л ә. Шул ук хәлгә життемени?

Ф а з ы л. Әйе.

Г а д и л ә. Ә ул кайда тора?

Фазыл. Ул да тулай торакта. Эш бу хәлгә килеп житкәч, тулай торакта тотып булмый бит инде.

Гадилә. Күпмелек булды соң инде?

Фазыл. Күп шул инде, күп. Бүген таңда дип әйтерлек.

Гадилә. Язылышкан идегезме?

Фазыл. Ансыз ярыймы соң? Менә шулай, Гадилә түти, тулай торакта хәзер бер генә көн дә торырлык мөмкинлегебез калмады. Зинһар, коткар. Бөтен ышанычыбыз синдә, безгә әнә шул әчтәге бүлмәңне бир. Башка барып егылыр урыныбыз юк.

Гадилә. Улым кайтса?

Фазыл. Кайтса, каникулга гына кайтадыр ич ул.

Гадилә. Әтиеннәргә хат яздыңмы соң, киңәштеңме алар белән?

Фазыл. Юк. Анда әле минем тагы ике абыем бар, өйләнмәгәннәр.

Гадилә. Хатын дигәнең кем була соң инде?

Фазыл. Теге, былтыр минем белән бергә укып бетергән Сурия.

Гадилә. Сурия? Белмим.

Фазыл. Син безне тилмертмә инде, җавабыңны бир, Гадилә түти.

Гадилә. Җавап качмас. Бар, башта Сурияңне монда алып кил. Сөйләшим әле мин аның белән дә. Мин димләмәсәм дә, җавабы минем өскә дә төшәр бит аның, почмак биреп сыендыргач.

Фазыл. Булды гына, Гадилә түти, хәзер алып киләм. Шатлыгыңнан ул нишләргә дә белмәс инде, җаникисәгем! Рәхмәт, Гадилә түти. *(Китә.)*

Гадилә *(тәрәзәдән карап)*. Кара, ничек йөгерә... Әй бу яшьлек! Әле кайчан гына без дә Хәйдәрем белән шашып йөргән идек, дөньяны кочаклардай булып. Тормыш корабыз, уникенең берсе юк. Юклык күренми, яшьлек ташый, бәхет ташый...

Кәүсәрия керә.

Кәүсәрия. Ул чибәр егет нигә шулай ут капкан шикелле чыгып йөгерде?

Гадилә. Өйләнгән, туй ясарга йөри.

Кәүсәрия. Ә? Шул яшеннәнме? Яшьлегенең, чибәрлегенең рәхәтен күреп калмыйча соң бер... Җүләрдер бу хәзерге яшьләр...

Гадилә. Шулай инде, яшьлек — җүләрлек дип белми әйтмәгәннәр.

Кәүсәрия. Тулай торакка алып кайтмый торгандыр бит бикәсен?

Гадилә. Юк, тулай торактан алып кайта.

Кәүсәрия. Кая?

Гадилә. Монда, миңа алып кайтырга исәбе, әнә кечкенә бүлмәмә. Рөхсәт сорый килгән.

Кәүсәрия. Квартирант булып, ә? Шыр тиледер бу яшьләр. Инде шул яшеннән өйләнү бик кирәк икән, һич югында, йортлы-җирле хатынны табарга иде.

Гадилә. Кит инде, егет кеше эше түгел инде анысы. Фазыл шикелле булдыклы егет була торып...

Кәүсәрия. Булдыклы егетләр җайлырак, җылырак оя карыйлар.

Гадилә. Тол хатын булса дамы? Тик байлыгы гына булсын?

Кәүсәрия. Әй, Гадиләттәй, җан кисәгем, хатынның ниндие юк та аның, кызның ниндие юк.

Гадилә. Шулай да инде күңел тартканын, үз тиңең кирәк.

Кәүсәрия. Тора-бара тиңләшә ул. Менә без дә Рәкыйпчигем белән тиң түгел идек. Торабыз бит әле. Ул да җаный дип өзелеп тора, өрмәгән җиргә дә утыртмый, юктан-бардан көнләшми, мин дә үлеп яратам үзен. *(Тәрәзәдән карап.)* Гомере озын булыр әле! Пеләшен ялтыратып кайтып килә чибәркәем. Кармак таяклары бер кочак, балыгы бер дә юк. *(Тәрәзәне ачып кычкыра.)* Рәкыйпчик, кайтасыңмыни, җан кисәк?

Рәкыйп *(тыштан)*. Син андамыни, җаный?

Кәүсәрия. Менә керләремне алырга дип кергән идем.

Рәкыйп *(тыштан)*. Кая, үзем. *(Өйгә керә.)* Нихәлләрең бар, Гадилә түти? Бүген иртән тулай торакта исәнләшкән идек шикелле.

Гадилә. Исәнләшкән идек. Синен ул гадәтең җаннарны эретеп җибәрә. Кайда очрашсаң да әллә каян сәлам биреп киләсең.

Рәкыйп. Шулай эретеп үзебезгә тарта алмабызмы дим мин сине. Синең кебек пөхтә җыештыручы килсә, ялт итәр иде лабораториябез.

Гадилә. Завод директоры да үзенә бик чакыра. Тулай торакны ышанып калдырыр кеше юк хәзергә. Аннан соң андагы балаларны да бик яратам. Үз балаларым шикелле.

Кәүсәрия. Әйдә, җаным, самоварым кайнагандыр, тәмләп чәй эчерим үзеңне... Столовойдан өчпочмаклар да алып кайткан идем. Юк балык артыннан арып йөрисең шунда.

Рәкыйп. Киресенчә, аннан мин ял итеп менәм. Тотынма, тотынма керләргә. Шулкадәр нәрсәне күтәрергә, җаный, йөрәгең сон!..

Кәүсәрия. Ярый, ал алайса. *(Сумкасын актарып Гадиләгә акча бирә.)*

Рәкыйп. Шулай да син безгә күчү турында уйла әле, Гадилә түти. *(Керләрне күтәрә.)*

Кәүсәрия. Рәхмәт, Гадилә түти, кулыңнан куан. Шикәр шикелле итеп югансың керләремне. Шәһәрдә торып та мин бу кадәр агартып юучыны таба алганым булмады. Гел синнән генә юдырырмын, исән булсам.

Кәүсәрия, Рәкыйп китәләр.

Гадилә *(үтүкләрен, үтүкләү әйберләрен өстәлдән җыеп ала)*. Я, нишләргә инде бу балалар белән? Килделәр бугай. *(Өй алды ишеген ачып.)* Я, керегез инде, кер.

Фазыл. Әйдә инде, Сүрия. Әйдә. Әнә бит, Сүрия ояла.

Гадилә. Әбау, мин сөйләшергә, киңәшергә дип кенә чакырган идем бит, сез чемоданнарыгыз белән үк. Я, кызым, төкле аягың белән димме соң? Төп йортка тәшкәндә, аяк астына тун җәеп кертә торганнар иде безнең якта яшь килен булып төшкән кешене. Туным да юк бит җәяргә... *(Мич арасыннан бер кечкенә генә тире кисәге алып җәя.)* Я, менә бас шунар. Бас, бас, аның йоласы шул. Я, бир приданыйңны монда. *(Сүрия кулындагы бер кечерәк чемоданны ала.)* Абау ла, монда шактый мал тутыргансың, ахры. Күтәрер хәл юк. *(Фазыл кулындагы аннан да кечкенә чемоданны күрсәтеп.)* Синеке моннан да зур икән. Әйдә, үзең кертеп куй эчке бүлмәгә. Минем көчем житмәс боларга. Я, кызым, утыр, чишен, дога кыла белмисез инде сез. Мин дә әллә кайчан онытып бетергәнмен. Болай утырып кына торыйк, йоласына туры килсен. *(Утыралар.)* Шулай... Хәерле сәгатьтә булсын, диикмени инде? Никах-миках юк инде ул хәзерге заманда. Кирәге дә юк. «Риза булып алдым, риза булып бардым»ны әйттергәннәрдер бит? *(Сүрия кызарып Фазылга карый.)* Әллә ансын да әйттермәделәрме?

Сүрия. Кайда?

Гадилә. ЗАГСта, язылышканда. Бер-берегезнең ризалыгын сораганнардыр ич?

Сүрия. Без әле анда булмадык.

Гадилә. Ә? Бу нәрсә була соң инде.

Фазыл. Юк шул, Гадилә түти. Без әле тик вәгъдә биреп, сүз генә куештык. Язылышырга ЗАГСка иртәгә барабыз. Сүрия башта бүлмә табуны шарт итеп куйды да... Мин теге, ни... квартирага кертмәссең, дип кенә уйлап таптым. Гафу ит, Гадилә түти.

Гадилә. Уф, әле эш узмаган икән. Әле иртәгегә кадәр барысын да ахырына кадәр уйлап бетерергә вакыт бар икән.

Фазыл. Нәрсәсен уйлыйсың инде аның. Килештек, бер-беребезгә сүз бирештек, булды.

Г а д и л ә. Юк, булмый, аның белән генә булмый, барысын да төптән уйларга кирәк. Бер-береңне сынап, бер-береңә тәмам ышанып беткәч кенә башларга кирәк ул тормышны. Ә менә сез ышанасызмы бер-берегезгә?

Ф а з ы л. Нигә ышанмаска? Без кемнән ким?

Г а д и л ә. Ким димим, бәлки артыктыр да, ләкин ышану кирәк. Ярату кирәк. Менә син, кызым, әйт дөресен, яратасыңмы аны? Менә шушы тик тормас тузган башны? Кызарма, кызарма, яшермә йөзеңне, күземә туп-туры карап әйт, яратасыңмы?

С ү р и я. Нишлим соң, яратам.

Г а д и л ә. Бикме?

С ү р и я. Бик.

Г а д и л ә. Ә ул сине? Я... ярата мы ул сине?

Сурия ни дип әйтергә дә белми аптырап Фазылга карый.

Ф а з ы л. Әлбәттә, яратам.

Г а д и л ә. Юк, үзе әйтсен, ярата мы ул сине?

С ү р и я. Белмим.

Г а д и л ә. Ә кем белергә тиеш, минме?

Ф а з ы л. Я инде, Гадилә түти, яратмаган кешене мин синең янга алып килер идеммени?

Г а д и л ә. Синең кемнәрең бар соң, кызым? Әтиең-әниең бармы?

С ү р и я. Юк, апа, мин детдомда үстем.

Г а д и л ә. Я, ярый, нишләмәк кирәк инде сезнең белән. Тормыш җиңеләеп бара бит. Шуңа күрә бик җиңел хәл кылырга яратасыз сез, хәзерге яшьләр. Булмәм җәл түгел. Сез шулай җиңел уйлагач, мин дә шулай җиңел генә бирәм инде ризалыгымны. Ахыры хәерле булсын. Караватыгыз юк инде сезнең? Әнә улым караватын алып торырсыз хәзергә. Яшь кеше әле сез, сыярсыз тар караватка да. Өстәл-урындыклар шулай ук юк инде сезнең? Сүриягә әнә табуреткамны бирәм, ә син, тузган баш, гармуныңның тартмасына утырып эчәрсең чәеңне. Чәй дигәннән, самовар куеп җибәрергә кирәк бит. Я, суга кайсыгыз бара?

Ф а з ы л. Суга үзем йөрим, самоварны Сүрия куяр.

Г а д и л ә. Самоварыгыз бармы соң?

Ф а з ы л. Безнең бит, Гадилә түти, чәйнекләр генә иде, тулай торакта калдылар.

Чиләк алып чыгып китә.

Г а д и л ә. Чынаякларыгызга кадәр тулай торакта калган булса кирәк.

С ү р и я. Безнең әле бернәрсәбез дә юк, Гадилә түти.

Г а д и л ә. Булыр, кызым, мәхәббәтегез булсын. Әйберләр бар әнә, йорт тулы. Күршегә чыгасы юк. Үз балаларым шикелле яшәгез. Әле тик яшь булуыгызга күрә генә әйтүем.

С ү р и я. Мин үзем дә берәр ел сабыр итикме әллә дигән идем. Фазыл бит әнә, сүз әйтергә дә ирек бирмәде, үпкәли башлады. Хәзер чыкмасаң, башкага өйләнәм, дип куркыта башлады.

Г а д и л ә. Башкага?

С ү р и я. Әйе.

Г а д и л ә. Син курыктыңмы?

С ү р и я. Курыктым шул.

Г а д и л ә. Син дә башкага чыгар идең.

С ү р и я. Башкага? Юк, беркайчан да. Миңа Фазылдан башка беркем дә кирәкми... Беркем дә кирәкми!

Г а д и л ә (*аркасыннан сөеп*). Мин дә әнә аның белән генә яшим. Хәйдәр абыең белән генә... Бар юанычым шул. (*Рәсемгә күрсәтеп ала.*) Балакаем минем, үземә охшагансың.

Чиләк күтәреп **Ф а з ы л** керә.

**Ф а з ы л.** Менә мөлдерәп тулган чиләк. Бәхетебезнең шулай мөлдерәп туласы көн кебек ачык.

**Г а д и л ә.** Шулай гына була күрсен инде, балакайлар.

**Ф а з ы л** *(чиләктән бер кружка тутырып су алып эчә).* Сурия, син давай чәй куй. Гадилә түти белән бергәләп чәй эчегез. Ә мин әле кичкырын гына столовойда ашаган идем. Чәй эчеп тормыйм инде. Аңар әле өйрәнмәгән дә. Су эчтем, булды. Мин футболга барам.

**Г а д и л ә.** Кая?

**Ф а з ы л.** Футболга.

**Г а д и л ә.** Бала.

**С у р и я.** Ой, Фазыл, китмә инде, барма инде... Минем янымда гына бул инде.

**Ф а з ы л.** Соң футбол бит, футбол. Мин бетүгә кайтам. Йөгереп кайтам.

**С у р и я.** Кирәкми, Фазыл!

**Г а д и л ә.** Ул нинди җүләр сүз ул? Футбол! Бирермен мин сиңа футбол. Ачыгыз тәрәзәләрегезне, керсен саф һава. Әзерләгез табын. Хәзер базга төшәм, варенье алып менәм. Чормадан каклаган казымны алып төшәм. Аннан гореф-гадәт буенча мин кунарга күршеләргә кереп китәрмен. Бу беренче таңны яшь гашыйклар үзләре генә каршылыйлар. Икәүдән-икәү генә калып. Чукыр-чукыр сөйләшеп, сөешеп. Ә син футбол дисең, җүләр. *(Шкафтан варенье вазалары, бал кашыклары алып чыгып китә.)*

**С у р и я.** Фазыл, Фазылым минем. Әйбәт тә кешегә алып килдең син мине... Син үзең дә әйбәт булырсың бит, акыллым?! *(Муенына сарыла.)*

**Ф а з ы л.** Әлбәттә. *(Маңгаеннан, битеннән, иңнәреннән үбә.)* Әлбәттә.

**С у р и я.** Без гел шулай сөешеп кенә яшәрбез. Әйе бит?..

**Ф а з ы л.** Әйе, әйе. Йөз кабат әйе.

## ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук бүлмә. Ике ел вакыт үткән. Кич. **Г а д и л ә т ү т и** чәй табынында күзлек киеп хат укып утыра. Ишектән атылып **Ф а з ы л** кайтып керә.

**Г а д и л ә.** Акрын, кеше төсле йөри белмисең, дуамал. Гел йөгерү дә чабу.

**Ф а з ы л.** Дөньясы йөгерек бит, Гадилә түти, куып җитәр хәл юк. *(Ашыга-ашыга чишенә.)*

**Г а д и л ә.** Дөньяны куып җиткән кеше юк аны.

**Ф а з ы л.** Ә без менә җитәрбез дә, тотарбыз да, авызлыклап та алырбыз. *(Почмактагы юынгычта юына башлый.)*

**Г а д и л ә.** Аннан нишләр инде ул дөнья. Авызлыклагач дим...

**Ф а з ы л.** Гел безнең кубызга гына биер. *(Юынып бетеп, юеш киемнәрен кия башлый.)*

**Г а д и л ә.** Кая болай ашыгасың?

**Ф а з ы л.** Клубка.

**Г а д и л ә.** Сурияне дә үзең белән йөртергә иде.

**Ф а з ы л?** Сурия? Ул кайтмадымыни әле?

**Г а д и л ә.** Сез бер лабораториядә эшлисез түгелме соң?

**Ф а з ы л.** Алар, смена бетүгә, Кәүсәрия апа белән кайтып киттеләр. Ә без Рәкыйп абый белән лаборатория начальнигын бераз селкетергә калдык.

**Г а д и л ә.** Селкетергә? Ничек инде ул селкетергә?

**Ф а з ы л.** Моннан ун ел элек тәкъдим ителгән детальләргәябышкан да, шулардан һич тә аерыласы килми. Әзер рецепт, үзләштерелгән мате-

риал. Жинел ич, сук та сук бер ук кирпечне. Ә без Рәкыйп абый белән яңа детальләр тәкъдим итәбез. Алар өчен үзенчәлекле материал кирәк. Аны эзерләргә кирәк, актарырга кирәк. Әйтик, Идел, Кама буйларыннан, кыя итәкләреннән,.су төпләреннән, ә ул...

Гадилә. Селкенергә теләмиме?

Фазыл. Селкенер. Селкенмәсә без аны бөтенләй төбе-тамыры белән йолкып ташларга да күп алмабыз.

Гадилә. Рәкыйп белән икегез генә селкетә алырсыз микән соң? Бик төптән юан нәрсә күренә. Тотынгач-тотынгач дүртәүләшеп тотынырга иде. Сурия белән Кәүсәрияне дә үз эртилегезгә алып.

Фазыл. Әй, алардан он да юк, йон да юк. Кызыксынмыйлар.

Гадилә. Ә сез кузгатып карагыз аларны да. Начальникка көчегез житкәнне, үз хатыннарыгызга гына көчегез житмәсмени?

Фазыл. Суриясе инде аның үз кабыгына төренгән. Производство белән дә кызыксынмый, бүтән белән дә. Хәтта кинога да сөйрәп алып чыгар хәл юк, ә син клубка дисең.

Гадилә. Ә син аның кабыгының эченә үтеп керергә тырыш, нәрсәгә төренде икән?

Фазыл. Кат-кат шул ул. Бер генә кат булса, үтеп тә керер идең бәлки.

Гадилә. Син аның янында ешрак булырга тырыш. Кайтып керүгә чыгып чабарга торма.

Фазыл. Техникумда да укыма инде, синенчә, шулаймы? Кайтты бугай...

Ишектән Кәүсәрия белән Сурия кайтып керә.

Кәүсәрия. Кара, безнең «бриз» кайтып та житкән.

Гадилә. Анысы нинди кушамат тагы?

Кәүсәрия. Уйлап табучылар — шаккатыручылар бюросы дигән сүз.

Гадилә. Бер дә көлке түгел, як-ягыңа караныбрак йөрсәң. Идел өстенә генә кара син, нинди шаккатыргыч аккошлар очып йөри башлады. Идел төбендә дә бәлки шундый шаккатыргыч нәрсәләр тулып ятадыр. Эзләнергә кирәк. Эзләнсеннәр. Яшьләр эзләүне ярата ул, эзләгән табар дигәннәр бит. *(Эчке бүлмәгә кереп китә.)*

Кәүсәрия. Я, начальникны шаккатыра алдыгызмы соң?

Фазыл. Шаккатырырлар, курыкма. Бөгәрләр дә, сыгарлар да, кирәк булса, сындырырлар да. Бездән бюрога дәшеп калдылар үзен. Рәкыйп абый да шунда китте.

Кәүсәрия. Син ул Кама буйларындагы ташлар, комнарны актарып үзең генә йөр инде, Фазыл, яме? Минем картымны сөйрәмә.

Фазыл. Картайтырсың аны. Бер яңа тәкъдим кертсәң, шунда ук яшәреп китә ул. Ут кебек яна. *(Гармунын алып китәргә әзерләнә.)*

Сурия. Син кая барасың, Фазыл?

Фазыл. Клубка.

Кәүсәрия. Мине алып бармыйсыңмы?

Фазыл. Анда нишләрсең икән син?

Кәүсәрия. Бөтен үзешчәнегезне авызыма гына каратып тотар идем тотуын. Минем жырлаганымны ишеткәнең юк әле синең.

Фазыл. Әллә жырлыйсың? Чынлапмы? Ул вакытта әйдә...

Кәүсәрия. Юк, миңа ярамый шул... Минем ирем көнләшә.

Фазыл. Юк ла, Рәкыйп абый көнче түгел ул.

Кәүсәрия. Синнән көнләшми ул, әлбәттә. Ә менә башкалар янына барып кара әле? Мин бит изге түгел, эчемдә жаным бар ла бит минем дә. Берәр чибәррәк яшь егеткә күзем төшеп куюым бар. Яшь егетләрнең карашы гына да көйдереп алучан була бит кайвакытта. Әйеме, Сурия?

Сурия. Белмим мин.

К ә ү с ә р и я. Син каян беләсең, синең бит көйдереп ала торганың үз янында.

Ф а з ы л. Рәкыйп абый көйдерми димәкче буласыңмы син?

К ә ү с ә р и я. Менә син аның яшенә җит тә, көйдереп кара, неме, Сүрия?

Ф а з ы л. Аның өчен үзеңә дә янып торырга кирәк бит.

К ә ү с ә р и я. Сүрия сүрелеп барамы?

Ф а з ы л. Мин алай димим.

К ә ү с ә р и я. Ә син сүрелдермә. Синең бер үзеңдә биш Сүриягә җитәрлек ут бар бит. Эх, тарт әле бер гармуныңны...

Тибрәткәндә бармакларың
Тальян гармун телләрен,
Яшь йөрәккә утлар ягып
Бәгъремне көйдерәсең,
Көйдерәсең белмәдем.

Кулларыңда тальян гармун
Сандугач булып сайрый,
Гармун тартып үткән чакта
Тәрәзәдән күзем алмыйм,
Йөрәгемдә ут кайный.

Шулаймы, Сүрия, ә? Кайнатадыр бу кайбер кайнар башлы кызларны, ә? Ничек итеп шундый чибәр егетне үзең генә кичләрен клубка җибәрәсең?

С ү р и я. Йөрсен.

К ә ү с ә р и я. Юк, мин җибәрмәс идем, беләгенә асылынып барыр идем, асылынып кайтыр идем.

С ү р и я. Асылынып йөреп кенә бәхетле булып булмый бит, Кәүсәрия апа.

К ә ү с ә р и я. Асылынып йөрисеңме, бусагаңа арканлап куясыңмы, барыбер, бәхет инде ул, тик шундый егет синең яныңда гына булсын...

Ф а з ы л. Нигә соң син Рәкыйп абыйны арканлап куймыйсың?

К ә ү с ә р и я. Рәкыйп абыеңны арканлап куймасаң да качмый ул. Урлап та китмиләр аны. Ахыр чиктә барыбер ул минеке. Ә менә мин синдәй егетләрне арканлап куяр идем, билләһи, җаным үлгәндер синең, Сүрия, синең өчен мин көнләшәм. Шуның өчен генә булса да артыннан клубка ияреп йөрми булмас, ахрысы.

Ф а з ы л. Әйдә киттек.

К ә ү с ә р и я. Юк, җанкисәгем, бүген булмый шул, иртәгә, ямме?

Ф а з ы л. Иртәгә минем техникумда имтихан.

К ә ү с ә р и я. Алайса, берсекөнгә, ярыймы, чибәр егет? Мин инде сиңа үңга-сулга күз сирпергә ирек бирмәм. Ә бүген Сүрия белән генә бар инде син клубка, ярыймы? *(Сүрияне ишек янына тарта, пышылдап кына.)* Мин хәзер теге даруны... *(Сүрия, дәшмә дип, авызын каплый.)* Пока, гармунымның каешы, кай тирәдә йөри икән минем кояш баешы. *(Көлә-көлә чыгып китә. Сүрия аны озата чыга.)*

Ф а з ы л *(ялгыз)*. «Сүрия белән генә бар инде син». Барамы соң ул Сүрия андый җиргә. Юк бит, кызыксынмый бит ул. Ә нәрсә белән кызыксына ул? Нәрсә тели? Аңламыйм. Ике ел торам, аңламыйм. Бергә яшә, бер-береңне аңлама. Әшмени инде бу? *(Сүрия керә.)* Күрдеңме? Ул бит сиңа караганда күп яшькә олы. Семья мәсьәләсендә дә бәхетле дип санап булмый. Үзенә күрә кичерешләре бардыр аның да. Ләкин төшенкелеккә бирелми. Дөньядан тәм табарга тырыша. Уйный-көлә. Туры килсә, танцевать та итә. Киноның берсен дә калдырмый. Шуның өстенә клубка йөрергә дә атылып тора. Ә син нәрсә?

С ү р и я. Бөтен кеше дә бер характерда булмый бит инде, Фазыл.

Ф а з ы л. Вакытсыз картаеп барасың лабаса... Җитте. Миңа артык

бернинди сәбәп куйма. Елап ята торган балаң юк. Киен. Бүгенге көннән бөтен күңел ача торган җиргә бергәләп йөрибез, танцевать итәрбез.

Сүрия. Ярый, йөрербез, Фазыл. Ләкин бүген түгел.

Фазыл. Бәлки, быел түгел димәкче буласыңдыр. Укырга да син быел түгел, быел түгел дип сузып киләсең. Әгәр мин әйткәч үк кергән булсаң, быел техникумның инде өченче курсында булыр идең.

Сүрия. Син укып бетер инде, аннары карарбыз.

Фазыл. Минем укуым сиңа комачаулыймыни?

Сүрия. Мин дә укысам, сиңа тиешле тәрбияне бирә алмам бит, Фазыл.

Фазыл. Ой, үтердең. Әгәр дә минем укуым өчен генә син үзеңнең киләчәгеңне корбан итәргә уйлагансың икән, юк... Мин моңар юл куймыйм. Бетте. Иртәгә үк техникумга гариза язасың. Әйдә, киен.

Сүрия. Кая?

Фазыл. Кая булса да. Тик өйдә генә утырма, якты дөньяга чык.

Сүрия. Ярый, Фазыл, чыгармын, чыгарбыз. Ләкин бүген түгел.

Фазыл. Нигә бүген түгел?

Сүрия. Кәефем юк.

Фазыл. Ни булды?

Сүрия. Авырыйм.

Фазыл. Авырыйсың? Тукта әле. Эштә дә әллә ничегрәк күренден син бүген. Әллә? *(Көлемсерәп җибәрә.)* Әллә берәр нәрсә бармы? Әллә чыннан да? Һиһаять?!.

Сүрия. Юк, Фазыл, син уйлаган нәрсә түгел... Болай гына... Син бар, соңга каласың, көтәләрдер.

Фазыл. Эх, Сүрия!.. Ничек кенә синең йөрәгеңне уч төбенә алып карарга! Күрергә иде нәрсәләр бар икән анда?!

Сәрия. Бар дим, зинһар, ачуланырлар.

Фазыл. Караңгы төн, ае да юк, ичмаса... Җылытмаса да, яктыртыр иде.

Авыр көрсенеп, гармунын тартып чыгып китә.

Сүрия *(ялгыз)*. «Җылытмаса да, яктыртыр иде...» Эх, Фазыл. Мәхәббәт түгел ич инде ул, җылытмагач!.. Чын мәхәббәт тәмен татып карамаганга гына белмисең син әле аны... Ә бит кешедә чын мәхәббәт кайчан да булса бер кабыначак. Шул вакытта нишләрсең син минем белән? *(Почмактан чемодан алып, аннан зур гына бер шәрә курчак чыгара.)* Фәрит!.. Сиңа әти булачак кешең Фәрит кушарбыз дигән иде. Күренми торыйк инде без аңа, Фәрит... *(Курчакны шүрлек почмагына яшерә.)* Шунда, ерактарак яшеренеп торыйк... Бәлки, еллар үтү белән... Соң түгел бит, әле бернәрсә дә соң түгел безнең өчен. Бәлки, чыгар ул кояш, җылытыр ул безне... җылытыр!

Җырлый.

Җылытыр өшегән
Йөрәкнең бәгырен,
Күзләрдән сирпелгән
Очкыннар ялкыны.
Җылытыр якыннан,
Җылытыр еракган
Җылытыр ул юллар
Һәм еллар аркылы.
Ул ялкын бер генә,
Ул ялкын мәңгегә
Сүнмәскә кабына
Ташкынлы йөрәктә.
Ул ялкын эретә,
Ул ялкын терелтә,
Ул ялкын көч кертә,
Көл итә теләсә.

Кәүсәрия керә, тыңлый. Соңгы куплетына ул да кушыла.

Ул ялкын кабынса,
Дәртләтеп яндырса,
Әрнү дә, сызлау да,
Газап та — рәхәт.
Ул ялкын күренми,
Ул ялкын сүрелми,
Ул ялкын мәңгелек,
Ул ялкын — мәхәббәт.

Кәүсәрия. Янасыңмы? Әле кайчан малай гына иде, интересный и булып житеште бит Фазыл... Көнләшмәслек тә түгел шул.

Сурия. Кем әйтте сиңа мине көнләшә дип?

Кәүсәрия. Яшермә, яшермә.

Сурия. Кемнән көнләшим? Юк аның яраткан кешесе.

Кәүсәрия. Сине дә яратмыймы?

Сурия. Белмим. Җаны урынында түгел, һаман нидер эзләнә. Н эзләгәнен үзе дә белми.

Кәүсәрия. Шуңа теге нәрсәне тәвәккәллим дисеңмени инде?

Сурия. Бу килештән ничек итеп аның да, үземнең дә кул-аякны бәй-ләргә кирәк соң?

Кәүсәрия. Тудырсаң, бәлки, Фазылың да бераз утырыр иде.

Сурия. Бала белән беркетеп куяр идең, дисеңме?

Кәүсәрия. Андый хәлләр дә була. Баласыз вакытта җилбәзәк йөргән ирләр, балалары булгач, бөтенләй берегәләр.

Сурия. Фазыл җилбәзәк түгел. Бала белән генә кешене бәхетле итеп буламыни? Ул аның иркен бәйләп кую булмасмы?

Кәүсәрия. Кирәк булса, бәйләп тә куялар. Кулыңнан ычкындыр-ма. Зур кеше булачак ул Фазыл.

Сурия. Әллә ниләр сөйлисең син, Кәүсәрия апа.

Кәүсәрия. Әллә нәрсә сөйләмим, мин тормышны күбрәк беләм. Бары шул. Ярата дип, яратмый дип, көрсенеп яшәмиләр бит инде дөнья-да. Үз рәхәтеңне үзең табарга кирәк.

Сурия. Мена син яратып торасыңмы Рәкыйп абыйны?

Кәүсәрия. Рәкыйп абыең миннән 18 яшькә олы ул, нәрсәсен яра-тасың аның.

Сурия. Ә нигә торасың?

Кәүсәрия. Миңа аның белән рәхәт. Ул минем өчен барысын да эшли.

Сурия. Ә мәхәббәт?

Кәүсәрия. Әй җанкисәгем, мәхәббәт ул — бер минутлык рәхәт.

Сурия. Юк, бу мәхәббәт түгел, бу ниндидер...

Кәүсәрия. Әй, ташла әле, юк-бар белән баш катырма. Фазылың беләме йөгең барын?

Сурия. Белми калуы хәерлерәк.

Кәүсәрия. Алайса, мин теге даруны табып кайттым. Хәзер алып киләм, ә син бирешмә, төкер барысына да. Яшьлек ике килми ул, шуны бел... Мин бик тиз әйләнермен. *(Китә.)*

Сурия. Әйе. Яшьлек ике килми. Ләкин мәхәббәт тә ике килми бит, Кәүсәрия апа! Яратам бит мин аны. Фәкать аны гына яратам. Ә мена яратам дип муенына асылынырга булдыра алмыйм. Мәхәббәтне көчләп тагып буламыни?

Гадилә чыга.

Гадилә. Теге киттеме?

Сурия. Китте.

Гадилә. Әйдә карлыган вареньесы белән чәй эчик әле. Менә чыная-гына әлү кагы салдым, алма да турыйм. Авыз тәмең ачылыр. Мондый вакытта әйбәт була ул әчкелтем-төчкелтем.

Сурия. Нинди вакытта?

Гадилә. Сөйләмә миңа, мин барын да күреп, белеп торам. Утыр. Менә нәрсә табып кайттым мин синең өчен. *(Кесәсеннән лимон чыгара.)*

Сурия. Уй...

Гадилә. Авыз суларың килдеме? Шулай итә ул андый вакытта.

Сурия. Андый вакытым түгел минем, Гадилә түти, син ялгышасың.

Гадилә. Баладан татлы дөньяда ни бар? Тормышның бөтен яме шунда ләбаса.

Сурия. Торырга квартирың булмасын.

Гадилә. Сөйләмә юкны. Әнә заводка өч катлы йорт салалар, бирерләр. Бирмәсәләр, тагын бу йортка ни булган? Сезне кысрыклаган кеше бармы? Әнә улымнан тагын хат алдым. Елга техникумын бетереп, диңгезнекенә киткән. Кайту турында уйламый да! Укып бетергәч, сине үз янына алдырам, дигән. Өйләнеп балалары булса, китеп бармый да булмас. Ул чагында бу йорт бөтенләй үзегезгә кала.

Сурия. Йорттамыни хикмәт? *(Урамнан гармун тавышы ишетелә. Ул якына бара.)*

Гадилә. Әнә кайта бугай Фазылың да, гармунын сөйрәп. Ул нинди эштер инде тормыш иткән кешегә урамда гармун шыңгырдатып йөрү? Өйгә керми әле ул. Капка төбендәге эскәмиягә утырды. Гадәт диген, дәшеп алмасаң, төне буе да утырыр шунда гармунын кычкыртып. Дәшим әле үзенә, керсен.

Чыга. Бераздан Каусәрия керә.

Каусәрия. Анда Фазыл гармун уйнап утыра. Бигрәкләр дә моңлы уйный инде. Күзенә күренмим, бүлмим дип арт капкагыз аша гына кердем. Менә мин сиңа теге даруны алып килдем. Бу даруны аптекалардан да, бер каян да таба алмыйсың. Итәк астыннан гына бирәләр. Кара аны, сиздермә, яшереп кенә эшлә. Фазыл уйнавыннан туктады, өйгә керә, ахры. Бар, эчке бүлмәңә кер.

Сурия эчкә үтә. Ишектән Фазыл белән Рәкыйп керәләр.

Каусәрия. Аның бу чибәре мине эзләп йөридер инде, бәгърем.

Рәкыйп. Сине дә, җаный, менә Фазыл белән Сурия дә срочно кирәк булдылар.

Каусәрия. Нәрсәгә тагын?

Рәкыйп. Шатлык, җаный, шатлык. Фазылның тәкъдиме кабул ителгән. Мин лаборатория начальнигы янынннан киләм.

Каусәрия. Чынлапмы?

Рәкыйп. Чын, җаный, чын *(Фазылга)*. Тыкырдатканнар егетне бюрода. Көннәр әйбәт торганда Каманың югарыгы агымына шушы атнада ук өч кешелек күчмә лаборатория җибәрәбез, ди.

Каусәрия. Камага? Анда нишләргә?

Рәкыйп. Каманың Агыйдел белән кушылган өлешендәге су төбеннән эре бөртекле ак ком ятмасын алып, шуның структурасын өйрәнергә, аның берничә төрле измәсенә шунда, урында анализ ясап карарга.

Каусәрия. Лабораториядә пычранып яту өчен үзебезнең Идел буендагы измә генә җитмимени безгә? Фазыл тәкъдиме шул булыр инде — мөгез чыгару. Укымышлы кеше бит, техникум бетерә. Аңа монарчы эшләп килгән измә генә җитми. Эзләнә, Кама, Агыйдел төпләрендә актарынырга кирәк, янәсе.

Фазыл. Завод эре панельле детальләр эшләргә күчә. Ә Кама төбендәге ак ком ятмасы моның өчен иң кыйммәтле материал булачак.

Рәкыйп. Шуның өстенә су юлы белән баржада заводка кайтаруның арзанлыгы... Бу беләсеңме, җаный, безнең өчен күпме экономия. Менә шул. Әзерләнергә кирәк. Сурия кая?

Кәүсәрия. Авырый ул, ятә.

Фазыл. Авырый? Ни булды?

Кәүсәрия. Хатын-кызда нинди авыру булмас. Кыскасы, командировка аңа противопоказано. Вот шул!

Фазыл. Шаяртма. *(Эчке бүлмәгә үтә.)* Сүрия, ни булды?

Сүрия *(эчке бүлмәдән, көч-хәл белән)*. Кәефем начар.

Фазыл. Бәлки доктор чакыртыргадыр.

Кәүсәрия. Кирәкми, үтә ул.

Фазыл *(эчке бүлмәдән чыга)*. Рәкыйп абый, доктор, тизрәк!

Рәкыйп. Җаный, син карый тор.

Ашыгып чыгып китәләр.

Кәүсәрия. Шулай бик тиз.

Сүрия *(эчтән)*. Ой, Кәүсәрия апа...

Кәүсәрия. Киләм, киләм.

Ашыгып эчке бүлмәгә үтә.

## ӨЧЕНЧЕ КАРТИНА

Кама буе. Кич. Кояш баеп килгән вакыт. Бер кешелек Фазыл палатасы. Аның алдында учак пыскып тора. Пәрдә ачылганда Фазыл, тирән хискә бирелеп, гармун уйнап утыра, Кәүсәрия Фазыл янына якыная. Аннан җырлап җибәрә.

Кәүсәрия.

Кама буйларыннан китеп,
Кояш бата офыкта.
Күңелләрем җилкенсә дә,
Канатларым җилпенсә дә,
Китә алмыйм очып та.

Җырлый-җырлый палаткага кереп китә. Түбәннән, яр астыннан бер яшь кенә кыз килеп чыга. Гармун уйнаган Фазылга сәер караш ташлап, поса-поса таллар арасына яшеренә. Яшь таллар арасыннан аз гына йөзен чыгарып Фазылны күзәтә, йотлыгып гармун моңын тыңлый, аннан палатка эчендә Кәүсәрия барлыгын сизеп, «ай» дип кычкырып, яшен тизлеге белән таллар арасыннан түбәнгә ташлана. Фазыл кинәт борыла, атылып Кәүсәрия чыга.

Кәүсәрия. Ни бар? Син кычкырдыңмы?

Фазыл. Кемгә, сиңамы?

Кәүсәрия. Белмим мин...

Фазыл. Нәрсә анда, минем палаткада нишләдең?

Кәүсәрия. Постелеңне әйбәтләп җыеп куйдым...

Фазыл. Рәхмәт.

Кәүсәрия. Кил әле, кара, карагач рәхмәт әйтерсең. Кил инде!..

Фазыл. Ярар, йокы ястык теләми.

Кәүсәрия. Аның каравы ястык нидер теләр. Монда, Кама буенда акылыннан шашуың бар.

Фазыл. Шашырга вакыт тими әле.

Кәүсәрия. Шулай инде, көне буе лабораториядә быкырдашасыз. Кичен шул гармуныңа төртенәсең, ә Рәкыйп балыкта. Мин генә япаялгыз... Җанымны кая куярга белмим.

Фазыл. Әнә, агач башына эл.

Кәүсәрия. Әй, син туң күчәнгәме соң хатыннар йөрәген аңлау. Ничек тора синең белән Сүрия. Кибеп какланган бит инде мескенкәем. Шушы күчмә лаборатория белән китеп бардың, аны ялгызын гына калдырып.

Фазыл. Ул авырый, аның урынына менә син килдең бит.

Кәүсәрия. Миңа бик исең китмәгән була бит әле. *(Чәченнән сыпырмакчы була.)*

Фазыл. Калдыр әле, Кәүсәрия апа...

Кәүсәрия. Апа? Синнән бер биш-алты яшькә олы булган белән дә... Йөрәгем минем синең Сүрияңнән яшьрәк әле, синдәй егетләрне куырып алырлык. Мә, тотып кара, ялкыны бәреп тора.

Фазыл. Шаярма әле!

Кәүсәрия. Шаярмагач та... Нишләргә кирәк монда? Скука. Мондый скука буласын белсәм, ике аягымның берсен дә атламый идем, биллаһи, ичмаса, күңел ачарлык бер җан иясе дә юк бит тирә-юньдә. *(Кинәт Фазылны кочаклап ала).*

Фазыл. Нишлисең? Җибәр! Оятың кая?

Кәүсәрия. Нәрсә? Әллә чыннан дип уйладыңмы? Әй, балакаем, сынап кына карадым мин сине. Сүрияң көнләшкәч, әллә бу шундый микән, дип. Рәкыйбемне сиңа алмаштырырга соң, җүләр.

Фазыл. Ә нигә муенга асылынасың?

Кәүсәрия. Асылынам бик... сиңа... син үҗәткә. Лучше мин төшеп су керәм. Нервларымны басам ичмаса бер, төнгә каршы. Только син карама, яме. Мин купальниксыз гына керәм. Тирә-юньдә бер кеше дә юк.

Фазыл. Бата башласаң, миңа кычкырма. Бу юлы чын-чыннан батсаң да, бармыйм.

Кәүсәрия. Килмә, килмә, дөмегермен, ичмаса, бер су төбенә китеп... котылырмын...

Кинәт ачулы тавыш белән кычкырып җырлап су буена төшеп китә.

Күңелләрем җилкенсә дә,
Канатларым җилпенсә дә,
Китә алмам очып та.

Фазыл аның артыннан көлеп карап кала. Шулвакыт таллар арасына яшеренгән Кыз чыгып, тиз генә Фазыл палаткасы эченә кереп югала. Фазыл аның итәген генә күреп кала. Кем икәнен белмичә, аптырап, палатка почмагына килеп поса. Кыз палаткадан чыгу белән аның колагыннан эләктереп ала.

Фазыл. Син монда нишләп йөрисең, ә?

Кыз. Ой... җибәр!

Фазыл. Җибәрермен менә мин сине. Әйт, нәрсә чәлдерергә кердең?

Кыз. Чәлдерәм бик... Чәлдерерлек нәрсәң бар соң анда. Коры печән тутырылган мендәр дә щетиналары шытып чыккан солдат одеалы.

Фазыл. Каян күрдең әле аның щетиналарына кадәр?

Кыз. Бу мескен монда ничек ята икән дип, ятып карадым. *(Чиркаулап.)* Әбәү! Күлмәк аркылы кычыттыра хәтта.

Фазыл. Кычыттырмаса чәлдерәсе идеңме?

Кыз. Чәлдерәм бик, әллә син мине «Зәңгәр шәл» театрындагы угры кыз дип белдеңме? Кирәк булса, мин үземнекен бирермен. Сырган юрган. Сатин.

Фазыл. Кая соң ул синең сатинын?

Кыз. Җәйләүдә.

Фазыл. Ә җәйләвең еракмы?

Кыз. Моннан алты чакрым.

Фазыл. Шулкадәрле җирдән килдеңме?

Кыз. Мин монда көн саен киләм, кичен сыерларымны тизрәк савам да монда киләм.

Фазыл. Җәяүме?

Кыз. Җәяү.

Фазыл. Үзең генәме?

Кыз. Үзем генә.

Фазыл. Ә нишлисең син монда килеп?

Кыз. Менә синең гармун уйнавыңны тыңлыйм.

Ф а з ы л. Ә нигә сон минем сине бер дә күргәнем юк.

Кыз. Ә мин күренмичә генә. Әнә таллар арасына качып.

Ф а з ы л. Гармун тыңларга бик яратасыңмыни?

Кыз. Бик.

Ф а з ы л. Үзегездә юкмыни?

Кыз. Бар да, менә синең шикелле телләрен сайратып уйный белүче юк.

Ф а з ы л. Җырлар идеңме?

Кыз. Җырлар идем. Кама буена яңгыратып бер туйганчы җырлар идем. Ой ул безнең Кама буйлары... Син бит әле аны, абый, бөтенләй күргәнең юк. Гел шушы кызыл яр буенда гына ятасыз. Безнең җәйләү буйларын, авыл тугайларын төшеп күрсәгез, тагын да ямьлерәк сайратыр идегез гармуныгызны. Ул бит моннан ерак түгел, көймә белән агымга түбән.

Ф а з ы л. Я, монда сайрап күрсәт, күңелне җәлеп итсәң, бәлки, төшәрмен дә.

Кыз. Монда булмый, оялам.

Ф а з ы л. Ояласың? Сиңа соң ничә яшь?

Кыз. Унҗиде. Тиздән унҗиде тула. Унсигезгә чыгам.

Ф а з ы л. Унсигезгә чыгасың? Ә уналты тулганга күптәнме соң әле?

Кыз. Күптән инде, айдан артык.

Ф а з ы л. О! Яшең шактый икән шул. Анда сиңа ияреп, сезнең җәйләүләргә, тугайларыгызга төшеп йөрүе дә куркыныч, егетең күрсә...

Кыз. Әй, минем егетем юк әле.

Ф а з ы л. Ә исемең бардыр бит?

Кыз. Исемем Энҗе минем.

Ф а з ы л. Энҗе... Матур икән.

Кыз. Синең дә исемең матур, җырдагы кебек.

Ф а з ы л. Кара, минем исемнәргә кадәр белеп бетергәнсең.

Кыз. Абый, сез монда нәрсә эзлисез?

Ф а з ы л. Матурлык.

Кыз. Матурлык су астында гына түгел, җирдә дә, җир өстендә дә күп.

Ф а з ы л. Ләкин безгә су астындагы матурлык, андагы матур ташлар, эре бөртекле төрле төстәге комнар кирәк.

Кыз. Алар нәрсәгә?

Ф а з ы л. Кешеләрнең тормышын бизәр өчен. Шул су астыннан алган ташлар, комнар белән яңа салына торган биналарны бизибез без.

Кыз. Ә нигә безнең җәйләү буйларына, тугайларга төшмисез? Әй анда ул, абый, ташлар... Ком бөртекләре... төрле төстә... Эреле-ваклы, ясмык кебек яссылы, түгәрәк, күпкырлысы, ниндиләре генә юк...

Ф а з ы л. Чынлапмы?

Кыз. Честно-комсомольское... Иртә белән кояш чыккан вакытта су өсте тып-тын була. Мин көймәдә акрын гына йөзеп Кама култыгына керәм. Анда су чеп-чиста, үзе тирән... Көймәдән иелеп су төбенә карыйсың, җем-җем итәләр, энҗе бөртекләремени... Көймәдән су төбенә чумганыңны сизми дә каласың.

Ф а з ы л. Әллә чумдың?

Кыз. Әйе.

Ф а з ы л. Төбенә төшеп җитә алдыңмы соң?

Кыз. Башта булмады. Тирән. Су күтәрә. Аннан яр буеннан көймә төбенә зур таш салып алып кердем дә шуны кочаклап чумдым.

Ф а з ы л. Җиттеңме?

Кыз. Җиттем. Кайдан учларга белмисең, күз камаша... Кайда саргылт, кайда кызгылт, кайда зәңгәрсу-яшькелт булып җемелдиләр. Мин аларны бер урыннан гына алмадым. Атна буе һәр көн иртән кояш чык-

канда төрле урыннан җыйдым. Каманың теге ягына чыгып та чумдым. Ул якта тагын да матурлар, эреләр...

**Фазыл.** Син аларны нәрсәгә дип җыясың соң?

**Кыз.** Сиңа күрсәтергә. Бәлки, ярап куярлар.

**Фазыл.** Кайда алар?

**Кыз.** Безнең Тугай буенда, мин аларны яшереп куйдым.

**Фазыл.** Еракмы?

**Кыз.** Юк, монда гына. Безнең Тугай буйларын белмисеңмени, әйдә, күрсәтәм.

**Фазыл.** Әйдә.

**Кыз.** Анда берәү дә төшә алмый, анда таллык, әрәмәлек, адашып бетә...

**Фазыл.** Киттек, әйдә!

*Энҗенең кулыннан алып таллар арасына кереп югалалар. Тау астыннан купальнигы өстеннән кигән халатын җилләндереп Кәүсәрия менә.*

**Кәүсәрия.**

Җилләр, җилләр,
Шаян җилләр...

*(Фазыл палаткасына килә. Палатканың итәген күтәреп карап).* Әбәү! Җилләр искән! Кая киткән икән? *(Палатка эченнән записка алып чыга.)* Бу нинди язу? Хатмы дип әйтим? *(Укый.)* «Фазыл абый, синең гармун моңың безнең җәйләү буйларына, тугайларга кадәр яңгырый. Бигрәкләр дә матур уйныйсың. Каршыңа утырып бер туйганчы җырлыйсы килә». Нәрсә бу? Каян килгән? «Фазыл абый, нигә син безнең җәйләү янындагы тугайга килмисең? Ул бик матур, күңелле урын. Каманың яшел болынына тугайланып кергән җире. Бүген кояш батып, ай калыккач, шунда кил, яме, мин сиңе күтәрмен. Шунда мин сиңа сез эзләгән бөртекләрне күрсәтермен». Ә? Менә кая киткән ул!.. Кызлар белән хат алышып!.. Теге картлач кайта бугай. Рәкыйп, Рәкыйпчик! Кайтасыңмы, җанкисәгем. Тизрәк мен, ачыгып беткәнсең, кадерлем...

**Рәкыйп** *(тау астыннан көчкә-көчкә күтәрелә).* Күрмисең, җаный, бүген никадәр балык тоттым.

**Кәүсәрия.** Балыгы балык, Фазыл качкан әнә анда.

**Рәкыйп.** Кая качкан?

**Кәүсәрия.** Кызлар янына, ниндидер җәйләүгә, тугайга.

**Рәкыйп.** Гаҗәп түгел. Өйдән чыгып китеп, морҗа күмелсә, андый эшне китап «дөрес» саный дия торган иде минем мәрхүм бабай. Монда бит Сүриясенең морҗасы гына түгел, тәтене дә күренми. Аннан өйдән чыгып киткәнгә дә айдан артты инде, кызлар янына барса да, гаҗәп түгел, яшь кеше әле ул Фазыл, икенче яшьлеген кичерә. Тем более беренче яшьлеген татымый калды.

**Кәүсәрия.** Ничек татымый калды?

**Рәкыйп.** Егет гомерен күрмәде. Малай килеш өйләнде.

**Кәүсәрия.** Шулай булгач, аның хакы бармыни? Кызлар белән йөрергә? Өендә хатыны булса да?

**Рәкыйп.** Бар дип әйтмим, шулай да күңел бит ул, яшьлек.

**Кәүсәрия.** Синең үзеңнең күңелең шундый. Мут. Шуңа күрә син андыйларны яклыйсың.

**Рәкыйп.** Кит әле, җаный, булмаганны.

**Кәүсәрия.** Сөйләмә миңа. Гомерең мине алдап үтте. Әллә яратып торасыңмы син минем белән. Яшьлегемә кызыгып кына торасың син. Минем яшьлегемне генә әрәм иттең. Берәр чибәррәк нәрсә күрсәң, күзләрең хәзер ялт-йолт, карак мәчеенеке шикелле. Ә мин, җүләр, аны чын күңелдән яратып, янып, аның өчен утка-суга керердәй булып, тырнак кадәр дә хыянәт итмичә...

Рәкыйп. Ә мин хыянәт иттемме кайчан да булса? Сиңа гына табып яшим бит мин. Я, акыллым, елама инде, тынычлан, сиңа бит ярамый, йөрәгең...

Кәүсәрия. Син мине йөрәк авырулы ясадың. Инфарктка китереп җиткерәсең инде тиздән...

Рәкыйп. Тынычлан, тынычлан, утыр шунда. Кая, валидол биримме?

Кәүсәрия. Кадалып кит валидолың белән, миңа валидол түгел, мәхәббәт кирәк. Янып торган мәхәббәт кирәк.

Рәкыйп. Соң, бирәм бит инде бар күгеп.

Бер итәк таш тутырып йөгереп, тиргә баткан Фазыл кайтып керә. Бераздан Энҗе кереп, бер читтә тора.

Фазыл. Рәкыйп абый, әйдә тизрәк лабораториягә керик әле.

Рәкыйп. Нәрсә бар?

Фазыл. Хәзинә. Нәкъ безгә кирәкләре, минемчә. Иртәгә кадәр түзәр хәлем юк. Карыйк әле.

Рәкыйп. Каян алдың?

Фазыл. Амфибия, су кызы, Русалка бирде. Дөньяда нинди кызлар була икән, ә? Үзе яшь кенә, ут чәчә. Энҗе-Зөбәрҗәт. Атналар буе су төбенә чумып учы белән җыйган. Иртәгә иртән миңа ул аларның урынын күрсәтәчәк.

Рәкыйп. Әйдә әле, әйдә, карыйк әле.

Кереп китәләр.

Кәүсәрия *(Энҗене күреп, аптырап тора).*

Энҗе. Исәнме, апа.

Кәүсәрия. Син кем?

Энҗе. Энҗе.

Кәүсәрия. Энҗе! Фазыл итәгенә төяп кайткан энҗеләрнең бер бөртегеме әллә?

Энҗе. Юк, апа, мин кеше. Исемем минем Энҗе.

Кәүсәрия. Хәер, Энҗе диярлегең бар икән, сүзем юк. Син үзең кайдан?

Энҗе. Колхоздан. Безнең колхозның монда җәйләве бар. Мин шунда сыерлар савам.

Кәүсәрия. Фазыл абыеңа ул бөртекләрне син табып бирдеңме?

Энҗе. Әйе.

Кәүсәрия. Әбәү... Өшетеп җибәрде.

Энҗе. Кереп ятыгыз, апа, кичен салкынча шул. Мин дә җәйләвемә кайтам. Хушыгыз. *(Китә, бераздан еракктан Идел буен яңгыратып саф моңлы тавыш белән кыз җыры ишетелә.)*

Кама буе тугай-тугай.
Тугайлары — тал тирәк.
Кама дулкыннары кебек
Нигә ярсый бу йөрәк?

Кама буе, туган ягым.
Яр буйлап кичләреңдә
Җырларым ташый... күңелдә
Иң татлы хисләр генә.

Кәүсәрия. Туган як. Минем туган ягым да юк, торган ягым да юк. Аның кебек җилпенеп оча да белмим мин, кысыр үрдәк.

Җыр дәвам итә, ут сүнә.

## ДҮРТЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук урын. Кич. Акрын гына пыскып янган учак янында Р ә к ы й п кичке аш әзерләп йөри. Каманың түбән агымыннан моторлы көймә кайтканы ишетелә.

Р ә к ы й п. Экспедиция кайта бугай. Ә яр буе кокының ашы әзер түгел әле. *(Ярга моторлы көймә килеп туктый, аннан Фазыл таеышы.)*

Ф а з ы л. Рәкыйп абый, лабораториядән минем инструментларны чыгар әле.

Р ә к ы й п. Соң бит инде. Ә... җәмәгать тәртибендә булышучы килгән икән. Кая, менегез әле монда, мен.

Яр астыннан йөгереп Э н җ е менә.

Э н җ е. Исәнмесез, абый.

Р ә к ы й п. Исәнме, сеңелем, исәнме! Синмени инде ул безнең коллективның добровольный члены?

Э н җ е. Әйе, мин. Кая, Фазыл абый сораган әйберләрне бирсәгез иде.

Р ә к ы й п. Ашыкма, сеңелем, ашыкма. Кая күрешик, мин Рәкыйп абыең булам, өлкән лаборант, яшем белән дә биредә иң өлкәне.

Э н җ е. Беләм, Фазыл абый сөйләде.

Р ә к ы й п. Фазыл абыең тагын нәрсә сөйләде?

Э н җ е. Артык бернәрсә дә. *(Фазыл менә.)*

Ф а з ы л. Күрдеңме, Рәкыйп абый, нинди булышчы таптым мин үзебезгә.

Р ә к ы й п. Әйбәт, әйбәт, ләкин моңарчы кайда булган ул? Кәүсәрия апаңны азаплап йөргәнче монда, авыру йөрәге белән.

Ф а з ы л. Кәүсәрия ханым кайда соң?

Р ә к ы й п. Ул авылга, почтага китте *(Фазыл палатадан чехолга төргән бер кочак инструментларын күтәреп чыга)*. Син кая болар белән?

Ф а з ы л. Менә теге як ярдан бераз югарырак менгәч, Камага борын булып кергән нинди дер бер Көл-тау бар, ди Энҗе. Шуның итәген бераз зондировать итеп карыйсы иде.

Р ә к ы й п. Көл-тау?

Э н җ е. Әйе. Ерактан ул сүнгән көл өеме кебек, нинди дер шәмәхәкөрән булып күренә. Шуңа Көл-тау дигәннәр.

Р ә к ы й п. Болай булгач, заводтан өстәмә штат сорап, сине, сеңелем, бөтенләй штатка алмый да булмас. Көн саен җәмәгатьчелек тәртибендә эксплуатировать итү килешмәс бит. *(Фазылга.)* Син кайда болай озакладың соң?

Ф а з ы л. Менә кайтышлый җәйләвенә туктап Энҗене алып чыктым. *(Әйберләрен күтәреп яр астына төшә башлый.)*

Р ә к ы й п. Алып килгәч, озатып куярга да онытма.

Э н җ е. Мин шул озатып кую шарты белән генә килдем дә.

Р ә к ы й п. Әлбәттә. Бәйрәм ашы кара каршы, диләр бит. Ул сине кайтарып куйгач, аның ялгызын гына җибәрмә, аны да монда кадәр китереп куй.

Э н җ е. Ой, алай төн буе озатышып йөрсәк, иртән минем сыерларымны кем савар.

Р ә к ы й п. Сыерларга караганда кешеләргә күбрәк әһәмият бирергә кирәк, сеңелем.

Э н җ е. Ой, мондый сүзләрең белән син мине бөтенләй авылдан кудыртасың, абый.

Р ә к ы й п. Кусалар, безгә заводка килерсең. Безнең профессиягә мәхәббәтең дә кереп бара.

Э н җ е. Фазыл абый, гармунны да алыйк инде. Без кайтканда ай калка. Ай яктысында Кама өстеннән җырлап кайтырбыз. *(Палаткадан гармун алып чыга да Фазыл артыннан яр астына йөгерә.)*

Р ә к ы й п. Син үзең җыр булып күренәсең бит әле мин картлач күзенә дә, Энҗе-Зөбәрҗәт.

Аста моторлы көймәнең кузгалып китүе һәм ерагая барган гармун-җыр тавышы ишетелә.

Р ә к ы й п. Барганда ук җырлый башладылар әле болар...

Җырлый-җырлый эшкә бара
Яшь егетләр, яшь кызлар...

Эх, безнең яшьлекнең романтикасы һаман яши әле бу тирәдә... Авыл яшьләренең рухы нык...

Эх... яшь егетләр...
Эх... яшь кызлар!..
Чибәрләр, алтын кебекләр,
Эштә ялкын кебекләр.

К ә ү с ә р и я кайтып керә.

К ә ү с ә р и я. Нишлисең, акылдан шашасыңмы әллә?
Р ә к ы й п. Менә, яшьлегем искә төшеп китте әле, җаный.
К ә ү с ә р и я. Яшьлек?
Р ә к ы й п. Әйе, яшьлек шул, җаный, яшьлек. Үзеңнең яшь вакытыңны исеңә төшер.
К ә ү с ә р и я. Нишләгән мин яшь вакытта?
Р ә к ы й п. Соң миңа, кырыктан узган иргә, гашыйк булдың түгелме? Хатын, бала бар дип тормадың бит.
К ә ү с ә р и я. Нишлисең яраткач...
Р ә к ы й п. Шулай шул, мәхәббәт ул, җаный, аны-моны тикшерми. Ә менә ничә ел инде синең белән рәхәтләнеп торабыз!
К ә ү с ә р и я. Берәүләргә рәхәт, берәүләргә газап.
Р ә к ы й п. Кемгә газап?
К ә ү с ә р и я. Ә Сүриягә Фазылҗанның бу кыланышы ишетелсә?
Р ә к ы й п. Нинди кыланышы?
К ә ү с ә р и я. Соң, теге кыз, кем әле?
Р ә к ы й п. Энҗеме?
К ә ү с ә р и я. Әйе, шул кычыткан чыпчыгы.
Р ә к ы й п. Юк, җаный, бер дә кычыткан чыпчыгына охшамаган ул. Күрдем мин аны, таныштым. Өметле күренә ул кыз.
К ә ү с ә р и я. Теләсә ничек булсын, хатыны бар өстеннән шулай акылын җуеп йөрү килешәмә?
Р ә к ы й п. Мин монда бернинди килешми торган эш күрмим. Фазыл акыллы егет ул. Инде егерме ике яшьлек янып торган егетнең табигатьне, айлы төнне, яшьлекне, матурлыкны яратуын да начарлык күрәләр икән кайберәүләр, димәк, ул кешеләр үзләре начарлык эстәп йөрүчеләр булып чыга, җаный.
К ә ү с ә р и я. Нәрсә? Мин начарлык эстәүче буламмыни, синеңчә?
Р ә к ы й п. Мин син димим бит. Фазылга тимик инде без, җаный. Аның гөнаһсыз яратуы берәүгә дә зарар итмәс. Кеше яратып яшәргә тиеш. Сизмисеңмени Фазылның ничек үзгәрүен? Һәрвакыт көрсенеп яшәгән егет хәзер ут булып яна. Күрсәң иде син аның көн буе лабораториядә нинди дәрт белән эшләвен... Кама буен гына түгел, дөньяны актарырга әзер.
К ә ү с ә р и я. Бу тирәнең комын тизрәк актарып бетерергә дә, Агыйдел тамагына күтәрелергә кирәк. Бәлки, бу кычыткан чыпчыгы калыр иде үзенең тугаенда.
Р ә к ы й п. Анысы калсын, анысында сүзем юк. Тик менә егетнең дәрте генә калмасын.

Кәүсәрия. Очрата алмыйм бит бу арада ул кызны. Кирәген бирер идем бирүен.

Рәкыйп. Очрашмасын инде ул нарасый синең белән. Кирәкми. Эча бирсен күбәләктәй җилпенеп үзенең болын-тугайларында. Ә без, картлар, аларга комачауламыйк, үз эшебездә булыйк. Кая, почта алып кайттыңмы?

Кәүсәрия. Алып кайттым, мә *(бер төргәк газета-журналлар бирә)*.

Рәкыйп. Заводтан пакет-фәлән юкмыни? Җибәргән анализларга җавап килергә тиеш иде.

Кәүсәрия. Юк, ә менә җиткән егетеңнән хат бар.

Рәкыйп. Харистанмы? Кая, бир әле. Анысы кемгә?

Кәүсәрия. Фазылга. Сүриясеннән. Укы хатынны. Акча сорамаганмы тагын малаең?

Рәкыйп *(конвертны ачып)*. Карточкасын җибәргән. Әтә-тә-тә... Кара, нинди чибәр кычыткан чыпчыгын кочаклап төшкән.

Кәүсәрия. Әбәү, прическасы... Тутый кош бүрегемени.

Рәкыйп. Ә күз төбендә нинди сызыклар. Япон кызыдыр бу.

Кәүсәрия. Чибәр. Современный. Артын укы, артын, нәрсә язган.

Рәкыйп. «Киленең Татьяна Михайловна».

Кәүсәрия. Өйләнгән. Менә, кыз-гыж, бабай булдыңмы инде?

Рәкыйп. Дедушка. Туйга чакырган.

Кәүсәрия. Синеме?

Рәкыйп. Мине дип... Икебезне инде.

Кәүсәрия. Кая әле, кая, нигә ялганлыйсың. Менә бит: «Папочка, приезжай на свадьбу».

Рәкыйп. Папочка дип, папочкасының ялгыз гына яшәмәгәнен белә ич ул. Ярый инде, нигә шулай күңеленә авыр аласың? Бергә барырбыз. Әнә алар, бу як ярга чыктылар. Әйдә керик, ятыйк *(Рәкыйп палаткага кереп китә)*.

Кәүсәрия *(үз-үзенә)*. Яшим дип яшим инде...

Палатка янындагы чиләкле суны алып учак өстенә сибә. Аннан авыр көрсенеп палаткага кереп китә. Сәхнә бераз буш тора. Бераздан тау астыннан Фазыл белән Энҗе менәләр.

Фазыл. Мин, Энҗе, гармунымны палаткага кертеп чыгам да сине җәйләвеңә кадәр озатып куям.

Энҗе. Ой, кирәкми, Фазыл абый, мин курыкмыйм. Ай яктысы якты, мин үзем генә рәхәтләнеп җырлый-җырлый кайтам.

> Чылтырап аккан чишмәләргә
> Суга дип килгән идем,
> Тиз генә әйләнеп өйгә
> Кайтырмын диген идем.

Кайта алмадым бит менә тиз генә әйләнеп. Фазыл чишмәсе шундый сихридер инде ул. Тиздән менә, ай бу турыга җиткәч, таң йолдызы калкачак. Ә син кереп йокла, ял ит. Иртүк тагын теге якка Көл тавына чыгам дисең.

Фазыл. Әйе, чыгам. Ул як ярда җемелдәгән энҗе бөртекләрен кояш нурында тикшереп карыйм. Беләсеңме, Энҗе, кешеләрнең ял итә торган биналарын, культура сарайларының, санаторий, курорт биналарының фасадларын әнә шул энҗедәй бөртекләрдән койган плитәләр белән бизисе килә... Менә бит нәрсә эзлибез без...

Энҗе. Таптыгызмы соң?

Фазыл. Таптым. Матурлык эзләгәндә матурны таптым. Бу бәхет түгелмени?

Энҗе. Бәхет! Синең хезмәтеңнең җимешен кешеләр күреп куанып яшәячәкләр, кешеләр сиңа гомер буе рәхмәт әйтәчәкләр. Минем дә синен

шикелле төзүче буласым килә. Кешеләр өчен матур биналар төзеп калдырасым килә.

Ф а з ы л. Соң, әйдә безгә. Мин сине үзебезнең заводның техника мәктәбенә урнаштырырмын. Аннан менә минем кебек я лаборант, я төзүче мастер булып чыгарсың.

Э н ж е. Барам, Фазыл абый, барам. Минем бит бик укыйсым килә.

Ф а з ы л. Укырсың, Энҗе, мин сиңа булышырмын. Әйдә, мин сине үзем белән үк алып китәм.

Э н ж е. Юк, Фазыл абый, мин әле хәзер үк бара алмыйм, мин синең аша гаризамны, документларымны җибәрәм. Ә көз көне укырга килермен. Син хат язарсың. Ярыймы, Фазыл абый?

Ф а з ы л. Ярый.

Э н ж е. Мин кайтыйм инде, иртүк сыерларымны саварга торасым бар.

Ф а з ы л. Мин дә... Мин дә барыйм синең белән. Ерак та түгел, әнә анда, борылышка кадәр генә.

Э н ж е. Кирәкми.

Ф а з ы л. Энҗе, кара инде күзләремә тагын бер генә мәртәбә...

Э н ж е. Куй, Фазыл абый. Мин оялам.

Ф а з ы л. Энҗе.

Э н ж е. Иртәгә кадәр.

**Фазыл кулыннан ычкынып таллар арасына кереп югала. Аннан аның ерагая барган жыры ишетелә.**

Кама буе тугай-тугай,
Тугайлары — тал-тирәк.
Кама дулкыннары кебек
Нигә ярсый бу йөрәк?

Ф а з ы л. Эх, Энҗе-Зөбәрҗәт!.. Бу нәрсә соң бу? Мавыгу түгелме? Унсигез яшемдә түгел бит инде мин мавыгырга. Матур, матурлык! Ләкин бер карауда күзнең карасын ала торган тышкы матурлык турында бармый бит монда сүз. Аның күңеле матур. Һәрнәрсәдән матурлык эзли торган, матурлыктан тәм таба белә торган матур. Аңа фәкать ярдәм итәргә. Абыйларча, туганнарча, кешеләрчә — бары шул. *(Палаткасына керә башлый, өстәлдә яткан хатны күрә.)* Хат! Сүриядән, Сүриямнән!.. Менә бит, минем үз матурым бар. *(Хатны ача, укый.)* Бу нәрсә бу? Нәрсә яза бу? «...Мин анда сине Энҗе тапкансың дип ишеттем». Ә? *(Кәүсәрияләр палаткасына борылып карый, яңадан укый.)* «Ашыкма, сынап кара, чынлап та энҗеме ул? Син эзләгән энҗе булса, аның белән бәхетле булырыңа ышансаң, минем өчен вөжданың газапланмасын, мин синең фәкать бәхетле булуыңны телим. Әгәр дә чын бәхетеңне тапсаң, мин юлыңа киртә булмаячакмын». Акылдан шашкан! Өч ел торабыз ләбаса без, шундый хат язарга тиеш идемени ул?! Эх, Сүрия, Сүрия! Аңламыйм мин сине... Аңлый алмадым бит һаман мин сине!.. *(Палаткага кереп китә. Күрше палаткадан әкрен генә Кәүсәрия чыга. Күктәге ай болыт астына кереп югала. Кама буе караңгылана. Палатка төбендә өрәктәй басып торган Кәүсәрия авызындагы папирос уты гына утлы нокта булып кала. Ерактан, Кама буеннан, Энҗенең җырлаганы ишетелә.)*

К ә ү с ә р и я. Җилләр, җилләр!.. Берәүләргә гел уңай яктан исә, икенче берәүләргә гел кире.

Ерактан Энженең шат жыры көчәеп, Кәүсәриянең үксүен күмеп китә.

Кама буе — туган як,
Яр буйлап кичләрендә
Җырларым ташый... күңелдә
Иң татлы хисләр генә.

## БИШЕНЧЕ КАРТИНА

Яңа салынган коммуналь йортта ике бүлмәле Фазыллар квартирасы. Уңда квартирага керә торган баскыч площадкасы һәм анда Рәкыйпләр квартирасы ишеге күренә. Пәрдә ачылганда Сүрия пианинода уйнап утыра. Бераздан Гадилә түти килеп керә.

Гадилә. Исәнме, кызым Сүрия?

Сүрия. Әйбәт әле, Гадилә түти. Әйдә уз, утыр.

Гадилә. Нихәл яшисең, бу арада килә алмадым.

Сүрия. Әйбәт. Менә яңа мебельләр алдык.

Гадилә. Фазыл кая соң? Кайтмадымыни әле?

Сүрия. Юк шул әле, эше күп бит аның хәзер...

Гадилә. Шулайдыр шул. Начальник итеп күчергәннәр икән дип ишеттем.

Сүрия. Әйе, үзебезнең лабораториянең начальнигы итеп куйдылар. Болай да тынгысыз кешегә җитә калды инде, көн юк, төн юк.

Гадилә. Шундый зур лабораториянең хуҗасы булгач, сәгать теленә ябышып кына утырмыйдыр шул хәзер. Әле менә заводка чакырганда күчмәгәнемә үкенеп тә куям кайвакытта. Яңа квартир алуыгызга бик шат. Тик минә минем яныннан киткәч, хәлегезне еш кына белә алмыйм. Ничек соң, Фазыл кичләрен клуб тирәсенә йөрмиме хәзер?

Сүрия. Кая клуб, Гадилә түти, беркая чыга алмый.

Гадилә. Чыгып йөрмәсен шул инде. Әле теге җәй көне булган җирennән, Кама буеннан килгән хат өчен дә бик борчылган идем.

Сүрия. Андый анонимкаларга әһәмият бирә башласаң.

Гадилә. Анысы ни дигән сүз була инде аның?

Сүрия. Анонимка — исемсез хат. Язган кешесе имзасын куймый җибәрә. Ялганы фаш ителүдән куркып. Ә җәй көне... Ой, җәй көне Гадилә түти... җәй көне ул минем Фазылым Кама буеннан бөтенләй башка кеше булып кайткан иде... Сокланып туя алмаслык иде хәтта. Нур сибеп тора иде...

Гадилә. Ә хәзер?

Сүрия. Хәзер тагын болыт басты. Күңелсез, уйчан... Бүлмәсенә керә дә бикләнә.

Гадилә. Эше күп бит, үзең әйтеп торасың, аннан соң, институтка да кергән ди түгелме соң быел?

Сүрия. Әйе, аллә бирәр генә кыш укуыннан ял итеп торасынмы, дигән идем, тыңламады. Авыр инде шундый тынгысыз эш белән укуны бәйләп алып бару.

Гадилә. Әйдә тырышсын, тырышкан таш ярыр, ди бит.

Кәүсәрия *(ишек төбеннән)*. Күрше, күрше дим, чык әле. Менә Фазылга телеграмма китергәннәр. Әйдә, кул куеп ал *(Сүрия чыга, кулына телеграмма тотып керә. Артыннан Кәүсәрия керә)*. Кая, кайдан килгән? Кемнән? Ач әле, ач, Сүриякәем.

Сүрия. Нишләп ачыйм, Кәүсәрия апа, миңа түгел бит ул.

Кәүсәрия. «Кызыл яр» пристаненнан түгелме соң?

Сүрия. Шулай дигән шул.

Кәүсәрия. Соң, шул бит инде җәй көне без булган җир. Кама буенда...

Сүрия. Булса соң?

Кәүсәрия. Теге хатта язылган кыздан түгел микән диюем.

Сүрия. Карагыз әле, Кәүсәрия апа, мин сезгә ул хат турында беркайчан да авызыгызны ачасы булмагыз, дип кисәткән идем шикелле.

Кәүсәрия. Ай алла, ачмасам соң, ачмам. Әле тик сине үз күреп борчылып кына әйтүем. Әнекәем лә, син дә мондамыни әле, Гадилә түти? Күрми дә торам. Исән-сау гына йөрисеңме?

Г а д и л ә. Әйбәт әле, менә тулай тороктан эштән кайтышлый хәлләрен белеп чыгыйм балакайларымның, дип кагылган идем.

К ә ү с ә р и я. Эшләре әйбәт. Фазылны начальник итеп куйдылар. Заводта 35 ел эшләгән кеше бер читтә калды. Гомерлек өлкән лаборант булып.

С ү р и я. Рәкыйп абый бит үзе теләмәде. Яшь кеше дип Фазылны үзе тәкъдим итте.

Г а д и л ә. Аны начальник итсәләр, син нәнкәсез кала идең бит, Кәүсәрия, анысын да уйлаганнардыр кешеләр.

К ә ү с ә р и я. Телең каһәр, гел чагып кына тора. Ярый, тик күрше хакы дип, якын күреп кенә. Безгә дә кереп утыр, Гадилә түти, самовар куярмын.

Г а д и л ә. Рәхмәт.

К ә ү с ә р и я чыгып китә.

Г а д и л ә. Бар да әйбәт, тик бу бәндә белән күрше булуы гына начар.

С ү р и я. Сөйләнә бирсен, аны кем тыңлый.

Г а д и л ә. Яз көне тыңлагансың бит һәм чак үлгәннән калдың шуның аркасында.

С ү р и я. Аны тыңламадым мин. Үзем шулай эшләдем. Шулай кирәк иде, Гадилә түти.

Г а д и л ә. Сөйләмә юкны. Менә хәзер шул җүләрлегең аркасында... Беренче белән шулай шаяраламрмыни. Ярый, мин кайтыйм әле, бу арада мәшәкәтем булып алды.

С ү р и я. Нинди мәшәкать?

Г а д и л ә. Улым кайтып китте бит.

С ү р и я. Кит әле, нигә безгә хәбәр итмәдең?

Г а д и л ә. Үзем дә юньләп күрә алмый калдым. Кичке пароход белән кайтты, иртәгесе белән китте. Узышлый гына сугылган.

С ү р и я. Өйләнгәнме соң әле?

Г а д и л ә. Юк. Язга тәвәккәлли бугай инде. Туйны өйгә кайтып, синең яныңда уздырам, ди.

С ү р и я. Туйдан безне калдыра күрмә тагын, Гадилә түти.

Г а д и л ә. Әйттең сүз. Туйның түр башында сез булачаксыз инде. Башкода булып. Үз балаларым кебек бит сез минем. Бу арада төшемә дә кергән идегез. Әйбәт торыгыз, юк-бар сүзгә колак салмагыз. Бала кирәк бу йортка, бала. Фазылның да күңелсезлеге шуннандыр, бәлкем... Ярый, хуш. *(Китә.)*

С ү р и я *(ялгыз)*. Ялгышасың, Гадилә түти... Бала белән генә кешене бәхетле итеп булмый.

Кухняга кереп китә. Фазыл кайтып керә. Ул арыган, талчыккан, күңелсез. Кире чыгып китәргә уйлагандай, ишек тоткасын тотып тора. Аннан акрын гына чишенеп, ишек янындагы вешалкага киемнәрен элә, кухнядан С ү р и я чыга.

С ү р и я. Кайттыңмыни, Фазыл? Утыр әйдә. Ачыккансыңдыр. Бүген бигрәк озакладың. Берәр киңәшмә-фәлән булмагандыр ич?

Ф а з ы л. Кайтышлый училищега кердем.

С ү р и я. Алай бит әле. Бүген беренче октябрь — училищеда уку башланган көн. Ничек соң, укучылар туплап бетерә алганнармы?

Ф а з ы л. Юк. Яңа набордан бер-ике кеше килеп җитмәгән. *(Папирос кабыза, арлы-бирле йөренә.)*

С ү р и я. Куй инде папиросыңны. Аш состым менә.

Ф а з ы л *(язу өстәле янында тукталып кала, өстәлдәге телеграмманы күреп ала)*. Бу нәрсә бу?

С ү р и я. Ай алла, онытып торам икән, сиңа телеграмма. Әлерәк кенә китерделәр.

Ф а з ы л. Синең шул булыр инде *(ача, укый)*. Сәгать ничә?

С ү р и я. Җиде.

Ф а з ы л *(телефонга килә, номер җыя)*. Пристань? Әйтегез әле, зинһар, «Тинчурин» пароходы килдеме? Нәрсә? Әле генә килде? Рәхмәт *(ашыга-ашыга киенә)*. Мин озакламам. Өстәлеңне күңеллерәк әзерлә. Кунак алып кайтам *(ашыгып чыгып китә)*.

С ү р и я *(бераз башы әйләнеп китеп, чигәсен тотып тора. Аннан телефон тумбочкасындагы ачык калган телеграмманы ала. Озак итеп аңа карап тора. Акрын гына укый)*. «Киләм. Каршы ал. Энҗе». *(Озын паузадан соң.)* Энҗе? Тукта әле? Кем бу Энҗе? Теге хәерсез анонимкачы хатында да ниндидер Энҗе исемле кыз турында язылган иде.

Р ә к ы й п керә.

Р ә к ы й п. Мин әле бу, күрше.

С ү р и я. Ә... сез икәнсез шул.

Р ә к ы й п. Кәүсәрия монда түгел микән дигән идем. Кайттым менә, аш та юк, чәй дә юк. Үзе каядыр чыгып киткән.

С ү р и я. Аш өстәлдә, Рәкыйп абый, әйдә, ашап алыгыз.

Р ә к ы й п. Рәхмәт, ашарга дип кермәдем. Әле менә Фазылның пристаньга йөгергәнен күрдем дә... Бүген көтте инде ул аны. Көне буе. Ну... ул кыз укырга килә. Фазыл аңа укырга урнашырга булышты. Гаҗәпмени? Бу нәрсә кайбер күп сөйләүчеләр өчен азык булырга мөмкин. Кыскасы, сине кисәтеп куйыйм дип кергән идем.

С ү р и я *(көлеп)*. Юк, Рәкыйп абый, Фазылны мин беләм бит. Аның шундый киң күңелле булуына мин шатланам гына. Әле ул кызга мин үзем дә кулымнан килгән кадәр булышачакмын.

Р ә к ы й п. Рәхмәт, Сүрия сеңелем. Әнә кайта бугай минем җанкисәгем дә. Шулай, ышанма юк-бар сүзгә. *(Рәкыйп ашыгып чыгып китә.)*

С ү р и я. Рәхмәт төшкере. Нишләсен соң инде үз ирке булмагач... Кешеләргә карата булган шул кечкенә генә игелекне дә хатынынннан яшереп эшләргә мәҗбүр инде ул, мескен. Кая соң, тизрәк табын әзерләргә кирәк. Кайтып та җитәрләр. *(Йөгерә-йөгерә чәй табыны әзерли. Өстәлгә кухнядан вазалар, шкафтан яңа сервизлар чыгарып куя, яңадан йөгереп кухняга кереп китә: ишектән чемодан күтәргән Фазыл һәм Энҗе килеп керәләр. Фазыл шат, бәхетле һәм җитез.)*

Ф а з ы л. Менә, безнең резиденция шушы инде, Энҗе. Кая, сал өстеңне. *(Чемоданны куеп, аның өстен салдыра башлый.)* Сүрия, Сүрия, кунак килде, каршы ал!

Кухнядан йөгереп С ү р и я чыга.

С ү р и я. О, әйдә, әйдә, сеңелем, рәхим ит. *(Аңа кулын сузып килә.)*

Ф а з ы л. Энҗе. Безнең училищеда укыйсы кыз шушы була инде, Сүрия.

С ү р и я *(кул биреп)*. Исемем Сүрия булыр минем. Әйдә, әйдә, тартынма. Менә монда утыр. *(Энҗе, нәрсә әйтергә белмичә, каушап, югалып кала.)* Фазыл, утырт инде кунакны.

Э н җ е. Юк, юк, рәхмәт. Мин нинди кунак булыйм, ди. Мин укырга дип килгән кеше, туры тулай торакка барыйм дигән идем... Менә бит, Фазыл абый җибәрмәде.

С ү р и я. Нинди юк сүз сөйләү ди ул. Әйдә, әйдә, утыр. Тенкәләтеп чит шәһәрдә тулай торак эзләп йөрниләрмени? Фазыл, нәрсә карап торасың?

*(Фазыл Сүриянең шундый шат, җитез һәм чын күңелдән кунакчыллыгына аптырап, нәрсә әйтергә белми югалып тора).*

С у р и я. Фазылдим!

Ф а з ы л. Ә... әйе, әйдә, әйдә, Энже, менә монда...

Э н ж е. Рәхмәт. Мин... мин сезне вакытсыз мәшәкатьләдем инде. *(Өстәл кырыендагы урындыкка утыра.)*

С у р и я. Нинди мәшәкать ди ул. Кунак килү зур шатлык ул безгә. Кунак безнең өчен бик тансык нәрсә ул. Яшерен-батырын түгел, менә ничә ел торабыз инде, минем әле бер рәхәтләнеп кунак сыйлап караганым юк.

Ф а з ы л. Сурия... Сүз белән сыйлаганчы, сыеңны чыгарыр идең!

С у р и я. Хәзер.

С у р и я кухняга чыгып китә, Ф а з ы л кочагын җәеп Э н ж е г ә килә.

Ф а з ы л. Энҗе! *(Энҗе урыныннан торып китә.)* Сагындым бит мин сине!..

Э н ж е. Ой! Бу нәрсә булды соң инде? Мин уңайсыз хәлгә калдым бит, Фазыл абый. Мин бит белмәгән идем, башыма да килмәгән иде бит...

Ф а з ы л. Тукта әле, утыр әле, нәрсәгә шулай өзгәләнәсең.

Э н ж е. Ичмаса әйтмәдең дә... Хатка да язмадың.

Ф а з ы л. Нәрсәне?

Э н ж е. Бу кем? Иптәшеңме?

Ф а з ы л. Әйе, иптәшем...

Э н ж е. Ничек? Ул юк иде бит. Җәй көне... Тегендә, Кызыл Ярда.

Ф а з ы л. Ул анда бара алмады, авырып калды.

Э н ж е. Ә нигә соң син миңа иптәшем бар дип әйтмәдең?

Ф а з ы л. Соң ул турыда сүз булмады да бит безнең. Син сорамадың да.

Э н ж е. Ой, зинһар, гафу ит. Мин үзем гаепле. Сорый да, сораша да белмәдем. Шушындый яшь егетнең хатыны бардыр дип башыма да килмәде. Ой, нишләдем мин?.. Нинди хәлгә төштем. Кем уйлаган, кем уйлаган! *(Вешалкага йөгереп килеп ашыга-ашыга киенә башлый.)*

Ф а з ы л. Син нишлисең, син кая?

Э н ж е. Тулай торакка.

Ф а з ы л. Җүләрләнмә, анда хәзер беркем дә юк, иртәгә бергә барырбыз. Үзем урнаштырырмын.

Э н ж е. Кем дә булса бардыр, комендант, швейцар.

Ф а з ы л. Соң бит инде, караңгы.

Э н ж е. Булсын.

Ф а з ы л. Энҗе!

Э н ж е. Тотма мине, Фазыл абый! Мин булдыра алмыйм! Булдыра алмыйм! Кала алмыйм. Иптәшеңнең әллә нәрсә уйлавы бар. Минем гаебем юк бит, булмады бит.

Ф а з ы л. Энҗе, акыллым, китмә. Китмә! Көттем бит мин сине, сагынып көттем... Китмә! Үзең белән бергә йөрәгемне суырып алып китәсең бит.

Э н ж е. Юк, тимим. *(Күз яше аша.)* Тигәнем юк. Беркемнең дә йөрәгенә тияргә теләмим. Үзем генә... Үземнең генә телгәләнсен йөрәгем. Шул кирәк! Шул кирәк миңа, җүләргә!

Ф а з ы л. Энҗе?

Э н ж е. Кирәкми, кирәкми, Фазыл абый! Калдыр. Калдыр мине! Шулай яхшы. Хуш! Озатма мине. *(Чемоданын алып яшен тизлеге белән чыгып китә.)*

Ф а з ы л. Эн-җе!

Кухнядан С у р и я чыгып аптырап кала. Күрше ишектә К ә ү с ә р и я күренә.

## АЛТЫНЧЫ КАРТИНА

Завод лабораториясе. Унда лаборатория начальнигы кабинеты. Сулда лаборатория бакчасы. Бакчада эскәмия, чәчәкләр түтәле.

Пәрдә ачылганда Фазыл кабинетта. Бакча аша үтеп, Сүрия кабинет ишегенә килә. Шакый.

Сүрия. Мөмкинме?

Фазыл. Әйдә, әйдә, кер.

Сүрия. Бая да кабинетына керә алмыйча ни гомер көттем. Менә директор сиңа җибәргән иде. *(Кулындагы язуны Фазылга суза.)*

Фазыл. Бу нәрсә бу?

Сүрия. Гариза.

Фазыл. Нинди гариза.

Сүрия. Техника бүлегенә күчерүләрен сорыйм. Ислам Гәрәевич лаборатория начальнигы «каршы килмим» дип, резолюция салса, карарбыз, ди.

Фазыл. Син нәрсә? Киңәшү юк, нитү юк. Мин бит сиңа лаборатория начальнигы гына түгел, ир дә.

Сүрия. Без сөйләшкән идек бит инде, Фазыл. Син институтны бетергәч, мин укырга китәргә тиеш идем бит. Димәк, минем чират, күп нәрсә онытылып беткән, хәзерләнергә кирәк.

Фазыл. Аны бит монда эшләп тә әзерләнеп була.

Сүрия. Булмый, Фазыл. Үзең беләсең, дежурный лаборант, сменалы эш. Цехтан цехка пробиркалар күтәреп йөри-йөри мин хәлдән таям. Техника бүлегендә — утырып эшли торган эш. Теория белән бәйләнгән. Миңа техникумга хәзерләнү җиңелрәк булачак.

Бакча түрендә Сүрияне эзләп килгән Рәкыйп күренә.

Рәкыйп. Сүрия!

Фазыл. Рәкыйп абый, кер әле. *(Рәкыйп керә, Фазыл Сүриянең гаризасын Рәкыйпкә суза.)* Бу нәрсә бу?

Рәкыйп. Гариза ич.

Фазыл. Гариза икәнен беләм, ләкин, өлкән лаборант буларак, бу нәрсә фәкать синең ризалык белән эшләнергә тиеш.

Рәкыйп. Мин күптән ризалыгымны бирдем инде.

Фазыл. Ә монда?

Рәкыйп. Монда кандидатура бар, Фазыл, училище бетерүчеләрдән Энҗене сорап, мин күптән заявка биргән идем.

Фазыл. Син? Кем кушты? Бу нинди башбаштаклык.

Рәкыйп. Беркем дә кушмады. Син командировкага киткәндә үз вазифаңны миңа тапшырып киттең. Миннән училищеның яңа чыгарылышына заявка сорадылар. Мин, үз кул астымда практика үткән укучылардан иң сәләтлесен Энҗе дип табып һәм Сүриянең укырга китәсен искә алып, ул кызны үзебезгә сорап заявка бирдем.

Фазыл. Юк. Теләсә кемне ал, ләкин ул кызны түгел.

Рәкыйп. Лабораториягә теләсә кемне алып булмый бит, Фазыл.

Фазыл. Һәм ул кызны да алып булмый. Әле Энҗе практика үткән вакытта гына да... Оныттыңмыни?

Рәкыйп. Производство интересы андый вак нәрсәләрдән өстен булырга тиеш, Фазыл. Аннан соң Сүриянең киләчәге турында да уйларга кирәк бит.

Фазыл. Мин Сүрияне күчерүгә каршы түгел, ләкин икенче бер кандидатура тапканчы көтәргә кирәк.

Рәкыйп. Ә мин Энҗедән дә кулай кандидатура күрмим. Һәм ышанам аңа. Бир әле, Сүрия, гаризаңны. Менә өлкән лаборант буларак

мин дә кул куям *(Фазылга.)* Мә, куй кулыңны *(Фазыл бер Рәкыйпка, бер Сүриягә карап авыр күрсенә дә теләр-теләмәс гаризага кул куя).* Менә шулай. Ә инде Энҗе мәсьәләсендә мин үзем директор белән сөйләшәм. Син сорамадың аны, мин сорадым һәм ул кыз минем кул астында эшләячәк. Әйдә, Сүрия, анда анализларны карап чыгасы бар. *(Китә.)*

Сүрия. Фазыл, акыллым, син миңа ачуланма. Һәм нигә син кемнәрнеңдер мәгънәсез сүзләренә әһәмият бирәсең?. Мин сиңа ышанам, сиңа шул җитмимени? *(Аның башыннан сыйпый, Рәкыйп артыннан чыгып китә.)*

Фазыл *(үз-үзенә).* Син миңа ышанасың, анысын беләм. Ләкин бит мин үз-үземә ышана алмыйм.

Бакча түреннән ашыгып Кәүсәрия чыга. Шакымый-нитми ашыгып Фазыл янына керә.

Кәүсәрия. Иптәш начальник, бу нәрсә булып чыга инде?

Фазыл. Ни булган?

Кәүсәрия. Нәрсә ул минем карт җүләр, Сүрияне җибәреп, лабораториягә бернәрсә белмәгән девчонканы китерергә йөри.

Фазыл. Бернәрсә белмәгән девчонкаларга бездә диплом бирмиләр, Кәүсәрия ханым.

Кәүсәрия. Тагын шунысын да уйлагыз, Фазыл иптәш, сезнең ул кыз белән бер яманатыгыз чыкты инде.

Фазыл. Аны сез генә чыгардыгыз, Кәүсәрия ханым.

Кәүсәрия. Ничек мин? Ә хат? Ә дәлилләр? Карагыз, үзегезнең аморальный тотышыгызны авторитетыгызга чәпәп куймасыннар.

Фазыл. Сез хәзер эштә булырга тиешме?

Кәүсәрия. Эштә.

Фазыл. Алайса эш урыныгызда булыгыз, Кәүсәрия ханым, барыгыз, бар, монда җыен чепуха белән минем башымны катырмагыз.

Кәүсәрия. Сез килә килгәннән бирле миңа бәйләнәсез. Күрә алмыйсыз сез мине *(елый.)* Мин болай да җиләк кебек вакытымны карт ир белән җәфа чигеп уздырам. Өстәвенә сез... Туйдым, туйдым. Бер генә көн дә тормас идем. Китәр идем. Лабораториядән, шәһәрегездән. Бүген үк, хәзер үк.

Фазыл. Мәгез кәгазь.

Кәүсәрия. Нәрсәгә ул?

Фазыл. Гариза языгыз, китәм дисез ич.

Кәүсәрия. Ах, шулаймы, ярый, мин башта гаризамны язып завкомга, парткомга барыйм әле. Аннан соң карарбыз, кем китәр. *(Дулап чыгып китә.)*

Фазыл. Һе... Бу хатынга нәрсә кирәк миннән? Болай да өчәүләшеп газап чиккәнебезне күрмиләрмени соң? Тырышам бит инде, мөмкин кадәр аның белән очрашмаска, онытырга тырышам. Йөрәктән йолкып ташларга тырышам. Акыл белән Сүрияне яклыйм, аннан идеал куям. Ләкин булмый бит, таштан койган идеал ничек җылыта алсын инде ул йөрәкне... Күпме газапланырга мөмкин?

Бакчада Энҗе күренә. Ул курка-курка гына Фазыл ишегенә килә.

Энҗе. Үзе генә. Нишләргә? Монда калсам, вөҗдан газабы, бөтенләй китсәм, җан азабы булачак. Ике ел газапландым, ике ел көрәштем үзем белән. Газабы да рәхәт иде. Ул миннән, мин аннан качып йөрсәк тә, рәхәт иде. Лабораториягә практикага йөргән вакытларымда аның өстәлем яныннан узып китүен генә сизү дә бәхет иде. Нишләргә? Калыргамы? Калсам, һаман да шулай газапланып яшәргә көчем җитәрме минем? Юк, юк... Минем мона көчем җитмәячәк. Мин артык түзә алмаячакмын. Китәргә! Еракка... Еракка китәргә! Ничек кенә өзгәләнсәм дә вөҗданым пакь булыр. Вөҗдан аклыгы мәхәббәтне җиңәргә тиеш. Батыр бул син,

Энже, каушама! *(Үзен кулга алып, кыю булырга тырышып ишекне шакый.)* Мөмкинме?

Фазыл. Керегез. *(Энҗе керә. Бакча түреннән Кәүсәрия чыгып ишек янагына сөялеп тыңлап тора.)*

Фазыл. Эн-җе! Якын кил!

Энҗе. Юк, юк, Фазыл абый, шуннан торып кына.

Фазыл. Ярый. Утыр ичмаса. Менә шулай... Каршыма утыр. Я, Энҗе, хәлләр ничек?

Энҗе. Укып бетердем. Шушы профессиягә мәхәббәт уятуыгыз, мине укырга урнаштыруыгыз өчен сезгә рәхмәт. Профессиямне мин бик яратам. Ләкин ни өчен сез мине җибәрмисез? Шушы заводта калдыруны таләп итәсез? Сезнең өчен мин кайда булсам да барыбер түгелмени?

Фазыл. Ә синең өчен, Энҗе, барыберме? *(Энҗе дәшми.)* Барыберме синең өчен?

Энҗе. Миңа кайда да бер газап. Мин ялгыз кеше. Түзәрмен.

Фазыл. Син китсәң, мин дә ялгыз калам бит, Энҗе, япа-ялгыз.

Энҗе. Кирәкми, алай уйламагыз... Алай уйлау — җинаять.

Фазыл. Әгәр ялгышу җинаять булса, минем ул җинаятем моннан алты ел элек эшләнде инде. Яшь вакытта уйланмыйча эшләнгән җинаять өчен алты ел җәзалану — бу бер кеше башына артык күп түгелме?

Энҗе. Кешеләр бит алай уйламыйлар.

Фазыл. Бөтен кешеләр дә бит Кәүсәрия түгел. Кәүсәрияләр алар бик аз.

Энҗе. Кешеләр менә монда нәрсә кайнаганын күрмиләр бит. Аны кешеләргә әйтеп буламыни? Тотма син мине, Фазыл абый, китим мин. Җитәрлек газапландым бит инде.

Фазыл. Китеп кенә газаптан котыла алырыңа ышансаң, мин сине тотмыйм, Энҗе. Бәхетле булуыңны телим, чын күңелдән.

Энҗе. Чын бәхет ике килми, мин аны беләм. Һәм болай да ярамый. Кеше бәхетен җимереп бәхетле булу — бу вөҗдансызлык.

Фазыл. Юк бит ул бәхет, Энҗе, һәм булмады да. Шулай булгач, нәрсәсен җимерәсең инде аның.

Энҗе. Вакыт күрсәтер, Фазыл абый.

Фазыл. Вакыт бит әле узмаган. Синең дә, минем дә... Энҗе, әллә тагын бер генә елга каласыңмы? Әллә тагын бер ел газапланып карыйбызмы? Ә? Энҗе, кал!

Энҗе. Булдыра алмыйм, Фазыл абый. Мин артык булдыра алмыйм. *(Күз яшенә тыгылып йөгереп чыгып китә. Бакча эскәмиясенә капланып тавышсыз гына үкси. Кәүсәрия килеп аның башын сыйпый.)*

Кәүсәрия. Елыйсыңмы?

Энҗе. Елыйм. Рәхәтләнеп елыйм.

Кәүсәрия. Ела, ела, елагач, бераз җиңеләеп киткән кебек була ул.

Энҗе. Мондый рәхәт елау белән мин гомер буе еларга да әзер, ишетәсезме, гомер буе!

Кәүсәрия. Шулай, әлбәттә, ләкин кешеләр аны аңламыйлар. Кешеләр синең кичерешләреңнән әллә нәрсәләр уйлап чыгаралар.

Энҗе. Минем кешеләр алдында берниндн гаебем дә юк. Минем вөҗданым пакь!..

Кәүсәрия. Кеше ире артыннан йөри, семья боза дип...

Энҗе. Ничек? Дөрес түгел. Минем беркем артыннан да йөргәнем юк. Минем беркем семьясын да бозарга уйлаганым юк. Юк, юк, юк!

Кәүсәрия. Имеш, кем өчен соң шулай өзгәләнә? Ни өчен соң дипломын алгач та тыныч кына башка шәһәргә китеп бармый, диләр. Ни өчен күз яшьләре белән кызгандырып, безнең лабораториядә калырга тырышып йөри, диләр.

Энҗе. Нәрсә? Минем китүемне телиләрме? Шулаймы? Соңыннан, качып китте дип, юк гаепне аның өстенә аударырга? Гаепсез кешене...

Тыныч семьяны бозарга? Юк, болай булгач, мин жибәрсәләр дә китмим инде. Үземнең һәм аның гаепсез икәнен исбат итәр өчен калам. Фазыл абый! *(Фазыл сүзен ишетүгә. Кәүсәрия шунда ук юк була, Энҗе атылып Фазыл кабинетына керә.)*

Энҗе. Фазыл абый, мин китмим, мин калам. Сезнең кул астында эшләр өчен калам. Миңа шуннан башка бернәрсә дә кирәкми. Минем моңа көчем житә. Мин көчле, мин гайбәттән көчле. Күрсеннәр, бар да күрсен! Мин моны исбат итәчәкмен!

Фазыл. Энҗе!.. Энҗе-Зөбәржәт! *(Аның кулыннан ала.)*

Энҗе *(читкә тайпылып)*. Юк, юк, кирәкми... Беркайчан да. Мин көчле. Мин үземнең хисләремне жиңә алам. Мин мәхәббәттән көчлерәк!

Гадилә түти керә, бар да уңайсызланып калалар.

Гадилә. Фазыл улым, сине Ислам Гәрәевич чакыра.

Фазыл. Хәзер. *(Чыга башлый да ишек төбендә тукталып кала)* Тукта әле, ничек Ислам Гәрәевич? Син аңа нигә бардың?

Гадилә. Мин директорга шушы гаризам белән барган идем. Мине тулай торактан заводка күчерүен сорап.

Фазыл. Ниһаять, күчәргә булдыңмыни инде?

Гадилә. Уйладым, уйладым да күчәргә булдым. Сезнең янәгызда буласым килә. Көн саен күреп торыр идем үзегезне. Бигрәк якын бит сез миңа.

Фазыл. Ярый, Гадилә түти. Мин хәзер Ислам Гәрәевичтә гаризаңны үзем оформить итәрмен. Тик минем синдә бер үтенечем бар иде.

Гадилә. Сөйлә, улым.

Фазыл. Бу кызны син беләсең инде. Ул училищены бетереп, безнең лабораториядә эштә кала. Аңа хәзер квартира кирәк булачак. Вакыты житкәч, бу мәсьәлә завкомда каралыр, ләкин хәзергә вакытлыча...

Гадилә. Тагын шул әлеге минем кечкенә бүлмәме?

Фазыл. Бик үтенәм.

Гадилә. Син бар, бар, анда директор көтә. Без үзебез Энҗе кызым белән хәл итәрбез бу мәсьәләне. *(Фазыл китә. Энҗегә.)* Ничек булыр икән соң? Минем ул бүлмәм бушын буш инде. Фазыл белән бер яшьлек улым быел өйләндем дип хат язган. Өйләнсә дә сүзем юк. Вакыты бик житкән. Борын асты кипмәгән килеш өйләнеп, кайберәүләр шикелле үзләрен дә, кешеләрне дә җәзага салмады минем балам, акыл тутырып өйләнде. Анысына рәхмәт. Ярый инде, язмыш дибез бит... Кешеләр язмышы бертөсле булмый дип, юаткан булабыз үзебезне. Ничек кенә булса да, кеше кадәрле кешегә ярдәм итми калып булмый. Әйдә алайса, киттек. Карап кара бүлмәне, ошаса урнашырсың.

## ЖИДЕНЧЕ КАРТИНА

Гадилә түти өе. Вакыт кич. Пәрдә ачылганда Гадилә түти ялгызы гына. Бераздан Сүрия килеп керә.

Сүрия. Хәерле кич, Гадилә түти.

Гадилә. Ә... Сүрия! Әйдүк, кызым, әйдә, түрдән уз. Сагындырып йөрисең син хәзер безне, онытгың. Килми башладың.

Сүрия. Бу арада, үзең әйтмешли, китапка төртенеп утырдым. Беркая чыга алмадым.

Гадилә. Нишләп алай китапка төртенә башладың әле?

Сүрия. Укырга китәргә әзерләнәм.

Гадилә. Бик әйбәт... Ә Фазыл нәрсә ди, жибәрәме?

Сүрия. Аның жибәрәсе килми. Заочно укырга куша.

Гадилә. Шулай гына эшләргә иде шул. Ни әйтсәң дә семья бит. Берегез анда, берегез монда яшәп...

Сүрия. Техникум бит ул, Гадилә түти... Читтән торып кына укырга инем көч җитмәс.

Гадилә. Фазыл укый бит әле әнә. Техникумда гына түгел, институтта.

Сүрия. Фазылдагы энергия миндә юк шул, Гадилә түти.

Гадилә. Кайчангарак китәргә исәп инде?

Сүрия. Техникумнан хәбәр көтәм.

Гадилә. Китмәскә иде сиңа, балакай. Берәр ел читтән торып укып карарга иде. Берәр җиңелрәк эшкә күчеп. Бәлки, җиңәр идең әле.

Сүрия. Азапланмыйм инде, Гадилә түти. Сәламәтлекне дә сакларга кирәк.

Гадилә. Саклый белмисез шул, балалар. Һаман нидер эзләнәсез. Эзгәләнәсез. Анламадым инде мин сезне, балакайлар, баштан ук. Фазыл өйдәме соң?

Сүрия. Командировкага китәргә йөри.

Гадилә. Озаккамы?

Сүрия. Озакка түгел, атна-ун көнгә генә. Энҗе өйдә юкмыни?

Гадилә. Кайтып җитмәде әле. Бүген нишләптер озаклады. Башка көнне вакытында кайта иде. Заводта берәр киңәшмә-фәлән юктыр ич.

Сүрия. Юк булса кирәк. Кайтышлый киногы кергәндер.

Гадилә. Кинога йөрергә дә яратмый ул. Синең шикелле, укырга китәм дип, җенләнә ул да. Төннәр буе бүлмәсендә бикләнеп утыра. Авыр бирелә булса кирәк ана да сабак дигәнегез. Иртән торып чыкканда күзләре шешенеп беткән була. Төне буе елап соң... *(Ишектән, ашыгып, Энҗе кайтып керә. Ул агарынган, кабалана-кабалана чишенә.)* Нигә шулай кабаланасың, әллә артыннан кудылармы?

Энҗе. Юк, беркем дә кумады.

Гадилә. Иплән кенә кайтсаң соң. Соңга калганың өчен монда шелтә бирергә торучы юк ич.

Энҗе *(Сүрияне күреп нәрсә әйтергә белмичә аптырап, югалып кала)*. Ә... Кунак бар икән ич, күрми дә торам. Сүрия апа... Ничек болай кичләтеп?

Сүрия. Менә синең яныңа килдем. Бер иркенләп сөйләшеп утырасым килде. Эштә сөйләшеп булмый үзең белән. Пробирканы күтәрәсең дә цехтан цехка чабасың.

Кәүсәрия керә.

Кәүсәрия. Әнекәчем лә!.. Кайтып та җиткән. Әле миннән икегез дә лаборатория бакчасында калган идегез бит. Әллә минем энгер-меңгердә күзләрем шайләмәганме? Әллә Сүрия булды микән ул? Шулайдыр. Мин дә хата, Сүрия булгандыр ул. Югыйсә, нишләп безнең Энҗе шушы вакытка кадәр бакча эскәмиясендә кеше ире белән япа-ялгыз утырсын. Булмаганны. Бәлеш... Сүрия дә монда икән ләбаса!.. Бу ничек була инде бу? Кайсыгыз иде соң сезнең әле хәзер генә бакчада Фазылга сыланып утырган.

Энҗе. Мин идем ул. Ләкин сез әйткәнчә сыланып утырмадым. Без сөйләшеп утырдык. Бакчада да түгел, лабораториядә. Инде хәзер канәгатьме?

Кәүсәрия. Канәгать, канәгать. Үзең канәгать булсаң, мин һәрвакыт канәгать. Ир белән торам ла мин. Үз ирем белән. Кача-поса кеше ирләре белән түгел.

Энҗе. Ой, нинди оятсызлык! *(Йөзен каплап, елап бүлмәсенә йөгерә.)*

Сүрия *(урыныннан тора. Акрын гына Кәүсәрия каршына килә. Аннан кизәнеп Кәүсәриянең яңагына суга)*. Менә монысы Энҗе өчен. *(Икенче яңагына суга.)* Ә монысы Фазыл өчен!

Кәүсәрия. Гадилә апа, күрдеңме, шаһит бул, судка бирәм.

Гадилә. Күптән кирәк иде сине судка бирергә, күптән? Җинел котылдың, синең шикелләләрнең яңагына сугу гына аз ул, бик аз. Бар үкчәнне күтәр минем өемнән. Икенче бусагамны атлап керәсе булма.

Кәүсәрия. Шулаймы? Ә мин, җүләр, үземчә, чын күңелдән аларга яхшылык эшлим дип, ялгыш юлга басарга бирмим дип йөргән булам, ә алар... Сез барыгыз да бер сүздә. Ярар. *(Янап чыгып китә. Әчке бүлмәдән Энҗенең елаганы ишетелә.)*

Сурия. Гадилә түти, син мине гафу ит. Мин сөйләшим инде ул бала белән. Мин шуның өчен дип килдем. Ахыр чиктә бу газаплануларга чик куярга вакыт.

Гадилә. Вакыт, кызым, бик вакыт *(ишеккә бара)*. Ой, күптән вакыт! *(Чыгып китә. Сурия эчкә үтә. Энҗе янына бара.)*

Сурия. Я, тынычлан. *(Су алып бирә.)* Мә, су эч...

Энҗе. Сурия апа, нишлим?

Сурия. Өзгәләнмә.

Энҗе. Минем һич гаебем юк.

Сурия. Ярату гаеп түгел.

Энҗе. Ялгыштым мин, Сурия апа, монда калып ялгыштым.

Сурия. Бәхеткә гел туры юл белән генә килмиләр.

Энҗе. Китәргә иде миңа, укып бетергәч тә китәргә иде.

Сурия. Үкенер идең. Ә үкенү тагын да зур хәсрәт.

Энҗе. Мин үземә ышанган идем. Көчем җитәр дип ышанган идем.

Сурия. Мәхәббәтне җиңә алган көч юк ул дөньяда.

Энҗе. Сез нәрсә турында?

Сурия. Син нәрсә турында булса, мин дә нәкъ шул турыда. Аерма фәкать шунда, син өч кенә ел газапланасың, ә мин инде нәкъ җиде ел газапланам.

Энҗе. Ләкин мин гаепле түгел бит, Сурия апа.

Сурия. Мин сине гаепләргә уйлаганым да юк. Шулай ук аны да гаепләмим. Сез икегез дә бәхетле булырга хаклы. Ләкин ни өчен мин сезнең юлыгызда киртә булып торырга тиеш? Һәм күпмегә кадәр?

Энҗе. Ни сөйлисез сез, Сурия апа?

Сурия. Тыңлап бетер, булмә. Безгә күптән аңлашырга вакыт иде инде. Сиңа да миннән качып йөрмәскә иде, миңа да бу очрашуны сузмаска иде. Ул вакытта Кәүсәрияләр гайбәтенә дә урын калмас иде. Ләкин мин Фазыл турында күбрәк уйладым. Коры мавыгу гына булмагае, дип шикләндем. Ләкин юк, бу мәхәббәт. Бу көчле мәхәббәт!

Энҗе. Сурия апа!

Сурия. Әйе, әйе, мин беренче мәртәбә аның йөзендә мәхәббәт чаткысын ул Кама буеннан кайтып төшкән көнне күрдем. Тирә-юньгә нур, бәхет сибеп тора иде аның йөзе. Мәхәббәт кешене үзгәртә. Ул өчләтә энергия белән эшкә, укуга тотынды. Мин читтән генә күзәттем. Шундый мәхәббәткә ничек киртә буласың? Бәхетле иде бит ул. Аның бәхетенә каршы төшәргә минем хакым бармы?

Энҗе. Ләкин бит бу җинаять, Сурия апа. Ышаныгыз, мин башта сезнең бар икәнне белмәдем. Ә инде белеп алгач, мин аннан качтым. Мин аны күңелемнән сызып ташларга тырыштым. Мин өч ел буе газапландым. Ә хәзер катгый карарга килдем, нәрсә генә булмасын, мин моннан китәм. Сезнең семьяны җимерергә минем хакым юк. Мине бирегә беркем дә тотып кала алмаячак. Әле менә хәзер дә, өч елга беренче мәртәбә, мин аның белән очрашып, шул турыда сөйләштем. Аннан гаризама кул куюын үтендем.

Сурия. Ә ул нәрсә? Куйдымы?

Энҗе. Юк. Ләкин минем башка юлым бар. Мин барыбер китәм. Мин беләм, сез бит аны яратасыз, Сурия апа, бик яратасыз.

Сурия. Яратам, бик яратам, ләкин мин ярату белән генә тормыш булмый бит. Ике якның да тигез мәхәббәте кирәк. Ә аңарда миңа карата

чын мәхәббәт беркайчан да булмады. Ул моны бик тиз аңлады. Ә мин соңрак аңладым, бик соң... Яшьлектә бер ялгыш булган икән, аны төзәтү җинел түгел бит. Бигрәк тә Фазыл кебек намуслы кешегә. Ул газапланып яшәде. Ләкин миңа хыянәт итмәде. Инде ул бәхетен тапкан икән, мин аның бәхетенә каршы төшәргә тиешме? Бу эгоистлык түгелме, Энҗе?!

Энҗе. Ләкин бит...

Сурия. Әйе, яратам. Яратам мин аны. Мәңге яратачакмын. Шуңа күрә дә мин аның бәхетле булуын телим. Аның бәхете минем дә бәхетем! Көчләп кешегә мәхәббәт тагып булмый. Ни өчен соң әле, хатыннар, үз бәхетебез өчен, икенче берәүләрне гомерлек җәзага салырга тиеш? Ни өчен? Аның бит бәхетле булырга хакы бар. Аңа бит әле фәкать егерме биш яшь. Өзгәләнмә син, Энҗе. Үзенне үзең җәберләмә. Кешеләр сезне аңларлар. Ә мин рәнҗемим сезгә. Фәкать бәхетле булуыгызны телим. *(Энҗенең маңгаеннан үбә.)* Менә шул. Хуш. *(Китә.)*

Энҗе *(тирән уйда)*. Юк, юк, дөрес түгел... Дөрес түгел. Мондый олы җанлы кешене яратмау мөмкин түгел. Яратыр ул аны... Аңлар. Мин киту белән аңлар. Мин генә аның күңел күзен томалап торам. Китәргә, китәргә! Мин түзәрмен!.. Тик ул гына газапланмасын. Мондый изге кешене газапка салу җинаять. Китәргә!

Акрын гына Кәүсәрия керә. Чәчләре тузган, йөзе йончылган, күзләре шешенгән, үзе исерек.

Кәүсәрия. Кая китәргә? Үзеңнән үзең качып буламыни? Менә мин җәһәннәмгә дөмегер идем. Минем дә синең шикелле өзелеп сөйгән егетем бар иде. Ярлы иде ул... ләкин чибәр иде, таза иде. Яшь иде... Ә мин аннан качтым. Яраттым, ә качтым... Авырлыктан курыктым... Җиңелне эзләп картка чыктым. Ә нәрсә таптым мин? Ялгызлык. Минем беркемем дә юк. Балам да юк, тормышым да юк. Шуңа мин бәхетле кешеләрне күрә алмыйм. Дөрес сукты ул минем яңагыма. Шул кирәк миңа. Шул кирәк! Ә син бәхетеңнән качма... Мәхәббәтеңнән качма! Үкенерсең, ой үкенерсең! *(Энҗе сүзсез кала.)*

## СИГЕЗЕНЧЕ КАРТИНА

Шул ук сәхнә, идәндә чемоданнар, төргәкләр, бәйләм-бәйләм китаплар. Энҗе ашыга-ашыга юлга әзерләнеп йөри. Әйберләрен җыя. Гадилә түти башына яулык бәйләгән, нишләргә белми йөри, әле әчке бүлмәгә, әле бире якка чыга.

Энҗе. Гадилә түти, чолан ачкычы кая икән, мин бер бәйләм китапларны шунда чыгарып куйган идем.

Гадилә. Белмим, белмим, башым катты. Башым бернәрсә дә эшләми. Сурияләргә бардым, анысы китәм дип, ду килеп җыенып йөри, монда кайттым, син... Нәрсә булды сезгә?

Энҗе. Бернәрсә дә булмады. Булгач, аннары соң була ул.

Гадилә. Аны... Фазыл кайткач, сөйләшеп-киңәшеп китәргә булмый микәнни?

Энҗе. Сурия апа бит ул укырга гына китә. Кайтыр.

Гадилә. Ә син инде бөтенләй китәсенме? Кайтмаска дип.

Энҗе. Әйе.

Гадилә. Соң сине дә бит бөтенләй җибәрмәгәннәр. Отпуск кына биргәннәр.

Энҗе. Отпусктан мин килмим. Документларымны хат белән соратып алдырам.

Гадилә. Соң шулай ярыймы инде?

Энҗе. Башкача минем чарам юк.

Гадилә. Ярый, анысына да күнәм. Ләкин нигә бүген үк китәргә, шулай ашыгып.

Э н җ е. Фазыл абый кайтып төшүс бар. Кичә Рәкыйп абый минем отпускнойга кул куйды да шунда ук почтага йөгерде. Мин күреп тордым. Мөгаен, Фазыл абыйга телеграмма суккандыр.

Г а д и л ә. Әй, балалар, балалар! Нәрсә булып бетәр бу эшегез, белмим. Кайсыгызны ачуланырга? Кайсыгыз хаклы? Кайсыгыз хаксыз? Аңлавы кыен.

Э н җ е. Мин хаксыз. Мине ачулан, Гадилә түти. Шуның өчен бөтен газапны үз эчемә туплап китәм дә мин. Ичмасам, үзем генә янармын.

Г а д и л ә. Билетың да алмаган бит әле синең?

Э н җ е. Шунда, пристаньга төшкәч алам.

Г а д и л ә *(тәрәзәгә карап)*. Ай аллам... Күңелемә ук килгән иде. Кайткан бит. Фазыл монда килә.

Э н җ е *(каушап)*. Нәрсә?

Г а д и л ә. Әнә йөгерә. Вокзалдан туры монда килә, ахры. Юл киемнәреннән, портфеле, сумкасы, иңбашында плащы.

Э н җ е. Гадилә түти, нишлим? Кертмә, зинһар, кертмә. Ишек алдыннан кире бор. Китте ул, диген... Төнге пароход белән ук китте, диген... *(Бүлмәгә йөгерә.)*

Г а д и л ә. Чемоданнарың соң?

Э н җ е. Җыям. Бар, бар. Ишек алдына каршы чык! *(Гадилә түтине эткәләп чыгарып җибәрә. Үзе ашыга-ашыга чемоданнарын, төргәкләрен эчке бүлмәгә ташый. Каушаудан китаплары чәчелә.)*

Ф а з ы л т а в ы ш ы. Кая, кая китте? Ышанмыйм! Энҗе! Энҗе! *(Атылып ишектән килеп керә.)* Энҗе!

Г а д и л ә *(Фазыл артыннан өйгә керә)*. Юк дим. Китте.

Ф а з ы л. Киткән... киткән! *(Башын тотып урындыкка утыра.)* Кая? Кая китте?

Г а д и л ә. Белмим. Төнге пароход белән китте.

Ф а з ы л. Бөтенләйгәме?

Г а д и л ә. Әйе, кайтмыйм, диде.

Ф а з ы л. Нигә? Нигә соң шулай эшләде инде? Эх, Энҗе, Энҗе! *(Күреп.)* Менә, менә бит аның китаплары...

Г а д и л ә. Җыймаган. Җыярга өлгермәгән.

Ф а з ы л *(эчке бүлмә ишегә төбендә төшеп калган яулыгын күреп.)* Яулык! *(Яулыкны ала, күкрәгенә кыса.)* Яулыгы! Аның яулыгы!

Г а д и л ә. Әй, бала, бала!

Ф а з ы л. Китмәгән. Китмәде бит? Гадилә түти, китмәде бит?

Г а д и л ә. Белмим, белмим.

Ф а з ы л. Энҗе! Энҗе! *(Эчке бүлмәгә керә, күреп.)* Энҗе, нишләвең инде бу синең?..

Э н җ е. Фазыл абый, гафу итегез... Фазыл абый, кичерегез мине!.. Мин китәм... Шулай кирәк.

Ф а з ы л. Юк, юк, җибәрмим.

Э н җ е. Эх, Гадилә түти!..

Г а д и л ә. Кертмә, үткәрмә ишектән дигән була. Ишектән үткәрмәү белән генә ни файда? Ул бит синең йөрәк түреңә үтеп урнашкан... *(Аяк очына гына басып чыгып китә.)*

Ф а з ы л. Энҗе!

Э н җ е. Юк, юк, Фазыл абый... зинһар... Үтенәм сездән, калдырыгыз мине!..

Ф а з ы л. Булдыра алмыйм, мин артык булдыра алмыйм, Энҗе! Хөкем итсеннәр мине кешеләр, мин артык яшерә алмыйм. Яратам, яратам!

Э н җ е. Акрын, зинһар!

Ф а з ы л. Ишетсеннәр... Бөтен дөнья ишетсен — яратам! Яшермә, яшермә, син дә яратасың бит мине? Әйт, яратасың?

Э н җ е. Өч ел. Нәкъ өч ел. Беренче мәртәбә Кама буенда сезнең гармун телләрен тибрәткәнегезне ишеткән сәгатьтән бирле. Өч ел инде мин шул моң белән яшим. Ул моң колагымда шаулаганда бар дөньямны онытам. Рәхәт тә, сагышлы да, татлы да, газаплы да иде... Нигә соң ул шулай үзенең татлы агышы белән генә бармады? Нигә соң ул мине сихри хисләр ташкынына бөтереп алып кереп, шушы авыр хәлгә китереп ташлады. Нигә, нигә?!!

Ф а з ы л. Әйе... Фәкать шул айлы төндә генә мин үземдә ниндидер бер сәер тойгыларның барлыкка килүен тойдым. Фәкать шул айлы төндә генә мин үземнең мәхәббәтемне таптым. Аңа кадәр миндә мәхәббәт булмаган. Сүрия яхшы хатын, минем аңа ихтирамым зур. Ләкин ихтирам белән генә яшәп булмый бит. Мәхәббәт кирәк, яну кирәк, ярату кирәк. Ә мин җиде ел газап чигәм. Менә әле дә ул мескен, Рәкыйп абый белән, вокзалга мине каршы алырга төшкән. Вагон тәрәзәсеннән перронда аларны күрдем дә качтым. Синә йөгердем. Мәхәббәтем, шатлыгым, бәхетемне күрергә. Ә син... Син минем бәхетемне урлап качарга җыенгансың!.. Эн-җе!.. Бу бит артык каты бәгырьлек.

Э н җ е. Шулай кирәк... Әллә миңа җинел дип беләсеңме? Китү белән генә бу газаптан котыла алырыма мин ышанам дип уйлыйсыңмы? Юк. Ләкин вөҗданым пакь булыр.

Ф а з ы л. Мине шушы хәлдә калдырып китепме? Тыныч кына яши алырмын дип уйлыйсыңмы, Энҗе?

Э н җ е. Ләкин башкалар тыныч булыр. Кешеләр миңа гаепле караш ташлый алмаслар. Сез дә кешеләр хөкеменнән котылырсыз.

Ф а з ы л. Кемнең соң безне хөкем итәргә хакы бар?

Э н җ е. Бар, Фазыл абый, бар.

Ф а з ы л. Бердәй типкән ике йөрәкнең икесе ике якта өзгәләнеп яшәве кирәкмени соң кешеләргә? Шуны кешеләр гаделлек дип атарлармы?

Э н җ е. Өченче берәүнең җәберләнмәве кирәк — гаделлек шунда. Йөрәктә тирән яра калса да, кешеләр алдында йөзебез ак булыр.

Ф а з ы л. Ой булмас, ой, төзәлмәс ул яра... Мәңге төзәлмәс.

Э н җ е. Төзәлер. Вөҗдан аклыгы бар нәрсәдән көчлерәк.

Ф а з ы л. Юк, мәхәббәттән көчле нәрсә юк дөньяда.

Э н җ е. Бар. Гаделлек. Гаделлек хакына мәхәббәтен корбан итүчеләр азмыни дөньяда?! Хуш, Фазыл абый... Барыгыз, кайтыгыз... Өегезгә. Сүрия апа янына. Ул изге кеше.

Г а д и л ә *(тыштан йөгереп керә)*. Киткән. Балалар, киткән бит, киткән!

Ф а з ы л. Кем?

Г а д и л ә. Сүрия. Сүрия балакаем киткән. *(Елый.)*

Ф а з ы л. Кем әйтте?

Г а д и л ә. Рәкыйп. Рәкыйп вокзалдан аны озатып кайтып килә.

Ф а з ы л. Кая ул?

Г а д и л ә. Анда... баскычта.

Ф а з ы л *(ишекне бәреп ача)*. Рәкыйп абый?!

Р ә к ы й п *(керә)*. Әйе, Фазыл, бу чын. Чын.

Ф а з ы л. Ул вокзалга мине каршы алырга төшмәгән идемени?

Р ә к ы й п. Юк. Син кайтасын әйткәч, ул тизрәк китәргә ашыкты да инде. Без синең поезд белән кайтасыңны белмәгән идек. Менә сиңа хаты. *(Фазыл Рәкыйп кулыннан хатны тартып ала, конвертын ерта, ләкин укымый.)* Укы, укы! Анда кешеләрдән яшерә торган нәрсә юк.

Ф а з ы л *(укый)*. «Фазыл, син мине гафу ит, акыллым. Техникумнан хәбәр килде. Мин китәм. Бөтенләйгә. Син ирекле. Мәхәббәтеңнән качма, әйбәт кыз ул Энҗе. Минем сезгә һич үпкәм юк... Минем өчен борчылма, газапланма. Мин үз бәхетемне үзем табармын. Сезнең һәр икегезгә бәхет теләп, Сүрия».

Озын пауза.

Р ә к ы й п. Әйе, дөньяда мондый хәлләр дә була икән... Ләкин алай авыр кичермә, Фазыл, имә башыңны.

Э н җ е. Эх... Рәкыйп абый... син соң...

Р ә к ы й п. Нәрсә?

Э н җ е. Юк, болай гына. *(Фазыл каршысына килә.)* Ә Сурия апа кайтыр ул. Кайтыр, Фазыл абый!.. *(Барып чемоданын ала.)*

Ф а з ы л. Энҗе, рөхсәт ит, бер генә мәртәбә, беренче мәртәбә һәм соңгы мәртәбә кочаклап бер үбим үзеңне.

Э н җ е. Юк, юк!

Ф а з ы л. Мәхәббәтем хакына?!.

Э н җ е. Булмый... Булмый, Фазыл абый, мин аны күтәрә алмыйм, мин ул кадәресен җиңә алырыма ышанмыйм.

Ф а з ы л. Кем уйлап чыгарган бу газапны.

Э н җ е. Үзебез. Барысына да үзебез гаепле. Үзебез үк җәзасын татырга тиеш!

Ф а з ы л. Энҗе, шулай итеп китәсеңмени инде.

Э н җ е. Китәм, Фазыл абый, китәм! Хуш, озатма мине, шулай кирәк.

Рәкыйп Энҗе кулыннан чемоданын ала. Энҗе ишек янындагы шүрлектән китаплар ала, түргәккә иярәп идәнгә курчак төшә. Энҗе белән Рәкыйп акрын гына чыгып китәләр. Пауза. Дөньясын онытып утырган Фазылның күзе идәндәге курчакка төшә.

Ф а з ы л. Бу нәрсә?

Г а д и л ә. Курчак.

Ф а з ы л. Кемнеке?

Г а д и л ә. Сезнеке. Әле күптән... Сурия беренче баласын көткәндә үк алып кайтып куйган иде.

Ф а з ы л. Бала? Әле без бала да көткән идекмени?

Г а д и л ә. Әйе шул... Көткән идегез... Булмый калды бит!

Фазыл курчакны алып озак аңа карап тора.

Әйе... уйлап житкермичә, ашыгып, курчак уены кебегрәк башладыгыз шул тормышыгызны!..

## Рәшит Гәрәй

### Туган якта

Бәрәнгеләр чәчәк аткан чак бу,
Көнбагышлар чәчәк аткан чак.
Чалгыларын каерып, яшь егетләр
Тугайларда печән чапкан чак.

Малай чагым калган эзләр буйлап
Йөрим менә тагын болында.
Кузгалаклы, йомшак үләннәрнең
Тәмле исе керә борынга.

Үзенә бишек булган җирдә генә
Басыла икән сусау-җирсүең.
Төшемдә дә хәтта иреннәрем
Пышылдыйлар «туган җир» сүзен.

### Ык өстендә йөзгән кәймәләр

Җәйлегендә кайтсам туган якка,
Ык буенда үтә кичләрем.
Үз-үземне онытып күзәтәм мин
Егетләрнең ишкәк ишкәнен.

Балыкчылар утыра тып-тын гына,
Кая инде мина ул тынгы...
Ык сулары ничек дулкынланса,
Хисләрем дә шулай дулкынлы.

Таныш җырга ияреп, хыялларым
Бик ерактан агып киләләр.
Яшьлегемә илтеп куяр кебек
Ык өстендә йөзгән кәймәләр.

## Безнең язмыш—туган ил язмышы

Әнкәй безне җиргә тудырган да,
Кайнар ашын, ялын оныткан.
Безгә йомшак чуәк бәйләгәндә,
Үзе йөргән чүбек оектан.

Әнкәй безне җиргә тудырган да,
Саф хисләре белән җылыткан.
Үсеп җитеп кеше булганбыз да,
Хәзер безгә диңгез тубыктан.

Әнкәй безне җиргә тудырган да,
Язмышыбыз өчен курыккан.
Безнең язмыш — туган ил язмышы,
Исән чакта шуны онытмам.

## Урман йоклый

Кайтып киләм, көн дә төшемә кергән
Каеннарны сагынып.
Йолдызларны үзенә ымсындырган
Яшел шәлен ябынып,

Урман йоклый... Аның тынлыгына
Хәйран калып үтәм.
Таң алдыннан әллә яфраклар да
Төш күрәләр микән?

Кочагыма алып, хыялымда
Бөтенесен назлыйм.
Тик берсен дә татлы йокысыннан
Уятырга базмыйм.

## Казлар каурый койган көннәрдә

Йорт казлары койган ак каурыйлар
Тирбәләләр зәңгәр күлләрдә.
Күл буенда йөрим бер ялгызым
Казлар каурый койган көннәрдә.

Сагыш белән тулы күңелем минем
Дулкынлана тирән күл сыман.
Аерылмасын икән, һай, беркем дә
Яшьли сөйгән якын дусыннан!

Күлгә аңа нәрсә... Кыш җитүгә,
Дулкыннарын җыеп ул тынар.
Тынмас ләкин минем йөрәгемдә
Син кузгаткан сихри дулкыннар.

## Сагынуларым чиктән ашканда

Сагынсам мин шундый итеп сагынам:
Йокыларым кача күземнән.
Юатма син мине андый чакта
«Түзем бул син!» дигән сүз белән.

Түземлелек кирәк бүтән җирдә,
Мәхәббәттә тапмыйм кирәген.
Сөйгән кешең искә төшкән чакта
Түземлеген җуйсын йөрәгең.

Сине уйламый соң, кемне уйлыйм,
Күкрәгемне сагыш басканда...
Төшләреңә кереп йөдәтермен
Сагынуларым чиктән ашканда.

## Кабынып яшә

Әй, ялгышам, һаман сөртенәм...
Сөйми башлыйм хәтта таңнарны.
Эчтән сызып йөрим-йөрим дә,
Җиргә ятып ауныйм аннары.

Җирем дәшә:— Күтәр башыңны,
Алга кара, алгы көннәргә.
Күрәсеңме, унган ир-атлар
Ничек кыю атлый үрләргә.

Олы максат өчен бик күпләр
Яна-яна күмер булганнар.
Кабынып яшә, миндә болай да
Җитәрлек ич сүнгән вулканнар.

## Күңелем минем һаман окопта

Җаның нигә тыныч түгел, дисең,
Борчыласың, дисең, юк-барга.
Төн йокыңны бүлеп, күз текисең
Еракларда янган утларга.

Заставалар күге аяз микән
Шушы утлар янган вакытта...
Үзем тыныч йортта, ә күңелем...
Күңелем минем һаман окопта.

## Салисә Гәрәева

# Күк күз

Күк күзле кыз, диләр, күк күзле кыз.
Кемгә охшап күзе күк икән?
Гаҗәпмени, андый зәңгәр күзләр
Болгар нәселендә күп икән?
Болгар заты, болгар токымының
Гасырларга тамырын илтүче;
Күзләрендә ике кояш йөртеп,
Бер күрүдә гашыйк итүче
Минем кызым, минем куанычым!
Кабатлаучы минем күңелне,
Бар кешеләр бердәм көрәшәбез
Тыныч тотар өчен күгеңне!
Күк тә зәңгәр, синең күзләрең дә,
Кояш балкый — син дә көләсең...
Миннән күпне җирдә күрәсең дә,
Миннән күпне килә беләсең.
Күк күзле кыз, диләр, ә бит синең
Зәңгәр күктәй аяз җаның да;
Син тугансың тыныч Россиядә,
Зәңгәр күкләр аяз чагында...

## Фәнис Яруллин

●

Кичтән юллар кара елан булып
Сузылып ята иде як-якка...
Төне буе яуган йомшак карлар
Манып киткән җирне ап-акка.
Кыш-художник үзенә тигән эшне
Башкарган бик җиренә җиткереп.
Бик тиз генә кеше күңелен дә
Булсын иде ап-ак иттереп.

●

Бер начарлык эшләде дә берәү
Карап куйды тирә-ягына.
Очрамады аңа бер кеше дә,
Озатып калды ялгыз тал гына.

Шатланды ул беркем күрмәгәнгә,
Буш булганга төнге сукмагы.
Ләкин менә үзен кешегә санау
Уена да кереп чыкмады.

●

Күккә менеп йолдыз чүпләп йөрдем,
Таныш миңа галәм юллары.
Кайчандыр бит синең мәхәббәтең
Алып менгән иде югары.
Язмышларның болай булачагын
Сизмәгән шул бер дә күңелем,
Егылганда катырак төшәр өчен
Булган икән биек менүем...

## Кайчакта кеше...

Кайчакта кеше бара-бара да,
Арып туктала.
Ә максатына барып житәргә
Бер адым кала.
Шул бер адымга дәртләндерергә
Кеше күңелен
Көч булсын иде, дәрт булсын иде
Минем шигырем.

Кайчакта кеше йөрәген тотып
Чүлләрдә ава.
Исән калырга бары бер йотым
Су житми кала.
Үлем кулыннан тартып алырга
Кеше гомерен
Шушы бер йотым су булсын иде
Минем шигырем.

Кайчак кешенең кара урманда
Сүнә дә уты
Кабат ягарга житми аңарга
Бары бер шырпы.
Ялкын итәргә ялгыз юлчының
Сүнгән күмерен
Шул соңгы шырпы булсын иде, дим,
Минем шигырем.

## Дифгать Сирай

### Буразна

Эзләсәм дә очын табалмадым,
Еракларга, ахры, сузылган.
Борылып карыйм.
Гомер буразнамның
Яртысы бит инде узылган.
Бу җирләрдән сука башы тотып,
Туры килде күпме узарга!
Бәхет булып өелеп калсын иде
Мин күтәргән һәрбер буразна.

### Җир катысы

Аяк асты — измә.
Баскан саен
Кереп чума итек балтырдан.
Тик тоясың үзең барганыңны
Юллар буйлап җирдән, катыдан.
Тәпи басып киткән көннән бирле
Күпме юлны артта калдырдым.
Җир катысын тоеп баргангамы,
Ныгая күк һаман адымым.

### Болын

Бер карасам текәп болыннарга
Язармын күк кинәт һушымнан...
Бала чагым тагын бер мәртәбә
Җырлап үтсен иде шушыннан.
Сарылсыннар иде үләннәре,
Әй кытыклап ялан тезләрне.
Мондагыдай матур чәчәкләрне
Кемнәрнең бар икән өзгәне?!
Тормыш ләкин шушы болын кебек
Гөл-чәчәкле генә булмады.—
Үләннәре канга манчылдылар,
Һәм җан сорап туплар улады...
Шуны уйлап баксам болыннарга
Язармын күк кинәт һушымнан,
Туплар түгел,
Бары җыр авазы
Яңгырап торсын иде шушыннан.


Тиргәмәсләр, җырларымны сузып
Чишмә буйларына төшкәнгә.
Сөенермен, йокыларны бүлеп,
Җырым белән керсәм төшләргә.
Җырлыйм әле, җырлыйм рәхәтләнеп,
Дәртле чишмә юкка чыңламас.
Минем өчен туган якларыма
Башка берәү килеп җырламас.

## Яра

Йөземдә бер яра эзе бар,
Әллә каян тора күренеп:
Баз кырына егылып төшкәнмен,
Чиләк алган чакта үрелеп.
Сабый чаклар үтте.
Без күргәнне
Дөнья онытыр микән аларны?!
Никадәрле тигез дисәк тә без,—
Җирнең дә бит йөзе яралы...

ЧУВАШ ЯЗУЧЫЛАРЫ
СОЮЗЫНЫҢ ӘДӘБИ
ЖУРНАЛЛАРЫ




**Алексей Талвир**

# ПИНЬПИ

ХИКӘЯ



Аркадий эштән кайтышлый автобус тәрәзәсеннән Анна Мурзайкинаны күрде. Беренче тукталышта ук уктай атылып чыкты да кызның каршысына йөгерде.

— Ә-ә, Аркадий! — диде Анна, шатланып.— Мин заводта булган идем инде. Механика цехының план-диспетчерлык бүлегенә житәкчелек итәргә кушалар. Нишләргә дә белмим. Син ничек уйлыйсың?

— Мин дә шуннан киләм. Ничек очрашмадык икән соң без?

— Син кайсы цехта булдың?

— Йөрмәгән жирем калмады.

— Ә сине кая жибәрәләр?

— Мин әле беркем белән дә сөйләшмәдем .. Бүген кич бездә кунаклар була. Килми калма. Альдияровны да чакыр. Без аның белән яхшы ук танышлар.

— Альдияровтан башка килсәм, кертмәссеңме?

Анна Мурзайкинаны Аркадий бала чактан ук белә. Аннаның әнисе — балалар врачы. Ул, Вутландагы барлык балаларны дәвалаган шикелле үк, кечкенә вакытта Аркадийны да карый торган иде. Аркадийның

Гаграда югалып, эссе кабудан авырган чагын хәтерли әле ул. «Шулай яр буеннан барсаң, Төркиягә хәтле җитәсе икәнсең бит»,— дип, бик күп еллар үткәч тә шаяртып ала иде әле Ага Атласовна.

Сугыш вакытында Аркаша бик еш кына Мурзайкиннарга Анна белән уйнарга керә торган иде.

Үсә төшкәч, ул кызлар белән уйнамый башлады. Соңыннан Анна да, Аркадий да Мәскәүдә укыдылар. Бер үк институтта. Анна Аркадийдан ике яшькә өлкәнрәк иде. Шулай да алар икесе бер курста укыдылар. Буйга җиткән Аркадий хәзер кызлардан оялмый иде инде. һәм алар янадан дуслашып киттеләр. Каникул вакытларында Вутланга бергә кайталар иде. Ә узган ел производство практикасын да бергә үттеләр. Хәзер икесенең дә кулларында заводка эшкә кайту өчен путевка бар.

Чын дусларча мөнәсәбәт булды алар арасында. Аркадий үзенең якын дусы Альдияровның Аннаны яратып йөрүен белә. Аның уенча, Аннага да егет охшый. Көнләвен ул Аннаны көнләми, ләкин шундый яхшы кызны Альдияровка тиң дип тә санамый. Альдияровны үзләренә кунакка чакырырга теләве дә, Аннага күңелле булсын өчен генә.

Караңгы төшүгә Иштуловларга кунаклар җыела башлады. Георгий Кокки һәм Тимбаев хатыннары белән килделәр. Кайчандыр алар Аркадий белән бер мәктәптә укыганнар иде — хәзер инде үзләре укытучылар. Аларның хатыннары да укытучы иде. Анна Мурзайкина таныш түгел кыз белән килде. Аркадийга кыюсыз гына кулын бирде һәм әкрен генә:

— Пиньпи,— дип таныштырды.

«Пиньпи?» — дип гаҗәпләнде Аркадий. «Мең яхшыдан берсе»,— дигән шушы борынгы чуваш исеме белән ата-аналар элек иң яраткан кызларын гына атаганнар.

Кара күзле кечкенә генә бу ябык кыз яшүсмер балага охшаган. Биек үкчәле туфлиләре дә аны олысымак итеп күрсәтми, киресенчә, балаларча бер кыюсызлыгын гына сиздерә төшә.

«Бу бакча баласын нигә дип алып килгән инде?» — дип уйлады Аркадий, эче пошып.

Өстәл янына утырдылар. Кокки яңа «пешеп чыккан» инженерны котлады. Кунаклар шау-шу килеп Аркадийны мактый башладылар. Пиньпи да Аркадий янына килде һәм кайдандыр түбәннән бокалын егеткә сузды.

«Бу бөҗәк тә зурлар күк кыланган була бит»,— дип уйлады Аркадий. Егетнең ни уйлаганын сизгән сыман, Пиньпи мәк чәчәгедәй кызарып китте, ләкин уңайсызлануын тиз басты.

— Сез Вутланда гына калмассыз бит? Берәр зуррак төзелешкә китәсездер.

Аркадий аңа җавап бирергә теләгән иде, ләкин төрле яктан рюмка тоткан куллар сузылды, көлү, шау-шу китте. Пиньпи шунда ук куллар арасында югалып калды. Танца башланды. Аркадий Аннаны чакырды. Шул вакытта ул Пиньпиның үзенә карап торуын күрде һәм эченнән генә көлеп:

«Бакча баласы да танцага чакырганны көтәме әллә»,— дип уйлады.

Соңга калып кына Иштуловларга зур сакаллы Тодор Грозданович Христов килде.

— Рәхим итегез, Тодор баю,— диде аңа Архип Прокопьевич, биюче яшьләр арасыннан үтеп, кунак каршына килде.— Нигә хатыныгыз килмәде?

Христовны өстәл янына утырттылар. Музыка тынуга, Аркадий Христов янына килде.

— Әле генә пионер галстугы тагып йөри иде! — диде кунак кече Иштуловка кулын сузып.— Кара, нинди егет булган!

Христов утызынчы елларны исенә төшерде. Ул чагында әле бирегә кара урман булган һәм урманчының ялгыз йортыннан башка каралтыкура күренмәгән.

— Син, Тодор баю, истәлекләр сөйләп юкка вакыт әрәм итәсең,— дип бүлдерде аны Архип Прокопьевич, кунакка бер стакан кызыл шәрап сузды.— Ишетәсеңме, сезнеңчә «баю» дип әйтәм. Болгариягә барып кайтуыңны сөйлә, ичмасам. Быел семьяң белән Дунай буена барып кайттың бит әле.

— Юк, бөтен семьям белән үк түгел... Славчо безнең белән бара алмады. Соңыннан ул үзе генә китте.

— Күптән барганың юк иде түгелме? Шактый вакыт үтте бугай? Туганнарыңны, таныш-белешләреңне эзләп таба алдыңмы?

— Кырык өч ел кайтканым юк иде. Картлар хәтерли әле, ә яшьләр дөньяда барлыгымны да белмиләр. Әниемнең абыйсы исән икән — картайган инде, туксан өч яшь аңа. Улына алтмыш, оныгына кырык яшь. Тракторда эшли, партизан булган. Бер айлап кунак булдык.

— Бөтенләйгә каласың килмәдеме соң?

— Ни дияргә соң, үзем генә булсам, бәлки калган да булыр идем. Семья булгач, бирегә, Идел буена тарта.

Кунаклар төн уртасында гына тарала башладылар. Аркадий аларны озата чыкты. Алар төнге тыныч урам буйлап киттеләр. Кемдер «Унике кыршаулы мичкә» дигән борынгы чуваш җырын башлап җибәрде. Аркадий гаҗәп моңлы да, көчле дә тавыш ишетеп, артына әйләнеп карады һәм Пиньпи Кашкарованы күрде. «Гаҗәп, бу бөҗәккә шундый матур тавыш каян килгән!» дип уйлады Аркадий. Каршы як ярында биек наратлар үскән елга буена төштеләр. Җыр тынды. Барысы да караңгы су өстендә җемелдәгән йолдызларга карап тора башладылар. Яр буенда зур көймә чайкалып тора иде.

— Әйдәгез, көймәдә йөрибез,— дигән яңгыравыклы тавыш ишетелде.

Берәү дә Пиньпига җавап кайтармады. Аркадийның күптән инде, бала-чагага йокларга вакыт, дип әйтәсе килә иде, тик ул һаман үзен тыеп торды.

Вакыт соң иде, саубуллашып тарала башладылар. Аркадий янына иң актыктан Пиньпи килде.

— Сез миңа билетсыз пассажирга караган ачулы кондуктор күк карыйсыз.

Аркадий шаяртуга җавап кайтармыйча әдәпле, шул ук вакытта коры гына итеп:

— Хәерле төн! — диде.

Аркадий баш очында гына этәч кычкырган тавышка уянып китте. Күркынып күзләрен ачты. Караңгылы-яктылыда Вутланнан килгән шефлар яткан печәнлек почмагы күренде. Печәнлек түбәсенә зур кара этәч менеп кунаклаган.

— Көш-ш, каһәр суккан!

Аркадий печән йомарлап этәчкә ыргытты. Этәч канатларын җәеп түбәнгә очып төште һәм егет яныннан йөгереп үтте. Шул ук вакытта бөтен авылны тутырып, тегеннән дә, моннан да этәчләр кычкыра башлады.

— Шулкадәр иртә уятмасалар,— дип, Тимбаев йокы аралаш мыгырданып алды.— Кояш та чыкмагандыр әле.

— Әйдә, йокла, этәчләр кычкырып туйдылар инде,— диде Аркадий,— хәзер төш турына кадәр тавышлары чыкмас.

— Барысына да син гаепле, шәһәр романтигы,— диде Тимбаев, авыр сулап.— Өйдә ятсак, туйганчы йоклар идек, юк бит, аңа печәнлек кирәк.

Аркадий җавап кайтармады. Одеалын баштанаяк бөркәнде дә яңадан йоклап китте.

Вутлан заводының эшчеләре һәм инженерлары кичтән үзләре шефлык иткән авылга килгәннәр иде. Үзешчәннәр концертыннан кайткач, Иштулов белән Тимбаез печәнлеккә ятарга булдылар. Әтәч тавышлары аларның йокыларын озакка бүлмәде, арыганлык үзенекен иткән иде, һәм дуслар кояш шактый күтәрелгәч кенә уяндылар.

— Бу нинди тәртипсезлек! Сәгать җиде! Торыгыз! — дип кычкырды Аркадий, кул сәгатен бора-бора.

Ишек алдында аларны Миннебай хуҗа каршылады. Миннебай кашсыз йөзе җыерылып беткән, сирәк чал сакаллы карт чуваш ул.

— Йокыгыз туймадымы әллә? — дип сорады ул.— Бездә Бутлан түгел шул — я әтәче кычкыра, я көтү куалар.

— Без шәһәрдә дә иртә торабыз,— диде Тимбаев һәм гаҗәпләнеп хуҗага карап куйды. Әле вакыт иртә булса да, аннан аракы исе килә иде.

Миннебай егетнең карашын сизеп алды, көлемсерәп:

— Иртүк кабып алган дип уйлыйсызмы? Юк, күгәрченем, төне буе йокламадым мин — әле генә кырдан кайттым,— диде.

— Эшләдегезмени? — диде Аркадий.

— Кая ул! — дип кулын болгады Миннебай.— Чук ясадык. Кичтән сезне дә чакырырга теләгән идек тә, көләрсез дип оялдык.

— Чук! Сез чук ясадыгызмы? — диде Аркадий ышанмыйча.

Бу — бик борынгы гореф-гадәт. Шундан калган бәйрәм. Тик әле хәзер дә авылларда чук ясыйлар дип аның башына да килмәгән иде. Юк, мөмкин булмаган хәл бу!

— Төне буе бәйрәм иттек,— диде Миннебай.— Эльбануны хөрмәтләп җыр җырладык. Борын замандагы ата-бабаларыбыз гадәтенчә таңга кадәр җырладык.

— Кем соң ул Эльбану? — дип кызыксынды Тимбаев.

Миннебай аңа берничә секунд карап торды да:

— Син чувашмы? — дип сорады.

— Юк, казакъ...

— Алайса, аңлашыла... Чуваш Эльбануны белергә тиеш. Белми калмас.

Аркадий уңайсызланды. Бу исемне әле аның да беренче ишетүе иде. Шул вакыт Миннебай карт менә аларга нәрсә сөйләде:

«Элек вакытларда чуваш җиренә бәла килә: Алтын Урда баскыннары тыныч халыкка сугыш башлыйлар. Чувашлар әз була, шулай да алар барысы бер булып туган җирләрен сакларга китәләр. Азамат авылы янында чуваш гаскәре дошманны каршылый. Ләкин көчләр тигез булмый һәм күп кенә кыю егетләр шунда һәлак була. Чувашларның сафы каушап кала. Шул вакыт читтә торган хатын-кызлар төркеме арасыннан батыр кыз Эльбану чыга.

«Оялыгыз, ирләр! — дип кычкыра ул сугышчыларга.— Шулай ук сез дошман атларына туган җиребезне таптарга ирек куярсызмыни? Хатыннарыгызны, сеңелләрегезне, газиз аналарыгызны хурларга ирек бирерсезмени? Алга, минем арттан!»

Кылыч тотып Эльбану дошманга каршы ыргыла. Аның артыннан бөтен чуваш гаскәре ташлана. Дошман кача. Ләкин шул сугышта Эльбану үлеп кала.

Шул вакытлардан бирле чувашлар һәр ел саен, уңыш жыеп алгач, Эльбану хөрмәтенә — халкыбызның батыр кызы хөрмәтенә — чук ясый».

— Менә бүген дә бәйрәм иттек,— дип сүзен тәмамлый Миннебай,— бәйрәмдә картлар гына булды. Яшьләр уңайсызлана. Дөресен генә әйткәндә, Эльбануның кем булуын аларның күбесе белми дә...

— Кызганыч, бик кызганыч,— диде Аркадий.— Кичә бер сүз дә әйтмәдегез. Безнең милли бәйрәмебез биг ул чук. Анда катнашудан нигә уңайсызланып торырга!

— Аның турында китапларга язганнары бармы соң? — дип сорады Тимбаев.

Миннебай җилкәләрен җыерып куйды.

— Белмим. Без, картлар, китапча яшәмибез бит. Эльбану турында миңа бабам сөйләп калдырган иде. Ул үзе һәрвакыт миңа, бу вакыйганы бабам сөйләде, дип әйтә иде. Эльбану истәлеге шулай картлардан яшьләргә күчеп килгән инде. Хәзерге яшьләр генә ул турыда кызыксынмыйлар. Без үлсәк, чувашлар Эльбануны бөтенләй онытачаклар.

— Юк, юк, алай булмас,— дип каршы төште Аркадий.— Тимбаев белән без әле генә ишеткәннәребезне язып, Чабаксарга, газетага җибәрербез. Шулаймы, Омар? Эльбануның истәлеген яңарту — безнең комсомол оешмасының намус эше, дип карыйм мин. Ул кыз турында яшьләр белеп торсын, ә соңыннан, бәлки, Азамат авылы янына Эльбануга һәйкәл дә куелыр әле.

— Менә яхшы булыр иде! — диде Миннебай, шатланып.— Мин үзебезнең комсомолларга әйттем бит, шәһәрдән килгән иптәшләрне чакырыйк, безнең Эльбануны яратырлар алар, дип әйттем. Ә алар беравыздан: «Гореф-гадәт бу, Миннебай бабай, наданлык»,— диләр. Ә мин болай уйлыйм: хәзерге заман булса, үзе үлсә дә, Эльбануга Алтын йолдыз бирерләр иде...

Сүзне дәвам итәргә туры килмәде, хуҗа хатын чәйгә чакырды. Дуслар тиз генә юынып, нигъмәт тулы өстәл янына утырдылар. Ни генә юк иде монда! Бәлеш, белен, ботка, чыгыг-эремчектән ясалган сыр... Өстәл янындагы урындыкта чиләк белән сыра тора. Аның өстенә чиккән сөлге ябылган.

Миннебай, кунакларны утырткач, стаканнарга сыра сала башлады.

— Безнең Чувашта ашар алдыннан кунакка өч чүмеч сыра эчерәләр иде,— диде ул.— Тик хәзер беркем дә чүмечтән эчми инде.

Ашап-эчкән арада Омар, ни өчен сезнең авылда борынгы чуваш исемнәре кушалар, дип сорады.

— Шулай шул,— диде карт,— менә мисалга минем гаиләне генә алыйк: биш улым бар минем, бишесенең дә исемнәре борынгыча — Седелей, Музилей, Яндимир, Микавар, Меткем. Барысы да совет елларында тудылар югыйсә.

— Хәзер кем булып эшлиләр? — дип кызыксынды Тимбаев.

— У, истә калдыруы да кыен! — дип көлде карт,— икесе укытучы, берсе агроном, Мәскәү институтын бетерде. Яндимир — колхоз председателе. Микавар армиядә, срогы тулгач та хезмәт итәргә калды. Исемнәрен каян алдым дисезме? Менә болай ул: элек поплар көчләп христиан исемнәре бирәләр иде. Тик безнең авыл бик бердәм булып чыкты, бирешмәдек — барыбызның да икешәр исеме булды. Берсе — поп куштырганы, икенчесе — үзебезнеке, борынгы чуваш исеме. Ә инде Совет власте булгач, эшләр башкача китте — поплар юк, улың булса да, кызың булса да, ничек теләсәң, шундый исем куш. Менә минем

Микедер күршем бар. Дүрт улы бар аның, үзе Фрунзе белән бергә Перекопны алган һәм барлык улларына да полководецлар исемен биргән: Фрунзе, Богдан, Багратион, ә иң кечесенә Чапай дип кушты. Әйтеп торабыз үзенә — матур исем түгел, дибез, Чапаевның аның үз исеме Василий булган, дибез. Юк бит, терәлгән дә каткан. Шулай дип яздырды бит малайны,— дип сөйләгәндә, карт тәрәзәгә күз төшерде.— Әнә иптәшләре белән тора ул, сезне каравыллыйлар. Шефлар һәрвакыт бүләк алып килә дип уйлыйлар.

— Нигә чакырмыйсыз соң аларны? — диде Аркадий, борчылып.— Керсеннәр. Без аларга китаплар алып килдек.

— Зарарсыз, көтәрләр әле. Ашыгыр җирләре юк, бүген ял көне.

* * *

Терлек фермасы Миннебай бабайның өеннән ерак түгел. Егетләр шунда барырга дип чыкканнар гына иде, яннарына, атылып, кечкенә Чапай килә башлады. Үзе нәрсәдер кычкыра, кулын болгый.

— Нәрсә яна? — дип сорады Аркадий, көлеп.

— Янмый...— диде Чапай, көчкә тын алып.— Машинагыз батты.

— Кая, нинди машина?

— Автобусыгыз буада йөзә,— дип кычкырды малай.— Киттек, коткарырга кирәк!

Колхоз буасы янына халык җыелган. Бер читтә корыч аркан таккан трактор тора, ә буа уртасында автобус түбәсе ялтырап күренә иде.

— Ничек булды соң бу? — дип сорады Тимбаев, колхозчылар янына килгәч.

Халык арасыннан күн курткалы яшь шофер чыкты. Ул уңайсызланып, юарга дип машинаны яр кырына китерүе турында сөйли иде.

— Мин анда ком дип торам, ә баксаң — ләм икән. Автобусым буага керде дә китте...

Шул арада «суга батучы»ны коткару чараларына керештеләр. Таза гына бер яшь егет — механика цехының эшчесе — чишенеп тә өлгергән. Автобусны арканга эләктерү өчен салкын суга сикерергә әзерләнә. Менә ул җайлап кына суга керде дә чумып та китте. Яр буенда торучылар кычкырып секундларны саный башладылар. Иллегә җиткәч, су өстендә кара чәчле баш күренде.

— Я, нәрсә? Ничек? — дигән түземсез тавышлар ишетелде.

— Эләктерә алмадым,— диде егет, авызына тулган суны бөркеп,— суы боз шикелле. Ни өчен шулкадәр салкын икән ул?

— Аның астында чишмәләр бар,— диделәр яр читеннән.— Җәй көнендә дә бик сирәк коеналар монда.

Егет судан чыкты да җылыну өчен сикергәли башлады.

— Кызганыч, бер ярты литр юк,— диде Миннебай бабай.— Юкса мин, яшьлекне искә төшереп, чумып чыккан булыр идем. Аракысыз куркыныч — ревматизмым кузгала.

Шул вакыт авылныкылардан берәү чумып карарга булды. Ләкин ул суда Вутлан слесарьннан да әзрәк торды, шунда ук ярга йөзеп килде.

— Я, таптыңмы?

— Табуын таптым, тик салкынлык өтә. Тирәндә утырмый ул, ыргакны капшап була. Каһәр төшкән суык кына кулны куыра.

Шул чакны кайсыдыр берсе сельпо кибетеннән бер шешә аракы алып килде. «Водолазлар» чиратлап шешәдән авыз иттеләр.

— Җитәр, җитәр,— дип көлештеләр карап торучылар.— Эшләгән эшегез юк әле.

Халык төркеме тагын шаулашып алды. Кара купальник кигән кечкенә генә, зифа гына бер кыз буага таба килә иде. Уң кулына корыч аркан тоткан.

— Кем ул? — дип сорадылар төркемнән.

— Кашкарова. Үзешчәндә ялгыз җыр җырлый ул. Токарь булып эшли.

— Төшермәгез аны. Салкын тидерсә, тавышы бетәр.

Ләкин Пиньпи инде суга кергән иде. Автобуска таба йөзеп килде дә чумды. Берничә секундтан су өстенә калыкты. Трактордан сузылган корыч арканның бер очы автобусның янында ук суга күмелеп калды.

— Эләктердем! — дип яңгыратып кычкырды Пиньпи.

Бер минуттан инде ул, суыктан калтыранып, яр буенда тора иде. Аның янына кызлар йөгереп килде, иңбашына плащларын салдылар, салкыннан күгәргән кулларын уа башладылар.

Кемдер аңа аракы эчәргә кушты.

— Юк, юк,— диде ул башын селкеп.

Пиньпи янына уңайсызланып Аркадий килде. Аны күргәч кыз башын аска иде.

— Тагын миннән көләрсезме? — диде ул әкрен генә.

— Ни өчен? — дип гаҗәпләнде Аркадий.

Пиньпи җавап бирмәде.

Аркадий Иштулов мастер Стемасовны алыштырырга тиеш иде. Цех начальнигы аларны таныштырды. Мастер аны шунда ук участокка алып китте. Барысын да карап чыккач, Стемасов:

— Үзең күреп торасың, егерме ике кешенең унтугызы яшьләр. Монда мастер булу гына җитми, педагог булырга да кирәк. Иң кыены — токарь Пиньпи Кашкарова белән эшләү. Фрезеровщица Даша Салмина да аннан юньле түгел.

Стемасовны смена начальнигы итеп күтәргәннәр иде, шуңа күрә Иштулов белән акыл өйрәткән сыманрак сөйләште.

— Аларны күз алдыннан җибәрмә,— диде коры гына.

Стемасов белән аерылышкач, Аркадий участокның технологиясен өйрәнә башлады. Эшнең төгәл оештырылуы, әле генә кайтарылган яңа станоклар ошады аңа.

Аркадий Пиньпи Кашкарова станогы янына килде. Иштуловны күргәч, кыз станогын туктатты да елмаеп:

— Рәхим итегез! — диде.

Иштулов кызның зәвыксыз киенүенә игътибар итте — сары джемпер, кара алъяпкыч, зәңгәр берет.

— Стемасов минем турыда әйтеп өлгергәндер инде,— диде Пиньпи, ачулы елмаеп,— дилбегәне каты тотарга куштымы?

Аның сүзләре Аркадийга ошамады. Алар бит әле рәтләп таныш та түгел. Егет кашларын җыерды, дәшми генә күрше станокка китте.

— Сезнең урында булсам, мин гомердә монда эшләргә ризалашмас идем,— диде Пиньпи кинәт кенә.

Аркадий ялт итеп борылды:

— Нигә?

— Күңелсез, мәшәкатьле. Дипломым булса, ничек тә конструкторлар бүлегенә керер идем.

Монсы инде артык иде. Кем белән сөйләшкәнен онытта кыз. Иштулов шунда ук аны туктатырга теләгән иде, бу уеннан кире кайтты, дәшми генә баштанаяк карап алды.

Кыз үпкәләде, кырт борылып, станогын җибәрде. Шуннан соңгы көннәрдә, Аркадий участокка килеп, эшчеләр белән исәнләшкән вакыт-

та, Пиньпи читкә борылып кала торган булды. Иштулов атнага ике тапкыр үткәрә торган техминимум дәресләрендә ул юри берни дә язмый, ничек тә егет сөйләгәннәр аңа кызык түгеллеген күрсәтмәкче була.

Эш вакытында Пиньпи еш кына станогын туктатып, каядыр барып килә. Кайсы бер көннәрне нормасын да көчкә-көчкә генә тутыра. Планерка вакытларында шуның өчен Аркадий аны тирги башласа, сүз бөтенләй икенче кеше турында барган сыман, игътибарсыз гына якягына каранып утыра. Планерка беткәч, цех буенча шаярып йөри, иптәш кызлары янына барып такылдый, кычкырып көлә, әзер детальләр салган ящиклар аша сикереп йөри.

— Сез ни өчен эшләмисез? — дип сорады бер вакыт Аркадий, Пиньпи каядыр югалып торганнан соң.

Кыз горур гына башын күтәреп, механик янына бардым, станогым киреләп тора,— дип әйтте. Икенче бер вакыт аңа электрик кирәк булып чыкты, өченчесендә кладовойдан яңа инструмент алган булды.

Иштулов Стемасовның Кашкарованы кулда тотарга кирәк дигән сүзләрен бик еш хәтеренә китерде. Ләкин ничек итеп шундыйны кулда тотасың? Икенче участокка, я булмаса бөтенләй башка бер цехка күчерү кирәк булмасмы аны?

Аркадий бу турыда цех начальнигы Чалдоновка әйтеп тә караган иде. Ләкин ул, кешеләрне үзең тәрбияләргә кирәк, башка җиргә күчереп котылырга түгел, дип кырт кисте.

Аркадийны институтта күп гыйлемнәргә өйрәттеләр. Ләкин берәү дә кешеләрне тәрбияләүгә өйрәтмәде, берәү дә эшче халыкның йөрәгенә үтеп керү юлларын күрсәтмәде.

— Тәрбияләргә кирәк,— диде Чалдонов.

Тәрбияләргә дип әйтүе генә ансат. Ә ничек тәрбияләргә! Бөтен бәла аның педагог булмавында гына микәнни соң?

Бу хәл цех начальнигында киңәшмә булыр алдыннан чыкты. Бусагада механик Кокки күренде, ул күзе белән Аркадийны эзләп тапты да ишеккә ымлады. Аркадий тиз генә чыгып китте.

— Кашкарова станогын ватты,— диде механик, ачу белән.— Күренеп тора, әллә нинди бәлаләр китерер әле ул кыз.

Аркадий цехка йөгерде. Пиньпи башын иеп станок янында тора иде.

— Майламыйча җибәргән,— диде йөгереп килгән механик, сулышы кабып.— Нинди машинаны бозган бит. Хурлык!

Кыз борылып карады. Аркадий Пиньпи бик борчыла дип уйлады. Ул инде механикны туктатырга авыз ачкан иде, ләкин кыз кинәт кенә башын күтәрде.

— Нәрсә дип каныгасыз әле,— диде ул, ачу белән,— майны салырга кирәк җирне белмәдем бит мин!

Аркадий түзмәде.

— Ничек инде сез, өченче разрядлы токарь башыгыз белән, машина майлый белмисез? Сезне шундый машинага куйган кешене әйтер идем! Беләсезме, күпме тора ул!

— Сорап караганым юк.

Ачуын көчкә тыеп, Аркадий механикка борылды:

— Станокны Кашкарова исәбенә ремонтлатыгыз.

Цехтан кергәндә ул Пиньпиның мыскыллы тавышын ишетте:

— Ремонтлатыгыз! Аннан гына бөлмәм әле!

Ике көннән соң белдерүләр тактасына приказ эленде:

«Кашкарова П. Г. тарафыннан ватылган станокны аның хисабына ремонтларга».

Участокның комсомол группасы эштән соң Кашкарованың тәртибен тикшерергә булды.

Аркадий участоктагы бердәнбер коммунист наладчик Тухтаркин белән янәшә утыра иде. Ул арттагы рәтләрдә Пиньпины күрде. Кыз «Огонек» укып утыра — сез теләсәгез нишләгез, ә мин үз эшемне беләм, янәсе.

Комсорг Бушуев җыелганнарны карап чыкты да берничә секунд Пиньпи белән Дашага дәшми генә карап торды. Нәрсә булырын көтеп, бар да тынып калды.

— Кашкарова, Салмина, журналыгызны куегыз,— диде Бушуев, кычкырып.— Җыелышта утыруыгызны онытмагыз, иптәшләрегезне хөрмәт итәргә кирәк!

Шул вакыт Анна Мурзайкина килеп керде.

— Утырырга рөхсәтме? — диде ул Бушуевка.— Мине бирегә комсомол комитетының члены булган өчен җибәрделәр.

Анна Аркадий янына килеп утырды.

Бушуев участоктагы кайбер иптәшләрнең хезмәт дисциплинасын бозулары турында сөйләде, ә инде токарь Кашкарованың эше — гадәттә булмаган хәл, дип әйтте.

— Шулай күпме сузылырга мөмкин инде? — дип сорады ул, ни өчендер җыелышка түгел, ә ВЛКСМ комитеты члены һәм диспетчерлык бюросы начальнигы Анна Мурзайкинага карап.

Анна елмаеп куйды. Җыелыштагылар да елмайдылар.

— Мин болай уйлыйм,— диде токарь Сәгыйт Сәйфетдинов, урыныннан кузгалып,— Пиньпига ярдәм итик без, гаебен аңласын. Иптәшләрен куып житсен. Мин дә шундый ук станокта эшлим һәм аны ярышка чакырам. Сменага утыз гына түгел, ә илле деталь эшләргә сүз бирәм.

— Син бишенче разрядлы токарь, ә Кашкарова өченче генә. Синеңчә куып житсен ул,— диде Даша Салмина.— Коммунистик хезмәт ударнигы булырга теләсәң, син кино белән циркка гына түгел, театрга да йөрергә, музыка да тыңларга, китап та укырга тиешсең. Син бит цирк клоуннарын гына яратасың.

Сәгыйт телсез калды. Каршы чыгарлар дип көтмәгән иде ул.

— Башта эш турында уйларга кирәк,— диде ул, акланырга теләп.— Ә нормага килсәк, болай итәргә була: Пиньпи кырык деталь ясасын, ә мин иллене. Мин аңар дүртенче разряд алырга да булышырмын. Ни генә әйтсәгез дә, иң әһәмиятлесе — эш.

— Һәм уку да! — диде Салмина.— Пиньпи белән без кичке институтта укыйбыз. Ә син?

— Институтта укыйсыз, ә заводта брак ясыйсызмы?—диде Тухтаркин.

Участокта Тухтаркин — иң өлкән кеше. Бөкрәебрәк йөри торган, озын буйлы, киң маңгайлы, игътибарлы карашлы бу кешегә Аркадий еш кына киңәшкә килә иде. Ул үзе салмак кеше, әмма җитез кул хәрәкәтләре аның зур тәҗрибәле, чыныккан эшче икәнен күрсәтә. Берәрсенең станогы рәтләп эшләмәсә, Тухтаркин дәшми генә килә дә, сәбәбен эзләп табып, иптәшенә аңлата, төзәтергә булыша. Эшчеләр аны яраталар. Әгәр мастер начар эшләгән өчен берәрсен кыздырырга тотынса, Тухтаркин бервакытта да аны яклап чыкмый. Аркадийның уенча бу — картның җитешсезлеге. Бер-ике генә сүз кыстырып җибәрсә дә ул, мастерга шул чакта җиңелрәк булыр иде.

Һәм менә Тухтаркин бүген беренче тапкыр халык алдында Пиньпи белән Дашаны тәнкыйтьләде.

— Сезнең кичке институтта укуыгыз бик яхшы,— дип сүзен дәвам итте ул, кызларга карап.— Ләкин ул кешене алга әйдәргә тиеш, артка өстерәргә түгел. Иптәшләреннән артка калу иптәшсез калу диләр иде элек картлар. Шуны онытмагыз. Эштә дә үрнәк булырга кирәк сезгә. Укый дип әйтсеннәр өчен генә укырга ярамый. Халкыбыз шундый зур эшләр башкара. Ә без артта барабыз. Әйбәт эш түгел бу! Солдатлар

сафта ингә-иң куеп баралар. Уңда — иптәшең, сулда — иптәшең. Шуны сизсәң, сиңа берни дә куркыныч түгел. Үзең үлсәң үл, дустыңны коткар, дип халыкта юкка гына әйтмиләр. Ялгышкан икән кеше — ярдәм ит. Бу бөтен коллектив эше. Мин шулай уйлыйм, иптәшләр.

Бүлмәдә тирән тынлык булып алды. Пиньпи башын тагын да ныграк иде. Өлкән эшченең сүзләре аны уйланырга мәҗбүр итте булса кирәк.

— Пиньпи, әйт әле безгә, үзеңнең иптәшләреңә, яхшы эшләү өчен ни комачаулый сиңа? — дип сорады Бушуев.

Ләкин кыз башын да күтәрмәде, дәшмәде дә.

— Тәкәбберлеге комачаулый аңар, шуңа күрә гаебен танымый, менә шул! — дип каты гына әйтеп ташлады Наташа Шкулькина.— Аңар инде егерме яшь, әле һаман бала булып кылана. Завод дилэр моны, балалар бакчасы түгел!

— Мин тагын шуны әйтергә телим,— дип, Тухтаркин яңадан урыныннан торды.— Тәнкыйтьләгән өчен Пиньпи безгә ачуланырга тиеш түгел. Дошман бер алдыңа төшәр, бер артыңа. Ә үзе астыртын тешләп алыр. Дусның тиргәп әйткән сүзе дә файда булыр.

Тухтаркиннан соң Анна Мурзайкина сүз алды:

— Карап-карап торам да үзегезгә, сөенеп бетә алмыйм: әйбәт кешеләр сез. Чын күңелдән Пиньпига ярдәм итәргә тырышасыз. Ә бит ул үзе дә цехның алдынгы кешеләре рәтендә булырга тели. Эштәге уңышсызлыкларына ничек борчылуын мин аның күзеннән күреп торам. Ләкин андый хаталар, уңышсызлыклар безнең һәркайсыбызда булырга мөмкин. Минемчә, Кашкаровага уйларга, көчен сынарга вакыт бирергә кирәк. Ярдәм кирәк булса, ул үзе үк безгә килер.

Анна озак сөйләмәде, ләкин кешеләр арасына җылылык кертте. Эшчеләр, берсе арты берсе торып, ничек итеп цехны алга чыгару турында тәкъдим иттеләр.

Тырышып укырга һәм ярты ел эчендә югарырак разряд өчен экзамен бирергә, дигән карар кабул иттеләр.

Бушуев җыелышны ябарга күтәрелгән иде, Пиньпи урыныннан сикереп торды да:

— Мин озакламый дүртенче разряд өчен экзамен бирәм,— диде.

— Дөрес эшлисең, Пиньпи! — дигән тавышлар ишетелде.

Кашкарованың сүзләре Аркадий өчен көтелмәгәнрәк булды, аның хәтта ышанасы да килмәде. Әле үзе күреп торды, Пиньпи иптәшләренең сөйләгәнен исе китми генә тыңлап утырды лабаса. Җыелыштан чыгуга ук ишеткәннәрен онытыр, заводны үз итми бит ул, дип уйлап утырганда — менә сиңа мә: дүртенче разрядка вакытыннан алда экзамен бирәм, имеш. Гаҗәп, бик гаҗәп...

Шулай уйлый-уйлый Аркадий озын коридор буйлап китте. Завод капкасы янында аны Анна Мурзайкина куып җитте.

— Әйт әле, Аркадий, Бушуев Пиньпины синең киңәшең буенча тәнкыйтьләдеме?

Аннага комсомол группасы җыелышы ошамавын Аркадий аңлады. Сәбәбен беләсе килде.

— Пиньпи бик хисле, хәтере тиз калучан,— диде Анна.—Станокны ремонтлау бәясен тотып калу да аңа җитәр иде. Ә бүгенге тәнкыйть чамадан артып китте. Зыянга булмасын.

— Нинди зыян булсын? — дип төксе генә сорады Аркадий.

— Заводны ташлап китүе бар.

— Сөймәгәнгә сөйкәлеп булмый.

— Комсомол оешмасы Пиньпи шикелле кешеләргә тормышта урын табарга булышырга тиеш.

— Әгәр ул үз урынын заводтан читтә эзләсә?

— Бөтен кешедән алда югары разрядка экзамен бирергә теләвен үзен ишеттең бит.

— Экзаменны бирерме әле, юкмы, ә станокны аңа ышанып тапшыру куркыныч.

— Ни өчен? — дип гаҗәпләнде Анна.

— Станокны үзенеке итеп карамый ул, аңлыйсыңмы,— диде Аркадий,— иртәгә тагын ватуы бар.

— Кешеләргә ышанырга кирәк,— диде Аня.

Бераз вакыт алар кичке тыныч юл буйлап, кичке шәфәкъ утларында елтыраган күлдәвекләрне әйләнеп үтә-үтә, дәшми генә атладылар.

— Пиньпи белән чын күңелдән сөйләшеп караганың булмадымы?— дип сорады Анна бераздан.— Ул ниндидер бер карчыкта тора. Хәлен белеп чыгарга иде, ничек яши икән?

— Мин ул турыда уйлаган идем. Өенә барырга уңайсызландым.

— Әйдә, бергә барыйк.

— Юк, Пиньпиның үпкәләве бар, тикшерергә килгәннәр дип уйлар. Холкын беләсең бит. Үзең генә бар инде. Ә туганнары кая соң аның?

— Әнисе үлгән. Әтисе икенче хатынга өйләнеп Мәскәүгә күчкән. Пиньпи бик күптәннән ялгыз яши. Әле без монда эшли башлаганчы ук сөйләгән иде аны миңа Пиньпи. Мин аны бик кызгандым һәм теге көнне сезгә алып килдем. Хәтерлисеңме?

— Әнә ничек икән...— диде Аркадий уйчан гына.— Белми идем әле. Керми калма син аңар, Анна.

* * *

Шулай да Пиньпины икенче эшкә күчерергә туры килде. Бу хәлне ул тыныч кичерде, борчылуын күрсәтмәде. Үзе урынына килгән эшчегә дәшми генә коралларын, ачкычларын бирде дә цехның әзер детальләр җыела торган башына китте. Әзер детальләрне чистартучы слесарь булып эшләргә тотынды.

Пиньпи әзер детальләрнең кырында калган металл валчыкларын игәү белән кырып төшерергә дә фанер җәйгән асфальтка тезә барырга тиеш. Шуннан аларны җыю цехына алып китәргә тиешләр. Бу — кара эш, бары кул белән генә эшләнә, җиңеләйтү чараларын бер дә кулланып булмый. Ләкин акчаны күп түлиләр. Станокта эшләгәннән күбрәк алып була.

Пиньпи урынына Аполлон белән Зинаның улы Мурат Сурманчевны куйдылар. Кашкарова аны күптән белә иде. Башта ул, Пиньпи шикелле үк, өйрәнчек булып йөрде, аннары слесарь, аннары токарь булды. Ә бу эш аның өчен яңа иде әле. Аркадий Муратның эше бармавын күреп алды. Пиньпи сменага утыздан артык деталь бирә иде, ә Мурат егермегә генә җиткерә.

Аркадий, кызыксынып, Пиньпины күзәтә башлады: үзен алыштырган токарьның уңышсызлыгына ничек карар икән? Ләкин кыз Муратны күрмәгәнгә салышты. Комсомол җыелышыннан соң берничә көн башын иеп йөрде, хәтта иптәш кызларына да дәшмәде. Әмма табигать биргән шат күңеллелеге үзенекен итте. Ул янадан көлә башлады, элеккечә җил-җил килеп цех буенча йөри. «Карагыз әле, миңа да техниканы ышанып тапшырдылар бит»,— дип, кайрак белән игәвен күрсәтеп көлә.

Берничә тапкыр Аркадий аның белән сөйләшмәкче булды, экзаменга әзерләнгәндә ярдәм итәргә теләде, ләкин Пиньпи аңар шулкадәр салкын һәм кырыс карый иде, егетнең чын күңелдән сөйләшү теләге шунда ук юкка чыга барды.

Муратның эше һаман җайланмый. Егетнең чын күнелдән тырышып та нормасын үти алмавын күрә Аркадий. Шулай итеп бер айлап вакыт үтә. Һәм кинәт бер көнне Мурат нормасын тутыра. Ләкин шатлык озакка бармый. Контролер аның утыз детален дә бракка чыгара. Аркадий тәмам күңелсезләнә: «Өйрәтәсең, өйрәтәсең, ә мәгънә юк».

Станоклар арасында йөргәндә Кашкарова янына килеп чыгуын сизми дә кала ул. Пиньпи бракка чыккан детальләр турында берни дә ишетмәгәндәй, тырышып деталь игәүли. «Пиньпи, иртәгә станокны кабул итеп ал, Муратны монда җибәрермен»,— дип әйтәсе килде Аркадийның. Ләкин тыелып калды. Алай кинәт кенә хәл итәргә ярамый.

Эш сәгатьләре бетте. Эшчеләр, эш урыннарын җыештырып, коралларын ящикларына бикләп, юыныргa киттеләр. Аркадий үзенең заводта тоткарланып калуын, ашка көтмәүләрен әйтеп өенә хәбәр итте дә цех конторына китте. Кашкарова урынына әзерлексез кеше куйганы өчен ул бүген үпкәсен Чалдоновка әйтергә теләгән иде, ләкин Чалдонов китеп өлгергән булган.

Аркадий буфетта гына капкалап алды да цехка кайтты.

Зур корпуста гадәти булмаган тынычлык хөкем сөрә. Баш корпусның яңа цехлары әле бер генә сменада эшлиләр, кичләрен бирегә ремонт бригадасыннан берничә кеше дә вахтер гына кала. Станоклар, насослар, компрессорлар иртә килгән көзге кичнең тынлыгына чумып утыралар.

Аркадий үзенең участогына килде. Ике рәт булып тезелгән станоклар арасында ялгыз шәүлә күренде. Мурат икән. Егет детальләр яткан өстәл өстенә иелгән һәм аларның диаметрларын үлчәп маташа иде. Мастерны күргәч, Мурат, уңайсызланып, детальләрен күчергәләп куя башлады.

— Син нәрсә, әллә төн буе эшләргә җыенасыңмы? — диде Аркадий.

— Туры килер... Үзем гаепле.

— Игәү белән җайларга телисеңмени?

— Әйе, станокка кабат куйсаң, күбрәк вакыт китә. Бөтенләй бозылып куюы да бар. Хәзер мин аның серен аңладым инде,— диде Мурат, кинәт кенә елмаеп.

— Я, я,— дип кызыксынды Аркадий.

— Менә, карагыз,— диде Мурат,— мин физика законын онытып җибәргәнмен: кызганда металл киңәя, суынганда кечерәя бит әле. Хәзер мин детальдәге тишекне зуррак бөке белән үлчим. Җайлы да, төгәл дә, тиз дә эшләнә. Аны миңа Пиньпи әйтте. Үзенең бөкесен бирде.

— Пиньпи? Әллә ул да китмәдеме әле? — дип гаҗәпләнде Аркадий.

— Институтка китте.

Аркадий өчен бу көтелмәгән хәл иде. Иң начар эшчеләрдән саналган Пиньпиның хезмәт сере булсын, имеш. Җитмәсә әле ул башкаларны өйрәтә.

Муратның эше тизрәк бетсен дип, Аркадий да ящиктан игәү алды һәм егеткә булыша башлады. Мурат каршы килде. Утызны гына түгел, йөз деталь булса да, эшен бетерәм, диде ул. Ләкин мастер аның сүзенә колак салмады. Мурат авыр сулап эшкә тотынды. Сирәк-сирәк кенә ул мастерга күз сала. Аркадий берничә карамый, тыныч кына эшли иде.

Алар — мастер һәм яшь эшче — тавыш-тынсыз гына эшлиләр. Тирәяктә йөзләрчә зур һәм кечкенә станоклар тора. Иртәнге шау-шуга кадәр алар, тонык кына ялтырап, тын калганнар.

Муратның станогы цехта иң кечкенә булса да, егет үзендә зур агрегатлар белән ярышырлык көч тоя. «Шушы эшне генә тәмамлыйм»,— дип уйлый ул тау-тау өелгән шарлы подшипникларга карап.

Кинәт цехка Пиньпи Кашкарова килеп керә, Аркадий аны күргәч:

— Тагын бер булышчы килде,— дип кыюсыз гына мыгырдана.

Пиньпи Аркадийның сүзләрен ишетмәгәнгә салынды. Дәшми генә килеп, ящиктан коралларын алды да, цехта үзе генә булгандай, Муратка булыша башлады.

— Институтта дәресегез бар түгелме соң? — диде Аркадий, түземчә.

— Зыян юк, бер-ике лекцияне калдырганнан берни булмас.

Тагын тынлык урнашты. Эш белән вакытның үткәне сизелмәде.

Кинәт ерактан Сәгыйт Сәйфетдиновның аяк тавышлары ишетелде. Аны беренче булып Пиньпи күрде.

— Төн уртасында нишләп йөрисең,— диде ул, аз гына елмаеп.

— Күңелсез хәл,— дигән булды Сәгыйт, авыр сулап.— Беләсезме, бик күңелсез хәл. Завод янында бер кыз белән күрешергә булган идек, килмәде.

— Үзең гаепле,— диде Пиньпи.— Кая чакырырга белмәгәнсең. Кызларны клубка, кинога, кафега чакыралар аны.

Сәгыйт уңайсызланып кулларын җәйде:

— Башка килмәде бит. Тәҗрибә юк. Киләчәктә истә тотармын. Ә хәзер... Өйгә кайтырга ерак, тукта әле, мин әйтәм, цехка кереп чыгыйм. Вахтерша таныш иде, кертте.

Сәйфетдинов артыннан Бушуев килде. Алар да озын өстәл артына килеп бастылар.

Мурат фуражкасының алдын артка әйләндереп киде. Булышырга килгән иптәшләренә ничек рәхмәт әйтергә белми иде ул.

— Син юкка гына институтка бармадың, Пиньпи,— диде ул, уңайсызланып кына.

— Зыян юк,— диде Пиньпи.— Дашадан күчерермен әле.

— Чыннан да, бер көн лекцияне калдырудан әллә ни зыян булмас, Пиньпи. Синең монда килүең әйбәт булды әле. Бик әйбәт булды.

Пиньпига «син» дип эндәшүенә ул үзе гаҗәпләнеп куйды. Ул, әле яңа гына күргәндәй, кызга карап торды: гәүдәгә җыйнак кына. Кара халат кигән. Арыган, ахры, агарынып киткән. Хәзер ул «кулда нык тотарга кирәк» булган холыксыз Пиньпига бер дә охшамый иде. Менә бит ул үзе теләп иптәшенә ярдәм итәргә килгән.

Шундый кыска гына вакытта кешенең холкы үзгәрә микәнни? Ләкин Пиньпига нәрсә тәэсир иткән соң? Бәлки мәхәббәттер? Шулайдыр, ахры. Ә ул, җүләр, аңламый тора. Пиньпи белән Мурат бергә укыганнар, эшкә дә бергә килделәр. Менә хәзер егеткә кыен вакытта сөйгән кызы аңар ярдәм итте. Шулай булгач, яшьләргә бәхет теләргә генә кала.

— Аркадий Архипович, мин әле генә өйгә шалтыраттым,— дип аның уйларын Мурат бүлдерде.— Өйдәгеләр безне ашка чакыра. Кичә балык тоткан идем.— Ул Сәгыйткә, Бушуевка һәм Пиньпига борылды.— Киттек, иптәшләр!

— Әйдә, бергә эшләгән икән, бергәләп ашап алыйк,— диде Сәгыйт.— Пиньпи, барасыңмы?

— Минме? Сез барсагыз, барам.

Бушуев мастерга карап алды. Аркадий баш тартса, барысын да үпкәләтәсен аңлады.

— Вакыт соң түгелме әле?

— Бала-чага вакыты. Ун да тулмаган,— диде Мурат.— Безнекеләр өмәчеләрне бик шатланып каршы алачак.

— Кыздырган балыктан мин дә баш тартмам, ахры,— диде Бушуев,— киттек, Аркадий Архипович!

Муратлар яшәгән өч катлы йорт бер катлы йортлар арасында аерылып тора. Моннан бер утыз ел элек биредә кара урман булган, хәзер йортлар тирәсендә сирәк кенә нараг агачлары утыра. Муратлар йорты биек, яңа, зур балконнары бар.

— Әйдәгез, рәхим итегез, чишенегез,— дип, аларны сөйкемле генә ханым каршылады.— Кул юарга теләсәгез, бирегә керегез.

«Сеңелесеңдер, ахры. Әнисенә бер дә охшамаган икән», дип уйлады Аркадий. Ләкин Мурат:

— Таныш булыгыз, иптәшләр, бу — минем хатыным,— диде.

Аркадий Пиньпига карап алды. Муратның өйләнгән кеше икәнен белмиме икәнни? Әллә ул өйләнгән булса да яратамы? Ләкин Пиньпи бик шат күренә, бертуктаусыз елмая, барысы белән дә шаярып сөйләшә.

Кунаклар юынып, өстәл янына уздылар. Кыздырган балык, гозлы кыяр, кәбестә, гөмбә — барысы да авыз суларын китереп тора.

Бүлмәгә поднос күтәреп Муратның әнисе керде. Ул виноклы графин һәм рюмкалар алып кергән иде. Күрше бүлмәдән ата кеше чыкты. Мурат шулкадәр әтисенә охшаган иде, моны күргәч, барысы да елмаеп куйдылар.

— Безнең Муратны шулай буксирга алырлык булгач, бригадагыз тату икән,— диде өлкән Сурманчев һәм улына борылды: — Хәзер инде син артка калмассың бит?

— Юк, эти, бу кичне мин эш университеты тәмамладым.

Үзендә эшләүче егетнең семьясы белән танышуга Аркадий бик канәгать иде. Сурманчевлар турында ул әлек аз-маз гына ишетеп белә иде. Ә хәзер менә сүз арасында Бушуев һәм Сәйфетдиновларның да тормышлары белән таныштты. Бары Пиньпи турында гына белә алмады.

Кунаклар саубуллашып китәргә җыенгач, Бушуев белән Сәйфетдиновның бер якка, Пиньпи белән Аркадийның икенче якка китәргә тиешлеге беленде. Башта кыз шәһәрнең төнге урамыннан тын гына барды. Шуннан соң Муратның хатыны турында сөйләргә тотынды:

— Менә дигән кеше ул Мая. Типографиядә китап төпләүче булып эшли, үзе бала үстерә, җитмәсә кичке институтта да укый. Муратның атасы белән бергә эшли ул. Сурманчев — типография начальнигы.

— Муратның өйләнгән кеше икәнен син белә идеңмени?

— Белмичә, Мая белән без бер группада укыйбыз.

Әйе, әйбәт психолог түгел ул Аркадий. Кызның йөрәгендәниләр барын һич кенә аңламый бит.

**Л. ИХСАНОВА** тәрҗемәсе.

## Педер Хузангай

Чуваш халык шагыйре.

# Йөрәк җыры

Акыл байлыкларын туплап
Үтә еллар, гасырлар.
Тарихчыны җәлеп итә
Чувашлар үткән юллар.
Без туры алга барабыз,
Үткәнне дә күрәбез:
Без — булган, без — бар, яшәрбез,
Шуны яхшы беләбез!

Кешелек, зур урман кебек,
Төрле агачларга бай,
Аңар күкләргә үрелеп
Үсәргә җирдә уңай.
Без киселгән, тапталганбыз,
Йолкынып ташланганбыз,
Шулай да шытып орлыктан
Үрелеп үсә алганбыз.

Без һәр халыкны дус күреп,
Туган күреп атладык.
Кояшны, айны, йолдызны
Үзебезчә атадык.
Акылны үстерде безнең,
Чыныктырды көрәшләр.
Без — булган, бар, яшибез! — дип
Тибә дәртле йөрәкләр.

Нечкә бизәкле чигүләр,
Тапкыр сүз дә һәм җыр да,
Кулдан-кулга, телдән-телгә
Күчәрләр чордан-чорга.
Максатыбыз бөек безнең,
Алга илтә юлыбыз.
Ышанып яшим көнелдән:
Без булган, бар, булырбыз!

«Ташка үлчим, чуваш телен!» —
Ди кайсыбер чуваш та.
Җирәнеп карыйм мин андый
Кешегә бу очракта.

Күзе томанлы җирбит ул,
Түбәнлектә калачак.
Бетсен ул, янсын, көл булсын:
Без булган, бар, булачак!

Зур бәхетләр яулап алып,
Үзенә һәйкәл салып,
Шушы бөек чорга житкән
Тигез хокуклы халык,
Ант итә үбеп туфрагын:
Гел яңаны корырбыз.
Кышын да, җәен, көзен дә
Без булган, бар, булырбыз!

Окоптамы, төзелештәме,
Һәркайда каләм алып,
Кәгазьгә түгел, ташка да,
Үз халкыма ышанып
Яздым мин. Сөекле халкым
Күземә карап миңа
Әйтә: Без — булган, без — бар,— ди,—
Яшәрбез! — ди мәңгегә!

**МӨХӘММӘТ САДРИ** тәрҗемәсе.

## Георгий Орлов

●

«Бергә атлап, бергә житик»,— диеп,
Дустым белән чыктым юлга мин.
Алдан бардым карлар ера-ера,
Әйтерсең лә житез юрга мин.
Буран чыккач, аңа каршы атлап,
Юлдашымны җилдән сакладым.
Аның авыр йөген үзем алып,
Көч-хәл белән алга атладым.
Аяк талды, күзләр томаланды,
Үзен генә сөйгән минем юлдаш
Ташлап китте бер көн үземне.

Колак сал син минем сүземә:
Дустың булсын яхшы үзеңнән.

●

«Шыта да тик корып бетә орлык,
Кирәк микән чәчү тузанга»,—
Җир турында кеше шулай әйтсә,
Күңел рәнжи, йөрәк кузгала.
Тавыш бирде кинәт миңа ана:
Җир дигәнең гүя ул бала.

Һич шаярмый бала чирле чакта,
Таза булса көлә, елмая.
Җиргә чәчкән орлыкларга кирәк
Нарасыйга булган тәрбия.
Уңыш алыр тик шул, бу туфракны
Кем кадерләп бала күк сөя.

Онытабыз кайчак җирне без,
Юкка гына әрли-тиргибез.

●

Көзгедәй төз юл сузылган,
Ике яклап баралар
Ефәк яулыклар бөркәнгән
Шомыртлар да алмалар.

Күбәләктәй зәңгәр күктә
Ак чәчәкләр уйныйлар.
Дөнья матур, сандугачлар
Иртә-кичен тынмыйлар.

Гөлләр бакчасы диярсең,
Олы юл, тирә-ягың.
Җырламый ничек түзәрсең,
Сөенгәч бөтен җаның.

Кеше матурлык ярата,
Матурлыктан көч-дәрт арта.

## Михаил Уйп

●

Безне кем таныштырды —
Белмим инде үзем дә.
Якын дустым, синең хакта
Уйлыйм язын, көзен дә.
Синең белән бергә булган
Дусларны алам искә.
Йолдызлардай синең күзләр
Балкыды айлы кичтә.
Тавышыңны әле дә мин
Еракларда ишетәм.
Мин үземне синең белән
Бергә кебек хис итәм.
Кил яныма, барыр идек
Икәүләп бер сукмактан.
Сине эзлим көн-төн, дустым,
Очрашырбызмы? Кайчан?

●

Тып-тын иде. Айлы кичтә
Йолдызлар җемелдәде.
Юлларыңа карый-карый
Көттем мин син гүзәлне.
Син килгәч, дулкынланудан
Йөрәк леп-леп сикерде.
Сөйләргә телем бәйләнде,
Әйталмадым исемеңне...
Күкрәгемә башың куйдың,
Күзләремә карадың:
Мин үземне бу дөньяда
Иң бәхетле санадым.
Онытылмас минутларны
Тотам исемдә һаман.
Син кабызган мәхәббәтнең
Ялкыннарында янам.
Сөеп калам сөелгәндә,
Яшьлек — янар, сөяр чак.
Кышкы салкыннарда миңа
Җылы бирә шул учак.

## Михаил Сениэль

### Ана җыры

Челтәрле күпер янында
Челтәрле яулыклар юдык.
Яңа заманда яшибез,
Зур бәхеткә ия булдык.

Кечкенә яулык, ак яулык,
Яратып бәйләнгән яулык.
Балаларым, канатларым,
Телим сезгә исән-саулык.

Кара урман артларыннан
Кәкүк җыры яңгырап килә.
Миңа җиңел булган чакта,
Дошман елый икән нигә?

### Яр буенда

И кояшым, кояшым
Суга кереп югалды.
Инде миңа нишләргә,
Зиһеннәрем чуалды.
Ыргак белән алыйммы,
Тигәнәгә салыйммы?
Сосыйммы соскы белән,
Кисимме пычкы белән?

Яр буенда, ялангач,
Уйга чумып утырам.
Ничек суга керергә:
Чирканып карап торам.
Җиде тапкыр чумылды,
Күпме соң су кирәргә?
Кояш артыннан тагын
Кирәк бит сикерергә.

## Василий Давыдов-Анатри

### Рәхмәт сүзе

Утыр, Вәкил, яныма,
Җырлыйк татар җырларын.
Күңелләрне күтәрик
Көйләп халык моңнарын.

Синең белән булганда,
Татарстан искә төшә.
Тукай, Такташ җырлары
Минем дә, юлдаш, истә.

Күптән, элек-электән
Чувашка татар туган.
Туганнар булганга, без
Калмадык сабан туйдан.

Җырың, сыйларың өчен
Рәхмәт яусын үзеңә.
Кил инде хәзер үзең
Акатуйга [1] безнең дә.

### Бала чак

Бала чакта колын булып
Уйнарга бик яраттым.
Тугай, үзәннәрне таптап,
Ялан аяк күп чаптым.

Укыдым чирәмгә ятып
Иванов шигырьләрен:
Нарспи белән Сәтнер [2] өчен
Тетрәнде күңелләрем.

Күз алдыма килде минем
Ерак Силби [3] урманы.
Әйтерсең лә, Нарспи ул
Әниемнең туганы...

Бала чактан дулкынландым
Олы язмышлар өчен...
Кайда сез, каһарманнарым,
Бала чак, хыял көчем?..

**КАВИ ЛАТЫЙПОВ**
тәрҗемәләре.

---

[1] Акатуй — сабан туй. (Чувашча.)
[2] К. Ивановның «Нарспи» поэмасы каһарманнары.
[3] Силби — шул ук поэмадагы авыл исеме.

Михаил Юхма

# КОЯШЛЫ ЧИГҮ

ХИКӘЯ

Күке оча кәккүк диеп,
Кәккүктәй кайталмыйсың.
Сандугач оча чут-чут дип,
Син сайрап кайталмыйсың.

Карлыгач оча канат кагып,
Син алай кайталмыйсың.
Таң ата, дөнья яктыра,
Яктырып кайталмыйсың.

Көн туа, дөнья нурлана,
Нурланып кайталмыйсың.
Сулар ага, дөнья шаулый,
Син шаулап кайталмыйсың.

*Һәлак булган батыр турындагы борынгы чуваш халык җыры*

Без, Ендимер карт белән икәү, пыскып янган учак янында утырабыз. Бөтен гомерен атлар көтеп уздырган карт бер көтүче ул. Өстәвенә, бу якның иң оста әкиятчесе икән. Аның йөзгә якынлашып килгән яше дә үз гомерендә бик күпне күргәнлеген, бик күпне кичергәнлеген әйтеп тора.

Мин Чабаксардан бирегә килеп төшкән көнне үк, ни йомыш белән йөрүемне белгәч, авыл Советында миңа әйттеләр:

— Билгеле, теге Ендимер абзый инде! Әкиятривіятьләрне аннан да күп белүче юк. Бөтенесен белә ул. Һәр куак, һәр түмгәк турында да ни дә булса сөйләми калмас. Тере энциклопедия ул. Сөйләтә генә бел, гомереңә онытылмаслык нәрсәләр сөйләр,— диделәр.

Кояшта янып каралган, уң-уникe яшьләрдәге, зур кара күзле бер кыз мине Ендимер бабай белән таныштырды. Карт мине ошатты шикелле. Шул кичне үк төнлә атлар саклый барырга чакырды.

Менә без өченче кич инде урман янындагы басуга ат көтүен алып килдек. Башка көннәрне безнең белән берничә үсмер егет тә килгән иде, бүген алар авылга кайтып киттеләр. Нәрсә дисең инде — күңелләренә дәрт кергән чаклары. Шундый матур, рәхәт төндә дус егетләре, күңел төшкән кызлары янында буласылары киләдер.

Бу төнне сүзебез ничектер тиз генә ялганып китмәде. Карт, ара-тирә таягы белән җиргә бәргәләп, уйчан бер кыяфәттә үз алдына утыра бирде. Мин аңа карап ятып торам. Аның бөтен чәч-сакалы ап-ак агарган, вакыт-вакыт күзләрен еракка текәп торган чагында ул көмештән койган бер сын төсле булып күренә.

— Нигә син дә авылга кайтып китмисең? Син дә яшь кеше бит әле,— ди бабай миңа.

— Кайтасым килми. Чит егетләр, кызлар янында уңайсызланам,— дим мин.

— Яшьли картаерга уйлыйсыңмыни? Алай итәргә ярамый, улым. Яшьлек ике килми ул. Яшь чагыңда да уйнамагач-көлмәгәч, тагын кайчан күңел ачасың? Яшь чак ул матур төш кебек кенә: уянасың — юкка да чыга. Аннары, кабат күрмәмме дип күзеңне күпме йомып ятсаң да, яңадан күрә алмыйсың. Яшь чагыңда яшьләр арасында күңелле ул,— диде бабай, мине кызганган да, акыл да биргән кебек.

Мин инде риваятьләр сараеның ишеге ачылдымы дип тә уйлаган идем, юк, ачылмаган икән әле: карт тагын тынып калды.

Авыл ягыннан әле кызларның сузып җырлаган моңлы җырлары, әле егетләрнең шаулашып көлүләре ишетелә.

Мин тагы картка карыйм. Ул чал бер кош шикелле бөкрәя төшеп утырган. Бөтен бите җыерчык кына, тик җыерчык ничектер килешә үзенә, аны акыллы бер карт итеп күрсәтә.

Кояш баешы ягыннан җил исеп куеп, учак төтенен миңа таба авыштыра башлады. Шуннан соң мин карт янынарак күчеп утырдым.

Ендимер бабай, миңа ачуы килгән кебек, вакыт-вакыт үрләп киткән учак ялкынына эндәшеп:

— Нигә телләреңне сузасың?! — ди. Аннары таягы белән утлы күмерләрне актаргаларга керешә.

Арттарак нәрсәдер кыштырдаганы ишетелә. Борылып карыйм. Озын, нечкә торыклы теге бурлы айгыр икән. Без аның белән бик дуслар. Ул килеп миңа борынын төртә. Нәрсә сораганын аңлыйм. Кесәмнән икмәк кисәге чыгарып, айгырга каптырам. Ул миңа рәхмәт әйткән кебек фырт итеп пошкырып куя да тагы борынын суза.

— Бүтән юк. Ашап бетердең бит инде,— дим мин, атның башын читкә этәреп.

Айгыр, әйткәнне аңлаган кебек, пошкырынып, көтүгә таба китә.

— ...Хайван да иркәләгәнне ярата шул,— ди Ендимер бабай, айгырга таба карап.

Мин аның белән килешеп баш кагам. Шуннан соң тирә-юнь тагы тынып кала.

Беравыктан карт, миңа таба борылып, тиктомалга:

— Минем сөйләгәннәр сиңа нәрсәгә кирәк ул? — дип сорап куя.— Узган ике төндә мин сиңа бик күп сөйләдем бит инде,— ди.

Сизәм, аның нәрсәдер сөйлисе килә. Мин аңар сүз башларга булышмакчы булам. Тик бабай шундук үзе сөйләп китә:

— Бик күптәнге хәл инде. Бервакыт шулай минем янга егетләр килде. Сембердән без, диләр. Якольч[1] мәктәбеннән, диләр. Бик зур кеше булган, ахры, ул Якольч дигәннәре. Миңа аны күрергә туры килмәде шул. Югыйсә Сембергә баргалаганым булды. Безнең Якольчны Ленинның әтисе Илья Николаич гаиләсенең дусты да булган, диләр.

Аннары карт, нидер исенә төшергән кебек, тагы сөйләп китә:

— Без юхманыкыларга Сембер якын гына иде. Ямщик булып бара торган идек без анда. Кире кайтканда Ямской юлы белән Сембер тавына менгәч тә, Суругут[2] әрәмәлеге күренер иде. Без инде өйгә, Юхмага кайтып җиткән кебек була идек.

Мин, картны тыңлый-тыңлый, чалкан әйләнеп ятам. Безнең турыда күк йөзе чалт аяз. Җидегән йолдыз үзенең чүмеченнән безнең өскә энҗе нурларын коеп тора. Меңләгән йолдыз, монда менегез, дигән ши-

---

[1] Якольч — Иван Яковлевич Яковлев — чуваш халкының язма телен һәм әдәбиятын тудыручы зур мәгърифатче.

[2] Суругут әрәмәлеге — Чувашиянең иң биек жирендә. Аяз көнне житмешсиксән чакрымнан да күренә.

келле, безгә күз кысып жемелдәшә. Төньяктан көньякка таба, еракка-еракка, җир белән күк тоташкан төшкә чаклы, Киек каз юлы сузылган.

— Беләсеңме, бабай, йолдызлар безгә моннан кечкенә төртке чаклы гына булып күренә, ә чынында алар бик зур, бездән бик ерак алар,— дим мин.

— Ерактыр шул. Тик шулай да...

Карт сүзен әйтеп бетермәде — яшен уты шикелле сызылып йолдыз атылды.

Шул чак күңелемдә балаларча бер дәрт уянды. Шаярасым килеп китте дә:

— Минем йолдыз — өстәгесе! — дип кычкырып куйдым.

— Юкка борчыласың, улым. Безнең йолдыз ул — ракета, шунда әйләнеп йөри. Бусы аның йолдыз түгел. Казял батырның утлы угы ул. Шундый уклары белән ул кешеләргә бәхет табарга комачаулаган аждаһаларга каршы сугышкан,— ди Ендимер бабай.

Менә риваятьләр китабы ачыла башлады бит.

— Ничек булган ул? Сөйлә әле, бабай!

— Ярый алайса, сөйлим инде,— диде карт, озак кына йөткереп азапланды. Ашыкмый гына чилемен чыгарып, аны чистартты, тәмәке тутырды. Сеңерле, сөякләч куллары белән утлы күмер кисәге алып, чилеменә салды.

— Бик борын заманда кешеләр дөньяда үзара тату, бәхетле яшәгәннәр,— дип сөйләргә керешге карт.— Билгеле, ул заманда алар бала акыллы булганнардыр, бәлки. Шулай да бәхетле яшәгәннәр, чөнки тату булганнар. Алар арасында явыз кешеләр булмаган.

Шулай итеп, еллар, йөз еллар узган.

Бервакыт дөньяга бер явыз кеше туган.

Явызлык яхшылык белән килешеп яши алмый. Явызга җирдәге чәчәкләр дә тиешенчә атмый төсле тоела.

Әлеге явыз адәм башка кешеләрне дошман күрә башлый. Аларның үзара тату, бәхетле яшәүләрен яратмый, бер-берен яратуларын күрә алмый. Үзе ул көзгә төн төсле караңгы чырайлы, елан шикелле көнче[1] кеше була. Бер кешене дә яратмый, үзен дә беркем яратмый.

Шуннан моның адәм ыруын харап итәсе, дөньяга үзе генә баш булып каласы килә.

Явыз кеше дөньяга явыз нәселен үрчетә. Аларны бөтен нәрсәдән көнләшергә, бөтен нәрсәне күрә алмаска өйрәтә. Көнче кешеләр беркемне дә күрә алмый торган булалар бит.

Явыздан туганнар да явыз булалар.

Кешеләр боларны куштаннар дип атыйлар.

Шулай итеп, еллар, йөз еллар уза.

Ул заманда күктә хәзерге кебек бер генә кояш түгел, өч кояш була.

Җир йөзен өч кояш яктыртып тора.

Җир дә бик җылы була.

Күккә таба үрләгән агач ботакларында бик тәмле җимешләр үсеп утыра.

Кырларда мул булып ашлыклар уңа.

Елга-суларда бик күп төрле балык була, кешеләр аларны корал белән дә, ялан кул белән дә тота торган булалар. Ул заманда кешеләр кышның нәрсә икәнен дә белмиләр. Адәм телендә салкын дигән сүз дә, боз дигән сүз дә булмый. Кеше телендә эссе, җылы дигән сүзләрдән килеп чыккан төшенчәләр күп була.

Кешеләр әнә шулай гомер итәләр. Бәхет, шатлык эчендә, мул, рәхәт яшиләр.

---

[1] Чувашлар шулай дип әйтәләр. Халык риваятьләрендә, кул-аяк, калат өләшкәндә еланга берсе дә тимәгәч, ул көнче булып калган, диелә.

Әмма адәм ыруын харап итәргә, дөньяга бер үзе баш булырга теләгән кешеләр аларның бәхетле тормышын бетерәләр.
Алар тудырган явыз токым бозык күнелле була.
Җирдәге җылы аларның ачуын китерә.
— Бик эссе!
— Мондый хәлдә яшәп булмый!
— Безгә өч кояш кирәкми!
— Берсе дә житкән! — дип кычкыралар алар.
Акыл ияләре аларга акыл бирергә тырышалар:
— Дөньяның үз тәртибе бар, аңлагыз, күктә өч кояш булу безнең өчен зур бәхет ул. Әгәр дә кешеләр шул өч кояшның берсен генә рәнжетсәләр дә, зур афәт тууы мөмкин,— диләр.
Ләкин куштаннар алар сүзен тыңламыйлар. Башка кешеләрне дә астыртын гына котырта башлыйлар:
— Бу кадәр эсселеккә түзеп булмый! Бер кояш кына булса, дөньяда яшәве жиңелрәк булыр иде. Курыксагыз, ике кояшны гына калдырыйк,— диләр.
Берише кешеләр алар белән килешәләр.
Беришеләре:
— Безнең акыл ияләре башкача әйттеләр бит! — дип икеләнәләр.
— Ул акыл ияләре үзләре өчен генә яшәргә телиләр. Алар үзләре өчен генә тырышалар. Аларга шулай файдалы,— диләр куштаннар, ләкин ничек шулай файдалы икәнлеген аңлатып бирмиләр.
Кешеләрнең дә алардан шул турыда сорарга кирәклеге башларына килми.
Шулай итеп, куштаннар яла өстенә яла, ялган өстенә ялган тарата лар. Яла дигәнең таудан тәгәрәп төшкән җепшек кар кебек бит ул — тәгәри-тәгәри зурая бара.
Көннәр узган саен куштаннар йогынтысына ияргүче кешеләр арта бара.
Көннәрдән бер көнне куштаннар үзләрен яклаучы кешеләргә жыен мәйданына җыелырга кушалар.
Зәңгәр күккә таба атылып утлы уклар менеп китә.
— Ни булды? Ни булды? — дип кычкыра мәйданга таба йөгерүче халык.
Алар берәр мөһим эш чыгып, мөһим карар кабул итәргә кирәк булган чакта һавага утлы уклар очканлыгын беләләр.
Халык җыелган төшкә акыл ияләре дә килә. Шунда алар куштаннарның:
— Безгә өч кояш кирәкми!
— Берсен юк итик!
— Бик эссе!
— Тын да алырлык түгел! — дип кычкырганын ишетәләр.
Акыл ияләре:
— Җәмәгать! Аңлагыз: бу дөньяның үз тәртибе бар! — дип каршы сүз әйтмәкче булсалар да, куштаннар аларга авыз да ачтырмыйлар.
— Житте-булды! Безгә бик күп акыл өйрәттегез!
— Без үзебез дә акыллы!
— Моннан куып жибәрергә кирәк аларны!
— Безгә акыл сатучылар кирәкми!
— Алар үзләре өчен генә тырышалар! — дип кычкыралар.
Ә халык кайсы якның дөрес сөйләгәнен аера алмый.
Куштаннар, шундый хәлдә көчләре күп булудан файдаланып, акыл ияләрен башта мәйданнан, аннары авылдан ук куалар.
Акыл ияләре, бу хәлгә рәнжеп, кешеләрдән бөтенләй еракка, урмансулар аша тауларга таба китәләр һәм шунда үзләре генә яши башлыйлар.

Аларның китүенә куштаннар бик сөенә.

— Менә хәзер иркенләп яшибез инде. Монда без үзебез хуҗа хәзер. Алай итмә, болай ит, дип безне өйрәтеп торучылар юк! Ул акыл иләреннән барыбер бернинди файда юк иде,— диләр һәм мәйданда тагы теге өч кояш турында сүз башлыйлар.

— Бик эссе. Тын алырлык түгел!

— Бер кояшны бетерергә кирәк. Шуннан башка чара юк,— диләр. Куштаннарның сүзенә алданган кешеләр:

— Дөрес, шулай итәргә кирәк,— дип кычкыралар. Һәм бөтенесе бер кояшны бетерергә дип килешәләр.

Ул заманда Казял исемле бик оста аучы-мәргән яшәгән.

Берничә куштан аучы Казял янына барып, аны халык исеменнән мәйданга алып киләләр.

Мәйданда куштаннарның башлап йөрүчеләре мәргәнгә:

— Без, халык белән киңәшеп, мондый карарга килдек: безгә өч кояш кирәк түгел, берсе бетәргә тиеш,— диләр.

— Ә мине нәрсәгә китердегез соң? — дип сорый аучы Казял.

— Син — иң оста мәргән. Синең укларың болытларны да тишеп чыга. Угыңны җибәреп бер кояшны юк ит,— диләр монда.

— Акыл иләре андый эшне эшләргә ярамый, дип әйтteләр бит.

— Без аларны моннан сөрдек. Алар, башка кешеләргә яман булсын дип, үзләре өчен генә яхшы булуын теләделәр.

— Акыл иләренең үзләре өчен генә яхшылык теләүләрен минем беркайчан да сизгәнем булмады... Киресенчә, алар гел башка кешеләр өчен тырышалар иде,— ди Казял, гаҗәпләнеп.

— Син сизмәсәң, без сиздек. Әйдә, угыңны төзә,— диләр куштаннар ачу белән.

— Юк, мин угымны кояшка ата алмыйм,— ди аучы.

— Димәк, син дә безгә каршы! Алайса без синең башыңны чабып өзәбез! — дип, куштаннар аның өстенә килә башлыйлар.

— Ихтыярыгыз. Тик мин кояшка каршы угымны күтәрә алмыйм,— ди Казял.

— Балаларыңны да асабыз-кисәбез. Җиде буынга хәтле нәсел-нәсәбеңне юк итәбез! — дип, куштаннар берсен-берсе уздырырга тырышып кычкыралар. Берничәсе шундук Казялның йортына китә, балаларын алып килеп, мәйдан уртасына чыгаралар һәм кылычларын күтәреп, чабып үтерәбез дип куркыталар.

Күз алдында газиз балаларын үтерә башласалар, нинди атаның йөрәге түзеп торыр икән?

Шул чак Казял түзми:

— Балаларыма тимәгез! Тимәгез! — дип кычкыра.

Ләкин куштаннар аны ишетмәгәнгә салышалар. Аучының бер баласын җиргә сузып салалар. Менә-менә кылыч баланың муенына төшеп, аның җанын кыячак...

Казялның йөрәге түзми, җаны тетрәп, «аһ!» — дип куя да:

— Балама тимәгез! Кушканыгызны эшлим! — дип кычкыра. Шундук угын күтәрә дә тартып торып сул яктагы кояшка атып җибәрә.

Ук килеп тию белән, кояш суга таш төшкән шикелле чулт итә дә сүнә.

Ләкин җирдә өч кояш бар чагындагы шикелле һаман да эссе.

— Шәп, Казял! Шәп!

— Икенчесен дә юк ит инде!

— Дөрес, икенчесен дә сүндерергә кирәк! — дип кычкыралар куштаннар.

Бу юлы инде Казял озак көттереп тормый. Ук савытыннан яңа ук алып, җәягә куя һәм уң кулы белән җәяне тартып, атып җибәрә, ук выжт итеп очып менеп китә.

Бусы уң яктагы кояшка барып тия. Кояш шундук сүнә.

— Шәп, Казял! Шәп! — диләр куштаннар. Шатлыкларыннан мәргәнне кулларына күтәреп алырдай булалар, берни белешмәстән, сикереп биергә тотыналар. Тик шул вакыт бер хатын, хафага төшеп:

— Ай алла! Кояш кача бит! Өченчесе кача! — дип кычкырып җибәрә.

Бөтенесе күтәрелеп күккә карыйлар һәм ялгыз калган кояшның кинәт күкнең түбәсенә үк, мәргәннең угы җитмәслек бик биеккә менеп баруын күрәләр.

Кешеләр, котлары алынып, шаккатып, тик басып торалар.

Куштаннар да, яман хәл килеп чыгуын тоеп, тавыш-тынсыз калалар.

Хатыннар куркынып, кычкыра-шаулый башлыйлар.

Кояш аның саен биеккәрәк китә бара.

Кояш югары китү белән җир өсте дә суына бара.

Ниһаять, ялгыз калган кояш, күкнең түбәсенә үк җитеп, туктап кала. Хәзер инде аның җылысы кешеләргә килеп җитми.

Җир өсте салкыная.

Бөтен җирне кар каплый.

Ыжгыра-ыжгыра салкын җил исә.

Кешеләргә татлы җимеш биргән агачлар суыкта өшеп һәлак булалар.

Кешеләрнең ашарларына ризыклары бетә. Ачлык башлана.

Шул вакытта гына бөтен кеше, явыз куштаннар сүзен тыңлап, зур ялгышлык эшләгәннәрен аңлыйлар.

— Куштаннар безне алдадылар! — дип кычкыралар һәм куштаннарның барысын әллә кайдагы кара урманнарга куып җибәрәләр.

— Хәзер нишлибез инде? — диләр кешеләр бер-берсенә.

Шунда Казял батыр сүзгә кушылып әйтә:

— Иң элек без акыл ияләрен эзләп табыйк. Алар белән сөйләшик, безгә хәзер нишләргә икәнлеген белик,— ди.

— Хәзер аларны кайдан эзләп табасың? — дип сорыйлар аннан кешеләр.— Алар безгә рәнҗеп-үпкәләп, бик ерактагы тау араларына киткәннәрдер.

— Ике кояшның бетүенә, соңгы кояшның да бездән китүенә бөтен кешедән бигрәк мин гаепле. Шулай булгач, мин акыл ияләрен эзли барам. Аларны тапмыйча кире кайтмыйм. Мине көтегез. Я акыл ияләре белән бергә кайтам, я бөтенләй кайтмыйм,— ди Казял.

— Бик авыр юл инде. Синең бөтенләй эзсез югалып калуың бар,— диләр аңа кешеләр.

— Үз гаебем аркасында кешеләр газап-михнәт күргәндә мин тик утыра алмыйм. Аларның бәхете өчен мин гомеремне дә кызганмыйм. Эзсез-хәбәрсез югалсам югалырмын. Аннан курыкмыйм. Кешеләр бәхете — минем үз бәхетем. Миңа фатиха бирегез, туганнар.

— Сиңа бездән фатиха. Үзең теләгәч, бар инде. Бик кыю эшкә барасың. Бөтен кеше синең юлың уңуын тели. Син эзсез-хәбәрсез югалып калмассың. Без синең исән-сау кайтуыңа ышанып, көтеп торабыз, Казял мәргән,— диләр кешеләр.

Оста аучыны дуслары, иптәшләре дә, кардәшләре, балалары да, сөйгән хатыны һәм әти-әниләре дә тоткарламыйлар, чөнки кешеләр бәхете өчен китә бит ул. Шулай итеп, аны юлга әзерлиләр.

Газиз әнисе аңа күкрәк сөтен кушып юсман [1] пешерә, калган сөтен чымга [2] агызып, улының кесәсенә сала.

— Анаң сөте сине бәла-казалардан коткарсын. Шуны онытма улым: без барыбыз да газиз җир балалары. Җир-анага сыен. Ул сиңа ярдәм итәр,— ди аучыга әнисе.

---

[1] Юсман — юка күмәч, юлга чыккан кешене ул җен-пәриләрдән саклый, имеш.
[2] Чым — кечкенә генә чүлмәк.

Казял батыр бөтен кеше белән саубуллаша да юлга чыга.

Көн артыннан көн уза. Атналар, еллар уза. Казял батыр һаман бара да бара. Адәм үтеп йөри алмаслык сазлыклар, чытырманлыклар, котчкыч таулар аша уза. Юлында бик күп киртәләр очрата. Юлбасарларны, күз күрмәгән ерткыч җәнлекләрне җиңеп, һаман бара бирә.

Юлында аны беркем, бер нәрсә туктата алмый.

Ашап-эчкән чагында да баруыннан туктамый. Арып-талса, хәлсез тавыш белән яраткан җырын җырлый башлый. Кешеләрнең иң бәхетле көннәре, ирек, яктылык турындагы, кешеләрне явыз җан ияләреннән саклап калучылар турындагы җыр ул. Бу җыр арып тәмам хәлдән тайганда да кешеләргә һәм аучы Казял батырга да көч, дәрт бирә, дәрт өмет уята.

Юлында усал кошлар, кабан тешле усал ерткычлар очраса, ул аларның барысын да җиңә бара. Алар белән сугышып барлык угын атып бетерә. Иң соңгысын соңгы ерткычның йөрәгенә кадый.

«Хәзер инде укка өмет юк. Башка ерткычлар өчен кылыч кына калды», дип уйлый Казял.

Һаман бара да бара. Тагын берничә суны кичә, кара урманнарны уза. Шунда бер тау тишегенә килеп чыга. Нәселдән нәселгә күчеп килгән хәбәрләргә караганда, акыл ияләре шушы тау арасында яшәргә тиешләр.

Дөм-караңгы төн җитә.

Күкрәп-яшенләп яңгыр ява.

Давыл куба.

Казял батыр тау тишегеннән берничә адым читкәрәк атлауга: «Ысс! Чышш!» иткән тавыш ишетә.

Каршысына өч башлы аждаһа килеп чыга.

Тау тишеген шушы аждаһа саклап тора икән. Ул анда беркемне кертми дә, чыгармый да икән. Шул сәбәпле акыл ияләре кешеләр янына әйләнеп кайта алмыйлар икән. Кешеләргә зур афәт китергәнлеген ишеткәч, ярдәм итик дип, күптән кайткан булыр иде алар.

— Ысс! Чышш! — дип аҗгыра өч башлы аждаһа.— Адәм токымына ярдәм итәргә теләүче синме ул? Мәнә сөякләреңне ватып көл итәрмен дә шуннан соң кояшның ни икәнлеген белерсең! — ди.

— Тотмаган аюның тиресен тунамыйлар! — ди моңа каршы Казял батыр.

— Алайса, сук беренче булып! — ди аждаһа.

— Батыр беренче булып сукмый.

Аждаһа утыз чакрымга сузылган койрыгын селтәп аучыга берне китереп суга. Казял батыр тез тиңентен җиргә сеңә. Икенче тапкыр китереп сугуга, аучы җиргә күкрәк тиңентен чума.

— Я, җиргә сеңдеңме?! Мәнә сиңа кояш шул булыр! — дип ысылдый аждаһа һәм өченче тапкыр китереп сугуга Казял батыр муен тиңентен җиргә бата.

Шул вакыт аучы:

— Газиз җир, көч бир миңа! — дип кычкыра.

Шулай диюгә, ул үзенә бик зур көч-куәт кайтканын тоя. Җир эченнән сикереп чыга да кылычы белән аждаһага китереп чаба. Аждаһаның бер башы өзелеп, утыз чакрымга тәгәрәп китә.

Казял шундук кесәсеннән әнисе пешереп биргән юсманны ала. Шуны ашагач, көче тагы да арта төшүен тоя.

Кылычы белән аждаһага икенче тапкыр китереп чаба, аждаһаның икенче башы алтмыш чакрымга тәгәрәп китә.

Казял батыр кесәсеннән әнисенең күкрәк сөте салынган чымны ала. Шул сөтне эчкәч, көч-куәте тагы да артып китә.

Бөтен көче белән аждаһага тагын бер китереп чаба.

Өченче тапкыр чапканнан соң аждаһаның соңгы башы туксан чакрымга тәгәрәп китә, ярасыннан чаптырып кара кан ага.

Адәм ыруын коткарырга дип ерак юлга чыккан Казял батыр шуннан соң тау тишегенә кереп, акыл ияләрен эзләп таба.

Алар, моңа бик сөенеп, батыр аучы белән, кешеләр янына кайтып китәләр.

Акыл ияләренең кайтуын ишеткәч, кешеләр тагын олы мәйданга җыелалар.

Акыл ияләре аларга болай диләр:

— Сез, куштаннар сүзенә ышанып, бик зур ялгышлык эшләдегез. Ике кояшны юк иттегез. Соңгы кояш, ялгыз калгач, кешеләрдән куркып, бик югары менеп киткән. Хәзер ул газиз җиребезгә җылысын бирә алмый.

— Җиребез элекке шикелле җылы булсын өчен безгә нишләргә кирәк соң? — дип сорый кешеләр.

— Кояшны кире кайтарырга кирәк.

— Ничек итеп?

— Аны кайтарып буламы соң?

— Акыл ияләре ни әйтсә, без шуны эшләргә әзер,— ди кешеләр.

Чәче-сакалы ап-ак бер карт алгарак чыгып:

— Алайса акыл ияләренең сүзен тыңлагыз,— ди.— Киткән кояшны кире кайтару өчен без барыбыз да аның алдында акланырга тиешбез. Кояш безгә ышана башласын, безнең зур ялгыш ясавыбызны аңлаганыбызны, шуңа үкенгәнебезне күрсен. Шуңа күрә бүгеннән башлап һәр хатын-кыз үзенең сөлгесендә өч кояш чиксен. Келәм тукучылар да өч кояш сурәте төшерсеннәр. Өч кояш сурәте ясалган барлык чигүне кояшлы чигү дип атарбыз. Ирләр дә өч кояшны онытмасыннар. Тамгалары арасында шуңа да урын калдырсыннар. Ялгышыбызны аңлавыбызны һәм шуңа үкенүебезне кояшка шулай гына күрсәтә алабыз. Аннары ул бәлки кешеләргә якынрак кайтыр.

— Чыннан да, шуннан соң кешеләр кояшлы чигү чигә башлаганнармы? — дип сорыйм мин, карт көтүчене сүзеннән бүлдереп.

— Әйе,— ди Ендимер бабай.— Шуннан соң сурбан да ясый башлаганнар. Кояш гел күрсен өчен, хатыннар үзләре чиккән сурбан киеп йөри башлаганнар. Һәр сурбанга кояш сурәте чигелгән була бит.

Ләкин куштаннар китергән бәхетсезлек моның белән генә бетми. Алар, еракка качып киткәч, кешеләрдән үч алмакчы булалар. Дөньяга канатлы аждаһалар тудыралар. Бу аждаһалар һавага күтәрелеп, болыт шикелле, күк йөзен каплап ала. Бик югары менеп киткән кояш хәзер кешеләрнең үзләрен дә, яхшы эшләрен дә күрә алмый.

Акыл ияләре:

— Канатлы аждаһаларны утлы уклар белән атып үтерергә кирәк,— диләр.

— Мин ул укларны ясап, канатлы аждаһаларга каршы көрәшә башлыйм,— ди Казял батыр.

Кешеләр, аның бу сүзен хуплап, аучыга бик күп ук әзерләшәләр.

— Хәзер мин канатлы аждаһаларны юк итәм! — дип, Казял батыр җәясен кулына ала, аждаһаларга бер-бер артлы ук җибәрергә керешә. Аждаһалар, канатларына ут кабып, янып төшәләр.

Шулай итеп, бик күп аждаһа юк ителә. Калганнары качып китә. Казял батыр алары артыннан да утлы укларын җибәрә. Һавада менә хәзергә кадәр утлы уклар оча, котылып калган аждаһаларны эзли алар.

Шуннан соң инде аждаһаларның куркынычы бетә.

Кешеләр кояш сурәте чиксәләр дә, кояш һаман якынаймый. Һаман да салкын, биек агачларда тәмле җимешләр үсми, җирне кар каплаган, ачы бураннар котыра.

Кешеләр тагы олы мәйданга җыелып, акыл ияләреннән киңәш сорыйлар.

— Без инде кояш сурәте дә чигәбез, Казял батыр безнең кояш белән дуслыгыбызны бозарга теләгән канатлы аждаһаларны да кырып бетерде. Ә безгә һаман да кояш җылысы килми. Ни чара кылыйк? — диләр.

— Кояш сурәтен чигү өчен янып торган кызыл төс кирәк. Ә бездәге кызыл төс андый булмады. Сәбәбе шундадыр бәлки. Җирдә кар, суык булгач, җете кызыл буяу ясый торган үлән монда үсми хәзер. Үзебез дә аптырыйбыз. Хатын-кызларыбыз сурбан ясый торган дөя йонын манар өчен җете кызыл буяуны каян табарга да белмибез,— ди акыл ияләренең берсе.

Манар өчен хәзерләнгән дөя йоны мәйданда бөтен халык күз алдында өелеп тора. Бөтен кеше, бернинди киңәш әйтә алмыйча, тик карап тора.

Шул вакыт күкрәп әйткән бер тавыш ишетелә:

— Нишләргә кирәклеген мин беләм! — ди Казял батыр.

Аучы, берни булмаган кебек, кынысыннан кылычын чыгара да аны күтәрә төшеп, сул беләгенә китереп чаба.

Үзәгенә үткән авыртуга түзә алмыйча аучы ир чайкалып куя, шулай да егылмый — чыдый. Шуннан соң ул кан агып торган кулын мәйдандагы дөя йоны өстенә китерә. Дөя йоны шундук кып-кызыл төскә манчыла.

Аннары кешеләр Казял батыр канына манчылган йоннан җете кызыл кояш сурәте чигәләр. Хатын-кызлар кояш чигелгән сурбаннарын башларына һәм аркаларына киеп йөриләр. Ирләр дә кып-кызыл кояш чигелгән күлмәк кияләр.

— Ә Казял батыр үзе нишләгән соң? Үлгәнме? — дип сорадым мин.

Ендимер карт минем соравыма җавап бирмәде.

Еракка карап, байтак вакыт тын гына утырды. Аннары, сүз тәртибен бозарга теләмәгәндәй, сөйләп китте:

— Кояш әкренләп кешеләргә якыная башлый.

Карлар эри.

Салкын бураннар басыла.

Елгалардан кар сулары ага.

Кешеләр, җиренең җылынуына, табигатьнең терелүенә сөенеп:

— Яз килде,— диләр.

Бөтен халык тәмле җимеш бирә торган агачларның яфрак ярганын, газиз җиренең мул уңыш китергәнен көтәләр.

Ендимер бабай тагы сүзеннән туктап калды. Берничә тапкыр челемен суыргач, сынаган кебек, миңа карап куйды.

— Әкият сөйләсәм дә, бөртек тә ялган сөйләмәдем,— диде.— Халык уйлаганны гына сөйләп бирдем. Халык сөенгәндә мин дә сөендем. Казял батырның исемен халык беркайчан да онытмас, рәхмәт укып аны гел телгә алыр. Аның һәр чигүендә Казял батыр эше, аның каны, аның өлеше бар.

* * *

Ендимер карт сөйләп бетерде. Мин, халыкның шундый акыллы риваятьләре булуына исем китеп, сүзсез калган идем.

Безнең өстә, очсыз-кырыйсыз күк йөзендә, меңләгән йолдыз җемелдәшә. Аларның үз телләрендә безгә нидер әйтәселәре килә кебек. Бәлки, алар халыкка кояшны кайтарышкан батыр турындагы үлемсез риваятьне безгә тагын бер тапкыр сөйләп бирергә телиләрдер.

Х. ЯХИН тәрҗемәсе.

Абдулла Сәләхетдинов

# РӘШӘ ДИҢГЕЗЕНДӘ АК КОРАБ



Кырлар киңлегендә рәшә тирбәлеп торган кеннәрдә күз салсаң, ерактан гаҗәеп зур корабка охшап күренә ул. Әйтерсең, ап-ак җилкәннәрен киергән дә күз җитмәслек төштә — горизонт артында җәйрәп яткан диңгез буйлап кайдыр йөзеп бара. Аның торбалары һәм ак җилкәннәре шундый биек, ара-тирә -сыек болытлар гүя аларга тиеп-тиеп узалар. Каршыда күренер-күренмәс булып кына тирбәлгән рәшә челтәре аша үтеп китә алсаң, шул ук ак кораб йөзгән диңгезнең ярына барып чыгарсың кебек...

Лениногорскиның үзәк мәйданыннан кузгалып киткән машина шул тарафка җилдерә башлагач, күз алдына шундый хыялый күренешне китердем мин. Нәрсәдән булгандыр андый хыял, аңлатуы кыен. Кышкы йокымсыравыннан уяна башлаган табигатьтәге җанлылыкмы, һаваның баш әйләндергеч сафлыгымы, көләч күк гөмбәзенең күз явын алырлык зәңгәрлегеме, әллә инде ерактан ак җилкәнле зур корабка охшап күренгән корылманың мәһабәтлегеме тудырды бу уйларны — төгәен генә әйтә алмыйм. Һәр хәлдә, тирә-юньдәге бөтен нәрсә:

чалт аяз күк;

чалт аяз күктә елмайган кояш;

кояш нурларына ертелгән тигез асфальт юл, юлның ике ягында насос сиртмәләрен талгын гына тирбәлдереп утырган скважиналар, шул скважиналар янындагы ак резервуарлар — мерниклар;

электр һәм телефон баганаларының бер-берсен куышкандай йөгерешүе... Кыскасы, ел иртәсе — язның тәүге бизәкләре белән индустриаль пейзаж матурлыгын берләштергән күренешләр хыялны канатландырырлык, йөрәкне җилкендерерлек, күңелне әсәрләндерерлек иде.

Ә әсәрләнгән күңелдә нинди генә хыялый уйлар тумас дисең!

Машина кояшлы кырлар буйлап сузылган асфальт тасма өстеннән алга чапты, үтә күренмәле нәфис рәшә челтәре шундый ук тизлек белән артка чигенә барды. Ул чигенгән саен, ерактан корабка охшап күренгән корылма да ачыграк төсмерләнде. Ниһаять, ак җилкәннәр дигәнем — биек колонналарга, кораб үзе зур завод корпусына әверелде.

Менә нинди икәнсең син, Карабаш нефть хәзерләү установкасы: олы да, мәһабәт тә. Бетон нигезләрдән калкып, күкнең зәңгәр гөмбәзенә таба биеккә күтәрелгән колонналарда кояш нурлары чагыла. Шул шаян нурлар инде аксыл төстәге металл белән тышланган конструкцияләрне «сихерлиләр» — көмешкә охшатып күрсәтәләр.

Шундый ук нурлар, идарә каршында тезелеп торган машиналарның тәрәзәләрендә чагыла-чагыла, бер-берләре белән качышлы уйныйлар кебек.

Ул нурлар проходнойда фуфайка җиңенә кызыл тасма бәйләп, иңенә мылтык асып торган олы гына гәүдәле сакчы апаның тулы битендәге сипкелләренә куналар, күзләрен чагылдыралар...

Түгәрәк йөзендә кояш чагылып торган апа бик җитди. Проходнойга якын килергә дә рөхсәт итми:

— Пропускыгыз?! — ди ул.

Әй минем кесәмдә пропуск юк. Аны каян аласын да белмим әле. Карабашка беренче тапкыр килүем. Аны — республикамның нефть индустриясе бастионнарын нан берсен — күреп сокландым, гомергә онытылмаслык итеп карап китәсем килә. Сурәте күңелгә сеңсен, Татарстан кодрәтенең символы булып йөрсен.

— Әнвәр Маннаповичтан рөхсәт алыгыз,— диде мылтыклы апай...

Әнвәр Маннапович Әхмәдиев — Карабаш установкасында баш кеше — директор.

Аның белән күрешкәндә: «Мәһабәт корылманың башлыгы да мәһабәт икән!» дип уйламый булдыра алмыйсың. Озын буйлы, төз гәүдәле, киң җилкәле ир уртасы — Әнвәр Маннапович. Кара тутлы, озынчарак йөзе мөлаем. Куе кара кашлар астыннан текәп карый торган коңгырт күзләреннән чаялык һәм тәвәккәллек сирпелеп торгандай тоела.

Ә болай, көндәлек ыгы-зыгыда, башкалардан берни белән дә аерып булмаслык гади кеше ул. Татарстан нефте данлыклы осталар итеп үстергән меңнәрнең берсе.

Тормыш — дәрья бит: үзе дә гел үзгәреп тора, кешеләрне дә үзгәртә.

Кичәге игенче — бүген «кара алтын» чыгару остасы.

Кичәге гади нефтьче бүген промышленностьның зур тармагына җитәкчелек итә, индустрия фронтында командир. Әнвәр Маннапович Әхмәдиев — шундый.

— Нефтьче булырга язмышым үзе кушкан миңа,— дип шаярта ул.— Нефтькә бай якларда — Ютазы районында тудым бит...

Юк, язмышка буйсынып яши һәм эшли торганнардан түгел ул. Үз дигәнен булдыра торган кеше.

Уба авылында туган игенче улы Әнвәргә: «Нефтьче булсаң икән!» — дип хыяллanып йөгерергә туры килми. Ләззәтле хыялга түгел, кече яшьтән үк нефтьче хезмәтенең авыр мәшәкатьләренә чума ул. Башта — оператор, аннары — мастер. Көндез эшли, кич укый. Армиядә солдат шулпасыннан да авыз итеп кайткач, участок начальнигы итеп күтәрәләр үзен. Менә шунда инде хыяллана башлый ул: «Эх, институтка керәсе иде!» — ди.

Хезмәт юлына аяк баскан чакта ук хыялын нефтьче эшенең мәшәкатьләрендә тапкан егет бу юлы да уй-ниятен имтиханга әзерләнү белән ныгыта.

Мондый кешеләр хыялны эштән, эшне хыялдан аермый күрә беләләр. Икесен бергә үреп, язмыш атын үзләренә кирәкле якка каулыйлар. Алар үз язмышларын үзләре язалар, шәхси тормышларын максатка яраклы итеп коралар.

Игенче иде Әнвәр — нефтьче булып китте.

Нефтьче иде — ил аңа солдат шинеле кидерде.

Вакыты җиткәч, шинельне салды да Әнвәр студент булды.

Һәркайда аңа тәвәккәллек, чаялык һәм тырышлык юлдаш иде. Мәскәүдән Губкин исемендәге нефть химиясе һәм газ промышленносте институтын тәмамлап кайтканда, аның шул юлдашларына тагын берсе — белем дә өстәлде. Белем — тәвәккәлгә таяныч, чаяга — булышчы, тырышка — кодрәт. Шуларның барысына да ия булып, инженер дипломы белән Әнвәр туган якларына кайтты.

Ә туган якларда таудай эшләр башкарыла иде. Нефть индустриясенең яңа бастионнары күтәрелә. Карабашта нефть хәзерләү установкасының да биек-биек колонналары монтажлана.

Тезелештә алдынгы индустриаль метод — атналык һәм тәүлеклек планлаштыру

ысулы кулланыла. Хезмәтне һәм производствоны оештыруның бу яңа формасы төзү эшләренең темпын тизләтә. Берничә сүз белән әйткәндә, индустриаль төзү методының асылы менә нәрсәдән гыйбарәт: бөтен эшләр, еллык һәм айлык заданиегә туры китереп, һәр атна өчен җентекле планлаштырыла һәм учетка алынып барыла. Атналык планда каралган эшләрне тәүлекләргә бүлү нигезендә производство һәм материаль тәэмин итү графиклары төзелә. Трестларда билгеләнгән шул графиклар һәр дүшәмбе саен «Татнефтестрой» комбинатында карала һәм раслана. Комбинатта расланганнан соң, алар трест начальнигыннан һәм баш инженердан башлап гади төзүчегә кадәр һәркем өчен һичшиксез үтәлергә тиешле законга әверелә.

Карабаш төзелешендә шундый челтәрле график буенча эшләүнең өстенлекләре ачык күренде. Ул ике ел да өч ай эчендә төзелеп бетте. Куәте ягыннан аның белән бер дәрәҗәдә торган Павловка установкасы өч ел төзелгән иде. Яңа метод белән эшләп, Карабаш төзүчеләре вакытны тугыз айга кыскарттылар.

Челтәрле графикларның өстенлеге шунда: алар төзелешнең бөтен барышын ахырына кадәр җентекләп планлаштырырга, аның срокларын бер көнгә кадәр төгәллек белән билгеләргә, эшләрне технологик эзлеклелек буенча алып барырга һәм контрольлек итәргә, теләсә кайсы сәгатьтә кирәкле информацияне алырга, күренгән «тар урыннарны» алдан билгеләргә һәм аларны бетерү өчен оператив чаралар күрергә мөмкинлек бирәләр.

Төзелеш әле барган чакта ук булачак установканың директоры билгеләнә.

— Хуҗалык итәргә әзерләнә тор. Тиздән ходка җибәрәчәкбез...— диләр аңа. Әнвәр Маннапович шул көннәрне искә төшерә.

— 1965 елның 6 нчы ноябренда эшләтә башладык корылманы. Онытырлык көн түгел. Бәйрәм алды... Установкаларны көйләү мәшәкатьләре дә, кешеләрнең бәйрәмчә күтәренкелек белән эшләүләре дә, нефтьнең беренче тонналарын хәзерләүгә кабул итү дә, мичләрне кабызып җибәрү дә — барысы да истә...

Монтаж эшләре көз ахырларында гына төгәлләнде. Көннәр кисәк кенә суытып җибәрде. Мондый салкында эшләтә башларга мөмкинме? Шул турыда киңәшергә дип, җиһазлар саткан Австрия фирмаларының вәкилләрен — монтажлауда катнашкан инженерларны промыселлар идарәсенә чакырдылар.

— Җиһазларыгыз һәм монтаж эшләрендә катнашуыгыз өчен рәхмәт, әфәнделәр. Тик... монтажлау төгәлләнде бит инде, үзегез күрәсез... Установканы эшләтә башларга вакыт җитте.

Австрия инженерларының күзләре шар булды.

— Эшләтә башларга?.. Шундый суык көннәрдәме? — диде аларның берсе.— Юк, мин мондый адымны ясый алмыйм. Җаваплылыгы зур, ә гарантия?.. Эшнең уңышлы чыгачагына гарантиягез бармы?..

Чит ил белгечләре барысы да установканы ходка җибәрүдә катнашудан баш тарттылар. Килешү буенча, алар монтажлауда да, әзер установканы эшләтә башлауда да катнашырга тиешләр иде. Моңарчы килешүне әйбәт кенә үтәп килгән белгечләр кирегә сукалый башлады:

— Кышкы шартларда аны ходка җибәрү мөмкин түгел...

Совет инженерлары, бик итагатьле һәм йомшак кына итеп, бу фикер белән килешә алмауларын белдерделәр:

— Без әзер нәрсәне ярты ел буена тик тота алмыйбыз, әфәнделәр. Халык хуҗалыгына зур зыян бу...

Әмма «әфәнделәрнең» үз кырыклары кырык:

— Булмый!..— диделәр.— Яз җитмичә булмый!..

Атна-ун көннән белгечләр киңәшмәгә җыелды. Фирма вәкилләре дә килде. Алар белән сөйләшү озакка сузылды һәм нәтиҗәсез төгәлләнде. Чит ил инженерлары рәсми белдерү белән соңгы сүзләрен әйттеләр:

— Һава салкын чакта установкаларны ходка җибәрүдә беребез дә катнашмаячак. Фирмаларыбызның күрсәтмәсе шундый. Совет инженерлары үзләре генә моны эшләргә алыналар икән — үз ихтыярлары. Ул чагында безнең фирмалар җиһазларның нормаль эшләве-эшләмәве өчен җавап бирмәячәк...

Установканы чатнама суыкта эшләтә башлау — аларның фирмалары файдасына сөйли торган шәп реклама иде, әлбәттә. Австрия белгечләре моны яхшы аңладылар.

Ләкин... хәтәр ягы да бар иде. Әгәр барып чыкмаса, суыкта эшләтә башлаган чакта җиһазлар түзмәсә?.. Юк, юк, ашыгырга ярамый. Җиһазларны сатучылар гына бит алар. Сатып алучылар ашыгалар икән — үз эшләре. Җибәрә алсалар — ярый, ә җибәрә алмасалар, бәла-казага юлыксалар, берәр хәтәр хәл килеп чыкса... Ул чагында да фирмалар оттырмый. Көннәр суык чакта установкаларны җибәрүдә катнашудан рәсми төстә баш тарттылар бит...

— Безнең киңәшне тотарга кирәк иде,— диярләр. Шул гына.

Җиһазларның яңа хуҗалары — совет белгечләре — бу хәлне икенче төрлерәк бәяләде. Монтаж эшләре тәгәлләнгән установканы язга кадәр эшләтми тору, унөч миллион сумлык җиһазларны ярты елга консервацияләп кую — хуҗалыкчыл булмый. Бу арада, исәпләүләр буенча, меңнәрчә тонна нефть хәзерли алачак. Шуның зур өлеше «Дуслык» нефть үткәргеченә җибәреләчәк бит. Юк, техник мәсьәлә генә түгел бу. Аны ничек тә хәл итәргә, уңышлы нәтиҗә бирерлек итеп чишәргә кирәк.

Берничә көннән «Иркеннефть» промыселлар идарәсенең начальнигы белән баш инженеры «Татнефть» берләшмәсенә килделәр. Карабаштан да инженерларны һәм директорны чакырттылар. Берләшмәнең баш инженеры Валерий Исакович Грейфер кабинетында тагын киңәшмә булып алды. «Уңай» һәм «каршы» фикерләрне, карашларны энә күзеннән үткәрде киңәшмә. Соңгы, хәлиткеч карар бер булды:

— Карабаш установкасын ходка җибәрергә!

— Чит ил белгечләре безгә әле җитәрлек таныш булмаган җиһазларны көйләүдә катнашудан баш тарталар икән — хәерле булсын. Установканы язгы кояш елмаячак көннәргә кадәр тик тота алмыйбыз. Хакыбыз юк моңа...

Нигезсез тәвәккәллек түгел иде бу. Киресенчә, инженерлык белеменә, установкаларда эшләячәк кешеләрнең зирәклегенә нигезләнгән, һәр яктан уйланылган тәвәккәллек иде.

Шул киңәшмәдән соң икенче көнне фирма вәкилләрен промыселлар идарәсенә чакырып, соңгы сүзне әйттеләр:

— Эшләтергә булдык... Ә сез... телисәгез, установкаларның ничек эшләвен күргәнче тора аласыз.

Китмәделәр, калдылар чит ил белгечләре. Эшләтә башлауда ярдәм итү максатыннан түгел, билгеле. Ни белән очланыр, янәсе, бу фанатикларның тәвәккәллеге. Иртәнге тугызда автобус аларны эшкә алып килде. Карап, күзәтеп йөрделәр. Кичке дүрттә шул ук автобус аларны яңадан шәһәргә алып китте. Фирма вәкилләренең бөтен «эше» шул булды.

Чит илдән сатып алынган установкаларның яңа хуҗалары — Татарстан нефтендә оператордан үскән инженерлар һәм игенчедән оператор булган Карабаш егетләре көнне төнгә ялгап эшләделәр.

Яңа скрипканы көйләү өчен дә вакыт кирәк.

Яңа чыгарылган мичнең җаена төшенү дә мәшәкатьле: я морҗасы тартмый аның, я кызуы килми.

Ә биредә, Карабашта, нинди зур корылманы көйләргә кирәк. Схемалары катлаулы — техниканың соңгы казанышлары нигезендә корылды бит ул. Совет Татарстаны читтән андый-мондый гына җиһазлар керттерми, булгач — иң камиле, иң яңасы булсын аңа. Дөньяда күрелмәгән гигантларны корырга көч һәм баш җиткәнне, нефть хәзерләү установкасының схемасын гына аңларлык баш, аны гына ходка җибәрерлек көч табылыр.

— Шулай уйладык, үзебезнең көчкә ышандык,— дип сүзен очлауга таба борды Әнвәр Маннапович.— Көйләү эшләре дүрт-биш көннән тәгәлләнде. Установкаларны җибәрдек. Язга кадәр бик күп нефть эшкәртелде. Ул-бу чыкмагае дип, көннәр җылынуын көтеп ятсак, зур оттырыш була иде. Болай үзебез оттык, халык хуҗалыгы отты...

Мин тел очында гына торган соравымны бирми түзмәдем:

— Установканы җибәргән мизгелдә күңелне шик корты борчымадымы соң?

— Саклык хисе өстенлек итте,— дип җавап бирде ул.— Тәвәккәл булу — гамьсез булу түгел бит. Безнең эштә саклык һәр адымда кирәк. Ул тойгы безнең канга сеңгән. Ут һәм нефть янәшә торган җирдә саксызлык була алмый.

...Без установка территориясенә чыгабыз. Директор булгач, кырыс вахтер апа да пропуск сорап тормады.

Аяк астында — бетон плитәләр. Каршыда — зур мич. Анда нефть җылытыла. Янәшәдә тагын бер мич: анысында — су җылына. Уңда һәм сулда — колонналар, һәрьякта — торбалар, торбалар. Ниндиләре генә юк аларның.

— Күзгә күренгән бөтен байлыгыбыз шул инде,— дип елмая Әнвәр Маннапович.

— Ә күзгә күренмәгәне?

— Анысы да шул колонналар һәм торбалар эчендә...

Әйе, аларда «кара алтын» агымы бер минутка да өзелми, ургый да ургый. Промыселлардан товар паркына килгән нефтьне насослар колонналарга куалап тора. Ул колонналар һәм торбалар буйлап көн саен меңнәрчә тонна «кара май» уза. Колонналарның берсе «кара алтынны» «кипшендерә», аның составындагы суны аерып ала, икенчесе җир тозларыннан арындыра. Стабильләштерү установкасы нефтьтән җиңел фракцияләрне — пропан, бутан, пентан һәм гексан дигән газларны аера. Ул газларның кушылмасы — тотрыксыз бензин — Миңлебай газ-бензин заводына һәм тагын да арырак — Түбән Кама нефть химиясе комбинатына китә.

Судан һәм тозлардан арындырылган «кара алтын» иң ерак юлга — «Дуслык» нефть үткәргече буйлап, тугандаш социалистик илләргә озатыла.

Колонналардагы һәм торбалардагы «кара алтын» агымын, аңардан аерылган газлар кушылмасы хәрәкәтен һәм су чишмәсе агышын беркем күрми. Монда бары тик мичләрдә дөрләгән газ ялкынын гына күзәтергә мөмкин. Бүтән процесслар барысы да шул герметик ябык колонналарда бара. Ләкин аларның ничек узуын идарә пультында утыручы операторлар һәрвакыт белеп тора. Аларга бөтенесе мәгълүм, бөтенесе ачык. Әнвәр Маннапович операторларны мактап туймый.

— Барысы да урта белемле. Бездә үскән егетләр. Практик эштә тәҗрибәләре зур.

Бу мактау сүзләре өлкән оператор Миндияр Гарифҗанов һәм технолог Әсгат Габетдиновка беренче чиратта кагыла. Алар установканы монтажлау вакытында ук эшли башлаганнар. Хәзер инде аларны яшь корылманың «картлары» — ветераннары итеп санарга да була.

Идарә пультында бөтен нәрсә операторларның күз алдында. Колонналарның насосларның эше турында кайчан сорашмасыннар, егетләрнең җавабы бер:

— Насослар әйбәт эшли.

— Температура һәм басым — нормаль.

— Һәрвакыт шулай нормаль булсын эшегез, егетләр...— дип, директор каядыр китәргә ашыга, сәгатенә карый.— Кама-Исмәгыйль установкасын җибәрүгә әзерлибез. Ыгы-зыгылы чак...

Без, идарә пультыннан чыгып, яңадан директор кабинетына керәбез. Әнвәр Маннапович, кирә-керешли үк, куен кесәсеннән кечкенә генә блокнот ала.

— Заводның эш күләмен күз алдына китерү өчен бер сан әйтмәкче булам.— Ул блокнот битләрен актара.— Әһә, менә икән: 1968 елда планнан тыш 23 мең 825 тонна нефть экспорт кондициясенә җиткерелде. Ә план буенча әзерләгәне...— Директор өстәлендә яткан счетның төймәләр рәте буйлап миллионнар чыбыгына җитте дә, шактый күп түгәрәкләрне тартып куйды һәм аларны шундук кире чигерде. Ул төймәләрнең санын блокнотыма яза алмый калдым.

— Кама-Исмәгыйль установкасы да эшли башлагач, боларга тагын яңа миллионнар өстәләр. Татарстан миллионнары,— диде ул, ниндидер эчке дулкынлану хисе белән.— Әйе, Татарстан миллионнары!

* * *

Карабаштан чыгып бераз баргач, машина тәрәзәсеннән нефть хәзерләү установкасы ягына карадым. Ул миңа, элекке шикелле үк, зәңгәрсу рәшә диңгезендә каядыр йөзеп барган гаҗәеп зур корабка охшап күренде. Ак җилкәннәрен киергән дә тыныч кына йөзеп бара шикелле. Юк, «шикелле» генә түгел, чынлап та бара ул — ак җилкәнле зур корабка охшаган Карабаш корылмасы.

# БАШ КОНСТРУКТОР

**Егет булсаң, егетлек күргәз илгә.**

УТЫЗ ИМӘНИ.

Һәр заводның үз биографиясе бар.

Бу биографиядә станоклар гөрелтесе, авыр прессларның уфылдау авазлары ишетелә, металл чыңнары яңгырый.

Бу биографиядә корыч эретү мичләрендә дөрләгән ялкыннар биюе, газосварка аппаратларыннан атылган яшькелт яшеннәр уйнавы, ахактай кызарган тимерләрдән як-якка чәчрәгән очкыннарның җемелдәве күренә.

Димәк:

завод биографиясен музыкаль авазлар белән симфония итеп язарга да була.

Завод биографиясен зур полотнода төрле буяулар белән әсәрләндергеч картина итеп сурәтләргә дә мөмкин.

Ләкин аны ничек кенә язсаң да, аның үзәгендә КЕШЕЛӘР булачак. Чөнки:

заводларны кешеләр,

кешеләрне заводлар үстерә!

Бөгелмә механика заводының биографиясе әле бик кыска. Ул моннан ундүрт ел элек кенә башланган. Ләкин барыбер меңләгән эшчеләрнең язмышлары белән үрелгән, шуларның хезмәте белән язылган ул.

Аны иҗат итүчеләрдән берничә кешене генә алам мин.

...Азнакай егете Бәшир Харисов Казан химия-технология институтын тәмамлап монда килгән чакта, предприятие бер яшьлек «сабый» булган. Ул әле продукция җитештерү турында түгел, үз-үзен җиһазландыру хакында гына кайгырта алган.

Унөч ел элек кесәсендә ёр-яңа диплом салып килгән егет — хәзер заводның баш конструкторы. Аның күтәрелүен завод үсешеннән, ә предприятиенең киңәюен Бәширнең һәм йөзләгән-меңләгән башка кешеләрнең хезмәтеннән аерып булмый.

Баш конструктор мине цехлар буйлап йөртә. Заводның үткәнен искә төшерә, бүгенгесе белән таныштыра, киләчәк турында да хыяллана.

— Эзләнүләр чорын кичердек инде без...— дип сөйли Бәшир.— Төп юнәлеш табылды: нефть эшкәртү заводлары һәм химия промышленносте өчен аппаратлар җитештерүгә күчтек. Шул юнәлештә үсәбез...

Кечкенә генә буйлы, бераз юантыграк гәүдәле, салмак хәрәкәтле ир уртасы Бәшир. Ашыкмыйча сөйли, завод биографиясе сәхифәләрен берәм-берәм ача.

Предприятие төзелеш механизмнарын ремонтлау заводы буларак барлыкка килгән. Аны шулай атаганнар да: «Төзелеш механизмнарын ремонтлау заводы». Ләкин яңадан-яңа цехларның сафка керүе, житештерү куәтләренең өзлексез үсүе аның җисемен дә үзгәртә, исемен дә алмаштыра. 1956 елда инде ул «Механика заводы» дип йөртелә башлый. Шуннан соңгы еллар — предприятиенең кызу темплар белән үсү һәм киңәю чоры.

1957 ел. Производствоның нигез куәтләре — төп корпус белән кайнар цехлар блогы сафка кертелә. Шул ук елның язында вагранка монтажлау тәмамлана һәм беренче чуен алына. Сентябрь ахырларында югары ешлыклы индукцион мичтә беренче корыч эретелә. Цехларда металл кисү һәм кыру станоклары, авыр пресслар урнаштырыла, компрессорлар монтажлана, кран-балкалар куела.

— Ул елда безгә ике куаныч бергә килде.— Баш конструктор сирәк гына елмая. Аның кара тут йөзе түгәрәкләнеп китә.— Куанычның иң олысы шул: заводның беренче чират комплексы тулысынча сафка керде...

Нефть аппаратлары цехына керәбез. Монда «кара алтын»ны эшкәртү заводлары һәм химия промышленносте өчен бик кирәкле җиһазлар — җылылык алмаштыргыч аппаратлар һәм үзәктән кудыргыч насослар эшләнә.

Җылылык алмаштыргыч аппаратлар тышкы яктан бик гади булып күренәләр. Икә очы да махсус капкачлар белән ябылган юан труба. Артык озын да түгел үзе. Мин

аларны зоопарк бассейнында башларын өскә калкытып яткан бегемотларга да охшаттым. Моны Баширга әйткәч, ул көлемсерәп җавап бирде:

— Корпуслары шуңа охшата аларны.— Үзе шундук җылылык аппаратының төзелеше турында сөйләргә кереште.— Менә шушы бегемотка охшаган аппарат корпустан, фланецлардан һәм нечкә көпшәләр көлтәсеннән гыйбарәт инде ул...

Баш конструктор бер очы әле ябылырга өлгермәгән аппаратка ияләде.

— Күрәсезме, күпме көпшә!..

Корпусның куыш эче бер-берсенә якын гына урнаштырылган һәм очлары тигезләп киселгән көпшәләр белән тутырылган. Әйтерсең, умарта кәрәзе. «Фланец» дигәннәре исә шул көпшәләр урнаштырыла торган тишекле түгәрәкләр булып чыкты. Аларны элегрәк коеп ясаганнар.

— Математик исәпләүләр нәтиҗәсендә без мондый фикергә килдек.— Харисов үзе фланецларның берсенә төртеп күрсәтте.— Боларны штамплау юлы белән дә ясарга мөмкин икән. Практика бу ышанычыбызны ныгытты. Штамплау ысулы белән ясалган фланецлар кую аппаратларның авырлыгын киметүгә китерде, конструкцияне дә үзгәртергә мәҗбүр итте. Соңгысын эшләү җылылык алмаштыргычның эффектлылыгын ун процентка арттырды. Элеккеге ун аппарат урынына яңа конструкциядәге тугыз җайланма җитә...

Харисов үз заводын илдә беренче, дөньяда данлыклы итеп күрергә тели. Хыялланырга җирлеге дә бар. Предприятие җитештерә торган аппаратлар бик күп илләргә озатыла. Польша, Румыния, Берләшкән Гарәп Республикасы, Эфиопия, Куба... Механика заводының продукциясен алдыручы илләрне саный башласаң, ике кулның бармаклары гына җитәрлек түгел.

Илебездә иң зур диаметрлы аппаратларны хәзергә шушы предприятие генә җитештерә. Әле күптән түгел генә монда, Советлар Союзында һәм дөньяда беренче буларак, «Гипронефтемаш» институтының сызымнары буенча үзәктән кудыргыч насослар ясауга керештеләр. Бу насослар үзләренең поршеньлы ишләренә караганда күп тапкыр уңай һәм җиңелрәк. Поршеньлы насосларның авырлыгы егермешәр тонна булса, үзәктән кудыра торганнары — 3,3 тоннадан артмый. Татарстан нефтьчеләре аларны дүрт күз белән көтәләр, бик теләп алалар. Харисовның әйтүенә караганда, Азнакайдагы беренче номерлы бораулау конторасы эшчеләре яңа насосларны сынап караганнар: хезмәт җитештерүчәнлеге шактый күтәрелгән.

Үзәктән кудыргыч насосларны җитештерү — катлаулы процесс. Бу яңа эшнең мәшәкатьләре корыч кою цехыннан ук башлана.

Насосларның аерым детальләре иң югары сыйфатлы корычтан коела. Аларның формалары да үтә катлаулы. Коелган детальне кирәкле формага җиткерү өчен кырукисү станокларында бик озак эшкәртергә туры килә. Эшне тизләтү юлын эзлиләр. Корычны булачак деталь формасына коярга кирәк, дигән фикер туа. Моңа ирешелсә, детальләрне станокларда эшкәртү вакыты да кыскарачак, корыч та экономияләнәчәк. Ләкин моны ничек эшләргә?

— Җавапны Хөснетдинов тапты,— ди баш конструктор.— Аның тәкъдиме буенча, детальләрне кирәкле формадагы даими савытларда коя башладык.

...Мөхәммәт Хөснетдинов — кою-тимерчелек цехы начальнигы. Без кергәндә, ул үзенең эш урынында иде. Чандыр гына йөзле, урта буйлы, төз гәүдәле ир уртасы. Күп йөргән, күпне күргән кеше, югары мәгълүматлы инженер. Сарман якларында Ран Тамак авылында туган. Урта мәктәптә укуны Уралда башлаган. Бөгелмәдә тәмамлаган. Аннары Мәскәү... Корыч институты... Дипломлы инженер... Кемерово өлкәсендәге бер заводта мастер. 1960 елда Бөгелмәгә күчерәләр. Механика заводында цех начальнигы булып инде җиденче елын эшли.

Бирелә корыч коюның яңа ысулын производствога кертү турында сүз чыккач, ул кинәт кенә:

— Мине урынсызрак мактыйлар,— дип куйды.

— Нишләп алай дисез, Мөхәммәт Садриевич?

— Күршеләр тәҗрибәсен генә файдаландык без. Пермь өлкәсендәге бер заводта корычны шулай койганнарын беләм. Дөрес, аларда бүтән детальләр, бездә — бүтән... Катлаулырак... Аерма шунда гына.

— Алдынгы тәҗрибәне производствога кертү — үзе дә новаторлык бит, Мөхәммәт Садриевич,— дип каршы төште аңа Бәшир.— Новаторлыкны мактамаска кушасыңмыни?

— Белмим, белмим...— Хөснетдинов мыек астыннан гына көлемсерәп, сүзне икенчегә борырга тырыша.— Күршеләр тәҗрибәсе ярап торды безгә. Эшне җиңеләйтә төште, үзкыйммәт шактый кимеде.

Мөхәммәт Хөснетдиновның тыйнаклыгы турында Бәшир миңа алдан ук әйтеп куйган иде. Шуңа күрә цех начальнигының болай сөйләшүе мине гаҗәпләндермәде. Мин аңа сокланып карадым. Тыйнак кеше, намуслы белгеч тора иде безнең алда. Заводта корыч кою эшендә борылыш ясаган ысулны кертү — аның өчен гадәти хәл. Ул моны үзенең вазифасы, бурычы дип саный. Уйлаганы — эшне җиңеләйтү, кайгыртканы — үзкыйммәтне киметү.

— Эшләгәч, уйланасың инде анысы,— ди ул.— Уйланмыйча гына тибелгән туп та капкага керми. Максат кирәк, юнәлешең булу кирәк...

— Син рационализаторлык мәйданындагы «туплар» турында сөйлә, Мөхәммәт Садриевич. Ничәне керттең инде?

Ни әйтер икән дип, Хөснетдиновка текәлдем.

— Билләһи, санаганым юк! — диде ул.— Теләсәгез, ышаныгыз, теләмәсәгез...

Бәшир, аның шулай әйтәчәген алдан белгән шикелле, артык кәефсезләнмәде.

— Ярый, алайса,— дип куйды ул.— Лилия Садыйковадан белешербез инде.

...Лилия Садыйкова — рационализаторлар һәм уйлап табучылар белән эшләү бюросының технигы. Хезмәте шундый: заводта ничә рационализатор һәм уйлап табучы бар, аларның кайсы нинди ачыш ясаган, нәрсә уйлап тапкан — барысын да белеп торырга тиеш Лилия.

Башта мин Хөснетдиновның ачышлары белән кызыксындым, билгеле.

Садыйкова калын генә кенәгәне тиз-тиз актарып чыкты да әйтеп куйды:

— Былтыр тугыз тәкъдиме булды. Шулардан җидесе производствога кертелгән. Алардан алынган экономик файда — 14 мең 568 сум.

— Ел саен шулаймы?

— Тәкъдимнәрне артыграк биргән еллары да бар. Хөснетдинов — иң актив рационализаторларыбызның берсе.

Лилия Садыйкова заводтагы уйлап табучыларның социалистик йөкләмәләр алуларын, ул йөкләмәләрне үтәү өчен көрәшүләрен сөйләде. Ярыш В. И. Ленинның тууына 100 ел, Татарстанның 50 еллыгына багышлана. Хөснетдинов та сүз биргән: 1970 елда кимендә биш мең сум экономия китерерлек тәкъдимнәр кертергә!

Заводны шундый кешеләр корган.

Заводны шундый ир-егетләр киңәйтә.

Эш өчен шулар ялкынлана.

«Рационализаторлар һәм уйлап табучылар» кенәгәсенә былтыр йөз дә биш исем теркәлгән. Ә быелның ике ае шуларга тагын 37 кешене өстәгән. Ике айга — утыз җиде тәкъдим. Һәр ике көннең берендә кемдер ачыш ясый, кемдер яңалык кертә. Кечкенә ачышмы ул, зурмы — хикмәте анда түгел. Хикмәт шунда: кешеләр туктаусыз эзләнәләр. Ә эзләгән — таба. Уйлап табучылар кенәгәсендә дипломлы инженер исеме белән янәшә генә гади эшчеләрнең фамилияләре дә теркәлгән:

«Шафиев Х. Р. Столяр. Партиясез. Ел буена уникe рационализаторлык тәкъдиме бирде. Тугызы уңай бәя алды һәм производствога кертелде...»

«Жерноков Н. А. Слесарь. КПСС члены. 1969 елда унөч тәкъдим бирде. Барысы да производствога кертелде. Тәкъдимнәренең экономик файдасы — 4650 сум...»

Рационализаторлык тәкъдимнәре станокларны камилләштерүгә, эш урыннарында өстәмә җайланмалар булдыруга — кыскасы, хезмәтне җиңеләйтүгә, продукциянең үзкыйммәтен киметүгә юнәлдерелгән.

Ике слесарь — В. И. Крюков белән А. Н. Синяшин югары ешлыклы иске электр установкасын «яңартып» җибәргәннәр. Искергән, сафтан чыккан дип исәпләнгән җайланма гөрләп эшли. Заводка бу елына ике мең сумга якын табыш бирәчәк. Берниндипланда каралмаган өстәмә керем!

Шулай, тамчылардан диңгез җыела, сумнардан миллионнар — халык байлыгы туплана.

...Бәшир Харисов мине үз хуҗалыгына — конструкторлык бюросына алып керде. Бу — заводның иң яшь бүлеге. Моңарчы предприятиегә кирәкле сызымнарны Мәскәү һәм Ленинград институтлары әзерләп биргән.

— Былтыр үзебез эшли башладык инде,— ди Бәшир.— Җитлегүебез шушыдыр... Сызымнар патшалыгы киләчәк өчен дә эшли. Кем-кем, ә конструкторлар яхшы белә: заводның җитештерү куәте һаман артачак, аңа таләпләр дә үсәчәк. Камиллекнең чиге булмаган кебек үк, камиллеккә омтылышның да чиге юк. Завод җитештерә торган аппаратларны камилләштерү бурычы бүген дә көн тәртибенә куелган, иртәгә дә шулай булачак. Шул ук вакытта аларның үзкыйммәтен дә киметергә кирәк. Димәк, туктаусыз эзләнергә! Бәшир шул хакта сөйли. Аның сүзләрендә бүгенге чынбарлык иртәгә тормышка ашачак хыял белән үрелә. Баш конструктор уйлары минем күңелемдә завод кешеләренең уй-хыяллары булып урнаша.

— Хәзер корычтан коя торган детальләрне киләчәктә пластмассадан ясарга керешәчәкбез. Аның корычны алмаштырырлык төрләре бар инде.

Бәшир ике кулына ике деталь ала. Алар икесе дә — «турайткыч аппарат»лар. Аерма тик шунда гына: берсе корычтан коелган, икенчесе пластмассадан ясалган.

— Һәр насоста боларның саны җитмештән артык,— ди Харисов.— Корычтан коелганы биш сумнан да кыйммәтрәк, пластмассадан ясалганы — 1 сум. Авырлык ягыннан да аерма зур: корычы килограммнар белән үлчәнә, пластмасса граммнар белән.

Бәшир ике детальне кулында уйнатып карый да өстәлгә куя, пластмассадан ясалган детальгә карап тора.

— Төмән нефтьчеләре өчен шәп булачак безнең насослар. Җиңел бит — вертолетка элдерәсең дә, кирәк җиргә җилтерәтеп кенә илтеп куясың...

Завод тәрәзәсеннән тышка, кар каплаган урамга карап, Төмән якларында нефть чыгаручылар турында уйлый Бәшир, аларның да хезмәтен җиңеләйтү турында хыяллана.

Табигый: ир булган ир иле турында уйлый. Иле турында уйлап, эшенең зурлыгын тоя, заводның тарихын иҗат итә.

# НУРЛЫ ҖЫРЛАР ОСТАСЫ

Заһид Хәбибуллин татар совет музыка сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән хөрмәтле композиторларыбызның берсе. Татарстанның төрле шәһәрләрендә һәм авылларында, район үзәкләрендә, шулай ук чит өлкәләрдә куелып килгән концертларда аның берсеннән-берсе матуррак уңнарча җырлары яңгырый. Симфоник оркестрлар ул язган инструменталь әсәрләрне башкара, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә Заһид ага Хәбибуллинның «Раушан» балеты зур уңыш белән бара. Кыскасы, композиторның иҗаты мул, төрләргә бай һәм кызыклы. Халык ул иҗат иткән әсәрләрне яратып кабул итә һәм аларга югары бәя бирә.

Моның сере нәрсәдә соң? Җавап бер — Заһид аганың гаять үзенчәлекле, кабатланмас музыкаль стильгә ия сәләтле композитор булуында.

Заһид Хәбибуллин иҗаты, аның музыкаль теле иң мөһим ике сыйфаты белән аерылып тора. Аның беренчесе — гражданлык хисе, икенчесе — халыкчанлык.

Үз иленең патриоты буларак, Заһид Хәбибуллин Ватан язмышы, халык тормышындагы вакыйгалар белән һәрвакыт бергә яши, заманга хас актуаль мәсьәләләрне, чор сулышын үзенең әсәрләрендә чагылдырып барырга омтыла. Бөек Ватан сугышы елларында композитор халыкны фашист илбасарларына каршы көрәшкә өндәгән «Команда, алга!» (Г. Кутуй сүзләре), Совет партизаннарының батырлыгын сурәтләгән «Егет-партизан» (Н. Арсланов сүзләре), тылда эшләүче хатын-кызларның иң изге теләкләрен белдергән «Җиңеп кайт» (К. Нәҗми сүзләре) һәм «Сугышчан егеткә хат» (халык сүзләре) дигән җырлар иҗат итә. Сугыштан соңгы елларда Заһид Хәбибуллин Совет халкының җиңүен һәм аның иҗади тыныч хезмәтен мактаган җырлар яза.

Заһид Хәбибуллин әсәрләре халыкчанлык көченең зурлыгы белән аерылып тора. Билгеле булганча, халык җырлары композиторларыбыз өчен илһам чишмәсе булып тора. Шуны әйтергә кирәк, чылтырап аккан чишмәнең нинди юллардан борылып-борылып агып килгәнен аңлаган кеше генә аның сафлыгын, матурлыгын күрә белә. Халык көйләре дә шулай. Аларны тыңлый, ишетә белгән, аларның үзенчәлекләрен, алардагы музыкаль алымнарны аңлаган иҗатчы өчен генә халык көйләре бай җирлек була ала. Һәр композитор, үз сәләтеннән, табигатеннән чыгып, халык көйләренең тегеяки бу төре белән аеруча кызыксына. Берәүләрне халкыбызның бәетләре үзенә тарта, икенче кешеләр озын, моңлы көйләрне ярата төшәләр. Заһид Хәбибуллинга исә халкыбызның кыска авыл көйләре, күңелле, дәртле җитез биюләре аерата якын. Һәм композиторның әсәрләрендә, бигрәк тә җырларында, шундый халык көйләренең йогынтысы өстенлек ала да. Бу фикерне раслау өчен, композиторның утызынчы елларда барлыкка килгән «Җырым булсын бүләгем» (М. Җәлил сүзләре), «Батыр егеткә» (Ә. Ерикәй сүзләре) дигән җырларын, «Бишле бию»ен, сугыш еллары җырларыннан «Җиңеп кайт», кырыгынчы елларда Гамир Насрый белән иҗади дуслыкта язган җырларыннан «Бригадир кыз Гөлниса», «Сабанчы егетләр», «Сайра син, тургай», «Комбайнчылар җыры», илленче еллар җырларыннан «Баулылар» (Н. Арсланов сүзләре) дигәннәрен исәбезгә төшерик. Бу җырларның күбесе колхозчыларның, нефтьчеләрнең ашкынулы, шатлыклы хисләрен, күтәренке күңел белән эшләүләрен тасвирлый. Аларның музыкасы күңелле, җанлы һәм хәрәкәтчән. Композитор бу җырларында халкыбызның авыл көйләренә, такмакларга, бию көйләренә хас музыкаль алымнарны



иҗади файдалана, ул аларны йөрәгеннән үткәреп, көйгә яңа яңгыраш бирә. Җырларның мелодияләре, төзелеше гади, җиңел, күңелдә калучан. Җырларның музыкасын баета торган тагын бер сыйфат бар. Ул да булса ритм. Заһид Хәбибуллин әсәрләрендәге ритм кызыклы, мавыктыргыч һәм житез.

Мәгълүм булганча, музыкаль әсәрдәге авазлар я озын, я кыска булып яңгырыйлар. Әсәрдә музыкаль авазларның озынлык ягыннан бер-бер артлы урнашуы һәм аларның үзара бәйләнештә булуы ритмны тәшкил итә. Әгәр дә кейдә музыкаль авазлар гел бер озынлыкта булып кабатланалар икән, көй эчпошыргыч бер нәрсәгә әверелә. Шуңа күрә һәр композитор, әсәр иҗат иткәндә, аның ритмын төрлеләндерергә омтыла һәм ритмны әсәрнең характерын ачуга буйсындыра.

Заһид Хәбибуллинның алтмышынчы елларда язылган җырларыннан «Казакъ дустыма» һәм «Казакъ кызы сөйгәнем» дип исемләнгәннәренә аерым тукталасы килә. Алар ритмик яктан иң кызыклы, иң хәрәкәтчән әсәрләр. «Казакъ дустыма» һәм бигрәк тә «Казакъ кызы сөйгәнем» дигән җыр тамашачыларның, тыңлаучыларның күңелен тиз арада биләп алды, бу җырларны хәзер һәркем сокланып һәм рәхәтләнеп тыңлый. Мондый бәхетле язмыш сирәк музыкаль әсәрләргә генә очрый. Бу ике җырда да казакъ һәм татар халкы арасындагы эчкерсез дуслык тирән чагылыш тапкан. Композитор җырларның музыкасында татар һәм казакъ халык көйләренә хас музыкаль алымнарны иҗади берләштереп яңа аһәңле әсәрләр язган.

Композиторның казакъ халык музыкасына мөрәҗәгать итүе очраклы хәл түгел. Заһид ага яшьлек елларын Казагыстанда уздыра. Ул Казагыстанның киң далаларында яңгыраган моңлы һәм дәртле халык көйләрен күңеленә сеңдерә һәм алар композиторның йөрәгендә гомер буена бетмәс-төкәнмәс иҗат чыганагы булып калалар. Заһид Хәбибуллин казакъ халкының гореф-гадәтләрен, телен өйрәнә, ул казакъча оста сөйләшә белә. Болар бар да аның иҗатына сизелерлек йогынты ясыйлар һәм татар совет музыкасында моңарчы һич тә очрамаган яңа аһәңле җырлар тудырырга җирлек булалар. «Казакъ дустыма» һәм «Казакъ кызы сөйгәнем» дигән җырларны дуслык хисләрен тирән чагылдыруы, ачык образлы, кызыклы ритмнарга корылуы, төзелеш ягыннан кызыклы булулары өчен иң уңышлы җырларның матур үрнәкләре итеп санарга мөмкин.

Композиторның иҗатында озын, моңлы җырлар да бар. Шундыйлардан утызынчы елларда Муса Җәлил сүзләренә язылган «Сагыну» җырын күрсәтергә кирәк. Бу әсәр тыңлаучылар арасында шулкадәр киң таралды, хәтта кайбер авылларда аны халык көе итеп саныйлар. Матур тел белән язылган шигъри текст композиторны тыңлаучыларның күңел кылларын тибрәтерлек көй тудырырга илһамландыра. Бу көй халык моңнарына бик якын һәм башкару өчен уңай язылган. Җыр кешенең эчке кичерешләрен ачык, тулы итеп чагылдыра. Кырыгынчы елларда иҗат ителгән «Иркәмә», «Зәңгәр» (Г. Насрый сүзләре), «Кечкенә Идел» (Ш. Маннур сүзләре) дигән ягымлы лирик җырлар концертларда әле дә гел яңгырап киләләр.

Композитор иҗатының тагын бер бик якты бизәге — «Бормалы су» татар совет музыкасында хәзерге заман уен җырларының иң матур үрнәге санала ала. Сылу, уңган кызларга багышланган бу җыр үзенең гаҗәп саф, нәфис көе белән һәр йөрәккә барып житә һәм аны дулкынландыра. Заһид Хәбибуллин бу талантлы әсәре белән үзен эзләнүчән, тирә-юньдәге тормышның матурлыгын күрә белүчән художник итеп танытты. «Бормалы су» җыры үзенчәлекле көе, төзелеше белән башка җырлардан аерылып тора. Җырның музыкасында лирик рус һәм хәзерге заман татар халык көйләрендәге музыкаль алымнар бик оста рәвештә бергә кушылганнар.

Композитор әсәрләре арасында лирик җырлар да аз түгел. Әмма аның иҗатында күңелле, житез, күтәренке рухтагы җырлар тагын да күбрәк һәм аларның саны ишәя

тора. Мәсәлән, соңгы вакытта язылганнарының шактые дәртле, җанлы әсәрләр. Менә алар — «Безнең кардәшлек» (Г. Зәйнашева сүзләре), «Солдат җыры» (К. Латыйпов сүзләре), «Мактанчык егет» (һ. Солтанов сүзләре).

Заһид Хәбибуллин татар халык көйләрен эшкәртүгә зур игътибар бирә. Ул эшкәрткән уңышлы көйләрдән «Арча», «Сарман», «Берсе алма, берсе хәрмә», «Уракчы кыз», «Җаныем-бәгырем» һәм башкаларны күрсәтергә мөмкин.

Инде аз гына композиторның балетларына тукталыйк.

Заһид Хәбибуллин, җырлар, скрипка өчен әсәрләр язу белән бергә, балет жанрында да эшли һәм бу аның өчен бик табигый хәл.

1950 елда Заһид Хәбибуллин, композитор Николай Пейко белән берлектә, «Язгы җилләр» балетын яза (Фәйзи Гаскәров либреттосы). «Язгы җилләр» — заман темасына язылган беренче татар балеты. Балеттагы вакыйгалар 1917 елның июль көннәреннән алып Октябрь революциясенең җиңүенә кадәрге чорны үз эченә ала. Әсәрдә төп герой — көрәшүче революцион халык. Зур иҗтимагый вакыйгалар фонында яшь кыз Нәсимә, аның энесе Гәрәй, эшче Гриша, большевикларның яшерен оешмасы җитәкчесе Алексей Халявин, ак офицер Мөбәракша, фабрикант Юныс бай һәм башкаларның шәхси язмышлары үстерелә. Балетның музыкасында гражданнар сугышы чорындагы рус һәм татар фольклоры, татар халкының көнкүреш һәм шәһәр җырлары киң файдаланылган. Балетта күмәк күренешләр, аерым алганда Маевка һәм тимерчелектәге күренешләр, музыкаль яктан уңышлы чишелгәннәр.

1960 елда Заһид Хәбибуллин үзенең «Раушан» исемле икенче балетын тәмамлый (Габдрахман Сәлимов либреттосы). «Раушан» балалар өчен язылган балет һәм ул әкиятләргә корылган. Әсәр тапкыр, кыю кыз Раушан, аның шук һәм кире, сугыш чукмары һәм мактанчык энесе Гали, аларның явыз һәм усал убырлы карчык патшалыгында йөрүләре, төрле хәлләргә очраулары турында сөйли. Тамашачы сәхнәдә үз балаларының бәхете өчен янып йөрүче Саҗидә апаны һәм явыз көчләргә каршы көрәштә кешеләргә ярдәм итүче сихерле Энҗе үрдәкне күрә.

Композитор балеттагы һәрбер төп герой өчен гаҗәп кызыклы музыкаль детальләр һәм мотивлар тапкан. Уңай образларны ул ягымлы һәм моңлы музыка, халык көйләре һәм биюләре белән тасвирлый. Тискәре образлар исә коточкыч ямьсез, колакка ятышсыз авазлар белән сурәтләнә. Балетта малайлар көрәше, аучы биюе, беренче пәрдә финалы, икенче пәрдәдәге биюләр һәм марш — барысы да тамашачыны кызыклы, сихри әкият дөньясына алып керә.

Музыкада ритмнар байлыгы чиксез. Бу исә балет өчен аеруча кирәкле шарт. Балет музыкасында «Каз канаты», «Былбылым», «Яз да була» көйләре, «Сак-сок бәете» һәм балалар җырларыннан алынган интонацияләр шактый күп. Балаларыбызны сәнгатькә якынайтуда «Раушан» балетының әһәмияте искиткеч зур.

Композитор Татар дәүләт академия театрының төрле спектакльләренә (Г. Насрыйның «Кушнарат», Г. Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» исемле романы буенча эшләнгән «Яшьлек иртәсе», Р. Ишморатның «Якын дус», «Серле моң» һ. б.) музыка язды. Бу спектакльләрдән «Агымсу», «Йолдыз», «Минем Харис — тракторист» дигән җырлар аерым әсәр буларак та башкарылалар.

Заһид Хәбибуллин үзен композитор буларак кына түгел, ә скрипкачы, халык көйләрен оста башкаручы итеп тә танытты. Ул озын көйләрдә моңлы борылышларны бөтен нечкәлеге белән тоеп уйный, кыска бию көйләрен темперамент белән башкара.

1950 елда татар совет музыкасын үстерүдәге зур хезмәтләре өчен Заһид Хәбибуллинга **Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде. 1968 елда «Безнең кардәшлек», «Солдат җыры», «Бормалы су», «Гөлләрем», «Казакъ кызы сөйгәнем», «Мактанчык егет» дигән җырлары өчен Заһид Хәбибуллин Тукай премиясе белән бүләкләнде.

20 сентябрьдә Заһид Хәбибуллинның туган көне. Аңа быел 60 яшь тулды. Бу — композитор талантының иң җитлеккән, иң өлгергән чагы: тәҗрибә тупланган, каләм шомарган, бары тик язарга, язарга һәм язарга!

Берсеннән-берсе матур әсәрләр иҗат иткән өчен Заһид агага мең-мең рәхмәтебезне белдерәбез һәм киләчәктә аңардан яңадан-яңа әсәрләр көтеп калабыз.

**МАҺИНУР ҖИҺАНШИНА,**
музыка белгече.

Дания Гыймранова

# ТЫНГЫСЫЗ КЕШЕ

Габдулла ага белән инде бүген генә өченче мәртәбә очрашабыз. Беренче тапкыр иртән сәгать тугызларда очраштык. «Хөсәен Ямашев» исемле постановкада катнашу өчен, аны радиога чакырганнар иде. Шуннан Габдулла ага театрга китте: сәгать унбердә «Тирән тамырлар» спектакленең репетициясе башланачак икән. Сәгать икеләр, өчләр тирәсендә мин аны СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында тарих фәннәре докторы Альфред Халиков бүлмәсендә очраттым. Соңыннан белдем: Габдулла ага борынгы архитектурабыз турында мәкалә язарга йөри икән. Моның өчен аңа дистәләгән фәнни китаплар белән танышырга, газета-журналлар актарырга туры килгән.



Күрәсез, ул инде күпме эш эшләргә өлгерде. Артистның шатлык-кайгылар, борчу-мәшәкатьләр белән тулы киеренке иҗат көне исә әле башланып кына килә бит. Институттан, ихтимал, Габдулла ага театр училищесына йөгерер. Анда аны укучылары көтә. Ә кичен Академия театры сәхнәсендә — «Хуҗа Насретдин» комедиясе... Төнге сәгать унбер. Әле генә спектакль тәмамланган. Кичке шәһәр урамнары буйлап кечерәк буйлы, түгәрәк гәүдәле, җитез хәрәкәтле бер кеше кайтып килә. Көн буена эшләп инде шактый арылган да, тик иҗат көне әле тәмамланмаган: өйдә аны Шекспир, Толстой, Чехов, Тукай, Исәнбәт, Хәсни әсәрләре көтә.

Әйе, РСФСРның халык артисты Габдулла ага Шамуков чын мәгънәсендә күп кырлы талант иясе. Ул актер, нәфис сүз остасы, педагог, бер үк вакытта мәсәлче, тәрҗемәче һәм күп санлы фәнни мәкаләләр авторы да. Бу кеше һәрнәрсә белән үтә нык кызыксынучан. Дөньяны танып-белүе, аңлавы гаҗәеп киң аның. Шунлыктан аның белән һәр очрашып сөйләшү күңелдә куанычлы, якты тәэсирләр калдыра. Һәрвакытта да тере, чая сүзле, җор табигатьле Габдулла абыйның эрудициясенә сокланмый мөмкин түгел! Шул ук сыйфатлар аның актерлык осталыгын да билгели.

* * *

Г. Шамуковның актерлык иҗаты 30 елларда башкорт театры сәхнәсендә башланып китә.

Әле 1934 елда ук Башкорт театрының художество җитәкчесе, режиссер Мөкәрәм Мәһдиев яшь артист Шамуков хакында болай дип яза: «Сүз остасы Шамуков, оста декламатор булуы белән бергә, бик ялкынлы артист та. «Алатау» пьесасында шагыйрь, «Чит кеше баласы»ндагы Караулов, «Ревизор»дагы Добчинский — аның күренекле эш-

өре. Аның иҗади эшенә тикшерүчәнлек, эзләнү, кызыксынучанлык хас һәм ул, башкаларга үрнәк булырлык дәрәҗәдә, әдәбият белән нык таныш. Аның шул сыйфатлары, киләчәктә дә дөрес юлдан барганда, театрга аннан зур эшләр көтәргә, хаклы рәвештә өмет багларга мөмкинлек бирә»[1].

Һәм, чыннан да, театр җитәкчелеге ялгышмый. Кыска гына бер ара эчендә Шамуков берсеннән-берсе кызыклы, берсеннән-берсе оста гәүдәләндерелгән дистәләрчә образлар иҗат итә. Алар арасында М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм»еннән Найденов, А. Таһировның «Соңгылар»ыннан комсомолец Тавил, Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр»еннән Сәйфулла, С. Мифтаховның «Зимагурлар»ыннан лавочник Шаһгали, М. Горькийның «Егор Булычев һәм башкалар»ыннан Алексей Достигаев, «Тормыш төбе»ннән Барон, Ф. Шиллерның «Юлбасарлар»ыннан Герман, Гогольнең «Өйләнү»еннән Подколесин, Н. Островскийның «Корыч ничек чыныкты»сыннан Сережа, М. Гафуриның «Кара йөзләр»еннән Сәгыйт, Вс. Ивановның «Бронепоезд 14-69»ыннан Вася Окорок кебек образлар бар. Бу исемлек үзе генә дә актерның никадәр төрле һәм капма-каршы характердагы рольләр өстендә эшләве турында сөйли. Әмма үзләренең асыллары, эчтәлекләре белән никадәр генә төрле булып күренмәсеннәр, Шамуков башкарган әлеге образларның барысы өчен дә кайбер уртак сыйфатлар хас. Аларда без 30 еллар өчен характерлы тормыш ритмын, заман сулышын тоябыз. Бу бигрәк тә совет чынбарлыгын сурәтләүгә багышланган әсәрләрдәге образларда нык сизелә. Искелектән, караңгылыктан, томаналыктан яңа арынып-уянып килгән «кара борынлы» авыл малаемы, әллә инде яңа тормышның беренче кирпечләрен салышучы эшче комсомолецмы — аларның һәркайсын Шамуков бөтен бер характер, кешелек горурлыгы уянып килгән көчле шәхес итеп сурәтли. Аларның һәрберсенә җирдәге явызлыкны, гаделсезлекне күрә алмау хисе, яңа, ирекле тормыш төзү эшенә кыю һәм актив төстә катнашырга омтылу хас. Актерның башлангыч чор иҗатында барлыкка килгән шушы поэтик агым, шушы төп алым киләчәктә Г. Шамуков иҗатының иң үзенчәлекле, иң матур сыйфатларыннан берсенә әверелəчәк. Һәм ул сыйфат, кызыл җеп булып, артистның бөтен иҗаты буенча сузылачак.

1939 елда Башкорт дәүләт академия театры Әхмәт Фәйзинең «Тукай» драмасын сәхнәләштерергә була. Тукай образы яшь актер Шамуковка тапшырыла.

Габдулла Тукай!.. Ул — халыкның иң яраткан шагыйре. Аның шигырьләре халык моңы, халык дәрте, халык хыяллары белән тулы. Артист өчен мондый рольне башкарудан да мактаулырак һәм җаваплырак бурыч булырмы икән?! Габдулла ага Шамуков, үзе башкарган Тукай роленә тукталып, болай дигән иде:

«Меңнәрнең йөрәгендә моң һәм җыр булып яңгыраган Тукай образы минем өчен дә бик якын һәм кадерле. Тукай минем шәхси һәм иҗат тормышымда тирән эз калдырган, мине бөтенләе белән биләп алган шагыйрь. Ул минем бик бәләкәй чагымнан ук хәтеремә сеңеп калган. Минем әнием гади бер татар хатыны Тукай шигырьләрен өзелеп ярата, аларны мөнәҗәт итеп көйли иде. Ә инде үсә төшеп, бабамның китаплар тулы корзинкасына хуҗа булып алгач, миңа Тукайның шигырьләре белән тагын да якыннан танышырга мөмкинлек туды. Анда шагыйрьнең әсәрләре шактый күп иде. Мин андагы шигырьләрнең барысын да диярлек яттан өйрәндем. Шул көннән башлап алар минем аерылгысыз тормыш юлдашыма әверелделәр, бөтенләе белән минем хисләремне, уйларымны, гакылымны биләделәр. Мине дә иҗат дөньясына чакырдылар».

...Акрын гына пәрдә ачыла. Залдагы халык тын да алмый Тукай-Шамуковны күзәтә. Ә ул исә үзенең кайгы-хәсрәт тулы йөрәген, иң изге, иң кадерле хыял һәм теләкләрен тамашачыларга ышанып тапшыра, күңел түрендә сер һәм хәзинә итеп саклап йөрткән уй-фикерләрен алар белән уртаклаша, дәрт һәм ялкын тулы шигырьләрен сөйли. Никадәр яктылык һәм гүзәллек балкый бу кешедән!

Спектакль тәмам. Ләкин тамашачы таралырга уйламый да. Ул үзенең сөекле улы Тукайны алкышлый, ул яшь артист Габдулла Шамуковның таланты алдында баш ия. Актерның илһамлы таланты, фикерләү осталыгы һәм тырышлыгы аңа кызыклы, эмоциональ яктан көчле яңгырашлы сәхнә образын тудырырга ярдәм итә. Шамуков тара-

[1] М. Мәһдиев. Башкорт театрының иҗади юлы. «Коммуна» газетасы. 1934 ел. 30 декабрь саны.

фыннан иҗат ителгән образ шигъри күңеле һәм ялкынлы табигате белән үзенә тарта. Аңарда Тукай кебек бөек шәхеснең фаҗигале язмышы һәм киләчәкне раслый торган оптимизм бергә кушылган. Бу образ үзенең рухы белән халык азатлыгы һәм бәхете өчен көрәш идеалларын чагылдыра. Ә халык исә мәңгелек. Һәм аның теләк-омтылышларын чагылдырган шагыйрь образы да мәңгелек. Шамуков бу образ аша тамашачыга әнә шул фикерне җиткерергә омтыла. Шагыйрьнең үлемсезлеге турындагы мәңгелек тема Шамуков тарафыннан иҗат ителгән Тукай образында үзенең матур гәүдәләнешен таба. Кадыйр Даян бу рольдән соң Шамуковның талантын табигый чишмәләргә тиңли.

Тукай образын башкару яшь артистка тагын да катлаулырак һәм зуррак темага— бөек юлбашчыбыз Ленин образына якынлашу өчен зарури бер адым була. Драматург Николай Погодинның Октябрь революциясенең 20 еллыгына багышлап язылган «Мылтыклы кеше» әсәре һәркемгә мәгълүм. Ул совет драматургиясе тарихында үзенә бер этап булып тора. Ул безнең драматургиянең алтын фондына кергән әсәрләрнең берсе. Пьеса беренче мәртәбә 1937 елда Мәскәүнең Евгений Вахтангов исемендәге театрында куела. Владимир Ильич Ленин образын күренекле рус совет артисты Б. Щукин башкара. Щукин юлбашчының эпик монументальлеген һәм гади кешеләргә хас мөлаемлыгын бер бөтен итеп гәүдәләндерүгә ирешә. Соңыннан Б. Щукин тарафыннан иҗат ителгән Ленин образы һәр актер өчен осталык үрнәге, үзенә күрә эталон итеп йөртелә башлый.

Милли театрларның юлбашчы образын сурәтләгән бу әсәргә мөрәҗәгать итүләре, һичшиксез, җаваплы һәм кыю адым иде. Эшнең масштаблылыгы, куелган бурычның зурлыгы театрлардан бу әсәргә иң яхшы иҗат көчләрен тартуны таләп итә. Башкорт дәүләт академия театрында «Мылтыклы кеше» 1941 елда, ә Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында ул 1946 елда куела. Ленин роле ике очракта да Габдулла Шамуковка тапшырыла. Шулай итеп, милли театр сәхнәсендә Ленин образын гәүдәләндерү бәхете, беренчеләрдән булып, Габдулла Шамуков өлешенә туры килә.

Юлбашчы образын тудыру артисттан киеренке иҗади хезмәт, күп вакыт һәм көч сарыф итүне сорый. Г. Шамуков алдында Бөек Октябрь көннәренең кырыс һәм дәһшәтле вакыйгаларына мөмкин кадәр тирәнрәк төшенү, яңа, ленинчыл хакыйкать туган чордагы социаль каршылыклар бәрелешен, Ленин фикерләренең һәм идеяләренең бөеклеген аңлау бурычы тора иде. Ленинның эчке рухи дөньясын үзләштерергә, аның психологиясен, хисләр һәм фикерләр табигатен аңларга, Ильичка хас тормыш ритмын үзләштереп, алар белән сәхнәдә яши белергә кирәк иде. Куелган бурычның масштаблылыгы актерның хыял һәм фикерләрен үрләтеп җибәрә.

Китаплар, китаплар, китаплар... Ленин томнары, аның замандашларының истәлекләре, якыннарының һәм Ильичны күргән-белгән кешеләрнең аның турындагы хикәяләре, Октябрь революциясе эпохасына караган тарихи материаллар. Иң беренче чиратта В. И. Ленинның сеңелесе Мария Ильинична истәлекләре, Г. М. Кржижановский, А. В. Луначарский, П. П. Керженцев язмалары һәм, әлбәттә инде, М. Горькийның «В. И. Ленин» дигән очеркы. Болар барысы да җентекләп, бик нык өйрәнелә.

«Аның образын иҗат иткәндә» исемле мәкаләсендә Г. Шамуков Горький очеркының әһәмияте хакында болай яза: «Мин аны укыганда юлбашчының җанлы образын тоям, ул минем белән янымда, мин аның тавышын, тын алуын, тамак кыруларын ишетәм, аның мәгънәле карашын, аңа гына хас булган киң маңгаен, гаҗәп энергияле җитез хәрәкәтләрен күрәм. Ул минем белән сөйләшә төсле. Тора-бара мин үземне шул образ белән берләшкән итеп сизәм. Өйдә утырганда, урамда барганда, театрга кергәндә, иптәшләр белән сөйләшеп торганда юлбашчының образын үземдә хис итәргә тырышам. Соңыннан Горькийның бу китабын һәрбер спектакль алдыннан укый башладым»[1].

Образның тышкы чалымнары өстендә эшләү дә актердан җентекле хезмәт, зур тырышлык таләп итә. Чөнки тарихи шәхеснең эчке дөньясын күрсәтү белән берргә, артист үзенең тышкы хәрәкәтләрен, йөреш-торышын да ул кешенекенә охшатырга тиеш була. Димәк, бу очракта артист үз кыяфәтеннән, фәкать үзенә генә хас булган

[1] «Азат хатын» журналы, 1962 ел, 9 сан, 10 бит.

хәрәкәтләреннән ваз кичәргә, үз характерына бөтенләй ят хәрәкәтләрне, йөреш-торышны үзләштерергә тиеш. Шул максат белән Шамуков «Ленин Октябрьда» һәм «Ленин 1918 елда» дигән нәфис фильмнарны берничә тапкыр карый. Әлеге фильмнарда В. И. Ленин ролен Б. Щукин башкара. Ленин образының тышкы охшашлыгын эзләү максаты белән, Шамуков Н. В. Андреевның «Лениниана» дигән скульптур портретлар сериясен өйрәнә. Артистны бигрәк тә скульптурның эскизлары кызыксындыра: аларда Ленинга хас аерым хәрәкәтләр, гәүдә һәм кул тотышлары, баш борылышлары мәңгеләшеп калган була. Алар белән танышканнан соң, Шамуковка, үзенең күп кенә кыланышларыннан, хәрәкәтләреннән арынып, Ильичка хас тышкы хәрәкәт һәм кыланыш чалымнарын үзләштерергә туры килә. Соңыннан эш дәверендә Шамуков Андреевның портрет һәм эскизларына кабат-кабат әйләнеп кайта һәм Ленинга хас булган яңадан-яңа чалымнар таба.



*Г. Шамуков В. И. Ленин ролендә.*

Тавыш өстендә эшләү дә җиңел бармый. Юлбашчыга хас сөйләмнең һәм сүзләр әйтелешенең дөрес яңгырашын табу өчен шулай ук тырышлык, игътибар һәм сиземләү кирәк. Кыенлыкның тагын бер ягы шунда: Ленин рус телендә сөйләшкән, ә Шамуковка башкорт, соңыннан татар телендә сөйләргә туры килә. Рус теленә хас интонацион байлыкны, Ленин сөйләменең мәгънәви һәм эмоциональ эчтәлеген туган тел чаралары белән ничек белдерергә? Ленин сөйләмен үзләштерү нигездә пластинкалар ярдәмендә алып барыла. Шамуковка бигрәк тә В. И. Ленинның «Нәрсә ул совет власте?» дигән мәкаләсе һәм Я. М. Свердловны күмү мәрасимендәге речьләре язылган ике пластинка нык ярдәм итә.

Владимир Ильич «р» авазын бераз йотыбрак һәм тиз-тиз сөйли торган булган. Ләкин аны тыңлаган кешеләр, Ленин фикеренең тимер логикасына буйсынып, аның кайнар көченә, энергиясенә бирелеп, әлеге сөйләм дефектын бөтенләй искәрмәгәннәр дә. Шуңа күрә актер Ленинның «р» авазын әйтүдәге үзенчәлегенә игътибар итмәскә була. Ул юлбашчы сөйләменең гомуми характерын — тизлеген, ышандыручанлыгын, культурасын, омтылышлылыгын, темпераментын бирүне максат итеп куя.

Җентекләп эзерләнү бушка китми. Театрда репетицияләр башлануга Шамуковның инде нык уйланылган һәм күңелдән кичерелән материалы була. Ләкин аның алдында әле иҗатның зур хезмәт, ихтыяр көче, характер җыйнаклыгы һәм нервлар көченешен таләп итә торган төп өлеше тора. Хәзер инде эзләп табылган тышкы детальләрне камилләштерү, шомарту һәм бер үзәккә җыйнау эше кала. М. Горький очеркында: «Аның хәрәкәтләре җиңел, җитез һәм саран, фикергә юмарт булган сөйләменә ярашып тора иде», дигән юллар бар. Шамуков Ленин образын иҗат иткәндә шушы характеристиканы нык истә тота. Юлбашчы характерының асылын М. Горький: «Хакыйкатьнең үзе кебек гади», дигән сүзләр белән билгели. «Мылтыклы кеше» әсәрендә дә В. И. Ленин «хакыйкатьнең үзе кебек гади» кеше итеп сурәтләнә. Һәм Шамуков та менә шул үзенчәлекне образның төп штрихларыннан берсе итеп сурәтләргә омтыла. Һәм шунлыктан, самимилек, эмоциональлек, юмор һәм югары сәхнә культурасы, кыскасы, Шамуков иҗаты өчен хас барлык уңай сыйфатлар Ленин ролендә әверүчә ачык чагылыш табалар.

Актер Ленин шәхесенең катлаулы берлеген: даһи мәһабәтлелеген һәм гадилеген, ирләрчә ныклыгын һәм тыйнаклыгын, кырыслыгын һәм миһербанлыгын, куелган максатка ирешүдә тайпылышсызлыгын, үзе сайлаган юлның дөреслегенә тирән инануын, рухи сизгерлеген һәм сәламәт юморын ачып бирә. Менә шушы күптөрле чалымнар Ильич образының тәгәл бөтенлеген тәшкил итәләр дә инде. Шамуков Ленин фикеренең һәм фантазиясенең агышын тоярга, аны дулкынландырган мәсьәләләр даирәсен аңларга тырыша һәм тамашачы алдында революция һәм халык юлбашчысы образын оста гәүдәләндерүгә ирешә. Шунлыктан һәм башкорт, һәм татар театры сәхнәсендә куелган «Мылтыклы кеше» спектакльләре зур сәнгатьчән хакыйкать, революцион дәрт белән сугарылган социал-философик яңгырашлы әсәрләр югарылыгына күтәреләләр.

Ленин образы өстендә эшләү дәверендә артист иҗатына хас сыйфатлардан эмоциональ башлангыч беренче планга чыга. Юлбашчы образын ул тирәнтен йөрәк тойгысы, зур дулкынлану белән иҗат итә.

Менә Ленин-Шамуков беренче тапкыр сәхнәгә килеп керә. Ачык киң маңгай, бераз кысыла төшкән искиткеч төрә, игътибарлы күзләр. Соры шинельле солдат Иван Шадрин аңа сорау белән мөрәҗәгать итә. Кыска гына әңгәмә, ә Ленин инде үзе белән сөйләшүче бу крестьянның бөтен үткәнен күз алдына китереп өлгерә булса кирәк. Шул минутта ук Ленин үзен борчыган мәсьәләләр буенча Шадрингә сораулар яудыра башлый. Аңа салкын окопларда ятып йончыган, ялыккан, җаны-тәне белән үз авылына, тыныч тормышка омтылган, ләкин, кирәге булыр әле дип, мылтыгын да ташламаган бу крестьянның нәрсә уйлавы кызык. Аның беләсе килә: «Әгәр дә патша генераллары Россиягә яңадан алпавытларны һәм капиталистларны кайтартырга теләсәләр, ул вакытта... солдат яңадан сугышырга ризамы?» Әйе, риза, менә бүген үк, хәзер үк риза икән! Ленин тагын бер тапкыр үзенең күзәтүләренең, фикерләренең, үзе тоткан юлның дөреслеген тикшерә һәм шул ук вакытта бу крестьянның буталчык фикерләренә юнәлеш бирә. Шадрин исә, ниндидер эчке бер сиземләү белән булса кирәк, үзенең әңгәмәдәшенең аңа якын, дус кеше икәнлеген чамалап ала. Бу юлы да Шадринны «кешеләрнең йөрәкләрен һәм симпатияләрен үзенә тарта торган ниндидер магнетизм» Ленин ягына тарта. Н. Погодин үзе бу диалогны бөтен пьесаның үзәге дип атый. Г. Камал исемендәге театр куйган вариантта да бу күренеш бөтен спектакльгә эпиграф булып яңгырый. Революциянең хәрби штабы саналган Смольный. Монда кызу эш кайный, биредә миллионнарның киләчәк язмышы хәл ителә. Кискен политик көрәш хөкем сөрә, сәгате, минуты белән вакыйгалар ташкыны үзгәреп тора. Бу ташкын тиз һәм катгый рәвештә хәрәкәт итүне сорый, революциядә катнашкан һәр кешедән зур оперативлык таләп итә. Һәм бөтенесенең үзәгендә, һәркемне тормышка, көрәшкә рухландырып, Ленин образы тора. Ленин — остаз, Ленин — дус һәм иптәш. Менә шул кеше белән очрашу солдат Иван Шадринның революцион аңы үсешенә этәргеч көч була, революцион давыл караңгы авыл мужигын көрәшкә уята һәм аны коммунистлар партиясенең аңлы көрәшчесенә әверелдерә...

* * *

Талантлы артист озакламый Казанга, татар театрында эшләргә чакырыла. Габдулла Шамуковның Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театры сәхнәсендә башкарган беренче образы шулай ук бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин роле булды. Бу вакытта инде ул үзенең сәхнә йөзен тапкан, иҗади яктан ныгыган һәм танылган сәхнә остасы иде. Бай тарихы булган, инде үзенең тормышчан сәхнә мәктәбен тудырган татар театры Габдулла Шамуковның талантын тагын да үстерү һәм камилләштерүдә бай җирлек була. Ул монда берсеннән берсе кызыклы сәхнә образлары иҗат итә. Башкорт театрындагы кебек үк, татар театрында да аның актерлык иҗаты ике төрле юнәлештә, ике төрле характерда үсүдә дәвам итә. Беренчесе лирик-героик характердагы рольләр, икенчесе исә сатирик һәм юмористик пландагы образлар иҗат итү.

Шамуковның комиклык талантын аның интеллектуаль сәләтенең аерым бер матур һәм мавыктыргыч үзенчәлеге итеп карарга мөмкин. Ул тудырган комедиячел типлар үзләренең фаш итү көче һәм сатирик юнәлешләре белән гаять дәрәҗәдә үткерләр һәм аныклар. Аларга сәнгатьчә эшләнгән булу, әдәби бөтенлек, төгәллек һәм масштаблык

хас. Гогольнең «Ревизор»ыннан Хлестаков һәм Добчинскийны, «Өйләнү»еннән Подколесинны, Островскийның «Котырган акчалар»ыннан Телятевны, Таҗи Гыйззәтнең «Ташкыннар»ыннан Басарыйны, Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр»еннән Нуретдинне, Мостай Кәримнең «Җырланмаган җыры»ннан Арыкбаевны, Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ыннан Ахунны, «Зифа»дан Балтаевны, «Һиҗрәт»тән шагыйрьне әнә шундый образлар рәтенә кертеп була.

Күләмнәренең зур яки кечкенә булуларына карамастан, бу рольләрнең һәркайсы Габдулла Шамуков башкаруында спектакльнең үзәк образлары дәрәҗәсенә күтәрелә. Әдәбият белгече, тәнкыйтьче Гази Кашшаф артистның менә шундый рольләреннән Басарый турында болай дип язды:

«Кечкенә рольне дә онытылмаслык осталык белән башкарган Габдулла Шамуковка тукталмый мөмкин түгел. Ул писарь Басарый ролендә уйный һәм, әйтергә кирәк, сәхнәгә дә үзенчә килеп керә. Караңгы авылда үзен түрә итеп күргән бу писарьның борыны һавада, ул доньяга сыймастай булып килеп керә һәм тәмәке төпчеген аяк очы белән ышкый-ышкый сүндереп, мәҗлеснең түренә уза. Ләкин ул бик эре булып кыланса да, чынында бик куркак икән. Аулак өйдә Гайнавал аны түр бүлмәдән куып чыгара, эзәрлекләнгән писарь-Шамуков, куркуыннан коя барырга бәлми бөтерелгәннән соң, мич башына менеп китә. Шүрләгән писарь мич башыннан муенын сузып Мирзаханнан ярдәм сорый. Бик оста табылган деталь. Бу образның оятсызлыгын, бозыклыгын Шамуков бик ачык һәм оста сайлаган штрихлар аша күрсәтеп бирә. Менә ул сатин күлмәктән генә калган һәм Зәмзәмбануны кочаклап утыра. Аңа дөнья яңадан тубыктан кебек, ул тагын һавалы һәм эре кыланып, чалбар кесәсеннән конфагыш ала да, аны берәмләп еректан авызына таба очыра. Әнә шундый детальләр аша Басарыйның вак җанлы, кеше бәхетсезлегеннән рәхәт табарга тырышуы, оятсызлыгы ачыла бара» [1].

«Советская культура» газетасының 1958 елгы саннарының берсендә исә Габдулла Шамуковның уены хакында түбәндәге юлларны очратабыз:

«Театрның актерлар составы гаҗәеп шәп.

Сез төрле спектакльләрдә теге яки бу актерны кабат очратасыз һәм аның төрле рәвешкә керә, үзгәрә алуына сокланмыйча булдыра алмыйсыз. Аларның сәхнәдә үзүзләрен тотышларына, кыланышларына гаҗәеп җиңеллек, иркенлек хас. Алар иҗатында тагын күзгә бәрелеп торган бер ачык сыйфат — ул да булса тәэсирлелек, үзүзеңнән онытылып, бар көчеңне биреп иҗат итү. Менә сез өч спектакльдә театрның күренекле артисты Габдулла Шамуков белән очрашасыз. Ул үзенең рухы, социаль эчтәлеге, темпераменты ягыннан капма-каршы характердагы өч образ иҗат иткән һәм күрүгезчә аның тарафыннан табылган тышкы буяулар һәм образның эчке хәрәкәте нинди дөрес!» [2]

Тәнкыйтьче нинди рольләр турында сүз алып бара соң?

Сүз Кәрим Тинчуринның «Җилкәнсезләр» сатирик комедиясендәге Нуретдин бай, Нәкый ага Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендәге язучы Илстан һәм «Зифа» комедиясендәге Балтаев образлары турында бара. Бу өч образ дерестән дә гаҗәеп төрле характердагы, өч төрле жанрдагы, өч төрле чор вәкилләре. һәм аларның һәрберсенә актер үзенә генә хас үзенчәлекле сәхнә бизәкләре, художество эшләнеше ягыннан төгәл буяулар таба алган.



*Г. Шамуков Нуретдин ролендә.*

Менә Н. Исәнбәтнең «Зифа» комедиясеннән Балтаев образы. Балтаев бу әсәрдә төп урынны билә тора һәм үткен эшләнгән образлар рәтенә

---

[1] Г. Кашшаф. Декада спектакле. «Совет Татарстаны» газетасы, 1956 ел, 31 октябрь саны.

[2] Н. Громов. Кому много дано... «Советская культура» газетасы. 1958 ел, 10 июль саны.

керә. Габдулла Шамуков тамашачыга үз героеның эчке дөньясын төгәл штрихлар белән ачып күрсәтүгә ирешә. Без Балтаев-Шамуковның кешеләр турында кайгырткан булып кылануында кеше язмышына кул селтәп каравын; ыгы-зыгы килеп, «эшем кешесе» булып йөрүендә эшлексезлеген; әхлак турындагы купшы сүзләрендә мораль тотнаксызлыгын сизәбез. Шамуков тарафыннан оста һәм үткен итеп сурәтләнгән бу сатирик образ бик күп еллар буена артистның репертуарын бизәп килде һәм татар театр тарихын тагын бер үзенчәлекле образ белән баетты.

1962 елда Татар дәүләт академия театры бөек рус драматургы Алексей Островскийның «Котырган акчалар» комедиясен сәхнәләштерде. Һәм ул соңгы биш елда куелган спектакльләр арасында аерата уңышлы спектакльләрдән берсе саналды. Телятев ролендә Габдулла Шамуков чыгыш ясады. Бу роль үзенең иҗтимагый яңгырашы ягыннан тискәре образлар рәтенә керә. Башкалар кебек үк, ул да соры корт, үлеп, череп барган дворян сыйныфы вәкиле. Ләкин аның уңай бер сыйфаты бар. Ул туры кеше. Сыйныфташларына да ул аек күз белән карый белә. Юк-бар иллюзияләр белән үзен юатмый, шулай ук башкаларны да алдамый.

Нәкый Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» комедиясе Татар дәүләт академия театрында 1939 елдан бирле уйналып килә. Бу спектакльнең саны 2 меңгә якын. Хуҗа Насретдин — татар халкының җор сүзле, оста телле, зирәк һәм акыллы бер вәкиле. СССР-ның халык артисты Хәлил Әбҗәлиловның комик таланты бу спектакльдә тулысы белән ачылды. Шулай ук башка рольләрдәге артистларыбыз да Хәлил ага Әбҗәлилов белән бергә аерылгысыз рәвештә еллар буена сәхнәдә чыгыш ясап килделәр. Алар арасында Ахун ролендә Шамуков та бар иде. Моннан берничә ел элек спектакль яңадан яңартылды. Монда без Габдулла ага Шамуков белән Хуҗа Насретдин ролендә очраштык. Шамуков, Хәлил Әбҗәлилов сәхнә тәҗрибәсеннән файдаланып, аның трактовкасын сакларга тырышкан һәм үзенең кешелек табигатенә тиң килгән Хуҗа Насретдин образын иҗат иткән.

1966—67 елгы сезонда театрда Габдулла Шамуковка итальян язучысы Эдуардо де Филиппоның «Бәйрәм кичендә» исемле комедиясендә синьор Купьелло образын тапшырдылар. Бу роль үзенең формасы һәм характеры белән трагикомедия жанрына карый һәм шунлыктан эчтәлеге белән гаять катлаулы.



*Г. Шамуков — Хуҗа Насретдин Ахун киемендә.*

Сәхнәдә түп-түгәрәк гәүдәле, искиткеч тере хәрәкәтле, сабый балаларныкыдай саф карашлы синьор Купьелло-Шамуков. Аны карчыгы яңа гына йокысыннан уяткан. Ул җай һәм акрын гына чалбар, жилетын кия, иске шарфын биленә бәйли, юынып алганнан соң үзенең уенчыклары янына килеп утыра һәм... татлы хыялларга бирелә. Синьор Купьелло өчен шушы уенчык курчаклардан кадерле тагын нәрсә бар икән?!. Аларда аның югалган теләкләре, өметләре, хисләре тупланган. Һәм ул үз тормышының фәкыйрьлеген, мәгънәсезлеген алар белән бизәргә, алар белән матурларга, ямьләндерергә омтыла. Буш хыяллар, чынга ашмаган теләкләр бу кешенең тормыш фаҗигасен тәшкил итәләр. Габдулла Шамуков бу рольнең эчке музыкаль яңгырашын тирәнтен тоеп, лирик бизәкләрне киң кулланып, үзенең философик яңгырашы белән катлаулы образ иҗат итте һәм безне талантлы һәм зирәк акыллы бер ша-

хеснең акча власте хөкем сөргән илдә фаҗигале язмышы белән таныштырды.

Габдулла Шамуковның театрда иҗат иткән соңгы рольләреннән берсе «Кол» спектаклендә Ксанф образы. Бу әсәр Бразилия язучысы Фигейредоның «Эзоп» дигән трагедиясе буенча эшләнде. Шамуков тудырган Ксанф образы үзенең тискәре фәлсәфи асылы белән әсәрнең герое мәсәлче Эзопка капма-каршы куелган. Ксанф-Шамуков җирдәге бар материаль байлыкка хуҗа булса да, кешелек эчтәлеге, рухы белән хәерче. Ничәмә-ничә колларның хуҗасы Ксанф чын мәгънәсендә үзе кол. Ул акча колы. Аныңча, һәр нәрсәне акчага сатып алып була, тормышның асылын акча тәшкил итә. Актер Ксанфның тормыш фәлсәфәсенең җиңелү тантанасын оста итеп күрсәтә алуга ирешә.

Без Габдулла Шамуковны тәрҗемәче һәм язучы да дигән идек. Ул дөнья әдәбияты һәм рус классикларының күп кенә күренекле әсәрләрен татарчага һәм башкортчага тәрҗемә итте. Алар арасында Шиллерның «Мәкер һәм мәхәббәт», Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» һәм «Отелло», Грибоедовның «Акыллылык бәласе», Горькийның «Тормыш төбендә», Островскийның «Котырган акчалар» һәм башка бик күп әсәрләре бар. Шулай ук, мәсәлче буларак, Крылов әсәрләре дә аның күңеленә хуш килгән һәм ул аларны татарчага тәрҗемә иткән. Татар язучысы Ибраһим Гази тәрҗемәче Шамуковны болай тасвирлый: «Рәхәтләнеп укып чыктым. Бигрәк тә Шамуков тәрҗемәләре яхшы эшләнгәннәр. Шигырьнең шигырьлеген саклый алып тәрҗемә итү авыр эш. Шамуков оригиналдагы формаль якларга колларча ябышмаган; юл саны да урыны белән арткан, рифмалары да автордагыча түгел, ләкин ни хикмәттер, аның тәрҗемәләре чын шигырь булып яңгырыйлар, рәхәтләнеп укыйсың, мәгънәсе дә ялтырап тора, оригиналга бераз да зарар китермәгән»[1]. Г. Шамуков үзе дә мәсәлләр яза. Күптән түгел Татарстан китап нәшрияты аның шул мәсәлләрен аерым җыентык итеп чыгарды...

«Сәхнә индивидуальлеге — ул иң элек кешенең рухи индивидуальлеге»,— ди Константин Сергеевич Станиславский. РСФСРның халык артисты Габдулла Шамуков турында сәхнә художнигы буларак сүз алып барганда, аның менә шушы рухи индивидуальлегенә тукталмыйча мөмкин түгел. Аның артистлык иҗатының асылын тормышка, кешеләргә, дөньяга гашыйк була белү, үзенең барлыгын онытып, мавыга алуы, аны һәм саф итеп сөя белүе тәшкил итә. Һәр роль, һәр образ артистның йөрәк хисе белән яктыртылып, акылы белән камилләштерелеп сәхнә тормышы күрә һәм шуңа күрә тамашачы йөрәгендә тирән эз калдыра. Без бу образлар аша артистның шәхес буларак киң һәм киң итеп фикерләүчән акылы, дөньяны, кешеләрне, матурлыкны искиткеч бер тирәнлек һәм нечкә хис итүчән табигате белән очрашабыз. Һәм киләчәктә дә артистның киң иҗат юлында яңадан-яңа гүзәл образлар белән очрашуын теләп калабыз.

---

[1] И. Гази. Крылов. Мәсәлләр. «Кызыл Татарстан» газетасы. Ноябрь. 1957 ел.

# СҮЗЛЕКЛӘР ТАРИХЫННАН

Татар теленең тарихы, ул узган катлаулы юл филология фәнебездә иң артта калган өлкәләрнең берсе дисәк, әллә ни арттыру булмас, шаять. Алай гына да түгел, хәтта бу мәсьәләгә караган мөһим документларның даирәсе дә әзме-күпме барланылмаган әле. Мостафа Ногман үзенең күптән түгел чыккан хезмәтендә[1] менә шул катлаулы һәм зур өлкәнең бер кечкенә генә мәсьәләсен — XVII—XVIII йөзләрдә төзелгән русча-татарча сүзлекләрнең тел тарихы өчен әһәмиятен билгеләп, аларның эчке хосусиятларын ачыклауны бурыч итеп куя. Һәм, әйтергә кирәк, автор үз теләгенә нигездә ирешкән. Бу фикерне дәлилләү өчен бер мисалны күрсәтү дә җитәр иде: әгәр моңа хәтле тюркология белемендә иң карт русча-татарча сүзлек сыйфатында 1785 елны Сәгыйт Хәлфин тарафыннан төзелгән хезмәт исәпләнеп йөртелгән булса, рецензияләнә торган китапның авторы аңа хәтле үк барлыкка килгән тагын ун данә сүзлекне гыйльми хәрәкәткә кертеп җибәрә. Шуның нәтиҗәсендә русча-татарча лексикография тарихы тагы да йөз елга олыгая төшә. Ягъни, икенчерәк итеп әйткәндә, ул тарихның башы моңарчы кабул ителгән XVIII гасыр азагыннан XVII йөз ахырына күчерелә. Шушы бер факт та М. Ногманның әһәмиятле табышы һәм тикшерүченең филология тарихына керткән лаеклы өлеше. Ләкин автор яңа ачылган документларның табылу тарихын әйтеп, аларның тышкы сыйфатларын сурәтләү белән генә канәгатьләнми, бәлки мәсьәләне әтрафлап яктыртырга, лексикографик проблемаларны да төптәнрәк хәл кылырга омтыла.

Хезмәт кыскача кереш, өч бүлек һәм кушымта рәвешендә тәкъдим ителгән библиографик белешмәдән гыйбарәт. Иллюстрацион материалларның да уңышлы гына сайланган булуын күрсәтергә кирәк. Тик 20—21 битләрдә бирелгән фотокопиянең негативтан алынуы гына беркадәр сәер: күз акка кара белән язуга күнеккән, киресенчә түгел...

Хезмәтнең русча-татарча сүзлекләр барлыкка килүдәге социаль-тарихи җирлекне күзәтүгә багышланган беренче бүлеге үзенең әһәмияте белән китапта каралган мәсьәләләрдән киңрәк. Чөнки анда сүз бер шул истәлекләр барлыкка килгән шартлар хакында гына булмыйча, бәлки XVII—XVIII йөзләрдә татар әдәби теленең таралу мохите, Россия империясе оешуда бу тел үтәгән функциональ роль дә әзме-күпме яктыртыла. Әмма бу бүлектә бәхәсле моментлар да юк түгел. Мәсәлән, автор гомум «татар лексикографиясе тарихының... башланып китүе» дәверен XVII йөз ахырларында төзелгән бер сүзлеккә генә кайтарып калдыра. Һәм шул истәлекне бер бөтен «башлангычның» мисалы — дөньядагы иң беренче русча-татарча сүзлек рәвешендә тәкъдим итә (12 һәм 13 битләр). Минемчә, мәсьәләне болай хәл итү шактый берьяклы. Чөнки, М. Ногман үзе үк дөрес күрсәтеп узганча, тәрҗемәле сүзлекләр тиктомалдан гына түгел, бәлки халыкара культура-экономик мөнәсәбәтләрнең үсү дәвамында туган зарури ихтыяҗларны үтәү нәтиҗәсендә генә барлыкка киләләр. Ә рус һәм татар культура-экономик бәйләнешләре исә, мәгълүм булганча, бик элгәредән башлана, һәм ул процесс Болгар, Казан дәүләтләре чорларында да өзлексез дәвам итә. Хәтта ике

---

[1] Мостафа Ногман. XVII—XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульязма сүзлекләр. Казан университеты нәшрияты. 1969 ел.

дәүләт арасында көчле сугышлар барган вакытларда да рус һәм татар сәүдәгәрләре нейтраль ярминкәләрдә очрашып, мул-мул итеп товар алмашканнар. Аннары Болгар, Казан шәһәрләрендә күп санлы рус сәүдәгәрләре яшәп, Мәскәү һәм башка рус шәһәрләрендә махсус татар бистәләре булуын игътибарга алсак, ике халык арасындагы дәвамлы мөнәсәбәтнең тирән тамырлы, киң диапазонлы икәнлеген аңларбыз. Шаять ул чорларда да ике тел арасында толмачлар да, шул толмачларның берсе төзеп, икенчеләре файдаланган русча-төркичә, яисә төркичә-русча сүзлекләрнең дә саны шактый булгандыр.

Әле генә әйтелгән фикерне куәтләр өчен XIV—XVI йөзләрдә рус һәм татар телләре арасында булган тыгыз дипломатик һәм официаль-политик мөнәсәбәтләрне дә күрсәтергә мөмкин. Мәсәлән, Алтын Урда һәм Казан дәүләтләренең әһелләре үзләренең рус князьларына адресланган хатларын татарча язып яткаННар, һәм алар Мәскәү канцеляриясендә рус теленә тәрҗемә ителгән (мондый тәрҗемәләрнең берничәсе фәндә мәгълүм). Кыскасы, шул элгәрерәк дәверләрдә дә безнең телләр арасында тәрҗемәле сүзлекләргә ихтыяҗ зур булган.

Автор татар әдәби теленең рус-көнчыгыш мөнәсәбәтләрендәге функциональ-арадашлык роленә дә кагылып үтә (русча-татарча лексикография тарихында бу, шиксез, мөһим мәсьәлә). Ләкин рус патшалары үзләренең грамоталарын, китапта әйтелгәнчә, бер төрки дәүләтләргә генә татарчалап язмаган (15 бит), бәлки башка телле илләргә дә татарча тәрҗемә белән бергә җибәргәннәр. Мәсәлән, Кырым, Төркия, Нугай, Казакъ, Комык, Үзбәк дәүләтләреннән тыш, Иран шаһы белән Һиндстан падишаһына, Кытай богдыханы белән Монголстан ханнарына да үз грамоталарын татарча тәрҗемәдә күндергәннәр алар. Мондый документларның сакланып калганнары да әллә ничә дистәдән артык.

Рус администрациясенең империя составына кергән төрки халыклар (башкорт, казакъ, нугай, комык һ. б.) белән мөнәсәбәтендә исә татар теле тагы да активрак кулланылган. Мондый очракта Россия дәүләт аппаратыннан чыккан документлар Казан татарлары әдәби телендә язылып, аларга каршы килгән җаваплар исә теге яки бу күләмдә авторларның туган теле үзенчәлекләрен чагылдырган. Һәм бу характердагы документларның саны (мәсәлән, Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Астрахань, Оренбург, Уфа архивларында) дистәләр белән түгел, бәлки йөзләр һәм меңнәр белән үлчәнә. Димәк, китап авторының «җирле провинцияләрдә (биредә сүз империянең көнчыгыш провинцияләре турында бара — М. Г.) гарәп язуын белгән рус чиновниклары булмый» дигән тезисы (47 бит) шактый җиңелчә әйтелгән фикер булып чыга. Чөнки, архив документлары күрсәтүгә караганда, XVII—XVIII һәм XIX йөзләрдә империя администрациясе үзенең көнчыгыштагы провинция аппаратларын гарәпчә язулы төрки документларын укый алырлык рус чиновниклары белән әзме-күпме өзлексез рәвештә тәэмин итеп килгән. Ә татарча телгә, мөселманча язуга «йөгерек» булган татар-мишәр толмачлары исә нәкъ менә шуларның житәкчелеге һәм контроле астында эшләгәннәр. Бу шартларның барсы да Россия халыклары тарихына караган татарча документларның күп санлы һәм әһәмиятле булуын тәэмин иткән. Бу телнең арадашлыгы аша төрле ил-дәүләт вәкилләре аңлашкан, аның ярдәмендә солых договорлары төзегән, дуслык мөнәсәбәтләре беркетелгән. Менә бу фактлардан киң файдаланылган булса, М. Ногманның күрсәтелгән чорга карата русча-татарча «сүзлекләр төзелүнең ныклы социаль-тарихи җирлеге булган» дигән йомгагы (23 бит) тагы да куәтләнә төшәр иде. Һәрхәлдә, хәзерге мәгълүм иң карт русча-татарча сүзлекнең С. Хәлфин хезмәтеннән 100 ел элгәрәк төзелгәнлеге бик табигый булган кебек, килачәктә аннан да борынгырак сүзлекләр табылса, һич тә гаҗәп түгел.

Хезмәтнең икенче бүлеге тикшерелә торган сүзлекләрне тасвирлауга һәм аларда китерелгән материалларны анализлауга багышланган. Китап авторының элгәрге лексикографларга карата ихтирам күрсәтүе бик мактаулы сыйфат. Шуңа күрә дә автор өйрәнелә торган документларның уңай якларын шактый тулы һәм истә калырлык итеп яктырта алган. Тик позитив бәя белән мавыгып китү моментлары да юк түгел. Мәсәлән, Матвей Котельников сөйләүнамәсе (автор русча «разговорник» мәгънәсен шулай бирә) турында фикер йөрткәндә, анда китерелгән татарча лексиканың сафлыгы, байлыгы турындагы хөкем нигездә дөрес. Ләкин лексик сыйфатларга карата бирелгән бәяне механик рәвештә синтаксик үзенчәлекләргә дә күчерә башлагач, зур аңлаешсызлык килеп чыккан. Мәсәлән, әлеге сөйләүнамә эчтәлеген тәфсилләп анализлагач, автор болай яза: аның «ярдәмендә сүзләр-

нең җөмләдәге табигый кулланышын күзәтә алабыз һәм шул чактагы татар теленең синтаксик формаларын күздән кичерәбез» (57 бит. Курсив минеке — М. Г.) Мисалларга мөрәҗәгать итик: **«Аккош, торна ашыйлар бака һәм еланны»** — «Лебедь и журавль едят лягушек и змей»; **«Көтүче көтәдер көтү басуда»** — «Пастух пасет стадо на пастбище» һ. б. Күренә ки, бу җөмләләрнең төзелеше төркичә **табигыйлектән** бик ерак тора (русча оригинал белән чагыштырыгыз). Димәк, бер аспектта дөрес булган уңай бәя белән мавыгу, аны абсолютка әверелдерү, кире нәтиҗәләр китереп чыгара икән.

Тикшерелә торган сүзлекләрнең лексик байлыгын, ул материалларның төрле катламнарын анализлауга багышланган өченче бүлек тә, тулаем алганда, уңай тәэсир калдыра. Тикшерүченең төп тезислары белән, нигездә, килешергә мөмкин. Төрле язма документларның, башка төрки телләрнең материалларыннан иркен файдалану да хезмәтнең кыйммәтен арттырган. Ләкин архаиклашкан сүзләргә бирелгән анализда ул сүзләрнең семантикасын, ягъни мәгънәләрен әтрафлап ачыклыйсы урынга, автор аларның этимологиясе (килеп чыгышы) турында өстен-өстен фикер йөртүләр белән канәгатьләнә.

Аннары Себер татарлары теле буенча төзелгән сүзлекләрне анализлаганда бу диалектның спецификасын гел үзбәк теле ярдәмендә генә аңлатырга тырышу тенденциясе дә бер яклылыкка китергән. Авторның «куцкар (кучкар)», «канцык (канчык)», «козы (кузы)» кебек сүзләргә генә таянып, «бохарлылар тәэсире күбрәк кош, хайван исемнәренә кайтып кала» дигән нәтиҗәсе (76 бит) әзер схемага субъектив рәвештә мисаллар чүпләүгә кайтып кала. Чөнки, беренчедән, моның ише сүзләрнең барсы да гомумтөрки лексикага керәләр, икенчедән, аларны үзбәкләр белән мөнәсәбәткә кермәгән башка татар диалектларында да очратабыз (фарси теленнән алынган «кураз» — «әтәч» исә ул Себергә бохарлылар килгәнче үк төркиләшеп өлгергән сүз). Гомумән, татар теленең Себер диалектын тикшергән чакта ул тарафка кайчандыр бер саркып алган үзбәкләр белән мавыкканчы, себерлеләр белән даими рәвештә янәшә яшәгән казакъларның, башкортларның һәм алар арасында сеңеп калган нугайларның телләренә күбрәк игътибар итәргә кирәк. Шулай эшләгәндә, янәсе «хәзер диалектологик сүзлектә очрамый» торган «цулук» (чолык, солок) кебек сүзләр «ата-анасыз» калмас иде. Ә үзбәк теле тәэсиренә килсәк, ул булган, тик бу тәэсир кош-корт, хайван исемнәрендә түгел, бәлки кайбер грамматик чараларда һәм дини тәгълимат аша кергән культура-идеология өлкәсенә мөнәсәбәтле сүзләрдә чагыла.

Ниһаять, элекке рус графикасы ярдәмендә генә бирелгән кайбер сүзләрне шул хәлдә язмыш иркенә калдырмыйча, җаялар эчендә генә булса да, транскрипцияләп бирәсе иде. Мәсәлән, «алуңгыз — алуңыз» (34 бит), «конгше — куңшы» (76 бит) һ. б. (Рус графикасында «ң» хәрефе булмаганга, аны шулай «нг» аша биргәннәр.)

Җыеп әйткәндә, М. Ногман чыгарган китап бик актуаль темаларның берсенә багышланган. Хезмәтнең документаль материалга бай булуы да игътибарга лаек. Шул ук вакытта бу эзләнү аерым кимчелекләр һәм ялгыш хөкемнәрдән дә азат түгел икән. Хәер, болай булуы да табигыйдыр, чөнки чирәм җиргә беренче буразнаны салуы гаять авыр булган шикелле, чирәм ятмаларны төгәл үзләштереп чыгу мәсьәләсе дә бер генә кешенең бурычы түгел.

**М. ГОСМАНОВ,**
филология фәннәре кандидаты.

## КҮРЕНЕКЛЕ СОВЕТ ТЮРКОЛОГЫ, СССР ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ ЧЛЕН-КОРРЕСПОНДЕНТЫ, ПРОФЕССОР А. Н. КОНОНОВНЫҢ МОСТАФА НОГМАНГА ЯЗГАН ХАТЫ

*Ленинград, 1969 ел, 16 декабрь.*

*«Хөрмәтле Мостафа Ногманович!*

Миңа җибәргән «XVII—XVIII йөзләрдәге русча-татарча кульъязма сүзлекләр» дигән кыйммәтле бүләгегез өчен зур рәхмәт.

Сезне шундый зур гыйльми уңышыгыз белән, ә үзебезнең тюркология фәненең аның кыен бер сәхифәсен ача торган бик кирәкле һәм мөһим бер хезмәт белән чын күңелемнән тәбрик итәм.

Татар телен өйрәнү тарихы турында, татар телен өйрәнүче татар галимнәренең хезмәтләрен җентекләп тикшергән бер очерк язылса, әйбәт эш булыр иде».

# ТОРМЫШНЫҢ ҮЗЕННӘН...

Бу китапка әдәби иҗат эшенә утыз елдан артык гомерен биргән өлкән шагыйребез Сибгат Хәкимнең төрле вакытта һәм төрле уңай белән язылган очерклары, мәкаләләре тупланган[1]. «Үз тавышың белән» дип исемләнгән әлеге җыентык белән очрашу шагыйрьнең шигъри иҗатын кабат искә төшерә: андагы кайсы гына язманы яки мәкаләне укыма, аларның нокъ менә лирик шагыйрь кулы белән язылуы күзгә ташлана.

Җыентык җыйнак-җыйнак биш бүлектән тора. Автор үзенең шигъри элгәрләре Тукай, Такташ, Пушкин, Лермонтовлар турында сүз аламы, әллә булмаса каләмдәш дусларының иҗатына күз сала яки сугыштан соңгы поэзиябезнең үсеш тенденцияләре турында уйланамы — һәр мәкаләдән аның үз йөзен, үз позициясен, үз карашын ачык күреп була. Китаптагы һәр бүлек әдәби иҗат эшенең теге яки бу мөһим бер ягына багышланган, һәр мәкаләдә нинди дә булса берәр кызыклы мәсьәлә күтәрелә.

Татар совет поэзиясендә В. И. Ленинга багышланган күп санлы шигырь, поэмалар бар. С. Хәким үзе дә бу өлкәдә уңышлы һәм иң актив эшләүче шагыйрьләребезнең берсе. Җыентыктагы «Җирнең иң биек төшеннән» һәм «Мин Ленин язмаларын укыйм» исемле мәкаләләрдә сүз Ленин һәм Татарстан, Ленин һәм татар әдәбияты турында бара.

Шигырь ничек туа?.. Чыннан да, шагыйрьләрнең үзләре өчен генә түгел, шигырь укучы һәркем өчен кызыклы сорау бу. С. Хәким шигырьнең туусын халык тормышы белән тыгыз бәйләнештә күрә: «...Хәзер син кайсы гына шигыреңне хәтергә төшермә, аларның нигезендә ниндидер берәр тормыш детале, вакыйгага ятканын күрәсең. Ул шигырьләргә карап үзең үткән юлны да хәтта ачык итеп күз алдына китерергә мөмкин. Тормышны үзең аша кичерми торып, юк, бер генә әйбәт шигырь дә тумый, ахрысы». Өлкән шагыйрьнең бу турыдагы фикерләре «Шигырь ничек туа?» исемле мәкаләсендә урын алган. Монда ул үзенең иҗат лабораториясенә ишекне киң ачкан. Анда теге яки бу әсәрнең язылу тарихына караган материаллар да, башка характердагы мәгълүматлар да әллә ни кадәр.

Шигырьләр чын поэзия әсәрләре булсын өчен, тагын бер мөһим моментны онытырга ярамый: шагыйрь туктаусыз эзләнергә тиеш. Ә эзләнүләрнең, С. Хәким әйткәнчә, чиге юк! Аның үз әсәрләре дә канәгатьсезлек, тынгысызлык аркасында туган. Әнә шул туктаусыз уйланулар, тормыш тәҗрибәңне бүгенге чынбарлык белән чагыштырып караулар «Давыл чәчәкләре», «Бер бәйгедә күргән идем аны», «Үрләр аша», «Дуга», «Васыятьләр» кебек зур эмоциональ куәт салынган әсәрләр язуга китергән.

С. Хәким тормышны, кешеләрне яхшы белә. Китапта урнаштырылган «Лейтмотив» дип аталган эсседә, мәсәлән, шагыйрьнең үз ягы белән, Казан арты белән аерылгысыз бәйләнгәнлек хисе уртада тора. «Шагыйрьне беренче яза башлаган елларыннан алып гомеренең соңгы минутына чаклы көн саен борчый, моңландыра, һаман дәшә-чакыра торган бернәрсә бар, ул — туган як, туган җир, халык һәм аның рухы. Бу — шагыйрьне халыкка, җиргә тоташтырган моң — синең бөтен иҗатыңның бер лейтмотивы кебек күзгә күренми яши. Шул моң, шул лейтмотив булмаса, бар да таралыр, бар да юкка чыгар төсле»,— ди ул.

[1] С. Хәким. Үз тавышың белән. Татарстан китап нәшрияты. 1969 ел.

Әлеге юлларда зур хакыйкать ята. Әйе, Сибгат Хәким авылдан килеп шагыйрь булган. Ләкин аның хис-кичерешләре, кайбер башка кешеләрнеке кебек, авылның басу капкасыннан чыккач та түгелеп-чәчелеп калмаган. Авылдашларының бар тормышы, бүгенгесе һәм үткәне, сөенечләре һәм көенечләре аның күз алдында. Шуңа күрә, якташларының образларын биргәндә, шагыйрьгә схематизм яки риторик алымнар белән эш итүнең бөтенләй кирәге юк. Кайберәүләр гел туган як турында язу чикләнгәнлеккә алып килә, дип карыйлар. Бу дөрес караш түгел. Туган як темасы аша гомумкешелек өчен мөһим булган проблемалар куела ала һәм талантлы язучылар, шагыйрьләр моны эшлиләр дә. «Үз ягың... Бу мине бикләмәде дә, чикләмәде дә... Бөек Ватан сугышында кулга корал тотып яклаган Россиянең Ржев, Орел, Курск кебек борынгы шәһәрләре Казан шикелле үк якын, Украина җирләре дә Казан арты шикелле үк күңелгә газиз булып калды...»— ди С. Хәким.

Иҗатының беренче елларыннан ук Сибгат Хәким башка халыкларның әдәбиятына, поэзиясенә зур ихтирам белән карый. Әйтергә кирәк, 1937 елларда аның шигъриятенең киңәттән ачылып китүе педагогия институтында төрле халыкларның әдәбиятын ныклап өйрәнү аркасында мөмкин булды. Әнә шул вакытлардан бирле ул Пушкинны, Лермонтовны, Некрасовны үз күрә, «бөтенләе белән моңнан гыйбарәт» булган Тарас Шевченконы якын итә. Шуның белән бергә, ул каләмдәш дусларының иҗатларын да читләтеп узмый, алардагы уңай якларны күрә, күрсәтә белә. Менә Әхмәт Фәйзи... Шагыйрь, драматург, прозаик, либреттист. Бу зур талантның татар әдәбиятындагы урынын С. Хәким бик дөрес билгели. Революциядән соң калкып чыккан Һади Такташ, аның тирәсендә Хәсән Туфан, Фәтхи Бурнаш һәм Муса Җәлилләр... С. Хәкимнең чордаш шагыйрьләре хакында язылган мәкаләләре шул яклары белән кызыклылар: аларда автор, әллә ни озын-озын дәлилләр китереп тормастан, кыска, ләкин төгәл итеп, теге яки бу шагыйрьнең художество фикерләвенә, стиленә хас үзенчәлекләрен күрсәтеп үтә. Әхмәт Исхак иҗатында эпик башлангычның өстен чыгуы, Нури Арслановның матур җыр текстлары язуын, Ф. Хөснинең художник-гражданин булуын күрә шагыйрь, үзенчә иҗат итүче әдипләребезнең булуына шатлана. Китапта урнаштырылган мәкаләләрнең берничәсен С. Хәким яшьрәк буын шагыйрьләр иҗатына багышлый. Үз иҗатына иң югары таләпләрдән торып караган Әнвәр Давыдов, юморны, сатираны бик белеп иярләгән Г. Афзал, яшьлек җырчысы И. Юзеев, кыска формаларда уңышлы шигырьләр иҗат итүче яшь шагыйрь Р. Харисовлар хакында сөйләгәндә, Сибгат Хәким игътибарын алар иҗатындагы иң әһәмиятле моментларга, уңышлы якларга юнәлтә.

Шигърият турында, шагыйрьләр турында шагыйрьләр тарафыннан язылган китаплар безнең татар әдәбиятында, кызганычка каршы, сирәк күренә. Ә укучы моңа сусаган. С. Хәкимнең әлеге җыентыгы исә шигырь сөючеләргә әйбәт бүләк. Шагыйрьнең тормыш һәм поэзия турындагы фикерләре безне дә уйландыра, чынбарлыкка тирәнрәк күз салырга ярдәм итә.

**Зөфәр РӘМИЕВ.**

Сәлим Шәйдуллин

# ТУТЫКМАС КОРАЛ

*Татар совет әдәбиятында мәсәл жанрының үсеш тенденцияләре*

Мәсәл жанрының бер чорда активлашу, икенче бер чорда пассивлашу закончалыгы, әлбәттә, татар әдәбияты өчен дә хас күренеш. Ләкин монда специфик үзенчәлекләр бар. Ислам диненең йогынтысы һәм царизмның милли-колониаль изүе көчле булу сәбәпле, бездә, гомумән, сатирик жанр соңга калыбрак туды. Феодализмның чәчәк аткан чорында татар әдәбияты Крылов югарылыгында димибез, хәтта оригиналь мәсәлләр иҗат итүче дә тудыра алмады. Әдәбият ул бурычны үтәргә җитлекмәгән иде әле. Зур әсәрләр эчендә гыйбрәтле вакыйгалар төсендә сөйләнеп үтелгән мәзәк яки хикәят формасындагы мәсәлләр генә очрый иде. Мәсәлән, XIV гасырда яшәгән шагыйрь Сәйфи Сараиның «Китабе Гөлстан бит-төркиۥендәге «Гөл һәм туфрак»ны [1], XVI гасыр урталарында яшәгән шагыйрь Мөхәммәдьярның «Төхфәи Мәрдән»ендәге «Җеп эрләүче сатучы ир белән хатын турында»гы хикәяне һәм XVII гасыр азагында яшәгән шагыйрь Һибәтулла Салиховның «Хикәяте фиттөмсил» дигән әсәрен шулар исәбенә кертергә була [2].

Ләкин феодализм җәмгыятенә каршы көрәш үскәннән-үсә барды һәм ул әдәбиятта да чагылыш табарга тиеш иде. Шундый көрәш формасы — мәсәл туарга тиеш иде. Һәм ул, башка телләрдән тәрҗемә ителеп булса да, татар әдәбиятына да килеп керде.

1905 елгы революция җиңелгәннән соң, татар халкының патша самодержавиесе һәм үз буржуазиясе тарафыннан изелүе тагын да көчәйде, алдынгы карашлы язучылар өчен иҗат итү шартлары, хак сүзне ачыктан-ачык сөйләү мөмкинлекләре бермә-бер кыенлашты. Менә шул елларда татар демократик язучылары Г. Тукай һәм М. Гафури шигъри мәсәл иҗат итү эшен башлап җибәрәләр.

1917 елларда революцион көчләр тупланып, буржуаз җәмгыятькә каршы ачык көрәш башланып киткәч, туры сүзне яшерү ихтыяҗы бетә, татар әдәбиятында мәсәл жанры тагын «югала». Хәзер инде сатираның ачыктан-ачык фаш итә торган төрләре игътибар үзәгендә тора.

Ләкин, сатираның күп кенә төрләре киң кулланылса да, татар әдәбиятында мәсәл жанры 20 елларда да игътибардан читтә калып килде. Мәгълүм булганча, 20 еллар әдәбияты үзенең үтә чуар, катлаулы һәм каршылыклы булуы белән аерылып тора. Бу чор — әдәбиятта эзләнүләр чоры иде. Язучылар яңа заман темасы, яңа кеше, яңа герой, яңа әдәби форма эзләү кебек мәсьәләләр белән мәшгуль

---

[1] Х. Госман. Ерак гасырларның авазы. «Казан утлары» журналы. 1966 ел. 12 сан. 132 бит.

[2] Ә. Исхак. Мәсәл турында кайбер фикерләр. «Идел» альманахы. 1959 ел. 2 сан. 83 бит.

булдылар. Мәсәл кебек «иске» образлардан, «иске» сурәтләү чараларыннан файдаланган «искечә» тәнкыйть жанры берәүне дә диярлек кызыксындырмады. Имажинистлар, футуристлар өчен ул «искелек калдыгы», «үткән заман чүбе» генә иде.

Дөрес, үзенең иҗат стиле белән мәсәл жанрына аеруча якын торган М. Гафури поэзиядә мәсәл алымын куллануданн бөтенләй үк аерылып бетә алмады. «Урак һәм Чүкеч», «Күз бәйләш — сукыр тәкә» кебек күп кенә мәсәлгә охшашлы шигырьләр, тәмсилләр язды. Хәтта 20 елларның азагында балалар өчен «Җиләк белән Алма агачы» исемле бер мәсәл дә иҗат итте [1]. Ләкин ул мәсәл, баштанаяк әхлак өйрәтүгә корылган булуы һәм Крыловка кадәрге чорда ук язылган йомшак мәсәлләрне хәтерләтүе аркасында, киң катлау укучыларның игътибарын җәлеп итә алмады.

Мәсәлгә охшашлы кайбер аллегорик шигырь һәм «тешсез» мәсәлләрне исәпләмәгәндә [2], татар әдәбиятында мәсәл жанрының 30 һәм 40 елларда да үсеше күренми. Беренчедән, моңа шәхес культының кире йогынтысы сәбәп булса (хәтта совет мәсәленең нигезен салган Д. Бедный да бу елларда мәсәл жанрыннан иркенләп файдалана алмады), икенчедән, Ватан сугышы тоткарлады. Сугыш елларында язучыларның игътибар үзәгендә күбрәк көннең кадагына сугып барырдай агитацион әсәрләр (лирика, публицистика, нәсер, очерк, кыска хикәяләр һ. б.) язу тора иде. Заман кирәшкә чакыручы патриотик әсәрләр сорый иде.

Бары тик Бөек Ватан сугышы чоры үтеп, «Чаян» журналы яңадан чыга башлагач кына, мәсәл жанры татар совет әдәбиятында җанланып китә. 1953 елда «Совет әдәбияты» журналы «Юмор һәм сатира» бүлеген ачып җибәрә. «Чаян» журналы редакциясе дә җиң сызганып эшкә керешә: оригиналь мәсәлләр белән бергә, башка милләтләрнең уңышлы яңа мәсәлләреннән дә тәрҗемәләр бирел бара башлый. Болар, әлбәттә, татар совет әдәбиятында мәсәл жанрының үсешенә уңай тәэсир ясамый калмый. Бер «Чаян» белән «Совет әдәбияты» («Казан утлары»)нда гына да 150 дән артык оригиналь мәсәл басыла. «Совет Татарстаны» («Социалистик Татарстан»), «Татарстан яшьләре» газеталары битләрендә дә мәсәлләргә шактый зур урын бирелә. Берничә мәсәл җыентыгы дөньяга чыга.

Сугыштан соңгы елларда бездә «Бедный теле»ннән аеруча актив файдаланган һәм файдаланып килүчеләрдән Ә. Исхак, Г. Шамуков, С. Баттал, Ә. Фәйзи, Ә. Еникәй, З. Мансур, Ш. Маннур, З. Нури һәм башка язучыларның исемнәрен күрсәтергә була. Ә. Исхак әйтмешли, «хәзерге көндә бездә инде берничә генә булса да мәсәл язмаган шагыйрь аз дияргә мөмкин» [3].

Советлар Союзының башка милләтләрендәге кебек үк, татар мәсәле дә эчтәлек һәм форма ягыннан зур үзгәреш кичерде. Шулай булмый хәле дә юк. Тар максатны күздә тотып, иске чараларга һәм әхлак өйрәтүгә нигезләнеп язылган мәсәл бүгенге укучының югары таләпләрен канәгатьләндерә алмый. Хәзерге мәсәлдән барыннан да элек политик үткенлек, конкрет максатлылык һәм югары идеялелек таләп итерә. Совет укучысы мәсәлнең яңа җәмгыять үсешенә кирт булып торган кимчелекләрне фаш итү өчен язылганлыгын сизеп, тоеп торырга тиеш. Шул ук вакытта мәсәлче халыкның гасырлар буена тупланып килгән бай акыл тәҗрибәсенә таянып эш итә.

Билгеле, күпме генә үзгәреш кичерсә дә, мәсәлнең төп жанр үзенчәлеге югалмый. Югыйсә, ул мәсәл булудан туктар иде. Аллегорик хикәяләү, мораль-нәтиҗә (нравоучение), көлү (насмешка), гомумиләштерү кебек алымнар бүгенге мәсәлләргә дә хас. Тик бу алымнарның хәзер функцияләре беркадәр үзгәрде.

Фикеребезне ныгыту өчен, совет мәсәле белән капитализм шартларында язылган берәр мәсәлне чагыштырып карыйк. Әйтик, М. Гафуриның реакция елларында

[1] М. Гафури. Сайланма әсәрләр. Казан. 1954 ел. 1 том. 400 бит.

[2] «Кәя күбәләге һәм тычкан» («Совет әдәбияты». 1939. 1 сан); «Яфрак һәм чикләвек» («Совет әдәбияты». 1939. 6 сан); «Каз белән каракош» («Совет әдәбияты». 1939. 12 сан); «Фил һәм таракан» («Чаян». 1940. 2 сан); «Попугай» («Чаян». 1940. 9—10 саннар); «Ат һәм машина» («Чаян». 1940. 21 сан); «Ефәк корты һәм Үрмәкүч» («Совет әдәбияты». 1945. 9 сан); «Ертык белән Тишек» («Совет әдәбияты». 1946. 4 сан).

[3] Ә. Исхак. Мәсәл турында кайбер фикерләр. «Идел» альманахы. 1959 ел. 2 сан. 83 бит.

(1907) язылган «Әтәч белән Сандугач»ын алыйк. Тәрәзә төбендәге читлектә утырган бер Сандугач җим эзләп йөргән Әтәчтән көлә һәм үзенең азык эзләп интекмәве, һәрвакыт тук яшәве белән мактана. Әтәч аңа болай дип җавап бирә:

— Ни файда аш күплектән?
Чыга алмыйсың читлектән.
Хәр көенчә азык эзләү —
Күп артыктыр чүплектән.

Сандугач, әченнән тынып, башын түбән сала. Автор шундый нәтиҗәгә килә:

Булмаса һич ихтыяр,
Ләззәттә ни рәхәт бар?
Хөрлек ни дигән сүз ул?
Өйрәнегез, балалар![1]

Мәсәл «Эзоп теле» белән язылган. Аллегория биредә фикерне яшерү өчен хезмәт итә. Бу мәсәлнең төп максаты — гомерен кичергән капиталистик стройны какшатырга һәм җимерешергә ярдәм итү, аллегория артына яшерелгән төп идеясе — азатлык өчен көрәшкә чакыру. Аңлашыла ки, реакция шартларында мондый идеяне башка формада әйтү һич мөмкин була торган эш түгел.

Совет чоры мәсәленә килик. Ә. Исхакның 50 еллар башында язылган һәм образлары ягыннан югарыдагы мәсәлгә якын торган «Күркә белән Сандугач»ын алыйк. Күркә бер атна эчендә шигъри роман язып ташлый һәм Сандугачтан шул роман турында фикер әйтүен үтенә. Сандугач, романны бик җентекләп укып чыккач, әлегә аның бернигә дә ярамаганлыгын әйтә, өр-яңадан эшләргә куша. Бер айдан соң Күркә тагын килә. Сандугач романны укып чыга, тагын бик нык эшкәртергә кирәклеген әйтә. Һәм бу шулай берничә мәртәбә кабатлана. Нәтиҗәдә, икәүләп тырыша торгач, ярыйсы гына әсәр языла. Кайбер рецензентлар романны хәтта мактап та чыгалар. Бу хәлне күреп, Күркә Сандугачның ярдәме турында бөтенләй оныта һәм бик нык күпереп, мактанып йөри башлый. Мәсәл болай тәмамлана:

Андый күркәләр
Безнең арада очрый әле һаман[1].

Монда инде эзопча сөйләүнең эзе дә юк. Эреләнү, һавалану символы булган күркә образын мәсәлче бары тик бер тиешлек эше белән күпереп йөрергә яратучы кешеләрдән көлүне көчлерәк һәм тәэсирлерәк итү өчен генә куллана. Сандугач образында да, мәсәлнең мораль өлешендә дә фикер яшерү күренми. Мәсәлнең төп максаты — бушбугазлыкны фаш итү, төп идеясе — яңа җәмгыятьнең үсешенә комачаулаучы шундый кимчелекләрне бетерергә чакыру. Билгеле, бу идеяне башка жанрларда да әйтеп булыр иде. Ләкин ул болай ук тәэсир ясый алмас иде. Шушы идеянең тулы яңгырашына ирешү өчен автор аллегорияне иң яхшы поэтик форма итеп санаган һәм ялгышмаган.

Бу ике мәсәл тышкы формалары белән дә аерылып тора. М. Гафури мәсәле тигез иҗекле шигырь белән язылган булса, Ә. Исхак мәсәле ирекле шигырь белән иҗат ителгән. Ирекле шигырь белән язу мәсәлчегә әсәрне сөйләү формасында алып барырга, кирәксез сүзләрдән котылырга ярдәм итә. Ләкин ирекле шигырь белән язылса да, чын татар совет мәсәле тудыруда әле беренче адымнар гына ясау чоры булганлыктан (1954 ел), Ә. Исхакның бу мәсәлендә М. Гафурилар заманына хас булган озын язу, еш кабатлау кебек кимчелекләр бар. Соңрак, 50 елларның азагына таба, Ә. Исхак «Ялагай белән Бюрократ», «Фәнни хезмәт», «Куян — редактор», «Попугай — лектор», «Карт Имән белән яшь Егет», «Мәче һәм рәсем» кебек уңышлы мәсәлләр иҗат итте.

Ә. Фәйзи, С. Баттал, Ә. Ерикәй, Г. Шамуков һәм башка язучыларның да 50 елларда язылган күп кенә мәсәлләре турында уңай яктан озак сөйләргә мөм-

[1] М. Гафури. Сайланма әсәрләр. Казан. 1954 ел. 305—306 битләр.
[2] Ә Исхак. Сайланма әсәрләр. Казан. 1965 ел. 129 бит.

кин булыр иде. Кызганычка каршы, совет чорында язылган бөтен мәсәлләрне дә заман таләпләренә җавап бирәләр дип булмый. Классик мәсәлнең тышкы формасына сукырларча ияреп, бүгенге чор өчен тәэсир көче аз булган йомшак әсәр иҗат итүчеләр дә шактый. Кайбер иптәшләр мәсәлнең яңа асылына төшенеп җитмиләр, аны бары тик хайваннар тормышына күчереп язылган гыйбрәтле хикәя дип кенә аңлыйлар, әхлак өйрәтү белән мавыгалар. Андый авторларның мәсәлләре филгә салам белән, ә чебенгә күсәк белән сугуны хәтерләтә.

Мәсәлнең әдәбиятта үз урыны бар. Оста кулында ул зур эстетик көчкә ия булган шигъри әсәр булып яңгырый.

Мәсәлнең яшәү-яшәмәү мәсьәләсе бер язучы теләгенә генә бәйләнмәгән. Кайчагында язучы мәсәл формасына мөрәҗәгать итәргә үзеннән-үзе мәҗбүр була. Моңа ышану өчен, берәр мәсәлнең туу тарихын карап китәргә мөмкин. Үзенең сөйләвенә караганда, шагыйрь Ә. Исхак бервакыт Яңа ел маскарадында шундый хәлгә очрый. Ялагайлардан туеп беткән зур бер түрә, үзен танытмыйча иркенләп ял итәргә уйлап, куян битлеге киеп, Яңа ел маскарадына килә. Ләкин, үзен мәһабәт рәвештә тотып, эре генә атлап керүе була, залдагылар моны танып алалар һәм, төрлечә ялагайланып, тирәсендә кайнашырга керешәләр. Түрә, кәефе кырылып, тиз генә борыла да залдан кире чыгып китә... Шушы кызыклы вакыйга Ә. Исхакта әсәр язу теләген тудыра. Күп тә үтми, ул «Түрә маскарадта» исемле шигъри мәзәк иҗат итә. Әмма соңрак автор үзе дә бу әсәрдән канәгать булмый: вакыйгага үткенлек җитеп бетми кебек. Әсәрне тагын да көчлерәк итәсе, фикернең тулы яңгырашына ирешәсе килә аның. Тик моның өчен нинди формадан файдаланырга? Автор «Түрә»не «Арслан түрә»гә алыштырырга һәм «Мәзәк»не «Мәсәл-мәзәк» итеп үзгәртергә карар кыла. Соңрак бу варианты да ошамый башлый, әсәрнең тәэсир итү көчен тагын да арттырырга мөмкин булып тоела. Ниһаять, автор шушы фикернең тулы яңгырашына ирешү өчен иң яхшы поэтик форма итеп мәсәл формасын саный һәм әсәрнең өченче вариантын иҗат итә. «Куян битлеге киеп» сүзен «Болан битлеге киеп» дигән сүзгә алыштыра (чөнки арслан кебек зур гәүдәле җанварга куян битлеге бик үк килеп бетми), «Мәсәл-мәзәк»нең «мәзәген» һәм «Арслан түрә»нең «түрә»сен төшереп калдыра. Нәтиҗәдә, хәзер безгә мәгълүм булган «Арслан маскарадта» исемле уңышлы мәсәл туа, шагыйрь конкрет бер вакыйганы сурәтләү аркылы зур гомумиләштерүгә ирешә:

Мин аңарга бары шундый киңәш бирәм:
Котылыйм дисәң ялагайлардан,
Иң алдан
Үзеңне тотарга өйрән! [1]

Югарыда сөйләгәннәрдән күренүенчә, 50 елларда иҗат иткән татар совет мәсәлчеләре арасында ике тенденция яши иде. Беренчесе — заман мәсьәләләрен яңача чишәргә, мәсәлнең тематикасын киңәйтергә, шаблон сюжетлардан качарга омтылу, икенчесе — элекке традициягә сукырларча иярү, мәсәлнең иске, үтелгән тар рамкаларына ябышып яту. Беренче тенденция көчлерәк һәм тирәнрәк булды. 60 елларда мәсәл жанрында яңа эзләнүләр башланды.

* * *

КПССның XX һәм XXII съездларыннан соң совет әдәбиятында барлык төр жанрларның да һәрьяклап үсүе өчен зур мөмкинлекләр туды. Партиябез карарлары яктылыгында туган уңай шартлар мәсәл жанрында да яңа эзләнүләргә киң юл ачты. Икенче сәбәп бу жанрга карата таләпләрнең артуы белән бәйле. Иске формада язылган мәсәлләр, иске образларның (арслан, аю, бүре, төлке һ. б.) кабатлануы укучыны туйдыра башлады. Мәсәл көчле фаш итү коралы булып калырга тиеш. Укучы игътибарыннан читтә калмасын, аны уйландырсын өчен, мәсәлдә образлылыкны һәм комизмны көчәйтергә кирәк иде.

[1] Ә. Исхак. Сайланма әсәрләр. Казан. 1965 ел. 142 бит.

Бүгенге мәсәлдә образлылыкны көчәйтү өчен кулланылган чараларның төрләре бик күп. Шундыйлардан: образ буларак тормыш-көнкүреш әйберләрен, төрле предметларны һәм төшенчәләрне куллану, юмористик сюжет төзү, көтелмәгән җавап чыгару, фикерне әйтеп бетермәү (бу алым хәзер художество чарасы буларак файдаланыла), сүз уйнату, кире образдан уңай образны «гаепләтү» кебек чараларны санарга була.

Татар әдәбиятында образ буларак тормыш-көнкүреш әйберләре сурәтләнгән яңа төр мәсәлләрнең беренче яралгылары, сирәк булса да, 50 елларның икенче яртысында күренә башлый. Бездә яңа образлар эзләү, яңа төр мәсәлләр иҗат итү бик катлаулы төстә, кыенлыклар аша барды. Инерция буенча иске традицияләрне кабатлау, яңа кимчелекләр җибәрү күренешләре дә булды. Ул мәсәлләргә әле күбрәк яңа образларны иске форма калыбына салып сурәтләү һәм фикерне маңгайга бәреп әйтү хас иде. Мәсәлән, бу — Ә. Исхакның «Ике йорт», «Лампа белән Кояш», «Кискә белән Чой», С. Батталның «Тутыккан савыт», Г. Шамуковның «Сукыр Лампа», З. Нуриның «Ике бүрек» һәм башка мәсәлләрендә ачык чагыла.

Шуларның берсенә, әйтик, С. Батталның «Тутыккан савыт»ына күз салыйк. Кухняда һәр көнне «шалтыр-шолтыр, чаң-чоң» китереп савыт-сабаларны юалар. Тик яхшы эшләгәне өчен шушы кухняга бүләк итеп бирелгән чәчәкле елтыр бер Савыт кына юылмый. Чөнки аның белән ашаучы да, эчүче дә юк. Иң югары шүрлектә, «почетлы урында» кадерләп кенә саклыйлар. Көннәрдән бер көнне Кухарка аңа май сала да, кыздырырга куеп, каядыр чыгып китә. «Әйләнеп керсә — бөтен кухня тулы ачы кара төтен». Тиз генә күтәреп караса, ни күрсен — почетлы Савытның төбе төшеп, мае агып, янып беткән! Чөнки ул «үтәдән-үтә тутыккан булган икән!» Автор мондый нәтиҗәгә килә:

Гыйбрәт: һәркем мохтаҗ тәнкыйтькә;
Почетлыларны да калдырмыйк читтә!
Юкса ул тутыгып һәм тулып йөрәк мае,
Җаваплы урында изрәп калмагае! [1]

Бу мәсәл, бер яктан, иске форма калыбына салып язылган булуы һәм фикерне маңгайга бәреп әйтүе, «гыйбрәт» өйрәтүе белән элекке йомшак мәсәлләрне хәтерләтсә, икенче яктан, яңа образлар куллану һәм сүз уйнату кебек чараларның беренче үрнәкләрен бирүе белән яңача яңгырый. Шулай да сүз уйнату алымыннан уңышлы файдаланып язылган мәсәлләр 50 елларда аз очрый иде әле. Ул елларда татар совет мәсәлчеләре юмористик сюжет төзү, көтелмәгән җавап чыгару кебек алымнарны күбрәк кулландылар.

Юмористик сюжетка корылган мәсәлләрдән югарыда Ә. Исхакның «Арслан маскарадта» исемле әсәрен карап үткән идек инде. Шуңа күрә кабат мисал китереп тормыйбыз.

Образларының яңа булуы һәм көтелмәгән җавап чыгаруы ягыннан Г. Насыйровның «Тәгәрмәч» исемле мәсәле аеруча характерлы. Бер Тәгәрмәч, үзенә игътибарның аз булуы сәбәпле, бик нык рәнҗеп, йөк тоялгән Арбаны харап итәргә карар кыла. Һәм бер көнне, уңайлы моментны туры китереп, күчәрдән төшеп тә кала... Әмма Арбага бер зыян да килми: «Үз юлы белән дөмбердә дә дөмбердә». «Чөнки игътибар итсәк, төшеп калган икән... бишенче көпчәк». Артык бер генә сүз дә кирәкми. Мәсәл шунда бетәргә тиеш иде. Ләкин автор, инерция буенча иске традициягә кереп китеп, тагын дүрт юл өстәп куя, идеяне «чәйнәп бирү» юлына баса:

Фикеребез шул:
«Бишенче көпчәкләрне»
Кирәк куярга кирәк урынга,
Ярамасалар... утынга [2].

Мәсәлнең төп өлешендә дә артык сүзләр шактый. «Күммиләр дангa», «сөйләгәчтен кул чапмыйлар» кебек сүзләр әсәрдә үзләре дә арбадагы бишенче көпчәк

[1] С. Баттал. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан. 1959 ел. 178—179 битләр.
[2] «Чаян» журналы. 1956 ел. 12 сан. 3 бит.

хезмәтен генә үтиләр. Иске традицияләрдән аерылып җитә алмау, урынсыз сүзләр куллану нәтиҗәсендә, кыска гына вакыйгаңы сурәтләүгә корылган мәсәл 42 юлга сузылган.

Әмма, әйткәнебезчә, әсәрдә яңа элементлар да юк түгел. Шагыйрь кызыклы сюжет, яңа образлар тапкан, көтелмәгән җавап чыгару кебек әһәмиятле алым кулланган. «Әлеге Көпчәк ычкынды кучәрдән...» дигән җиргә җиткәч тә, без «менә хәзер Арба ватылыр, аңа төялгән йөк харап булыр» дип көтәбез. Ләкин көткәнебезнең киресе килеп чыга: Арба исән-имин кала. Көпчәкнең бишенче көпчәк булуы да беленгәч, сатирик юмор туа һәм укучыны елмаерга мәҗбүр итә.

Яңа образлар һәм алымнар эзләү барышында татар мәсәлчеләренең иҗатында бүгенге рус мәсәлчеләренең йогынтысы да шактый нык сизелә иде. Мәсәлән, Ә. Исхакның «Ике башак» (1955) һәм З. Нуриның «Ике бүрек» (1957) дигән мәсәлләре үзләренең идея юнәлешләре белән С. Михалковның «Москвич» белән «Победа» исемле мәсәлен хәтерләтәләр. Бу мәсәлләрнең өчесендә дә ике предметны үзара сөйләштерү юлы белән үз интересын гына кайгыртучы начальник тәнкыйтьләнә. Идея кабатланышы шулай ук З. Мансурның «Үгез» (1953), Н. Таҗиевның «Әлгәч» (1958) һәм Ә. Исхакның «Йок һәм Дөя» (1959) исемле мәсәлләрендә дә күренә.

Бүгенге мәсәлчеләрнең образлар белән эш итүендә төп дүрт төрле юнәлеш күзәтергә мөмкин. Алар: иске образларны иске формада сурәтләү, яңа образларны иске форма калыбына салып язу, иске образларны яңа формада гәүдәләндерү һәм яңа формада яңа образлар иҗат итүдән гыйбарәт. Әлбәттә, бер юнәлештә начар мәсәлләр генә, ә икенче юнәлештә гел яхшылар гына языла дип аңларга ярамый. Тәҗрибәле мәсәлче тарафыннан зур проблема күтәреп һәм көлке тудыру чараларыннан уңышлы файдаланып язылса, образлары һәм формасы ягыннан искечә булса да, мәсәл укучы игътибарыннан читтә калмый.

Яңа образлардан һәм чаралардан уңышлы файдалану очраклары да бар. Бу юнәлештә иҗат ителгән уңышлы мәсәлләр арасында Ә. Гайнановның «Түбәннән тәнкыйть» дигән әсәре аеруча игътибарга лаеклы. Кер кыстыргычлары Баганаңың чери һәм какшый башлавы турында үзара шау-шу куптаралар. Әмма Бауга тезелгәч, барысы да авызларын йомып калалар. Автор мондый нәтиҗәгә килә:

> Әйе,
> Тыгыз бәйләнештә иде
> Багана белән Бау.

Мәсәлче актуаль мәсьәлә күтәргән. Чыннан да, андый кешеләр бүген дә очрыйлар әле. Алар: безнең начальникның җитәкчелек итү методлары искерде! Аны алыштырырга кирәк!» дип колактан-колакка сөйләшеп йөриләр, ә отчет-сайлау җыелышлары килеп җиткәч — ләм-мим. Авызларына су капкандай утыралар. Автор әнә шундый кимчелекле күренешләрне фаш итү бурычын куйган һәм максатка ирешкән. Монда инде фикер маңгайга бәреп әйтелми, мәсәлче аны укучыларның үзләренә уйларга калдыра. Ләкин биредә фикерне әйтеп бетермәүнең максаты элекке чор мәсәлләрендәге фикер яшерү максатыннан тамырдан аерыла. Сыйнфый җәмгыять чорында иҗат иткән мәсәлчеләр фикер яшерү алымын дошманны алдау өчен, аның каршы ударларыннан саклану өчен маскировка төсендә кулланган булсалар, бүгенге мәсәлчеләр аны, әйткәнебезчә, сәнгатьчә сурәтләү чарасы рәвешендә файдаланалар. Сатирик жанр буларак, мәсәл көлке тудырырга һәм укучыны уйландырырга тиеш. Мәсәл жанрының үзенчәлеге шунда — комик элементлардан башка ул яши алмый. Фикерне яшереп сөйләү — көлке тудыру һәм укучыны уйландыру өчен иң яхшы чара. Шуңа күрә фикерне әйтеп бетермәү хәзерге мәсәлләр өчен дә кирәкле чараларның берсе булып кала.

Соңгы ун ел эчендә татар әдәбиятында күп кенә шигъри кыска мәсәлләр иҗат ителде. Тирән мәгънәле, образлары оста файдаланылган кыска мәсәлләр туу — мәсәл жанрының үзгәрүен һәм үсүен билгеләүче иң характерлы сыйфатларның берсе. Андый мәсәлләр 6—8 юлдан артмый. Күп очракта ул 4 юллык, хәтта 2 генә юллык та булырга мөмкин. Ләкин бу юнәлештә дә эшләр шома гына бар-

мый. Фикерне маңгайга бәреп әйтү, образлардан дөрес файдаланмау, вак проблемалар белән мавыгу кебек күренешләр кыска мәсәлләр арасында да очрый.

Иске образларны яңа форма калыбына салып гәүдәләндергән мәсәлләр арасында уңышлылары да күп. Ф. Гомәровның «Кысла» дигән мәсәлен («Чаян». 1960. 19 сан. 7 бит) карыйк. Бер Кысла, җыелышта катнашучыларны ярышка чакырып, ялкынлы чыгыш ясый. Җыелыш бетү белән, ярыш башлана. Әле генә ялкынлы речь сөйләгән Кысла «Стартка!» дип кычкыра да артка таба китеп бара... Монда инде укучы заманны буташтырмый, авторның актуаль мәсьәлә күтәргәнлеген, бушбугазлыкны фаш иткәнлеген тоеп тора. Мәсәлдә фикерне әйтеп бетермәү һәм көтелмәгән җавап чыгару кебек көлке тудыру алымнары уңышлы файдаланылган.

Яңа образларны яңа формада сурәтләү алымына килик. Бу юнәлештә аеруча Ә. Исхак уңышлы эшли. Аның образ буларак тормыш-көнкүреш әйберләрен, төрле предметларны сурәтләгән шигъри кыска мәсәлләре фикерне әйтеп бетермәү, укучыны уйланырга мәҗбүр итү ягыннан һәм зур проблема күтәрүләре, шигъри фантазиягә бай булулары белән зур популярлык казаналар. Шулай ук алар тематикасы һәм кулланылган чаралары төрле-төрле булулары белән дә аерылып торалар. Берничә мисал китерик. Менә «Пәрдә» исемле мәсәл:

— Артымда ни барын
Күрсәләр әгәр дә,
Нишләрмен мин? — диеп,
Калтырый ди Пәрдә.

Өстән генә карaганда, әллә ни искитәрлек нәрсәсе юк та кебек. Әмма Пәрдә образының нигезендә кыңгыр эшләрне яшереп торучы җанлы кеше образы ятканлыгын исәпкә алсак, әсәр безне уйланырга мәҗбүр итә. Пәрдәнең үзе яшереп торган кыңгыр эшләр фаш ителүдән куркып, калтырап яшәве көлке туууга сәбәп була.

Шагыйрьнең «Телефон» дигән мәсәлендә ирония тагын да үткенрәк төс алган:

Телефон — ул шундый
Хәйләкәр аппарат:
Үзгәртә тавышын
Кешесенә карап!

Бу әсәрдә кулланылган көлке тудыру алымы яңа һәм үзенчәлекле. Беренче мәсәлдә Пәрдә образы һәм аның артындагы гөнаһлы күренешләр икесе дә көлү объекты итеп алынган булсалар, биредә инде Телефон образы тәнкыйтьләнми, бәлки аның аша сөйләшүче ялагай яки икейөзле кешеләр фаш ителә.

Ә. Исхакның ике юллык мәсәлләре арасында да матур үрнәкләрне күп табарга мөмкин. Мәсәлән, «Үтә беркатлылык» дигән мәсәлдә үз-үзенә гадәттән тыш югары бәя биргән геройны көлкегә калдыру алымы бик уңышлы кулланылган:

Әйткән барометр бер заманны:
— Мин ясыйм бит, дуслар, бу һаваны!

Ә «Кинаясез мәсәл»ендә исә кире образдан уңай образны «гаепләтү» алымы оста файдаланыла:

Аяк сөртми уза да ул синең түргә:
— Бигрәк пычрак яшисең! — дип сине сүгә.

Кыска гына мәсәлгә автор зур идея сыйдыра алган. Башына «Кинаясез мәсәл» дип куелса да, әсәрдә кинаяи ярылып ята. Бу инде үзе үк мәсәлченең кинаядән оста файдалануын күрсәтә.

Ә. Исхак яңа төр мәсәлләр иҗат итү эшенә җиңел генә карамый. Ул үзенең кыска мәсәлләрен басылып чыкканнан соң да кат-кат эшли. Мәсәлән, аның архивында «Геометрик көнләү» дигән мәсәленең берничә варианты саклана. Бу мәсәлнең татар матбугатында басылып чыкмаган соңгы вариантын карап үтү кызыклы булыр дип саныйбыз:

Кәкре Сызык
Түгәрәк Сызыктан кенли:
Яшерә, имеш, ул очын шулкадәр нык,—
Кая яшергәнен һичкем белми!

Күренүенчә, мәсәлче беренче варианттагы Туры Сызык образын Кәкре Сызык образына алыштырган. Ни өчен? Чөнки Туры Сызыкның Түгәрәк Сызыктан көнләве бик үк ышандырып җитми. Ә Кәкре Сызыкның Түгәрәк Сызыктан (әйтик, тәҗрибәсез каракның тәҗрибәле каралтан) көнләве — табигый күренеш. Шулай итеп, шагыйрь, беренче вариант белән генә тынычланып калмавы, кат-кат уйлануы нәтиҗәсендә, төгәлләнгән әсәр иҗат итүгә һәм сатирик юморны көчәйтүгә ирешкән.

Соңгы елларда Ф. Кривин йогынтысы безнең язучылар арасына да үтеп керде. Татар матбугатында, сирәк булса да, яңа төр прозаик мәсәлләр күзгә чалына башлады. Мәсәлән, 1961 елда «Чаян» журналының 20 санында урнаштырылган «Самовар һәм Термос», «Капка», «Төймә» исемле кечкенә хикәяләр шундыйлардан. Башына «Мәсәл» дип куелмаса да, мәсәл жанрының төп сыйфатларына (сөйләү һәм максат, сатира һәм ирония, аллегория һәм гомумиләштерү) ия булганлыктан, аларны мәсәл дип карарга кирәк. Бу мәсәлләрдә күренешләр тәнкыйтьләнгән һәм фикерне әйтеп бетермәү, сүз уйнату алымнары уңышлы кулланылган. Шуларның берсенә, әйтик, «Төймә» дигәненә конкрет тукталыйк.

Кыскача эчтәлеге болай. Юл уртасында яткан ялтыравык Төймәне Бераү күреп ала да үз пинжәгенең якасы янына урнаштырып куя. Ләкин, элмәге зуррак булганлыктан, Төймә үз вазифасын үти алмый — пинжәкнең изүе гел ачык йөри. Шул сәбәпле, түбәндәге төймәләргә авырлык килә, һәм алар берәм-берәм коелып бетәләр. Алар урынына яңалары куела. Тик әлеге ялтыравык Төймә генә алыштырылмый. Чөнки ул урынына бик нык беркетелгән була. Мәсәлдә фикер әйтеп бетерелмәгән. Шулай да без аның нинди дә булса бер штатны күздә тотып язылганлыгына тиз төшенәбез. Иң өскә урнаштырылган ялтыравык Төймә образында кода-кодагыйлык юлы белән штат башлыгы итеп куелган сәләтсез яки белемсез кеше образы гәүдәләндерелә. Ләкин мәсәлдә Төймә образы түгел, бәлки аны дөрес файдалана белмәүче кешеләр, ягъни күренешләр тәнкыйтьләнә. «Тышкы ялтырау белән ялтырый иде ул», «Төймә бик югары урынга менеп утырды», «колачы җитенкерәми», «бик нык беркетелгән иде ул урынына» һ. б. ш. җөмләләр әсәрдә сүз уйнату алымының ачык мисалы булып торалар.

Югарыда сөйләгәннәрдән чыгып, мондый нәтиҗә ясарга мөмкин. Мәсәл бүгенге чорда кирәкле, актуаль жанрлардан санала, коммунистик җәмгыятьнең үсешенә комачаулаган һәртөрле искелеккә каршы көрәштә әһәмиятле корал булып тора. 50 елларда татар совет әдәбиятында «Бедный теле», ягъни совет мәсәленең асылы, төп сыйфатлары чын мәгънәсендә кулланыла башлавы, 60 елларда татар совет мәсәленең нигездә яңа формасы табылуы, яңа төр мәсәлләрнең матур үрнәкләре тууы шуны күрсәтә. Татар совет язучыларының соңгы ун ел эчендә иҗат иткән мәсәлләре бу жанрның халыкка хезмәт итү мөмкинлекләре гаять зур икәнлеген раслый.

# ГАБДУЛЛА АБЫЙНЫ СОҢГЫ КҮРҮЕМ

Мин үзем 1894 нче елда Татарстанның хәзерге Чистай районы Наратлы карьясендә туганмын [1]. Гыйлем-тәхсил алуым Казанда «Касимия» мәдрәсәсендә сигез ел.

1912 нче елда мәшһүр Хөсәен Ямашевны күмүдә катнаштым.

1913 нче елның яз көннәрендә Габдулла Тукаевның Клячкин шифаханәсендә авырып яту хәбәрен «Йолдыз», «Кояш» газеталарында укып, шәригъым Хәлил Шәймарданов белән (ул Камыргуҗа авылыннан иде) Габдулла абый янына, аның хәлен белергә барырга булдык һәм 31 нче мартта Габдулла абый яткан больницага киттек. Гәрчә ул безне белмәсә дә, без аны күреп беләдер идек. Без бит гади татар шәкертләре. Мин үзем, Габдулла абыйның шигырьләрен калдырмый укып барганлыктан, бик күп әсәрләрен яттан белүче идем.

Больницага килгәч, сестра безнең икебезне дә берьюлы уздырмады. Башлап мин керергә булдым. Ишектән керү белән зур якты бүлмә, сул якта биек караватта ике кулын баш артына куеп, ярым утырган хәлдә Габдулла абый ята. Мин аны күрүгә бөтенләй курка калдым. Ул бик ябыккан иде.

Мин аның хәлен сораша башладым. Ул, ачылып китеп, бүген хәле бераз яхшыруын, өстәлдә яткан кәгазьләрне күрсәтеп, бер шигырь язганын әйтте. Аның тиздән сәламәтләнеп чыгуын көтүебезне әйтеп, чыгарга җыенгач, ул болай диде:

— Кайчак берәү больницага авырып керсә, куркып калалар, ул, имеш, сәламәтләнә алмый дип уйлыйлар. Менә хәзер яз, бозлар китеп, һавалар яхшырса, мин моннан чыгып, дәваланырга башка якка китәм әле.

— Габдулла абый, шулай булсын, без шуны көтәбез,— дип мин аны куәтләп торам. Ул минем килүемә, гәрчә без таныш булмасак та, чиксез шатланды...

Мин аңа иптәшемнең дә килүен һәм аның коридорда калуын әйткәч, ул авыр гына:

— Керсен,— диде.

...2 нче апрель көнне чыккан газеталарда Габдулла абыйның вафаты турындагы хәбәр урнаштырылган иде.

Касыйм БОГДАНОВ.

---

[1] Бу истәлекләрнең авторы Үзбәкстанның Сыр-Дәрья өлкәсендә яши. Күп еллар казакъ һәм үзбәк халыклары арасында мәгърифәтчелек белән шөгыльләнгән, хәзер пенсиядә.



## *Гариф Гобәйгә*

Гариф Гобәй «Каланча»га менгән кеше,
Маякчының кызы белән йергән кеше,
«Ләйсән яңгыр»лар яудырып, «Без үскәндә»
Кечкенәләр өчен язган өлкән кеше,
Өстәвенә «Корьән серен» белгән кеше.



## *Сәрвәр Әдһәмовага*

Горькийларны саф татарча сөйләттерде,
«Абай»ның думбырасын көйләп бирде,—
Сәрвәр апа шундый безнең! Иренмичә
Яшьләрне дә тәрҗемәгә өйрәт инде.

НУРИ АРСЛАНОВ эпиграммалары.

## *Идрис Туктарга*

Җитмешкә җиттем дип, эштән
Туктамый безнең Туктар.
Киңәше аның: «Шәп языйк,
Кирәкми безгә чүп-чар!»





## *Мөхәммәт Садрига*

Эшен эшләр чын күңелдән,
Сүзен әйтмәс алдап ул —
Туры ярыр, туры барыр...
Чөнки шундый солдат ул!

И. Хантимиров шаржлары.
Н. Кизәнев эпиграммалары

## Зәки Нури

### Мактандылар...

Чебеш әйтте: тиздән этәч булам,—
Күзгә мине суеп ашыйлар!
Чебен әйтте: мин дә дәү фигура,
Чөнки Филне миннән ясыйлар.

### Яратуның сере бар

Яратты бит пыялачы бер агай
Йортта көн дә туп тибүче баланы.
Пыяланы бала ватып тормаса,
Пыялачы аны куя аламы?!

### Җиңеп булмый

Циркларда аю биетәләр,
Тынлаталар филне, тигрны.
Ә тормышта һаман җиңеп булмый
Ак шәрабны... һәм ак шигырьне...

### Батырлыкка ода

Эре атлап туйга бара бер Куян,
Инде хәтта сәлам бирми Бүрегә:
— Аю ала минем өлкән кызымны,
Гашыйк булды бары тик бер күрүдә!

### Бюрократ

Мин дә күрдем тере бюрократны,
Әйтте миңа: — менә, карагыз,
Кәгазь китә, кәгазь килә безгә,
Бөтенесен терки барабыз...

## Трамвайда

Яшь егет утырып барыр.
Карт абзый болай диер:
— Яшь чагында утырып калсын,
Картайгач басып йөрер!

## Сылтау өчен

— Клубы юк. Мөдир диеп нигә
Акча түли колхоз Солтанга?
— «Ник культура артта кала» диеп
Бәйләнсәләр, кемгә сылтарга?!

## Ала алмый

— Күпме әйтәм, күпме көтеп була:
Ник алмыйсың эшкә Гөлсемне?
— Бөтенесен син әйткәнгә алдым,
Куып булмый хәзер беркемне!

## Институт бетергәч

— Ник китмисең Ерак Көнчыгышка,
Тыңламасаң эшең уңмас бит?!
— Доцент әйтте: синең белем белән
Бик еракка китеп булмас! — дип.

## Хәтерләми

— Исеңдәме: «Һич онытмам!» дидең,
«Сөям!» диеп даннар тараттың?
— Хәтерләмим... Чөнки мин бит сине
Бар дөньямны онытып яраттым.

## Базга төшкәч

— Мин егылып үләр идем
Шул кадәрле эчкәнче.
— Мин бит эчкәч егылып төштем,
Төшкәнем юк эчкәнче.

## Соңга калып кайткач

— Йокла, карчык. Дәшмә, сөйләшмә!
Соңгы көне бит бу атнаның...
— Мин йоклавын, карчым, йоклармын,
Эндәшмичә ләкин ятмамын.

## Бәйрәм ашы—кара-каршы

— Ник бирмисең биш сум әҗәтеңне,
Биш ай инде йөрим артыңнан?
— Мин бит аны ун ай сорап алдым
Кадерлерәк итеп алтыннан.

## Сәүдә

— Шатлыгыңны күпме түләп алдың,
Кайгыңны син саттың күпмегә?
— Сәүдә бара... һаман иргә чыгам,
Тик әләгеп булмый иплегә.

## Кибетче «Волга» алгач

— Күр син аны, күпме акча!
Ничек урчи-үсә белә?
— Димәк, җиде кат үлчи дә
Бер катны шәп кисә белә.

## Бала белән сөйләшү

— Исемең ничек?
— Күпбелмеш.
— Ә әткәң исеме ничек?
— Әнкәй кайчакта «Пескәй» ди,
Кайчакта әйтә: «Көчек».

## Бер генә сәбәп


— Ник артыңнан синең кызлар чаба?
— Уфтанмыйча аны сөйләп булмый:
Һәммәсеннән бурыч алган идем,
Берсенә дә әле түләп булмый.

## ИЛЛЕ ЖЫР

Бу жырлар барысы да партия һәм Ленин турында. Аларны ноталары, татар һәм рус телләрендәге текстлары белән Татарстан китап нәшрияты күптән түгел бастырып чыгарды. Китапка эпиграф итеп Владимир Маяковскийның атаклы юллары бик урынлы алынган:

Партия һәм Ленин —
алар игез уллар.
Тарих-анага алар кадерлектә тигез.
Ленин дибез без
партияне уйлап.
Ә Ленинны уйлап без
партия дибез.

Укучыларыбызга зур һәм тирән эчтәлекле, форма ягыннан күп төрле, эшләнеше белән нәфис бер музыкаль альбом тәкъдим ителә. Бөек юлбашчыбыз Ленин еллыгы, туган Татарстаныбызның ярты гасырлык юбилее бүләге дә һәм партиябезнең озаклаunion булачак XXIV съездына шагыйрьләр һәм композиторларның иҗат отчеты булarak та бүләк бу. Илле жыр китабы менә кемнәрнен иҗат җимеше: шагыйрьләр М. Садри, Ә. Ерикәй, Б. Рәхмәт, Г. Лотфи, З. Мансур, З. Нури, Н. Гайсин, И. Юзеев, С. Урайский, С. Хәким, Ә. Исхак, М. Хөсәен, Г. Зәйнашева, М. Ногман, Х. Вахит, Н. Дәүли, Ә. Давыдов, Г. Латыйп һәм башкалар; композиторлар С. Сәйдәшев, М. Мозаффаров, Н. Җиһанов, И. Шәмсетдинов, А. Ключарев, Ш. Мәҗитов, Х. Вәлиуллин, Ә. Бакиров, С. Садыйкова, Б. Мөлеков, Р. Яхин, Р. Еникеев, З. Хәбибуллин, А. Батыршин, А. Вәлиуллин, Ф. Әхмәдиев, А. Шәрәфиев. Китапка шулай ук рус композиторларыннан А. Новиков, Р. Бойко, А. Островский, А. Филипенко, С. Туликовларның да берничә әсәре кертелгән. Җыр текстларының иң зур күпчелеген русчага Марат Таҗетдинов тәрҗемә иткән, рус шагыйрьләре М. Львов, И. Кәлимуллин, Б. Зернит, В. Савельев, Т. Кузовлева эшләнешендәге текстлар да бар. Китапның төзүчесе Әнвәр Бакиров.




## ЮГАРЫ БӘЯ

Башкалабыз Мәскәүдә Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының гастрольләре зур уңыш белән тәмамланды. Театр коллективы Казанга кайтыр алдыннан Бөтенроссия театр җәмгыяте бинасына килде. Бирелә Мәскәүнең күренекле театр белгечләре, драматурглар һәм журналистлар бар иде.

Г. Камал исемендәге Татар театрының Мәскәүдә барган спектакльләре турында сөйләшүгә багышланган утырышны РСФСР Культура министрлыгы вәкиле Разия Халитова ачты. Фикер алышуларда «Театральная жизнь» журналының баш редакторы Юрий Зубков, сәнгать фәннәре кандидатлары Ольга Кандалова, Аркадий Анастасьев, тәнкыйтьче Л. Горовалар катнашып, театр репертуарының бай һәм кызыклы булуын билгеләп үттеләр. Бу сөйләшүләрдә «Зәңгәр шәл», «Американ», «Шамил Усманов» спектакльләре тәнкыйтьчеләр тарафыннан югары бәя алдылар. Алар «Туй алдыннан», «Әни килде» һ. б. спектакльләрнең дә тамашачы тарафыннан җылы каршылануын әйттеләр.

Республикабызның театр коллективы башкалабыз Мәскәүдән яңа иҗат уңышларына рухланып, зур дәрт белән кайтты.

## ВЕНГРИЯ ГАЛИМНӘРЕ ТАТАРСТАНДА

Венгрия Фәннәр академиясе музыка институтының гыйльми секретаре Ласло Викар һәм Будапешт университетының профессоры, тел белгече Табор Берецки күп еллардан бирле Идел буе халыкларының культурасы белән кызыксыналар. Табор Берецки, мәсәлән, мари теле үзенчәлекләре турында кандидатлык диссертациясе яклаган. Ласло Викар исә Нью-Йорктагы җәйге университетта, Вена Академиясендә, Шотландиядә борынгы татар музыкасы турында лекцияләр укыган.

Бу ике галим татар музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов белән тыгыз элемтәдә яши. Алар арасында халык музыкасы

буенча китаплар, ноталар, пластинкалар алмашу күптән бара. Табор Берецки белән Ласло Викар моннан ике ел элек Татарстанга килеп, Кукмара, Балтач, Арча районнарында экспедициядә йөреп киткәннәр иде.

Быел җәй алар тагын безгә килделәр. Дуслары Мәхмүт Нигъмәтҗанов белән бергә Тәтеш, Буа, Кама тамагы, Алабуга, Минзәлә, Чистай, Чирмешән районнарында йөреп, халкыбызның борынгы фольклор үрнәкләрен җыйдылар.

## ТӨМӘН МАРШРУТЛАРЫ

Илебезнең төрле өлкәләре һәм республикаларыннан җыелып 50 язучы озаклаunion бик күп нефть (1975 елда — 100 миллион тонна!) бирәчәк Төмән өлкәсенә бардылар. Геологлар, нефть чыгаручылар, урман кисүчеләр, балык тотучылар, игенчеләр һәм терлекчеләр белән йөзләп очрашу булды. Әдипләр, схемасы түбәндә китерелгән дүрт маршрут буйлап 10 мең чакрым чамасы ара үтеп, 850 чыгыш ясадылар, аларны 50 меңнән артык укучы тыңлады. Әкиятче шагыйрь Ершов иҗатына багышланган әдәби бәйрәмгә Тобол кремле мәйданына 5 мең кеше килде. СССР һәм




РСФСР язучылар союзы идарәләре, КПСС-ның Төмән өлкә комитеты һәм ВЦСПС чакыруы буенча күп милләтле Совет әдәбиятының Себердәге бу декадасында Татарстан язучылар оешмасыннан шагыйрь Зәки Нури катнашты. Ул, Ялутыр районының Явбай авылында һәм Александр Матросов исемендәге пионер лагеренда, Төмән шәһәренең политик мәгариф йортында һәм Өлкә башкарма комитетының Актовый залында, нефтьчеләрнең яңа шәһәрләре Горноправдинск, Нефтеюганск, Нижневартовск һәм Сургутта, Ханты-Мансийск милли округы башкаласында үткәрелгән әдәби кичәләрдә, Ершов бәйрәмендә, Ханты-Мансийск, Нижневартовск телестудияләрендә, Төмән өлкә газеталары битләрендә чыгышлар ясап, Татарстан язучыларының һәм «Казан утлары» журналының эше турында сөйләде.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУ

Советлар Союзы Герое М. Җәлил һәм аның көрәштәшләре кичергән героик тормыш белән кызыксыну илебез халыклары арасында көннән көн арта. Үзбәкстанның «Правда Востока» газетасы редакциясендә Муса Җәлилнең көрәштәшләре белән кызыклы очрашу булды.

Бу очрашуларда ялкынлы шагыйрь Муса Җәлил белән бергә фашистларга каршы аяусыз көрәшкән, хәзер инде тыныч хезмәт фронтында эшләүче җәлилчеләр — тезүчеләр бригадиры Гараф Фәхретдинов, ветеринария врачы Рушад Хисаметдинов, математика укытучысы Фәрит Солтанбеков, фәнни-тикшеренү институтында товаровед Мәхмүт Мухсиновлар һәм һәлак булган патриотларның туганнары Мөнәвәрә Шабаева белән Фәния Хәбибуллина-Сәйфелмелековалар килгән иде.

Алар, дулкынланып, авыр көрәш елларын искә төшерделәр, сугышчан вакыйгалар турында сөйләделәр.

## ЛЕНИН ТУГАН ШӘҺӘРДӘ

Минзәлә драма театры коллективы җәйге гастрольләрен В. И. Ленин туган шәһәрдә башлады. Ульяновск тамашачыларына алар Ә. Баяновның «Һәйкәл», С. Кальметовның «Ана йөрәге», Ә. Мирзаһитовның «Куендагы елан» исемле спектакльләрен күрсәттеләр.

Театр коллективы бу шәһәргә зур җаваплылык тоеп, дулкынланып килгән иде. Тамашачылар спектакльләрне яратып карадылар.

Минзәлә артистлары бөек юлбашчыбыз исеменә бәйле урыннар белән таныштылар, Мемориальдә булдылар.

## КИТАПХАНӘЧЕЛӘРЕБЕЗГӘ ЗУР БҮЛӘК

Татарстан — Россия Федерациясендә китапны иң күп укучылар республикасы. РСФСР да һәр кеше бер елда уртача 19,6 китап укыса, бездә бу сан хәзер төп-төгәл 20 не тәшкил итә. Узган елда гына да, мәсәлән, укучыга китапханәләр 20 миллионнан күбрәк китап биргәннәр. Аларның китап кинштәләрендә ел саен 500—600 мең «белем чишмәсе» өстәлә тора. Авыл җирләрендә генә дә һәр авыл Советына уртача ике китапханә туры килә. Колхозлар һәм совхозлар үзләре дә китап алдыруга ел саен 90 меңләп сум чамасы акча тоталар. Соңгы елларда 164 яңа китапханә төзелде. Китапханәләрдә эшләүче 2 меңнән артык кешенең 60 проценты махсус югары яки урта белемле, 4 меңнән артык кеше культура-агарту уку йортларында белемен күтәрә, 210 кеше хөкүмәт орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде, РСФСРның яки Татарстан АССРның атказанган культура работнигы исемен йөртүчеләр күп.

1969 елгы эш йомгаклары буенча, китапханәчеләрнең Бөтенроссия социалистик ярышында ирешкән яхшы күрсәткечләре өчен күптән түгел республикабызга РСФСР Культура Министрлыгының һәм культура работниклары профсоюзы Үзәк Комитетының күчмә Кызыл Байрагы, беренче дәрәҗәле диплом һәм акчалата бүләк бирелде. Җиңүчеләргә байракны, Казанга килеп, республика китапханәчеләре җыелышында РСФСР культура министры урынбасары В. М. Стриганов иптәш тапшырды. Шунда ук Буа, Саба, Мөслим, Октябрь районнары культура йортларына «РСФСРның иң яхшы культура йорты» исеме бирелү документы һәм беренче дәрәҗә дипломнар, Минзәлә район Культура йортына икенче дәрәҗә диплом, ә Аксубай районы Культура йортына Татарстан АССР Культура Министрлыгының күчмә Кызыл Байрагы бирелде. Үз эшләрен аеруча оста башкаручы китапханәчеләр — әдәбият һәм художество пропагандасы осталары — СССР Культура Министрлыгының «Отличник» дигән значогы белән бүләкләнделәр.

## МАТБУГАТ КОМБИНАТЫ

Саннары һәм тиражлары елдан-ел арта барган газеталар-журналларны эшләү һәм тизрәк чыгару өчен Казанның Бауман урамындагы матбугат йортыбыз кысанланды. Хәзер Казан диңгезе булып җәелгән Казанка елгасы буенда көндәлек матбугат чыгару өчен яңа комбинат салына. Казанлылар әлегә аны журналистлар йорты яки пресса бинасы дип тә йөртәләр. Аның газеталар корпусы инде күтәрелеп тә килә. Казанда басыла торган барча үзәк газеталарның текстын бирегә фототелеграф буенча кабул итәчәкләр. «ГАУ» маркалы, 45 метр буйлы газета агрегаты аларның дистәләбен берьюлы баса алачак, үзенең санау механизмы ярдәмендә төргәкләргә бүлеп, кәгазь капчыкларга ук салып бирә торган булачак. Яңа комбинатны өлгертү өчен 10 миллион сум акча тотыла. Ул 1972 елда эшли башларга тиеш.

## БУКЕТКА ЯҢА ЧӘЧӘКЛӘР

«Дуслык букеты» исемле сериядә тугандаш әдәбиятларның шигырь китапларын татар телендә Татарстан китап нәшрияты 1967 елда ук чыгара башлаган иде. «Азербайҗан шагыйрьләре», «Казах шагыйрьләре», «Үзбәк шагыйрьләре», «Белорус шагыйрьләре» дигән чәчәкләр букеты инде укучылар кулында. Быел аңа «Төркмән шагыйрьләре» һәм «Кыргыз шагыйрьләре» дигән тагын ике чәчәк өстәлде. Билгеле булганча, һәр китапның җыйнак кына итеп язылган кереш сүзе, әсәрләре китапка кергән авторлар турында кыскача биографик белешмәләре бар. Соңгы ике «Чәчәктә» укучыларга төркмән поэзиясеннән 1700—1760 елларда яшәгән Азадидан алып хәзерге яшь буын шагыйрьләргә кадәр 36 авторның иң яхшы шигырьләре, кыргызларның 23 шагыйре тәкъдим ителә. Букетта илебездәге барча милләт поэзиясеннән дә шундый бер чәчәк булырга тиеш.

## ӘДӘБИ СУКМАКЛАР

Күренекле тәнкыйтьче һәм Чиләбедә язучылар оешмасы башлыгы Александр Шмаков «Әдәби сукмаклар» дигән яңа китабын Көньяк Урал нәшриятында рус телендә чыгарган. Анда биографияләре яки иҗатлары Урал яклары белән теге яки бу яктан бәйле булган Радищев, Серафимович, Бедный, Фадеев, Сейфуллина кебек зур әдипләр турында тарихи-әдәби очерклар бирелә, күп кенә Урал язучыларының иҗат портретлары күрсәтелә. Шунда ук татар әдәбиятының




күренекле вәкилләре Акмулла, Мәҗит Гафури турындагы кызыклы мәгълуматлар да яктыртыла. Себердә Троицк әдәбият төбәге һәм Чиләбе культура учагы булган. Бу урыннар Акмулла, Г. Тукай, М. Гафури, Дәрдмәнд, С. Рәмиев исемнәре һәм эшчәнлеге белән бәйле. Монда прогрессив галим һәм язучы Мөнир әфәнде Һадиев, 1917 елдан башлап партия члены, шагыйрь Габдулла Гатауллин («Апуш»), шагыйрь Хөсәен Әминев һәм Әкрәм Галимов («Чаллы-татар» яки «Кара туры егет») иҗат иткән. Шунда ук казакъ телендә «Ай-кап» исемле журнал, «Ак-молла» исемле сатирик басма, «Урал бүләге» дигән татарча альманах чыгарыла, 1906 елда мөселман китапханәсе ачыла. «Әдәби сукмаклар»да шуларның барысы турында да җентекләп язылган документаль материаллар бар.

## НЕФТЬ ҺӘМ МАТБУГАТ

Казанда шушы темага журналистларның Бөтенсоюз күләмендәге иҗади семинары үткәрелде. Урынның шулай сайлануы бер дә очраклы түгел, әлбәттә. Быел Татарстан нефтьчеләре илебезгә 100 миллион тонна нефть бирәчәкләр. Бу — хәзер һәр өч моторның берсен безнең ягулык эшләтә дигән сүз! Конференциядә нефть промышленностен һәм нефтехимияне тагын да үстерүнең актуаль

проблемалары турында СССР нефть чыгару һәм нефть эшкәртү промышленносте министрлыкларының министр урынбасарлары чыгышы, эшләп чыгаруны арттыру һәм матбугат бурычлары турында «Экономик газетаның баш редакторы, фәнни-техник прогрессны тизләтү һәм матбугат дигән темага «Социалистик индустрия» газетасының баш редакторы докладлары тыңланды, киң күләмдә тәҗрибә уртаклашылды. Кунаклар Татарстанның нефть районнарында булдылар.

## РАЙОН ТЕАТРЫ КАЗАНДА

Республикабыз башкаласының Галиәсгар Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт Академия театры бинасында Әлмәт дәүләт татар драма театры үз спектакльләрен күрсәтте. Тамашачылар Т. Гыйззәтнең «Чаткылар», Г. Мөсреповның «Козы-көрпәш һәм Баян-сылу», И. Кәтиевның «Яшьлек чәчәк атканда» исемле әсәрләрен зур кызыксынып карадылар. Шул уңай белән район театры иҗади уңышлары һәм республика хезмәт ияләренә культура хезмәте күрсәтү буенча зур эше өчен Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы белән бүләкләнде.

## ЯЗУЧЫЛАРГА — МАКТАУ ГРАМОТАЛАРЫ

Нефть һәм химия промышленносте работникларының профсоюз өлкә комитеты һәм «Татнефть» берләшмәсе нефть районнарында яшәүче әдәбият һәм сәнгать әһелләренең бер төркемен мактау грамоталары белән бүләкләде. Бүләкләнүчеләр арасында республикабызның Әлмәт бүлеге язучыларыннан Г. Афзал, Р. Фәйзуллин, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, М. Хәсәнов, С. Сөләйманова иптәшләр бар. Мактау грамоталарын һәм истәлекле значокларны «Татнефть» берләшмәсе начальнигы урынбасары Ү. Г. Саттаров тапшырды һәм язучыларның иҗат эшендә зур уңышлар теләде.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Баулы хезмәт ияләре белән Гомәр Бәширов, Әлмәт язучылары Э. Касыймов, С. Кальметов, Р. Фәйзуллин Татар Тумбарлысы, Татар Кандызы, Бәйрәкә, Кәрәкәшле, Кызыльяр авылларында очраштылар. Татар әдәбиятының 50 ел эчендә ирешкән уңышлары турында сүз барды. Авыл эшчәннәре аларның яңа әсәрләре белән танышты.

• • •

Әлмәт шәһәренең Техника йортында язучылар, китапханә хезмәткәрләре, үзешчән сәнгать осталары катнашында «Туган җирем — Татарстан» дигән темага зур әдәби музыкаль кичә үткәрелде. Кичәгә язучылардан Г. Афзал, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова, Ю. Эминев, К. Булатова, Э. Мөэминова, яшь язучылар З. Йосыпов, А. Ганиев иптәшләр катнашты.

• • •

Казагыстанның Троицк шәһәрендәге татар-башкорт китапханәсендә башлап язучы шагыйрь Басыйр Рафиков чыгышы булды һәм үзешчән сәнгать осталары яңа шигырьләр укыдылар.

## ЯШЬЛӘР ИҖАТЫН ТИКШЕРҮ

Азнакай районыннан Әнәс Исхаков һәм Лениногорск шәһәреннән Разим Вәлиуллин иҗаты Казанда, индивидуаль семинарда тикшерелде. Яшь авторларның шигырьләрен тикшерүдә Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев катнаштылар.

• • •

Сарман районы газетасы редакциясендә яшь язучы Хәниф Хөснуллинның «Уларым, сез кайда?» исемле яңа повесте тикшерелде. Семинар җитәкчеләре Гариз Мөхәммәтшин һәм Илдар Юзеев әсәрнең уңай һәм кимчелекле якларын күрсәттеләр, повестьның игътибарга лаек булуын, әмма әле бик нык-лап эшләнергә кирәклеген әйттеләр.

• • •


Язучылар союзының Әлмәт бүлегендә Х. Хәйруллинның «Аралар ерак булса да» дигән романы тикшерелде. Язучылардан Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, шагыйрьләр Р. Фәйзуллин, К. Булатова, драматурглар Ю. Эминов, Х. Сафина һәм журналистлар роман тормышны белеп, тиешле тирәнлектә язылган, аны, әдәби яктан бик яхшы эшкәртеп, матбугатка тәкъдим итәргә мөмкин дигән фикергә килделәр.


Хәким Хәйруллин сугыш елларында шахтер булган, хәзер Лениногорскида «Татбурнефть» трестында эшли.

# БӨДРӘ ТАЛ

ТАТАР ХАЛЫК җыры

Ф. ӘХМӘТОВ эшкәртүендә






Талдан талга куна микән
Таң алдыннан сары ла сандугач.
Кушымта: Бәдрә тал...
Чит җирләргә чыгып ла
Гыйбрәт ал.

Җырлау түгел, җыларсың да
Өзелеп-өзелеп кенә лә сагынгач.
Кушымта.

Сары сазлык, һай, селкенчәк,
Бөгелә-сыгыла үсә бәдрә тал.
Кушымта.

Бәдрә талпардай боргалаүып
Нишләп йөри икән лә безнең яр.
Кушымта: Бәдрә тал...
Чит җирләргә чыгып ла
Гыйбрәт ал.

*Хөрмәтле иптәшләр!*

1971 елда «Казан утлары»н ел башыннан ук ала башлау өчен 25 ноябрьга кадәр язылып калырга кирәк. 25 ноябрьдан соң язылган иптәшләр исә аны февраль санынннан гына ала башлаячаклар.

Безнең журналга бернинди чикләүсез һәм илебездәге теләсә кайсы элемтә бүлегендә язылырга мөмкин. Аңа язылу шартлары «Союзпечать»ләрдәге газета-журналлар каталогында күрсәтелгән. «Казан утлары» ул каталогка 73210 номерлы индекс белән теркәлгән.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ